ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2005



# ҮТКӘН ЕЛЛАР СӘХИФӘСЕ

**(«Безнең юл»)**




Елга-дәрьяның чыганагы булган кебек, журналыбызның истәлекле юбилей үткәрелә торган 1000 нче санының да үз башлангычы—исәп буенча беренче саннары, беренче данәләре бар. Алар инде хәзер архивларда яки аерым библиофил-коллекционерларда да сирәк очрый торган библиографик берәмлекләр. Беренче сан—бүгенге "Казан утлары"ның башлангычы саналган "Безнең юл" журналында 1922 елның май аенда дөнья күргән.

Беренче санның җаваплы мөхәррире—Гасыйм Мансуров. Шиксез, журналны оештыруда күренекле язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның роле зур булган. 1923-24 елларда—ел ярым чамасы—җаваплы мөхәррир булып Мидхәт Бурундуков эшләгән. 1925 елның башыннан 1930 елга кадәр журнал җитәкчесе сыйфатында аерым шәхес күрсәтелмәгән, җаваплылык вазифасы коллективка—редколлегиягә йөкләнгән. Редколлегия составына Ш. Камал, Г. Сәгъди, Х. Туфан, Г. Толымбайский, Г. Алиевлар кергән.

Ул елларда, аерым юнәлештәге төркемнәр булса да, язучыларның күпчелеген берләштергән махсус оешма булмый әле. "Безнең юл" төрле юнәлештә иҗат итүче күпсанлы әдипләрне һәм галимнәрне туплаучы бер органга әверелә. Журналның нигезен әдәби әсәрләр тәшкил итә. XX гасырда татар әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар шушы журналда катнаша. Ул чорның өлкән язучылары—Ш. Камал, М. Гафури, М. Гали, С. Кудаш, Ф. Сәйфи-Казанлы; яшьрәкләрдән—Х. Такташ, Ф. Бурнаш, К. Нәҗми, М. Җәлил, Ш. Госманов, Х. Туфан, Г. Кутуй, С. Баттал, Ш. Маннур, М. Максуд, Ә. Еники, Ф. Хөсни, А. Шамов; галимнәрдән—Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, Н. Хәким, Г. Гали һ. б. журналның актив авторлары булганнар.

Мәгълүм ки, бу чор, Октябрь революциясе тудырган гражданнар сугышыннан соң, совет хакимиятенең ныклап тамыр җибәргән, партия диктатурасының көчәйгән чоры, хәлле крестьяннарны җиреннән куып, күмәк хуҗалыклар төзи башлау еллары... Табигый ки, журнал, еллар елъязмасы буларак, шул чор сәясәтенә, иҗтимагый тормыш хәлләренә күп урын биргән яки бирергә мәҗбүр булган. Ни генә булмасын, журнал тиз арада халыкның яраткан журналына әверелә.

"Безнең юл" нигездә айга бер мәртәбә (кайбер очракларда ике ай бер санда бирелгән) чыга һәм аның тиражы 1000-1500 данә тәшкил итә. Журнал 1922 елдан алып 1929 елга кадәр гарәп шрифтында, 1928-29 елларда кайбер саннар катнаш—гарәп һәм латин имласында бирелгән) басыла. "Безнең юл" җәмгысе 81 сан чыккан.

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2005*

**11**

**(997)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(8432) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Марсель ГАЛИЕВ. Дөньямның көйле гаме. *Шигырьләр.* ..... 5
Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Караболак. *Роман.* ..... 10
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Ай йөзендә алтын алка... *Шигырьләр.* ..... 59
Динә ӘХМӘТОВА. Тәте. *Хикәя.* ..... 64
Шәмсия ЖИҺАНГИРОВА. Кояш белән серләшү. *Шигырьләр.* ..... 80
Лилия ГАЗИЗОВА. *Шигырьләр.* ..... 84
Нияз ВӘЛИ. Җил чәчәге. *Шигырьләр.* ..... 91

**ЯҢА ИСЕМНӘР**

Мидхәт САДЫЙКОВ. Яңгырлы җәй. *Парчалар.* ..... 88

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Наил ШӘРИФУЛЛИН. Үзебезне саклыйк! ..... 95
Зәрия ХӘБИПОВА. Фәлсәфә җитми безгә. ..... 99

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Бизмәндә—шигъри роман. ..... 101

**СӘНГАТЬ**

Гөлнур ГОБӘЙДУЛЛИНА. Җыр-моң белән үрелгән гомер. ..... 110

**ФӘН**

Равил ӘМИРХАН. Татар матбугаты үткән юл. ..... 114
Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 130
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. ..... 163

**ХӘТЕР**

Ләйсән ШАҺИН. Төрек әсирләренең истәлекләре. ..... 133
Таһсин ИЙБАР. "Себердән Сәрәндипкә" әсәреннән өзек. ..... 135

**ЮМОР-САТИРА**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Мәзәк хәлләр. ..... 168

Мең санның бер чаткысы. ..... 5, 109, 113, 176
Котлыйбыз! (Вахит Юныска 75 яшь). ..... 178
Берлекнең яңа әгъзалары. ..... 180
Укучы сүзе. ..... 182
"Казан утлары" архивыннан. ..... 184
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 187

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Ф. БАЙРАМОВОЙ "Карабулак" (начало); рассказ Д. АХМЕТОВОЙ "Курок"; стихи М. ГАЛИЕВА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, Ш. ЗИГАНГИРОВОЙ, Л. ГАЗИЗОВОЙ, Н. ВАЛЕЕВА.
"Новые имена": миниатюры М. САДЫКОВА.
Дискуссия "Герой нашего времени": статьи Н. ШАРИФУЛЛИНА "Сохраним себя", З. ХАБИПОВОЙ "Нам не достает философии".
"Литературная критика": статья Т. ГАЛИУЛЛИНА о романе в стихах Р. Хариса.
"Искусство": статья Г. ГУБАЙДУЛЛИНОЙ о творчестве композитора А. Монасыпова.
"Наука": Р. АМИРХАН. "История развития татарской печати";
А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
"Память": Л. ШАХИН. "Воспоминания турецких пленных";
Т. ИЙБАР. Отрывки из воспоминаний "Из Сибири в Сарандип" (начало).
Страницы из "Татарской энциклопедии".
"Страничка из 1000 номеров "Казан утлары".
"Юмор-сатира": Т. НАЗМИЕВ. "Забавные истории".
В номере отмечается 75-летие В. Юнусова.
Новые члены Союза писателей.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Дом Кекина в старой Казани—работа А. Тимергалиной; писатель Р. Ягфаров.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by F. BAIRAMOVA «Karabulack» (beginning); story by D. AHMETOVA «Cock»; verses by M. GALIEV, E. SHARIFULLINA, Sh. ZIGANGIROVA, L. GAZIZOVA, N. VALEEV.
«New names»: miniatures by M. SADYKOV.
Discussion «Hero of our time»: articles by N. SHARIFULLIN «Save ourselves», Z. HABIPOVA «We haven't got enough philosophy».
«Literary criticism»: article by T. GALIULLIN about novel in verses by R Haris.
«Art»: article by G. GUBAIDULLINA about creativity of composer A. Monasypov.
«Science»: R. AMIRHAN. «History of development of Tatar press»;
A. TIMERGALIN. «Dictionary of Nation».
«Memory»: L. SHAHIN. «Memoirs of Turkish captives»; T. IYBAR. Fragments from Memoirs «From Siberia to Sarandip».
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Page from 1000 issues of «Kazan Ytlary».
«Humour - satire»: T. NAZMIEV. «Funny stories».
In issue it is celebrated 75th anniversary of V. Unusov.
New members of Union of writers.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Kekin's house in old Kazan -work y A. Timergalina; Writer R. Yagfarov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 20.10.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–790. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



## Марсель Галиев

# ДӨНЬЯМНЫҢ КӨЙЛЕ ГАМЕ

### Туган тел

**Бөек тә син, боек та син,**
**И туган тел, туган тел,**
**Күп гамәлләр кылган тел!**
**Аргамаклар җилеп чапкан,**
**Былбыл сайрап кунган тел.**

**Елатасың, юатасың,**
**И туган тел, туган тел.**
**Кәүсәр сулар юган тел!**
**Әткәм нигез ташы куйган,**
**Әнкәм бишек корган тел.**

**Уйлатасың, уятасың,**
**И туган тел, туган тел,**
**Дәрья булып тулган тел!**
**Шанлы, данлы дәверләрнең**
**Хөкемдары булган тел.**

**Талымлы син, ягымлы син,**
**И туган тел, туган тел,**
**Халкым кебек уңган тел!**
**Күктән иңгән иман нурын**
**Мәңге саклый торган тел!**

Марсель ГАЛИЕВ (1946) — *шагыйрь, прозаик; егермедән артык китап ("Апрель кызы", "Сиңа мин кирәк", "Догалы еллар" һ. б., шул исәптән дүрт томлык "Сайланма әсәрләр") авторы. Казанда яши.*

## Ышанам

Мин ышанам сиңа, Күкләр шаһы,
Барлыгыңа гадел ышанам.
Бу ышаныч керми миңа читтән,
Мулла-мунтагайдан, ишаннан...

Бу ышану иңдерелгән миңа
Асмани—күк дөньяларыннан.
Һәр тереклек иясенә Күктән
Нинди олуг мадәт салынган.

Галәми моң дулкынында рәхәт
Сулгып әйләнәдер һәр җисем.
Камил сайланышка дучар итеп,
Алган Раббы иң һиммәтлесен.

Нинди кодрәт, нинди илһам нуры!
Бар тереклек илаһ могҗиза.
Акыл көчсез калып сәҗдә кыла,
Бөек сәнгать өчен җан фида.

Уйлый белә, уйный белә Җиһан,
Актарыла вакыт-дәрьялар.
Йолдыз белән йолдыз бәрелешеп,
Хасил була яңа дөньялар.

Шул гарасат, чиксез мәңгелектә
Без мосафир булып йөзгәнбез.
Уттан-судан яралтылган җаннар—
Күкнең җиде катын күргәнбез.

Киек каз юлыннан бу җиргә без
Сыналырга төшкән юлчылар.
Кем төшенми, шул төшемле яши,
Гөнаһларга күпме Җир чыдар?

Гаҗизләмим, Каһһар, сорау биреп,
Тәкъдир йолдызларың—күгеңдә.
Син хәрәкәт биргән хәятләрнең
Җан тибеше чиксез кальбеңдә.

Кичер мине, бер горурлык белән
Аваз салсам:—Без бар! Без әле!..—
Бер кәррәлек зәррә[1] булган Җирнең
Инсан дигән гамьле бизәге.

Мин ышанам сиңа, Күкләр шаһы!
Яшәү җирдә—илаһи дәвам.
Кальбеңдә бер тере күзәнәк мин,
Сәмави сүз иңгән үз догам.

---

[1] Зәррә — атом

## Хәят

Төн. Таулар. Сирпелеп исәдер
Галәми җилләр генә.—
Картайган сүзләре егыла
Шагыйрьнең йөрәгенә.

Төн. Дәрья. Ярларга үрелә
Адашкан дулкын гына.
Картайган йолдызлар егыла
Күк-галәм упкынына.

Ничекләр ышаныйм дөньяга
Шом-афәт киләсенә.
Сабырлык догасы кылыймны
Бу—кодрәт Иясенә?..

## Кояш капкасы

Көн туа. Кояш капкасы
Чатыртауда ачыла.
Шул капкадан ыспай басып,
Көн колыны—Таң чыга.

Ялларын җилпеп ала да,
Баса ул аягүрә.
Кытыкланып уяна җир
Таң тоягы тиюгә.

Чык төсләре яшьнәп китә
Тауларым итәгеннән.
Таң җиле яратып кына
Чәбәкли битләремнән.

Офыкларда—бөдрә дулкын,
Урманнар—яшел күбек.
Яшьлегең шул яшеллектә
Адашып яши кебек.

И, туган җир! Синдә генә
Дөньямның көйле гаме.
Җиләндә җиләк тәме шул,
Җиләндә җиләк тәме.

Их, мәталчек атып уйнар
Таулар да олыгайган.
Чатыртауның маңгаена
Нинди сүрә язылган?

Шул сүрәне укыр өчен
Бармы тел ачкычларың?!
—Бар ул миндә, миндә!—диеп
Очынып әйтер чагың.

Артык бәхеттән исермәс
Өчен бар шундый йола:
Тауның бәрхет маңгаена
Каплан да... Ялгыз ела...

Түгелеп, тау мендәренә
Бер гөнаһсыз калу да—
Килешәдер мондый чакта
Иркәләнеп алу да.

Җилкенеп калкыр да, жаның
Колачлар таң галәмен.
Бу—синең соңлап уянган
Гамьле-иләсле мәлең.

...Кояш капкасын ачканда
Ишеттем шыгырдавын.
Шигъри сүзләрне, ашыгып,
Уяттым бугай тагын.

Ярлыка, туган ягым!..

## Шәһәрдә нәүмиз хәтер

Сагындыра: горур шайтан таяклары;
Нөгештәге үткен күрән кыяклары.

Чишмә төбендәге җем-җем чуерташлар,
Бишташ кебек чәчелгәнбез, уендашлар.

Ак тузанлы Пауыл дәдәй тегермәне,
Алмалары—тупыр-тупыр өлгергәне;

Сагындыра: төнен бүре улаулары,
Кар сайратып үткән бәсле олаулары.

И ярышып, ат җигәргә өйрәнүләр,
Аулагөйләр чиратына көйләнүләр...

Йөзек салыш, йолдыз санау уенында
Тәүге үпкән кунак кызы—куенында.

Бар иде бит һәр авылның бер җүләре...
Бер җүләргә тормый хәзер мең җүләре!

И ул чорның садә-газиз ярлылыгы,
Бай күңелгә уртак иде бары-югы.

Тыңлый идек сугыш кичкән агайларны,
Якын иде Берлин-Балтач аралары.

Эстәрленең суы, димә, тездән генә,
Тоташкан ул ерак Каспий диңгезенә.

Бәхиллә син безне, хәтердәге авыл,
Атлантида кебек, күмде сине давыл.

Нәүмиз еллар... Бар да калды аргы ярда,
Узган гасыр... Юллар инде бармый анда.

Юлым бүлә урамнарның ак сызыгы,
Учта—асламчыдан алган таш сызызгы.

## Дөнья каршында

Дөньяга карап йөземне
Чыттым да, чытмадым да,
Сират күперләре аша
Чыктым да, чыкмадым да.

Өлешкә тияр көмешләр
Тиде дә, тимәде дә;
Ятларга каласы ярлар
Сөйде дә, сөймәде дә.

Койрык чәнчеп чабар бәхет
Килде дә, килмәде дә;
Кырыс еллар горур башны
Иде дә, имәде дә.

Елгыр җаннар ятьмәсенә
Каптым да, капмадым да;
Тел-дәрьяда Сүз хикмәтен
Таптым да, тапмадым да.

Бу җирдә яшәү кадерен
Сиздем дә, сизмәдем дә;
Дөньялыкның биш кыйтгасын
Гиздем дә, гизмәдем дә.

Әйтерләр: гомер челтәрен
Үрде дә, үрмәде дә;
Яшәүнең тәмен бозмыйча,
Үлде дә... үлмәде дә!..

## Ямансу

Үртәлеп карыйм суларга:
Агып бара гомерләр.
Чүгәли учак утлары,
Сыктап сүнә күмерләр.

Айгылдап кешни айгырлар,
Ярларын ташлый сулар.
Без киткәч тә дөнья шулай
Бик азга ямансулар.

## Табарлар безнең эзләрне

Еланнан елау көтмә син.
Еланнан елау көтмә.
Елатыр елларны йолып,
Дөнья тетмәсен тетмә.

Уйлар уйла бер, утырып
Елантау итәгенә.
Халкыңның гомер агачы
Күрмәде ниләр генә.

Текә язмыш маңгаена—
Күпме әр, күпме яра?!
Янә, яшәреп, еланнар
Иске кабыгын сала.

Иске кабыгын сала да,
Ысылдап урап ала.

Эчкә елан йотканнарның
Җан күзе салкыная.

Атилла оныкларының
Учагы сүнеп бара.
Үрчи мөгезле еланнар,
Кыйтгалар ятка кала.

Еланнан елау көтмә син.
Еланнан елау көтмә.
Бүген җуйган зурлыгыңны
Үткәннән өмет итмә.

Табарлар безнең эзләрне,
Әйтерләр хәйран калып:
—Үзе үстергән еланнан
Чагылып үлгән халык...

---

## *Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

### “Безнең юл” идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә *(сөючеләргә)** МӨРӘҖӘГАТЬ

Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан, **“Безнең юл”** журналын чыгара башладык. “Безнең юл”ның чыгуы Татар җөмһүриятенең мәркәзендә – Казанда булса да, бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халыкларына хезмәт итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке, Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең ярдәменә ышанып, эшкә керештек. Үтенәбез: бер яктан, бу журналның таралуына, икенче яктан, гыйльми-сәяси, әдәби материаллар, мәкаләләр җибәрү белән бу журналга булышсыннар иде.

Кулъязмалар өчен акча түләнә. Даими абүнә җыючылар, даими язучылар белән аерым мөгаһәдәләр *(килешүләр)* ясала. Эшче-крестьян гаммәсенең *(массасының)* азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде.

**“Безнең юл” идарәсе.**

*(“Безнең юл”. – 1922. – N 1.).*

---

* Курсив белән җәяләр эчендә бирелгән аңлатма сүзләр документларны «Казан утлары» өчен әзерләгәндә безнең тарафтан өстәлде. – *Р.Мәрданов.*



## Фәүзия Бәйрәмова

# КАРАБОЛАК

РОМАН

## Беренче бүлек

1946 елның җәе коры килде...

Май аеннан кара көзгә хәтле бер тамчы яңгыр төшмәде, кыштан чәчкән игеннәр тамырдан корыды, яз чәчкәннәре бөтенләй тишелеп чыкмады... Бар өмете бәрәңгедә булган авыл халкы, җәй буе яңгыр яумагач, бәрәңгесез дә калганын аңлады. Кемдер һаман күккә карап, яңгыр көтте, бакчасына көянтәләп су сибеп, бәрәңгесен коткарып калырга тырышты, әмма җәй уртасына ул җирләр кара көйгән, бәрәңге сабаклары корыган иде инде... Яңа гына авыр сугыштан котылган, яртысы ятим һәм гариплрдән торган Караболак халкын шом басты, кем ничек булдыра, шулай озын һәм салкын кышка әзерләнә башлады...

"Бөтен ил белән шушы хәл", дисәләр дә, Урал арьягына урнашкан Татар Караболагы авылы халкына, бу тирәдә яшәүчеләргә әлеге корылык икеләтә газап алып килде. Беренчедән, үз гаиләләре өчен каты курку булса, икенчедән, бу як халкы, үз авызларыннан өзеп, Иртәштә төзелеп яткан Базаны ашатырга тиеш иде... Кем ул База дигәннәре, нәрсә—анысын Караболак халкы белеп тә бетерми, әмма кара урман эчендә барган ул төзелешне ашату алар өстенә йөкләтелгән. Һәр йорт башына мәҗбүри төшерелгән салым бар, каян алып, ничек түләргә тиеш аны авыл халкы—ул турыда алардан сораучы юк. Имеш, Иртәш күле буенда Чиләбе кебек зур шәһәр төзелә икән, Караболак халкы да шунда барып, рәхәтләнеп яши, эшли алачак, ди... Имеш, яшьләргә хәтта армия хезмәтен дә шунда гына үтәргә мөмкин булачак икән... Бу төзелешләр Караболактан утыз-кырык чакрымнарда гына булганга, авыл халкы моны башта сөенеп кабул итте. Әмма Иртәш төзүчеләрен үз авызларыннан өзеп ашатырга кирәклеген белгәч, аларның шатлыклары тиз юкка чыкты. Алар өчен бүгенге көндә үз

---

Фәүзия БӘЙРӘМОВА — *язучы һәм җәмәгать эшлеклесе; татар һәм рус телләрендә дөнья күргән 20 дән артык китап авторы. Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Чаллыда яши.*

тормышларын алып бару, үз гомерләрен саклап калу мөһимрәк иде... Көтүдән ач кайткан сыерлардан ничек итеп сөт аласың да, үзеннен ач балаларына бирмичә, ул сөтне ничек итеп Иртәшкә озатасың инде? Тавык артыннан төшкән һәр йомырканы алтын кукәй кебек кадерләп җыеп барган хатын-кызлардан аны ничек тартып аласың да, Иртәш төзүчеләренә бирәсең? Кыш ашатырга азыклары булмаган арык сарык малын үзен суеп ашыйсыңмы, тагы шул күзгә күренмәгән Базага җибәрәсеңме?

Авыл советы рәисе Нәбиулланың башында хәзер әнә шул уйлар гына... Район үзәге Коншактан ул әнә шул борчулы уйлар белән кайтып килә. Аларга анда бик каты әйтеп җибәрделәр—бу мәсьәләдә бернинди саботаж, сүз тыңламау булырга мөмкин түгел, һәр авыл үзенә бирелгән бурычны үтәргә тиеш икән. Татар Караболагының элек-электән баш бирмәс мишәр авылы булганлыгын белгәнлектән, Нәбиулланы кат-кат кисәттеләр, ил, дәүләт, партия исемнәре белән куркыттылар, Сталин, Берия исемнәре белән янадылар... Җыелып килгән авыл җитәкчеләренә Иртәштәге төзелешнең гаять мөһимлеген кат-кат исләренә төшерделәр, аны өзүче халык дошманы дип аталачагын әйттеләр. Әмма нәрсә төзиләр Иртәштә шулай ашыга-ашыга, нигә ул шул дәрәҗәдә серле һәм хәвефле—ул турыда берни әйтмәделәр, бу турыда артык төпченмәскә куштылар...

Әмма Нәбиулла—сигез ел армиядә булып кайткан кеше, шуның 5 елы сугыш кырларында үтте. Ул җилнең кайсы якка искәненә карап та тиешле нәтиҗә чыгарырга өйрәнде инде, тормыш өйрәтте. Биредә дә ул тиз чамалап алды—артык сүз куертмыйлар икән, димәк бу төзелештә нindider хәрби сер бар. Аларның анда Чиләбе кебек шәһәр төзеп ятуларына Караболак хатыннары гына ышаныр ышанса. Кара урман уртасында, күлләр белән чорналып алган сазлык урынга нигә дип шәһәр китереп төзесеннәр икән? Аның өчен әнә шул ук Чиләбе өлкәсендә буш яткан күпме кыр-дала бар, кил дә шәһәр төзе шунда... Юк, боларга нәкъ менә Уралтау итәгендә булган шушы кара урманнар, дингезләргә тиң саф сулы күлләр, Караболак, Кояш, Мусакай авыллары тирәсендәге җәннәттәй җирләр кирәк булган... Моның сере, хикмәте нәрсәдә икән? Нәрсә төзиләр алар анда, бөтен дөньялары белән кубарылып?

Коншакта бер хәбәр ишетте ишетүен Нәбиулла—имеш, атом сугышы була калган очракта, хөкүмәтне Мәскәүдән шушында күчерәселәре икән, шулар өчен җир асты шәһәре төзиләр икән Иртәштә. Бу чыш-пыш инде халык арасында шактый таралып өлгергән, аны тыючы да, артык куертучы да юк. Әмма Нәбиулла бу хәбәргә артык ышанып бетмәде. Ай-һай, әллә кайдагы Урал артына күчерерләрме икән хөкүмәтне Мәскәү хәтле Мәскәүдән? Күчерсәләр дә, әнә шул Куйбышев тирәләренә күчерерләр... Ә менә "атом сугышы" дигәннәренә колаклары торды Нәбиулланың. Кем белән атом сугышы? Кара-каршы сугышу өчен тагы кемдәдер атом бомбасы булу кирәк бит. СССРда хәзергә ул юк, булса, бөтен дөнья белер иде... Бүгенге көндә бары тик Американың гына атом бомбасы барлыгы билгеле, ул аны узган ел Япония өстенә ташлады. СССР газеталары бу хакта күп яздылар, әле кичә генә Германиягә каршы сугышта союзниклар булган Американы пыр туздырып, гаепләп ташладылар, халыкны яңа атом сугышы белән куркыта башладылар.

Нәбиулла уйларын төенләп бетерә алмый калды, бөтен дөньяны кот чыгарлык көчле шартлау тавышы тетрәтте, аяк астында җир сикереп куйган кебек булды. Иртәш борылышына җитеп килгән туры айгыр бу көтелмәгән тавыштан башта чүгеп, туктап калды, аннан, кая барганын белмичә, күзе-башы тонып, котырып чаба башлады. Нәбиулла дилбегәне ун кулына чорнап тотты, очып барып төшмәс өчен, гарип сул терсәге белән арба төбенә таянды. Ул арада Иртәш ягында тагы көчле гөрселдәү ишетелде, бу тавыштан хәтта

юл читендәге агачлардан соңгы яфракларга хәтле коелып төште. Шартлау турында уйлаганчы, Нәбиуллага башта туры айгырны тыярга кирәк иде, чөнки ул Караболак борылышын узып китеп, туп-туры Свердлау ягына карап чаба башлады...

Ат үзенең чабышын бераз акрынайткан арада, Нәбиулла арбадан сикереп төшеп, туры айгырның башына барып ябышты. Айгыр, авыз тирәсендә ак күбекләрен пошкыртып, күзләрен алартып, хуҗасына карап торды да, аның кул көченә буйсынып, артка таба чигенә башлады. Нәбиулла аны шулай чигендерә-чигендерә кире борып, Караболак юлына чыгарды. Шартлау яңадан кабатланмады, ат тынычланды, алар, сикәлтәле юл буйлап, авылга таба юнәлделәр... Бераз тынычлангач кына, Нәбиулла теге серле шартлау турында уйлый башлады. Гадәттә, вак-төяк төзелеш эшләрендә мондый хәрби шартлатуларны кулланмыйлар, мондый шартлатулар таш кирмәннәрне җимергәндә яки бик тирән баз-котлованнарны казыганда гына кулланыла. Димәк, Иртәштә, чыннан да, дөньяда тиңе булмаган зур төзелеш бара, димәк, бу эшкә хәрбиләр дә тартылган һәм ул иң элек хәрбиләр өчен кирәк булырга тиеш.Чыннан да, халык сөйләгәнчә, җир асты бункерлары төзиләр, ахры. Тик нәрсә өчен, кемнәр өчен ул җир асты төзелешләре? Нигә аның тирәсендә шул хәтле сер, нидер яшерү, янау һәм куркыту соң? Авылдагыларның да котын алгандыр бу шартлаулар, өйдәгеләр аның өчен хафага төшмәсеннәр тагы...

Өйдәгеләр турында уйлауга, Нәбиулланың күз алдына хатыны Хәбирә килеп басты. Ул бүген-иртәгә бәби табарга тиеш, насыйп булса, ата кешенең кулларына алачак беренче баласы... Кулларына алачак, ди, чөнки аның беренче баласы 1937 елда, ул солдат хезмәтенә киткәч туган һәм әтисен бер тапкыр да күрмәгән килеш, якты дөньядан китеп барган... Сигез елга сузылган армия, сугыш, яраланулар, больницалар аның яшьлеген дә, гаилә тормышын да, беренче баласын да урлады. Менә хәзер ул, утыз яшенә җитеп килгәндә, тагы беренче баласын көтә... Кем генә булса да—малаймы, кызмы, ул Нәбиулла өчен дөньяда иң газиз кеше булачак, яшәү мәгънәсе, җан тынычлыгы булачак... Сугыш кырларында, ак кар өстендә яралы хәлдә үлем көтеп ятканда, ул Аллаһдан бер генә нәрсә сорады—нәсел, балалар калдырырлык гомер... Нәбиулланың нәселсез, баласыз килеш бу якты дөньядан китәсе килми иде... Чөнки аларның Караболак авылында бары тик зур нәселле, ишле балалы йортны тота алган кеше генә чын ир-ат санала. Бар балаларын да тиешенчә урнаштырган, белем һәм һөнәр биргән, башлы-күзле иткән ата гына ил агасы була ала... Алар авылында Нәбиуллага хәтле дә шулай булган, йөз ел элек тә шулай яшәгәннәр, хәзер дә, шөкер, нәкъ шулай дәвам итә... Авыл халкы яхшы нәселгә, яхшы ата-анага, акыллы, таза-сау балаларга зур игътибар бирә. Шушындый сугышлардан да исән калган, ут, үлем эченнән исән чыккан Караболак егете Нәбиулла кемнән ким? Ул сугышта үзенә сүз бирде—исән кайтсам, бер дистә балабыз булыр, диде. Инде менә Хәбирәсе аңа шушы бәхетне бирергә тора—бүген-иртәгә бәби көтә алар...

Шушыларны уйлагач, аңа туры айгыр акрын бара кебек тоелып китте. Ул баш очында дилбегәсен уйнатып, атның янбашына тартып җибәрде. Туры айгыр, тагы күзләрен алартып, кушаяклап чабып китте. Аның үзенең дә бу ерак юлдан тизрәк авылга кайтып җитәсе, туйганчы Караболакның йомшак суын эчәсе, туйганчы солы чемченәсе килә иде... Караболакка алар кичке якта, көтү кайткан турда килеп керделәр. Акрын гына атлаган арык малларны аралый-аралый, өй турларына кайтып җиткәндә, Нәбиулланың йөрәге күкрәгеннән чыгарлык булып ашкынып тибә, күңеле, уйлары үзеннән дә алда оча иде...

Нәбиулланың ашкынуы, өмет-хыяллары юкка гына булмаган икән—ак

пәрдәләр тарттырылган ачык тәрәзәдән, бөтен урамга, юк, бөтен дөньяга бала елаган тавыш яңгырый иде! Юк, мескен, шыншып елау түгел иде бу, ә бөтен җиһанны тетрәтеп, дөньяга килү турында хәбәр бирү, ярсып аваз салу иде! Бу тавыштан Нәбиулланың тез буыннары йомшарып китте, күзләренә яшь бәреп чыкты. Үз баласының шушы беренче авазы ана дөньяда иң матур, иң көчле, иң моңлы тавыш булып ишетелде. Сугыш кырларында, җир асты куышларында, яуга күтәрелгәндә, яраланып, бер ялгызы үлем көтеп ятканда, больницаларда аның колагына ничә тапкыр менә шушы тавыш ишетелгән иде инде! Үз баласының беренче авазы, Алып Хан нәселенең ораны менә нәкъ шундый булып ишетелгән иде ана...

Ул атылып өйгә керде. Өйдә кайнашкан хатын-кызларны бөтенләй күрмичә, ул бала тавышы ишетелгән якка—чәчәкле чаршауга таба атлады. Калтыранган куллары белән чеметеп кенә чаршау читен ачты, иң элек, килене янында кайнашкан әнисен күрде, аннан карашы илаһи бер күренешкә тап булды... Чәчәкле ястык-түшәк өстендә, ак биләүгә төргән сабыйны кочагына алып, Хәбирәсе елмаеп ята иде...

—Менә, әтисе, сиңа кыз алып кайттым,—диде ул, нигәдер бераз унайсызланган кебек.

—Кыз?!—диде Нәбиулла, чын-чынлап гаҗәпләнеп.—Тавышы буенча, мин аны малайдыр, дигән идем... Урамның теге башына ишетелә бит тавышы!

—Аллага шөкер, дүрт саны исән, таза-сау бала,—диде шунда Нәбиулланың әнисе Нурҗамал карчык та сүзгә кушылып.—Бәхете белән үссен, нәселебезне дәвам итсен...

Карчык шулай гөрли-гөрли чыгып китте, Нәбиулла исә тизрәк хатыны янына килеп тезләнде. Аның бу кечкенә ак йомгакны җентекләп карыйсы, кулларына аласы, күкрәгенә кысасы килә иде... Чөнки озак, бик озак көтте Нәбиулла аның дөньяга килүен...

—Сиңа охшаган,—диде Хәбирә, йокылы-уяулы яткан кызчыгын иренә таба борып.

Нәбиулла күзләре белән генә түгел, бөтен йөрәге, җаны-тәне белән баласына капланды. Чынлап та, бала Нәбиуллага каплаган да куйган иде! Ул биләүгә сыярга теләмичә киерелеп яткан эре гәүдә, нык утыртылган баш, алар нәселенең тамгасы булган төз, туры борын... Озынча алсу йөз, сызылып киткән кыйгач кашлар, бөгелеп килгән озын керфекләр... Бөтенесе үз урынында, бөтенесе шундый камил һәм матур, ана карап, сокланудан Нәбиулла хәтта тын ала алмыйча торды. Охшаса да охшар икән бала шул хәтле Алып Ханнар нәселенә! Нәкъ шундый бала туар, дип көткән, өмет иткән иде бит Нәбиулла... Хәбирәсе аңа нәкъ ул теләгән баланы бүләк итте, нәсел дәвамчысын тудырды, рәхмәт яугыры!

Ул, хисләнеп китеп, хатынының кайнар кулларыннан кысты. Хатыныннан сөт исе, бәхет исе килә иде...

—Исемен ничек куярбыз соң, әтисе?—диде Хәбирә, бераз иркәләнә төшеп.

—Исеме?—Нәбиулла бераз уйланып торды.—Исеме Гөлҗиһан булыр, әнисе. Авылның гына түгел, бөтен җиһанның гөл-чәчкәсе булырлык бала бит ул, әйеме, кызым?

Гөрләп торган бу тавышка бала томырылып зур күзләрен ачты. Ата белән баланың карашлары бер мизгелгә очраштылар, таныштылар һәм бер-берләрен мәңгегә табыштылар... Нәбиулла шуны сизеп өлгерде—яңа туган сабыйның карашында ниндидер җитдилек, олы мәгънә бар иде... Ул әтисенә дә, бу якты дөньяга да сынап, олыларча карап ята... Менә бала башын әнисе ягына борды, сөт исен эзләп, борынын аның күкрәгенә төртте...

Әнисе ярдәме белән үзенә кирәкне эзләп тапкач, комсызланып имә башлады. Аңа хәзер ашарга, яшәргә, үсәргә кирәк иде... Караболакта "Алып Ханнар нәселе" дип аталып йөртелгән токымны дәвам итәргә кирәк иде... Әби-бабалы, ата-аналы, зур нәсел-нәсәбле абруйлы татар гаиләсендә туган Гөлҗиһан исемле кыз бала бөтен нәсел өчен, авыл өчен, милләт өчен көрәшче булып үсеп җитәргә тиеш иде... Бу юлда аны зур сынаулар, зур газаплар, зур югалтулар һәм зур саваплар көтә иде... Әмма хәзергә Гөлҗиһан үзе әле бу хакта белми, әти-әнисе янында, фәрештәләр саклавында ул дөньяга беренче авазларын сала иде...

## Икенче бүлек

1946 елның сентябрь башында, Караболак авылында Гөлҗиһан исемле кыз бала дөньяга килгән көннәрдә, Иртәш күле буенда беренче совет атом бомбасына нигез салдылар... Биредә "Аннушка" дип аталган беренче атом реакторы өчен баз казый башладылар, анда атом бомбасы өчен ураннан плутоний аерып алынырга тиеш иде... Бу баз-котлованның тирәнлеге илле дүрт метр булып, аның аждаһа авызы йөз метрдан артык булырга тиеш иде... Бераз казып кыя-ташларга очрагач, аларны җимерү өчен хәрби төзүчеләр иң көчле шартлаткычларны кулланырга мәҗбүр булалар... Гөлҗиһан туган көннәрдә Караболак, Иртәш буйларын әнә шул шартлаулар тетрәтә... Шулай итеп, Караболактан 40 чакрымда беренче совет атом бомбасын ясау өчен нигез салына... Әмма моны хәзергә авыл халкы да, Нәбиулла белән Хәбирә дә, аларның яңа дөньяга килгән кызлары да белми әле... Хәтта баштарак төзүчеләр үзләре дә бу җир асты шәһәрен ни өчен төзегәннәрен белмиләр иде... Бу хакта Сталин, Берия, Курчатов кебек санаулы кешеләр генә белә һәм Караболак янындагы яшерен атом төзелеше белән алар турыдан-туры Мәскәүдән идарә итәләр иде...

Атом буенча беренче фәнни хезмәтләр СССРда 1932-1935 елларда ук күренә башлый. Әмма Германиядә, Америкада һәм Англиядә инде бу өлкәдә шактый зур ачышлар ясап өлгерәләр һәм бу хәл Советлар Союзына тынгылык бирми. Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан Германия инде атомны таркатып, аннан плутоний ясарга өйрәнеп җитә һәм бу хакта бөтен дөньяга хәбәр бирә. 1941 елның көзендә Америка һәм Англия дә ашыгыч рәвештә атом бомбасы өстендә эшли башлыйлар...

Бу шомлы хәбәрләрне берәмтекләп җыеп барган Лаврентий Берия, әле 1940 елның башында ук атом коралы мәсьәләсендә Сталинга мөрәҗәгать итә, аның алдына чит илләр буенча көткән мәгълүматны китереп сала. Әмма фин сугышына кереп баткан Сталинга атом түгел, танклар кирәк була. Ул Бериягә шулай дип җавап бирә дә. Тик Мәскәү һәм Ленинград галимнәре уран, плутоний буенча эзләнүләрен барыбер туктатмыйлар, Берия дә атом бомбасы турында шымчылыгын дәвам итә. Шуның нәтиҗәсендә, СССР Фәннәр Академиясенең Президиумы 1940 елның 30 июлендә уран мәсьәләсе буенча махсус комиссия төзи. 1940 елда профессор Курчатов кул астында уранның төшен таркату буенча зур ачыш ясала, бу инде атом бомбасын ясау буенча беренче адым була. Бу ачышның идеясе чит ил галимнәреннән урланган булуы турында да хәбәрләр бар, чөнки СССРга, ничек кенә булса да, бөтен дөньяны куркытып кулда тотарлык көчле атом коралы кирәк була... Шул ук елның октябрендә академик Фресман кул астындагы комиссия илдә уран ятмаларын эзләү буенча эш башлап җибәрә...

Әйткәнебезчә, Берия шымчылары чит илләрдә атомга кагылган мәсьәләләр буенча зур эзләнүләр алып баралар, чөнки фәнни-техник

шпионаж да НКВД карамагында була. Шулай итеп, СССР тарафыннан Германия, Америка, Англия галимнәренен атом өлкәсендәге ачышларын урлау чоры башлана... Һәм 1942 елның башында бу мәгълүматлар тагы бер тапкыр тупланып, Берия тарафыннан Сталин өстәленә салына. Сталин атом бомбасы белән ныклап кызыксына башлый һәм галимнәр алдына тиз арада бу коточкыч үлем коралын житештерү бурычын куя. Шул елның көзендә булачак "атом атасы" Игорь Васильевич Курчатов Казандагы эвакуация куышыннан Мәскәүгә чакыртып кайтарыла. 1943 елның 15 февралендә СССР Оборона комитеты карары белән атом-төш коралы ясау буенча фәнни үзәк төзелә, анын башына академик Курчатов куела. Бу эшләрнен барысы белән дә НКВД житәкчелек итә, СССРда атом бомбасы ясау турыдан-туры Берия кул астында бара...

1945 елның 15 июлендә Америка Кушма Штатлары беренче атом бомбасын сыный. СССР, бигрәк тә Сталин, бу хәбәрне авыр кабул итә, имеш, нигә—Америка, нигә СССР түгел?! Имеш, шушылай итеп, Америка СССРдан Ватан сугышындагы жинүен урларга тырыша... Ул арада Америка 1945 елның 6 һәм 9 августларында Японияне Хиросима һәм Нагасаки шәһәрләре өстенә атом бомбалары ташлый. Мона кадәр беркем белмәгән атом утында 75 мең япон бер мизгелдә терелэй янып үлә... Бу хәбәр дөньяны тетрәтә... Шулай итеп, дөнья өр-яңа чорга—атом-төш коралы житештерү чорына керә... Илләр һәм милләтләр, бер-берләрен уздырып, коточкыч үлем коралы әзерли башлыйлар...

Әмма зур сугышлар өчен әзерләнгән бу бомбалар, иң беренче чиратта, шул жирдә яшәүче халыкның үз башына кара кайгы булып төшә... Атом коралы белән бергә, жир шарына мона кадәр күрелмәгән яңа афәт—радиация тарала башлый... Шулай итеп, үлем гыйфрите шешәдән чыгарыла, атомга ияреп, күзгә күренмәс радиация килә, радиация исә яман шеш афәтен тудыра... Әмма ил житәкчеләре атом коралы хакына бернәрсә белән дә исәпләшеп тормыйлар. Советлар Союзы да, бөтен барлыгы белән, атом-төш коралы житештерүгә кереп бата... Сугыштан соңгы авыр бер чорда халык кулына ипи урынына атом бомбасы тоттырыла...

Дөресен әйтергә кирәк, СССРга атом бомбасын ясап бирүдә немец галимнәре, яһүдиләр зур өлеш кертә. Беренче чорда илнең хәтта үз ураны да булмый, аны жинелгән Германиядән һәм басып алынган Чехославакиядән ташыйлар. Немец һәм яһүдиләр ярдәмендә лаборатория юлы белән ураннан плутоний эшләп чыгарырга өйрәнгәч, атом бомбасын күпләп житештерү, ягъни, куәтле атом промышленносте булдыру көн тәртибенә килеп баса... Ил сугыш хәрабәләре арасында ята, ирләр аз, халык ач, ә шулар белән атом-төш коралы житештерергә кирәк... Сүз атом шәһәре, дистәләгән куәтле атом реакторлары, радиохимия, механика буенча йөзәрләгән жир асты һәм жир өсте заводлары, атом калдыкларын саклау объектлары төзү турында бара... Сүз тиз арада СССРның беренче атом бомбасын ясау һәм аны сынау турында бара... Һәм шушы үлем индустриясен урнаштыру буенча ил буйлап урын эзләп йөри башлыйлар...

Берия командасының Сталинны ышандыруынча, атом бомбасы ясый торган урын үзәктән, ягъни, Мәскәүдән ерак урнашырга тиеш була. Ягъни, заводта атом-төш шартлаган очракта, хөкүмәт зарар күрергә тиеш түгел. Бериянең исбатлавынча, ул яшерен бер караңгырак почмакта төзелергә тиеш, ягъни, чит ил шымчылары аны эзләп таба алмаслык булсын... Галимнәрнен тәкъдиме буенча, атом коралы ясый торган корылма зур суга бик якын урнашырга тиеш, чөнки реакторларны бертуктаусыз суытып тору өчен бик күп күләмдә су кирәк булачак икән... Мондый көчле промышленность урнашкан жирдә гади эшче көчләр, ягъни, авыл халкы күп яшәргә тиеш.

Аларның бер өлеше атом объектларында эшләргә тиеш булса, икенче өлеше авылларда алар өчен ризык җитештерү белән шөгыльләнә. Соңгы нәтиҗә исә—СССР кулындагы көчле атом коралы, ул моның белән бөтен дөньяны били һәм буйсындыра ала... Атом промышленностеның радиация белән бәйле буласын галимнәр белә, әмма бу мәгълүмат халыктан яшерелә. Әле башланып та китмәгән төзелеш, Берия командасы ярдәме белән, коточкыч дәүләт серенә әйләнә, бу тирәдә яшәүчеләрнең туулары гына түгел, үлемнәре дә дәүләт сере итеп каралырга тиеш була...

Шушыларның барысын да истә тотып, атом бомбасы ясау өчен Урал аръягындагы татар җирләре сайлап алына... Кара урман эчләрендәге Иртәш күле буенда, Кыштым һәм Кәсле шәһәрләре арасына СССРда беренче атом шәһәре төзергә карар кабул ителә. Бу урын бөтен яктан да шымчы Берия һәм атомчы-галим Курчатов планнарына туры килә. Ул Мәскәүдән ерак, аны чит ил шымчылары эзләп таба торган түгел—Урал аръягындагы кара урманнар эчендә урнашкан... Су дисәң—бөтен тирә-якта диңгез кебек дистәләгән күлләр—Иртәш, Кызылташ, Карачай, Олыагач... Очсыз эшче көчләр дисәң—янәшәдә генә зур-зур татар авыллары, алар арасында дүртәр, бишәр мең кеше яшәгән Мөслим, Усть-Багаряк, Татар Караболагы, Коншак, Аргаяш кебекләре дә бар... Курчатов үзе дә Уралда туып үскән кеше, ул татарларның ни дәрәҗәдә эшчән, тәртипле халык икәнлеген белә, алар белән атом шәһәрләре төзеп буласына ышана... Хәзер шуны хәрбиләргә ышандырырга кирәк була...

1945 елның октябрь аенда урыс генераллары Завенягин һәм Комаровский, шактый түбәннән очып, "Дуглас" самолетында бу җирләрне күктән карап йөриләр... Шушы мизгелдә аста үз тормышлары белән яшәп яткан татар авылларының, Уралтаудагы татар халкының язмышы хәл ителә... Атом бомбасы нәкъ менә шушында ясалачак... Һәм Сталинның махсус боерыгы белән, Иртәш күле буйларында дөньяда тиңе булмаган зур төзелеш башланып китә. 1945 елның 9 ноябрендә бирегә беренче төзүчеләр китерелә, аларны брезент палаткаларга, җир куышларына, якын-тирә авыллардагы мал абзарларына урнаштыралар... Шулай итеп хәерче ил атомга барып тотына, үз халкының бугазына басып, ул аннан атом бомбасы ясата... Бу яшерен төзелеш, беренче көннәреннән башлап, Сталинның шәхси күзәтүендә була, аның шымчылары исә моннан кайтып кермиләр. 1946 елның җәендә һәм көзендә бирегә СССР Министрлар Советы рәисе урынбасары Л.Каганович һәм НКВД җитәкчесе Л.Берия килеп җитәләр. Һәм 1946 елның көзендә Иртәштә беренче атом реакторына нигез салалар, кыя-ташлы җирләр болай гына бирешергә теләмәгәч, аларны теткәләү өчен хәрби шартлатулар кулланалар...

Сентябрь башында Коншактан кайтып килүче Нәбиулла Иртәш күле буеннан әнә шул шартлауларны ишетә...

Аның беренче баласы Гөлҗиһан әнә шул шартлаулар астында дөньяга килә...

Уралтау артындагы борынгы татар җирләренә атом аждаһасы чыга...

Ул җәннәт кебек татар илләрен, кыя-таш кебек татар ирләрен тетрәтә, теткәли башлый...

Борынгы татар иленә зур афәт якынлаша...

## Өченче бүлек

Ул кышны Караболак халкы чын мәгънәсендә ачлыктан интекте. Икмәксез, мал азыгыннан мәхрүм калган кешеләрдән ит, сөт, май, йомырка планы сорап теңкәләренә тиделәр, карап торган соңгы сарыкларын алып чыгып киттеләр. Моны күреп, халык мал-туарын яшерә башлады,

андыйларны исә берәм-берәм район үзәгенә чакыртырга тотындылар. Ул арада, бөтен халыкның котын алып, Караболак буенча корал тоткан хәрбиләр йөри башлады, алар инде мал-туарның гына түгел, кешеләрнең дә баш санын алалар, төрле рәсми кәгазьләргә кул куйдырталар, кисәтәләр иде. Моңа кадәр батырлык, кыюлыклары белән аерылып торган Караболак халкы да курка калды, чөнки таләпләр, гомер булмаганча, бик каты иде. Иртәш, Сөнкүл, Кояш тирәсендәге урманнарга керергә ярамый, ул яктагы күлләрдән балык тотарга ярамый, бу тирәдән үрдәк-куян атарга рөхсәт юк, анда хәтта җиләк-гөмбә җыю да тыелган. Мондый хәлләрне хәтта сугыш вакытында да күрмәгән караболаклылар, хәрбиләрдән рәтле җавап ала алмагач, Нәбиулла өстенә ябырылдылар. Әмма Нәбиулла үзе дә ярамыйдан артыгын белми иде, белгән очракта да, ул аны халыкка әйтергә тиеш түгел иде...

Нәбиулла Коншактан, әлбәттә, күбрәк белеп, ишетеп кайткалый, һәм бу хәбәрләрдән аның чәчләре үрә торырлык була. Иртәш тирәсендәге ул төзелешкә Мәскәүдән зур кешеләр—Каганович һәм Берия үзләре килеп киткәнлеге билгеле булды. Коншактан тагы шуны белеп кайтты Нәбиулла—бу тирәләрне "особорежимная зона" дип игълан иткәннәр икән... Бу зонага Кыштым шәһәре һәм Коншак, Кәсли, Аргаяш, Кузнецкий районнарының 99 авылы кергән, Татар Караболагы да шулар арасында булып чыкты... Саналган авылларның җитәкчеләрен район үзәкләренә җыеп, менә шуларны бик яхшылап аңлаттылар. Ягъни, бу тирәләрдә урманнарга керергә ярамый, күлләргә якын килергә рөхсәт ителми, Кыштым-Кәсли юлы халык өчен ябыла... Әмма тыю-кисәтүләр әле моның белән генә бетмәгән, аның тагы да авырлары әле алда булган икән...

Нәбиулла, авыл советы рәисе буларак, Коншактан тагы яңа күрсәтмә алып кайтты—моннан соң Караболакның һәр кешесе махсус теркәлү үтәргә тиеш иде. Ягъни, 1947 елның ахырына Татар Караболагы авылының һәр кешесен паспортлы итәргә һәм пропискага кертергә кирәк булачак. Ягъни, авыл халкы катгый рәвештә теркәлергә һәм хисапта торырга тиеш иде. Шуннан башка авылда яшәргә рөхсәт ителми. Гомер булмаган хәл—авылда хәтта төн кунып чыгарга да һичкемне кертергә рөхсәт ителми, килгән кешегә теркәлмичә вакытлыча яшәү турында инде сүз дә була алмый. Гомер буе балалары Чиләбедә, Урал заводларында эшләп көн күргән Караболак халкы монысына бөтенләй кутәрелеп бәрелде—кунакка куна кайткан үз балаларын кая куйсыннар алар, кайда теркәтеп йөрсеннәр? Әмма Иртәш якларыннан берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр килә башлагач, Караболак халкы тынып калды, хәвефкә төште... Ул тирәдәге авылларны, төбе-тамырлары белән кубарып, әллә кайларга илтеп ташлый башлаганнар икән! Имеш, ул База дигәннәренә җир җитми икән, Караболак халкы гомер буе утын әзерли торган Кыштым леспромхозын да үзләренә алганнар, бөтен җиргә тимер чыбык тарттырганнар, мылтыклы солдатлар куйганнар, дип сөйлиләр... "Кызылташ", "Доброволец", "Беренче май", "Красный луч" колхозларын, авылларын, халкы белән бергә, башка урынга күчергәннәр, имеш, совхозларны, ул тирәдәге әртилләрне бетергәннәр, ди... Иртәштәге ул җир асты шәһәре шул хәтле зур булачак икән, бу тирәдәге авылларга хәтле килеп җитәргә мөмкин, ди. Әле Караболакны да күчерергә мөмкиннәр икән, заводка җир җитмәсә... Инде ничә авылны кузгатканнар, туздырып ташлаганнар, ди, чиратта Караболак икән...

Берсеннән-берсе шомлы бу хәбәрләрдән, имеш-мимешләрдән Караболак халкы өркеп калды. Җитмәсә, гомер булмаганны, авылга милиционерлар һәм махсус күзәтчеләр билгеләделәр, алар Караболактагы һәр үзгәрешне, һәр йорттагы хәлне районга җиткереп торырга тиешләр иде... Бу хәлләрнең барысы да Иртәштәге төзелеш белән бәйле икәнлеген инде күпләр аңлый

башлады. Ул арада авылга эшче көчләр жыярга вербовщиклар килеп житте, алар ир-егетләргә җәннәт тормышлары вәгъдә итеп, Иртәштәге төзелешкә кодалап йөрделәр. Караболак егетләре шундук бу кармакка капты, бәхет эзләп, Иртәшкә чыгып китте һәм беркайчан да янадан авылга әйләнеп кайта алмады... Чөнки 1947 елдан башлап, Иртәштәге База төзелешенә кергән кешеләрне зонадан бөтенләй чыгармый башладылар, хөкүмәтнең карары шундый иде. Кая анда атна саен авылга кайтып йөрүләр, аларны ата-аналары, туганнары үлгәч күмәр өчен дә Иртәштән читкә чыгармадылар... Язган хатлар барысы да ачып укылды, артыгын ычкындырган кешеләр шунда ук хөкем ителде, юкка чыгарылды. Чөнки яңа гына тагы Иртәштәге атом төзелешенә килеп киткән Лаврентий Бериянең әмере шундый иде. Берегә кергән, яшәгән, эшләгән һәр кеше, егерме биш ел буе Иртәш турында беркемгә берни сөйләмәскә, дип, махсус документларга кул куя иде... Беренче совет атом бомбасын ясау коточкыч дәүләт серенә әверелде...

Әлбәттә, Караболак халкы аларын ук белмәде, әмма сугышта булган, житәкчелектә эшләгән ир-атлар шактый нәрсә сизенәләр иде. Нәбиулла да эшнең кайсы якка баруын чамалый башлады, чөнки Коншакта да анысын-монысын ишетеп кайта, халык та сөйләп тора... Шул хәтле серлелек, тыюлар бары тик хәрби эшләр белән генә бәйле булырга мөмкин... Ә кайда хәрбиләр—анда корал, анда сугыш, анда үлем... Сугышларны күргән Нәбиулланың туган авылы, гаиләсе, яңа туган кызы өчен жаны борчылды, күңелен шом басты. Тыныч түгел иде Нәбиулланың күңеле, чөнки Караболакта, бөтен тирә-якта ниндидер шом, афәт йөри кебек иде... Урал аръягында меңнәрчә еллар үз жайлары белән яшәп яткан татар авылларының асты-өскә килә, кайсын көчләп башка урынга күчерәләр, кайсының бөтен ризыгын мәжбүри алып чыгып китәләр, ир-атларны жыеп йөриләр... Шуның өстенә, гомер булмаганны, әллә нинди шымчылык, шикләнү, әләк, яла ягулар башланды, ялган китте... Кем килгән, кем киткән, каян килгән, кая киткән—болар барысы да авыл советына язып бирелергә тиеш, өстән әмер шундый. Авылда артыгын эшләү түгел, артыгын сөйләү дә куркыныч була башлады... Ә халык сорый, йөдәтә, авылны тагы имеш-мимеш, шик баса...

Әмма Нәбиулла өчен иң авыры әле бу түгел, ә авылдан сөрелергә тиешле кешеләрнең язмышлары булып чыкты. Коншакка жыеп, тагы әйттеләр: 1947 елның август аенда хөкүмәт шундый карар чыгарган—База төзелеше тирәсендәге режим зонасыннан бөтен ышанычсыз кешеләрне чыгарып бетерергә кирәк икән... Ягъни, шушы 99 авылдан кем мона кадәр жинаятьтә гаепләнеп, хөкем ителгән, төрмәдә утырган—барысын да бу тирәдән сөрергә, куарга кирәк булачак... Бөтен нәселләре белән, ягъни, үзләрен, туганнарын, балаларын... Болар җәмгысе тирә-якка 1116 гаилә жыела икән, ягъни, 2939 кеше, шуларның 746сы—балалар... Куылырга тиешле берничә гаилә Караболакта да бар булып чыкты. Бу эшләрне оештыру белән район үзе Коншак кына түгел, Чиләбе үзе шөгыльләнә икән. Мәскәүнең аерым күзәтүендә тора, дип тә кисәттеләр. Нәбиуллага хәтта сөрелергә тиешле кешеләрнең исемлеген дә бирмәделәр, бары тик атлар әзерләргә генә куштылар. Караболак элек-электән ышанычсыз авыл булгангамы, алдан белдерсәң, сөрелүчеләр качып бетәр, дипме, Нәбиуллага бары тик бу эшнең вакытын гына әйттеләр. Хөкүмәтнең гаять мөһим бу карары үтәлүен өзсә, Нәбиулланың үзен дә, сөрелүчеләрне дә трибунал көтәсен кисәттеләр... Караболакның ышанычсыз кешеләрен илдән сөрү 1947 елның кара көзенә билгеләнде...

Бу хәбәрне алып кайткач, Нәбиулла төне буе йоклый алмады. Кемнәрне Караболактан сөрергә жыена соң Чиләбе комиссиясе? Нигә аны шул хәтле зур сер итеп саклыйлар, хәтта авыл советы рәисенә дә алдан әйтмиләр? Кайчандыр эшләгән жинаять өчен сөрәләр икән, бу сугыш чоры гамәлләренә

туры килә инде, ул вакытта авылда булган хәлләрне Нәбиулла бөтенләй белми. 1937 елда Караболактан чыгып киткәндә, Нәбиуллага әле 20 яшь тә юк иде, шул чыгып китүдән ул авылга 1945 елның көзендә генә кайтып керде. Шул арала Караболакта кемнәр нәрсә эшләгән, нәрсә өчен утырган яки утыра—ул үзе дә белеп бетерми әле.

Шул чагында аның йөрәге жу итеп китте. Тукта, немец әсирлегендә булганнар да шул ышанычсызларга керәме икән? Аның күршесе Якуп та бүгенге көндә Себер төрмәләрендә утыра бит, хәзер аның гаиләсен ни көтә? Якупның бар гаебе—әсирлектә булу. Ул вакытта әсирлеккә Нәбиулла үзе дә эләгергә мөмкин иде бит, алар Якуп белән янәшә генә иделәр... Нәбиулла һаман оныта алмый—1942 елның кышында, Ленинград өчен барган каты сугышларда, алар чолганышта калдылар. Чолганышта калганнар арасында берничә татар, шул исәптән, Нәбиулланың Караболактагы күршесе Якуп та бар иде. Якуп—Нәбиулладан берничә яшькә олы, сугышның беренче көненнән ут эчендә йөри икән. Аларның бу үлем кырында очрашулары бер могҗиза булды, ә аерылулары—ин зур фажига... Сугышка киткәч, Якупның Караболакта беренче баласы туган, ул Нәбиуллага гел шул турыда сөйли иде, гомерендә бер тапкыр күрмәгән шул баланы сагынып үлә иде...

Чолганышта калгач та, телендә соңгы сүзләре шул булды:

—Күрше, әгәр исән калсаң, Фәргать улымны ташлама,—диде ул.—Безнең язмыш хәзер билгеле түгел, Алла кулында...

Нәбиулланың сул кулы чәрдәкләнгән иде, Якуп аны үз күлмәген ертып, кысып бәйләде.

—Болай үлем көтеп ятып булмый, якташ, мин үзебезнекеләрне эзләп китәм,—диде ул аннан соң.—Сина ярдәм алып киләм, шушы урында көт...

Шул китүдән Якуп башка әйләнеп кайтмады. Каны агып, әҗәл көтеп яткан Нәбиулланы, нindiдер могҗиза белән, санитар кызлар килеп эзләп тапты. Аларга, чыннан да, Якуп хәбәр итеп өлгергән, ә үзе, ак кар өстенә төшкән утлы күмер кебек, юкка чыкты. Аның ул вакытта адашып әсирлеккә эләгүен, өч ел гомерен немец пленында уздыруын Нәбиулла Караболакка кайткач кына белде. Якупны әсирлектән совет армиясе коткара, әмма шул ук совет власте аны, туган авылына да кайтарып тормыйча, бер әсирлектән икенчесенә—10 елга Себер лагерьларына озата... Шулай итеп, үзе сугышка киткәч туган улын бер тапкыр да күрмичә, күршесе Якуп тагы әсирлеккә дучар була...

"Аларны да алырлармы икәнни?"—дип уйлады Нәбиулла, бик нык борчылып. Якупның карт ата-анасы, эне-сенелләре, хатыны, улы Фәргать аның күз алдына килеп басты. Әллә, төнлә кереп, кисәтергәме икән? Ә кая барсыннар алар бу кара төндә, карлы-янгырлы кара көздә? Бәлки әле аларга кагылмаслар да, Нәбиулла юкка гына шулай борчыладыр? Ул карт-карчыктан, бала-чагадан, хатын-кыздан авылга, Иртәш төзелешенә нинди зыян булырга мөмкин? "Юк, совет власте бу эшкә бармас,—дип уйлады Нәбиулла.—Андый заманнар үтте бит инде..."

Иртә белән, бераз яктыруга, авылга хәрбиләр кереп тулды. Алар барысы да урыслар иде. Араларында Нәбиулла белгән бер генә кеше дә юк... Хәрбиләрдән тыш, Нәбиулла Чиләбедән килгән махсус комиссия әгъзаларын да күреп өлгерде, алар да урыслар иде. Иртәшкә янәшә генә утырган Караболакка, усаллыгы белән тирә-якка даны таралган бу татар-мишәр авылына хәтта урыс генералының үзенең килүен күреп, Нәбиулла эшнең ни дәрәҗәдә житди икәнлеген аңлады. Соңыннан белде ул—генерал погонлы бу спай кеше Иртәштәге яшерен төзелешнең төп шымчысы Иван Ткаченко булып чыкты. Аның белән Чиләбедән өлкәнең милиция начальнигы Розов, исполкомнан Кудрявцев диган кешеләр дә килгән иде. Әлбәттә, аларның

төп эшләре Караболактан берничә гаиләне сөрү генә булмагандыр, моның өчен НКВД генералларының, Чиләбе түрәләренең авылга килүе кирәкми, бу эшне автоматлы солдатлар да үтәп чыга ала иде. Аларның ни өчен Караболакка килүләрен Нәбиулла еллар үткәч кенә аңлады, әмма ул вакытта Караболак фаҗигасын үзгәртерлек түгел иде инде...

Менә ул, НКВД генералы, теләр-теләмәс кенә машинасыннан төшеп, татар авылына карап тора... Авыл нык, хәлле күренә, каралты-куралар яңа, урам тулы бала-чага, боларны хәтта сугыш, ачлык та кырып бетерә алмаган... Әмма тиздән бередә барысы да үзгәрәчәк... Барысы да... Юк, авылдан сөреләсе берничә гаилә турында ул уйламый да, аның өчен монда калучылары мөһимрәк... 1944 елда Кырым татарларын, чечен-ингушларны илләреннән сөргүдә башлап йөргән бу генерал соңыннан Литваны канга батыра, шушы тырышлыклары өчен ул Суслов тарафыннан Уралга, атом төзелешенә җибәрелә...

Җыелып авыл советына кергәч, алар Нәбиулланың кулына исемлек тоттырдылар, куылучыларга җыенырга бер сәгать вакыт бирделәр. Нәбиулладан бары тик аларны ат-арба белән тәэмин итү генә сорала иде, калганына аны якын да җибәрмәделәр, бар эшне НКВД хәрбиләре үз кулларына алдылар... Бу эштә аларның тәҗрибәләре зур иде. Исемлеккә күз төшерүгә, Нәбиулла унлап гаилә арасында Якупларның да фамилиясен күрде. Калганнар кайсы—бер уч ашлык, кайсы сугыш вакытында салым түли алмаган өчен утыртылган кешеләр иде. Алардан авылга бер зыян да юк, алар башкалар кебек үз хезмәтләре белән көн күреп яталар иде. Һәм беркем белән киңәшеп тормыйча, аларны авылдан сөрергә булганнар. Моны белгәч, Нәбиулланың бугазына төер утырды, күкрәген ачу уты көйдереп узды. Авыл халкын бу хәтле саннамау, мыскыл итү аны ярсып аягына бастырды.

—Бу кешеләрнең илдән сөрелерлек ни гаепләре бар соң?—дип сорады ул, комиссия әгъзаларына сөзеп карап.—Сугыш вакытында ачтан үлмәс өчен кырдан алган бер уч ашлык моңа сәбәпче була аламы?

Чиләбедән килгән комиссия әгъзалары алыптай бу авыл иренең сүзләреннән башта өнсез калдылар. Аларга Караболак авылы халкының усаллыгы турында кат-кат әйткәннәр иде. Алдына-артына карап йөрмәсәң, монда урам уртасыннан юкка чыгуың да бар икән... Кисәтүләре дөрес булып чыкты, инде авыл советы рәисләре шундый булгач, башкалар турында ни әйтәсең? Хөкүмәт карарын шик астына алу өчен куш йөрәкле булу кирәк. Ә бу татар әнә, ярсыган үгез кебек, боларга карап каткан... Әгәр эшне тиз тотмасаң, монда фетнә күтәрелергә дә бик мөмкин. Кайда диген—атом төзелешенең борын төбендә! Мондый хәлне Мәскәүдә генә түгел, чит илләрдә дә тиз ишетәчәкләр, төпченә, казына башлаячаклар... Ә бу хәл бер дә атомчылар файдасына түгел... Әлбәттә, урам тулы НКВД солдатлары, корал белән боларны бик тиз бастырырга була, әмма тавыш чыгарырга ярамый... Димәк, бу бунтарьларны хәйлә белән алдырырга, мәкер белән бетерергә кирәк...

—Бу—хөкүмәт карары, безнең аңа буйсынмый хакыбыз юк,—диде НКВД генералы, тыныч булырга тырышып.

Чөнки аңа урамнан, капка төпләреннән йөзләгән, хәтта меңләгән кеше нәфрәт белән карап тора иде. Күпләрнең кулында—сәнәк, лом, балта... Мөгаен, сөрелүчеләр турында хәбәр авылга таралып өлгергәндер, кешеләр берәм-берәм дә, төркем-төркем дә авыл советы бинасы янына җыела башладылар. Аларга каршы НКВД солдатлары тезелеп басты, ике яктан бер саксыз хәрәкәт булса да, бөтен авыл, шул исәптән, Ткаченко үзе дә ут астында калачак иде... Үткенрәк мишәрләр авыл советына да кереп

тулдылар, алар Нәбиулланың сүзен, әмерен көтәләр иде...

—Мин бу эшне үти алмыйм,—диде Нәбиулла, кара исемлекне комиссия әгъзалары алдына куеп.—Мин моның өчен сигез ел солдат хезмәтендә йөрмәдем... Мин үз халкымны авылдан куу өчен Гитлер белән сугышмадым... Дөрес хәл түгел бу...

Ишек төбендәгеләр дә шаулашып алдылар. Халык соңгы вакытлардагы чикләүләрдән, талаулардан, билгесезлектән тәмам туйган иде, инде авылдан ук сөрә башлагач, элеккеге гадәт буенча, күпләр сәнәккә тотынды. Әлбәттә, НКВД генералы, теләсә, аларны минут эчендә бастыра ала, әмма ана гауга кирәкми. Иртәш телгә керергә тиеш түгел. Аннан, аның эшемени ул—авыл мужиклары белән сугышып йөрү? Алар болай да үзләренә кирәкне алачаклар, аларның монда калулары кирәк. Югыйсә, Ткаченко аларны бөтен авыллары белән бер көн эчендә Уралтауның теге ягына илтеп ташлый ала, әмма алар өчен җәһәннәм менә монда әзерләнгән...

—Сез беләсез, хәзер бу тирәдә зур төзелешләр алып барыла,—диде ул, ишек төбендә өелешеп басып торган авыл ирләренә карап.—Сугыштан соң промышленностьны күтәрергә кирәк, илгә тракторлар, машиналар, комбайннар кирәк, күп кирәк... Шуңа күрә ул заводлар инде Урал арьягында да төзелә башлады... Шуңа күрә без заводлар төзеләчәк җирләрдәге күп кенә авылларны башка урыннарга күчерәбез... Ул исемлектә сезнең авыл да бар иде, әмма халыкның күплеген искә алып, без аңа кагылмадык... Совет властына каршы булган берничә гаиләне генә бу удар төзелешләр барган урыннан башка җиргә күчерергә булдык... Әмма без бу фикеребезне үзгәртә дә алабыз, бүген бу гаиләләргә кагылып тормыйбыз, иртәгә бөтен авылыгызны Уралның теге ягына күчерәбез... Сез шуңа ризамы?

Халык дәшмәде. Беркем дә мәсьәлә болай куелыр дип көтмәгән иде. Һәркем үзе турында, үз гаиләсе, балалары язмышы хакында уйлады. Караболактан башка алар тормышларын күз алларына да китерә алмыйлар иде...

—Алайса, авыл халкына менә шуларны чыгып аңлатыгыз хәзер,—диде Ткаченко, эшне һаман үз җаена борып.—Һәм тыныч кына өйләрегезгә таралыгыз... Безгә хөкүмәт карарын үтәргә мөмкинлек бирегез...

Авыл ирләре бер—Нәбиуллага, бер урыс генералына карадылар. Нәбиулла дәшмәде, чөнки ул күп кенә татар авылларының, төзелешкә җир житми, дигән сәбәп белән, башка урынга күчерелүләрен белә иде... Ә күчү—ул инде таралу, бетү, Караболакны бөтенләй тузгытып ташлау булачак... Авыл халкы моның өчен Нәбиулланы кичермәячәк... Димәк, аз корбаннар биреп булса да, Караболакны саклап калырга кирәк, авылга тидермәскә... Шуңа күрә ул ишек төбендәге ирләргә берни әйтмәде, карашын читкә борды... Ирләр кинәшергә урамга чыгып киттеләр...

Ткаченко, исемлекне алып, авыл активистларына тоттырды. Өлкәнең башкарма комитетыннан килгән түрә Нәбиулладан пичәтне сорап алды, милиция начальнигы исә аны бер читкә алып барып утыртты, янына кораллы ике сакчы куйды. Коммунист һәм комсомоллар, сөрелергә тиешле кешеләр исемлеген алып, авыл буйлап чыгып киттеләр... Аларга баштан-аяк коралланган НКВД гаскәре иярде... Ткаченко төркеме, урамга чыгып, бу хәлләрне күзәтеп торды, алар бар яктан да кораллы сакчылар белән уратып алынган иде...

Куылырга тиешле һәр капка төбенә, кораллы хәрбиләр озатуында, җигүле ат-арба килеп тукталды. Кешеләргә кирәк-ярак әйберләрен җыярга, бала-чагалары белән арбага чыгып утырырга бер сәгать вакыт бирелгән иде. Авыл өстендә тавыш, гарасат купты. Хатын-кызлар кычкырып елый, ирләр каядыр йөгерә, карлы-яңгырлы урам пычрагына чүпрәк-чапрак, түенчекләр

коела, мал-туар үкерә иде... Сөрелүче һәр йортны хәрбиләр сырып алган, мылтык көпшәләрен һәркемгә төбәп, атып җибәрергә әзер торалар... Ул арада авылга тагы өч йөк машинасы хәрбиләр кереп тулды. Караболак камалышта калган кебек булды... Кешеләрнең котын алып, авыл өстендә хәрби самолет очып йөри башлады. Аның тавышыннан, колакларны ертып үкерүеннән арба артына бәйләнгән сыер маллары, бауларын өзеп, авыл буйлап чабып киттеләр... Караболакта мәхшәр купты...

Бер Караболакны гына түгел, бөтен Кырымны сәгать эчендә сөргенгә сөргән Иван Ткаченко бу юлы да җинде—өйлә турында унлап олау Чиләбе юлына карап кузгалган иде... Алар өчен һәм тагын шундый йөзләгән, меңләгән җаннар өчен анда 300 тимер юл вагоны әзерләп куелган һәм бу ышанычсыз кешеләр Урал аръягына—Златоуст, Миасс, Сатка тирәсенә сөреләчәкләр иде... Аларга беркайчан да атом төзелеше тирәсендәге шәһәр һәм авылларда—Чиләбедә, Магнитогорскийда, Карабашта, Кыштымда, Уфалейда, Коншак, Кузнецкий, Кәсли һәм Аргаяш районнарында яшәргә рөхсәт ителмәс... Шулай итеп, әле ясалып та өлгермәгән атом бомбасы меңләгән кешене көчләп нигезеннән кубарыр, оясын туздырыр, туган якларыннан аерыр... Шушы атом аркасында мең еллык татар авыллары үзләренең ирекләрен югалтырлар, мәңгегә органнар күзәтүе астында калырлар... Әмма бу хакта әле куылганнар да, авылда калганнар да берни белми...

Унынчы арбада, әнисе итәгендә, төрмәдәге Якупның биш-алты яшьләрдәге улы да утыра... Ул әле кая барганын, ни өчен барганнарын аңламый, аның бары тик күрше кызы Гөлҗиһан янына кереп, шул матур бала белән уйныйсы килә... Нәбиулла абыйсының атына печән ашатасы килә, урам малайлары белән авыл янындагы тау куышларында качыш-качыш уйныйсы килә... Ә аны, арбага утыртып, әллә кая алып баралар... Әнә тәрәзәгә капланып, аңа карап калган күрше кызы Гөлҗиһан да ераклаша, Караболак та әкренләп артта кала, тау куышлары да күздән югала... Фәргатьнең арбадан сикереп төшеп, янадан авыл ягына йөгерәсе килә, әмма янда мылтыклы абыйлар утыра... Алар булмаса, Фәргать инде күптән Гөлҗиһаннарда булыр иде, алар икесе бергә мич башына качарлар иде, аларны беркем эзләп таба алмас иде... Хәтта менә бу мылтыклы абыйлар да... Фәргать алардан курка һәм башын тизрәк әнисенең бишмәтенә төртә... Сверлау борылышын узгач, инде Караболак та күренми башлый, энгергә төренеп, бөтенләй күздән югала... Авыл ягына каерылып-каерылып караган кешеләрнең, карлы-янгырга кушылып, битләреннән ачы күз яшьләре ага... Чөнки Караболак кала бит, Караболак кала, ургып аккан елгалары, саф чишмәләре, серле күлләре, борынгы зират-курганнары, Аллакүле, тау куышлары белән Караболак кала... Арбаларга беркайчан да авылдан чыкмаган 80-90 яшьлек карт-карчыклар, яна туган сабый балалар, сугыш гарипләре, хатын-кыз төялгән... Карт-коры эчтән генә Коръән укый, тәкъбир әйтә, Караболак белән бәхилләшә... Хатын-кызлар, соңгы тапкыр авыл өстенә карап, күңелләреннән мөнәҗәт әйтәләр, Караболак белән бәхилләшәләр... Көзге бозлы юлда, Чиләбе ягына карап, атлар бара, язмыш арбасына татар халкы төялгән... Караболак урманнары, Биташ күлләре аларны дога һәм мөнәҗәт белән озатып кала...

Атамның бер гөле идем,
Анамның былбылы идем,
Бу хәсрәткә гаҗиз булдым,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ...

Эчемдә кайгылар тулды,
Йөземнен нурлары сулды.
Йөрәгемдә кайгы тулды,
Сабыр бирсен үзе Аллаһ...

Үләр идем, үләр хәл юк,
Бу хәлләргә түзәр хәл юк.
Кинәш итәр кешем дә юк,
Сабырлык бир үзен, Аллаһ...

Сабырлыкнын сабакларын
Китаплардан караганнар.
Сабыр иткән кешеләрне
Шәһитләр дип санаганнар...

## Дүртенче бүлек

Караболак...

Татар Караболагы...

Каралып, ургып аккан елгасы да шул исемдә, авылы да... Дөрес, янында Урыс Караболагы да бар, алар да, Караболак елгасы буенда урнашканга, авылларына шундый исем биргәннәр...

Караболак елгасын элек бик киң, тирән сулы елга булган диләр, аның аргы ягына кешеләр түгел, атлар да йөзеп чыга алмаган, чөнки агым бик көчле булган. Суының шундый кара-кучкыл төстә булуы аның төбендәге кара ләмнән икән, ә болай, бик чиста сулы елга ул—Караболак... Авыл халкы үзе дә суны шуннан эчә, мал-туарына да шуннан ала, гомер буе шул су бәрәкәте белән яши. Дөрес, авыл янында гына Аллакүл чишмәсе бар, аның суын халык бары тик шифага гына тота, олы як аны өшкереп эчә. Татар Караболагы авылы халкы үзенең алыптай озын буйлы, озын гомерле булуы белән бөтен тирә-якта аерылып тора, бередә йөз яшьтән узучылар да шактый. Баһадир гәүдәле Караболак татарлары үзләренең усаллыклары белән дә дан тоталар, әмма бу явыз усаллык түгел, гадел турылык, зирәк үткенлек. Шуңа күрә Караболак халкыннан тирә-юньдә өркеп торалар, аның чаялыгын, елгырлыгын еш кына мишәрлекләреннән күрәләр...

Караболак элек-электән бай, матур яшәгән, үзенең тырышлыгы белән тирә-юньгә дан тоткан. Ул шулай ук бу якларда иң чиста авыл булып та саналган, бередә баскыч төбендәге ташларга хәтле ялтыратып юып куя торган булганнар. Шуңа күрә бу авылга читтән килен булып төшкән кеше зур сынаулар узган, бик тырышлар гына монда яшәп кала алган. Караболак халкы, усалдан саналса да, язылмаган кануннары белән яши. Шуларның берсе—"Миңа тимә, мин сиңа тимәм", дигән шарт. Ягъни, бу авыл халкы, үзенә тимәсәләр, кешегә кагылмаган, үзенә кагылсалар, җавапсыз да калмаган... Мең еллар буе халыкта корычтай холык чыныккан, Караболак татарлары беркайчан да үзләрен җәберләргә ирек бирмәгәннәр... Бу авылда беркайчан да эчү, урлашу булмаган, бары тик читтән килгәннәр арасында гына шундый ямьсез гадәтләр күренә башлаган... Әмма бу авылда начар кеше озак яши алмаган, андыйларны куганнар... Гаять горур, укымышлы, һәр йортта китап булган Караболак татарларынын көтүен дә Урал аръягыннан килгән күчманнәр көтә торган булган... Караболак халкы, борынгы шәҗәрәләргә таянып, үзен Нух пәйгамбәр заманнарыннан калган

Алып Ханнар нәселен дәвам итүчеләр, дип санаган һәм шуларның яшәү рәвешенә тугры булып калган...

Заманында өяз үзәге булып торган, зур базарлары, мәктәпләре, дүрт-биш мәчете, укымышлы, галим кешеләре белән бөтен тирә-якка дан казанган бу татар авылы чал Урал артында, кара урманнар эчендә, күл-сазлыклар арасында ничек барлыкка килгән соң? Нигә Караболак халкы үзенең кырыс холык-фигыле, алыптай гәүдә төзелеше, ханнарча яшәү рәвеше, зирәклеге белән бу якларда яшәүчеләрнең барысыннан да аерылып тора? Тарихчыларның язуы буенча, бу авыл 1553-1554 елларда, Явыз Иван Казан каласын басып алгач, Идел-Чулман буйларыннан качып киткән татарлар тарафыннан салынган икән. Авыл көнен, Караболак тарихын шулай билгеләп үтәләр дә. Картларның сөйләвенчә, башта бирегә Муса исемле кеше килеп урнашкан, ул тирә хәзер "Торчак", дип, ә Караболак авылының ул ерак башы Мусакай, дип атала. Мусаның Бәйрән(Бәйрәм) исемле улыннан Әбделмән, аннан—Фәйзулла, аннан—Сәйдулла, аннан—Хәбибулла, аннан—Әсәдулла, аннан—Шәрәфетдин туа... Алар янына Зөлкарнәйләр, Уразайлар нәселе килеп кушыла... Шулай итеп, 450 ел вакыт эчендә 4-5 мең кешелек зур татар-мишәр авылы барлыкка килә... Моны рәсми тарихчылар яза.

Әмма...

Әмма Караболак күпкә, бик күпкә карт авыл ул... Ул гына да түгел, хәтта зур тарихчылар да җавап таба алмаган борынгы курган, кирмәннәр иле ул Караболак тирәләре... Картларның сөйләве буенча, монда элек иксез-чиксез диңгез җәйрәп яткан... Бөтендөнья Туфаныннан калган зур су булган ул... Ул заманда бу тирәдә кешеләр бары тик Урал тау башларында гына исән калганнар, шунда гына яшәгәннәр, чөнки аның түбәсенә су менеп җитә алмаган... "Без Нух пәйгамбәрнең улы Яфәстән таралган нәсел",— дип сөйли торган булган Караболак картлары. Алар Нух пәйгамбәр көймәсенең Урал тауларына туктавы турында буыннан-буынга сөйләп калдырганнар... Моннан 100 мең еллар элек, әле таш гасырларда ук, алыптай гәүдәле ул кешеләр Урал тауларыннан түбән төшәләр һәм дөнья буйлап тараладар... Караболактан ерак түгел, Аллакүл, дип аталган бер хикмәтле күл бар. Картларның сөйләве буенча, Уралтаудан төшкән Алып кеше шунда Тәңрегә үзенең беренче гыйбадәтен кылган, таш өстендә аның галәмәт зур аяк эзләре уелып калган... Күл тирәли унике таш сын тезелешеп баскан булган, хәзер алардан инде таш өемнәре генә утырып калган... Кайберәүләр аларны ташка әйләнгән кешеләр, ди... Алар арасында иң зур сынны Әбиташ, дип йөртәләр, халык исә үзенчә кыскартып, Биташ, дип тә атый. Күлнең исемен дә кайчагында шулай дип йөртәләр. Әбиташ, чыннан да, зур гәүдәле хатын-кызга охшаган һәм ул йөзе белән Иртәш ягына карап тора. Бәлки анысы Иртәш тә түгелдер, Ирташтыр, әмма халык үзенә җайлап, хәзер шулай дип йөртә... Әбиташ янында шактый зур җир куышы—мәгарә бар, аннан бик шифалы чишмә агып чыга, Караболакның олылары, кай төшләре авырса да, шуның суын өшкереп эчәләр... Элегрәк мәгарә диварларында казанда аш пешерүче зур гәүдәле хатын-кыз рәсеме дә булган, хәзер анысын бары тик шәйләргә генә була инде...

Галимнәрнең язуы буенча, моннан берничә мең ел элек үк биредә яшәүче халык бакыр һәм тимер кою серләрен белгән, алардан эш һәм сугыш кораллары ясаган. Бу хакта Караболак янындагы курганнардан табылган борынгы әйберләр сөйли. Борынгы кешеләр биредә кирмән-калалар салып яшәгәннәр. Караболак янында әле дә биеклеге—5, киңлеге 10 метр булган борынгы курган бар, Чиләбе, Мәскәү галимнәре аны скиф каберлеге дип билгеләп китәләр. Караболак картлары бу урынны элек-электән изге урынга

санаганнар, безнең борынгы бабабыз Алып Хан рухына догаларын кылганнар... Халык сөйләве буенча, бу тирәләр, Нух пәйгамбәр нәселе күмелгәнлектән, изге җирләр санала икән. Караболак халкы инде мең еллар ислам динендә булса да, әллә кайдагы тамырлардан, әллә кайдагы тирәнлекләрдән борынгы гореф-гадәтләр баш калкытып куя... Мәсәлән, авыл халкы бу тирәләрдә кешегә авыр вакытларда ярдәмгә килә торган изге затлар яшәвенә чын күңелдән ышана. Аларны бередә Яхшылар, дип атыйлар, күзгә күренми торган бу затларны намаз картлары Аллаһның фәрештәләре, ди, кайберәүләр иялэр, дип йөртә... Алар өч сүздән артык әйтмиләр икән, кешене уятып, бәла-каза буласын кисәтәләр, ди... Һәрхәлдә, Караболак халкы шулай сөйли һәм ул моңа ышана...

Шушыларга карамастан, авыл халкы бик дини, җәйге чилләләрдә дә уразасын калдырмый, тыелган заманнарда да качып намаз укучылар күп булган... Бигрәк тә—өлкәннәр һәм хатын-кызлар дин-ислам чикләреннән чыкмаска тырышалар, мөселманча киенеп, мөселман ризыгы белән тукланалар. Ирләр исә дингә алай ук ябышып ятмый, әмма теге заманнарда гаетләрдә Караболакның бөтен мәчетләре дә шыгрым тулы була иде, дип сөйлиләр. Патша заманында да иманында нык торган Караболак халкын совет власте шактый йомшарта, диннән биздерә. Бигрәк тә авылга читтән килгән халык, укытучылар, коммунист-комсомоллар, урыслар һәм башкортлар Караболакка үзләренең "бәйрәмчә яшәү" рәвешләрен кертеп өлгерәләр. Сугыштан соң дин инде йортларга куып кертелгән була, ул аерым гаиләләрдә генә сакланып кала...

Караболакта бик борынгы бер гореф-гадәтнең яшәп ятуын да әйтеп үтәргә кирәк. Ул—кот койдыру. Кайдан, кайчан килгән гадәт бу—монысын беркем әйтә алмый, әмма аны барсы да белә, кирәк тапканда, күпләр кот койдыра. Кеше бик нык куркытылганда яки үлем чире белән ятканда кулланалар бу имләү чарасын. Һәр заманда Караболакның кот койдыра торган үз карт-карчыгы булган, шулай да, бу эшне күбрәк хатын-кызлар башкара. Соңгы гасырда исә авылда кот коючы булып 110 яшьлек мишәр карчыгы йөри. Ул авырган кешене башта Коръән аятьләре белән өшкерә, аннан үзе генә белгән "кот догасын" укый, аннан, шапылдатып, авыруның арка-күкрәкләренә суга башлый. Монысы халык телендә "шапылдату" дип атала. Әгәр бала бик нык курыкса, сөйләшә алмас хәлгә килсә яки тотлыга торган булып калса, аны кара мунчага алып кереп, үзенә күрсәтмичә генә өстенә кара тавык утырталар. Кара тавык ачы кыткылдап җибәрүгә, бала да куркып кычкырып җибәрә. Чыккан коты шушы каты курку аша, ана яңадан керә, имеш... Әлбәттә, бу эшләр муллалардан яки укытучылардан качып кына эшләнә, чөнки дин дә, фән дә мондый алымнарны кабул итми...

Караболакта шулай ук яңа туган рахит баланы, биләүсәгә төреп, ипи калагына утыртып, уты сүнгән зур мичкә кертеп чыгара торган булганнар, шулай итеп, ана да "кот койдырганнар"... Баланың елап бүсере чыкса, аякның баш бармагы белән баланың кендегенә өч тапкыр басып алганнар, бу хәл өч тапкыр кабатланган... Күз тигәннән, сихердән, җеннән дә Караболакның үз догалары, үз дәвалары бар... Әмма халык күпчелек дәваны ислам диненнән, әбиләрнең мең төрле үлән-тамырларыннан, Караболакның шифалы суларыннан тапкан... Биташ күле тирәсендәге зәңгәр балчыкны халык тән яраларына сөрткән, суын җан яралары өчен кулланган... Һәм күпләр туксанга, йөзгә хәтле яшәгән, үзеннән соң ун-унбиш бала, йөзләгән оньк, зур нәсел калдырган... Авыл гариплекне, тилелекне белмәгән, таза агач кебек, тамырларын бик тирән җибәреп, гөрләп үскән дә үскән... Атом чорына ул менә шушы хәлдә килеп кергән...

Караболак халкының сөйләм теле тирә-юньдәгеләрдән шактый аерылып

тора. Авылның исеменнән үк күренгәнчә, биредә төп халык татарлар яши, әмма аларның сөйләмнәрендә мишәрлек чатнап тора. Әйтик, алар кәгазьне мишәрчәләп, "кагиз", диләр, какны—"кагыт", пычакны—"пыцак", дип сөйлиләр. Караболак халкы шулай ук җөмлә ахырында "кый" дип өстәп куярга бик ярата, "бардым кый", "кайттым кый" , дип сөйли... Аларның тагы бер яратып куллана торган сүзләре бар—"дан" сүзе. Караболаклылар, "яхшы булган", диясе урынга—"дан булган", диләр, "дан кеше", дип сөйлиләр... Алар әнине—инәй, әтине—атай, әбине—нәнәй, бабайны—карттай, дип әйтергә дә яраталар... Хәер, Урал арьягына Казан дәреслекләре белән килгән әдәби татар теле Караболак халкын да Казанча сөйләшергә өйрәтә башлады, ләкин юк-юкта "инәй", "нәнәй"ләр ычкынып китә әле, "кый" да ишетелеп ала... Караболак халкы бик җор телле, әйтем, шигырьләр белән сөйләп җибәрә, һәм монда һәркемнең үз кушаматы бар... Биредә "Аять ашлары" дип йөртелгән Корьән мәҗлесләре уздырырга бик яраталар, хатын-кызлар анда озаклап мөнәҗәтләр әйтәләр, белгән кеше Корьән укый... Һәм тагы бер гадәт—кеше үзе үлгәнче үзенә бәет чыгара... Шулай дөнья белән, авылдашлары белән бәхилләшә, аларга соңгы сүзен әйтеп калдыра...

Менә шундый гаять үзенчәлекле, бик борынгы авыл ул—Татар Караболагы... Үз җирендә пәйгамбәрләрне һәм әүлияләрне, ханнарны һәм каһарманнарны, борынгы скифларны һәм һуннарны яшәткән, тамырлары Атилла һәм Алтын Урда чорларына ук барып тоташкан авыл ул—Татар Караболагы... Холкы һәм акылы белән барысыннан аерылып торган, ханнар нәселен дәвам иткән, кыпчак-мишәрлеген, татарлыгын саклап кала алган авыл ул—Татар Караболагы... Һәм заман ахырында атом аждаһасы белән берүзе йөзгә-йөз калачак авыл ул—Татар Караболагы...

## Бишенче бүлек

1949 елның җәйге чиллә вакыты иде...

Ураза быел шушы вакытка туры килде, өлкәннәр, хатын-кызлар, хәтта балалар да—уразада. Әмма мәктәпләрдә бик каты әйтелгән, өстән дә бик каты кисәтелгән—совет балаларын ураза тоттырмаска. Башка авылларда бу таләп бик тиз үтәлсә дә, Караболак халкын буйсындырып булмый, мәктәптә барлык балалар да диярлек ураза тота. Читтән, бигрәк тә, Уралның арьягыннан килгән укытучылар өчен бу хәл коточкыч булып күренә, шуна күрә алар балаларны уразадан чыгару өчен барысын да эшлиләр... Җәй көне булуга карамастан, балаларны лагерьга җыеп, һәр иртәне рәтләргә тезеп куялар. Читтән килгән коммунист-комсомол укытучылар, кулларына сулы тимер кружкалар тотып, рәткә тезелгән балаларга көчләп су эчертеп йөриләр... Эчмәгәннәрнең ата-аналарын авыл советына чакыртып, теге вакыттагы кебек, Урал арьягына сөрү белән куркыталар... Шуңа күрә олылар уразада булуларын яшерергә тырышалар, иртән сәхәрне дә тәрәзәләрен томалап кына ашыйлар, кичен авыз ачуларын да кешедән яшерәләр... Караболак халкын бер яктан атомчылар кысса, икенче яктан атеистлар аларның җаннарына тиеп тора... Шулай итеп, совет властьы халыкның мең еллар буе алып барган тормышына, тәртибенә үз тамгасын сала, аңа үз яшәү рәвешен көчләп тагарга тырыша... Халык бу хәлләргә үзенчә каршы тора, әмма күпләр моның белән ризалашырга мәҗбүр була, чөнки һәркемнең проблемасыз, тыныч яшисе килә...

Гөлҗиһаннар өендә дә уразаны качып тоталар. Аның карттай-нәнәе дә, атай-инәе дә ураза тоталар, Гөлҗиһанның иң яраткан бабасы—Таһир бабай да ураза тота... Ул әле бабай да түгел, җир җимертеп, тракторда эшләп йөри, әмма кечкенә кызчык Гөлҗиһан аны, яратып: "Бабай",—ди...

Гөлжиһан үз яшенә күрә түгел, гаҗәеп тере, зиһенле бала булып чыкты, бөтен урамны, күрше-тирәне исемнәре белән белә, инде укый-язарга тырнаштыра, кызыксынмаган нәрсәсе юк... Гөлжиһан әле кечкенә, ул ураза тотмый, әмма һәр көнне олылар белән сәхәргә торып утыра, кичен олылар белән бикләнеп "авыз ача"... Ул күп вакыт каршыда гына яшәүче карттайларында була, шунда йоклап та кала, кайсы көнне әтисе кайтып житеп, аны кулларына күтәреп үзләренә алып чыгып китә... Гөлжиһан әтисен барысыннан да ныграк ярата, хәтта Таһир бабасыннан да артыграк... Хәтта әнисеннән дә... Юк, икесен дә тигез ярата Гөлжиһан... Алар аны кулларында гына күтәреп йөртәләр...

Гөлжиһанның әтисе хәзер авыл советында эшләми, аны теге вакытта чыгарганнар. Авыл халкы дәррәү күтәрелеп якламаса, бәлки аны утыртып та куйган булырлар иде... Караболак халкы Иртәш төзелешенә эшче һәм ризык бирмәү белән яный башлагач кына, органнар Нәбиулланы тынычлыкта калдырды. Бәлки аны сугышта алган орден-медальләре күп булу коткарып калгандыр, бәлки яралы-гарип булуы... Әлбәттә, бу хәлләрдән соң Нәбиулланы партиядән дә чыгардылар, әмма, грамоталы кеше буларак, аны ферма мөдире итеп куйдылар. Гөлжиһанның әтисе, нәкъ элеккегә кебек, иртән караңгыда чыгып китә, кич караңгыда кайта. Аның әнисе дә көне буе кырда, көне буе колхоз эшендә... Шуна күрә Гөлжиһанның күп вакыты әби-бабасы янында уза, алар, Караболак гадәте буенча, янәшәдә генә яшиләр.

Ә Караболакта гадәт шундый—бередә малай өйләнгәч, аны башка чыгаралар, ягъни, үзенә йорт салып бирәләр, төпчек малай ата-ана янында кала... Аерылып чыкканга бөтен нәсел, бөтен туган-тумача булыша, чөнки үз йорт-жире булган кеше генә бередә ир-ат санала. Кызларны яшьли кияүгә бирәләр, киленнәргә кадер-хөрмәт зур монда. Гомер буе шулай булган, халык хәзер дә шулай яшәргә тырыша, әмма заман бу тәртипкә дә үз төзәтмәләрен кертә. Караболак яшьләре хәзер авылда яшәүгә караганда, читкә китүне артыграк күрәләр... Кем укырга дип китә дә өйләнеп кайтмый, кем бәхет, эш эзләп чыгып китә... Күпләр хәзер кайсы—Чиләбедә, кайсылары Сверлауда, Иртәштә, башка шәһәрләрдә... Әби-бабасының төпчек уллары Хәбибулла хәзергә мәктәптә укып йөри, әмма аңа да тиздән армияга... Аннан авылга кайтырмы ул, юкмы—әлегә беркем белми...

Кичләрен авыз ачарга Гөлжиһан һәр көн әби-бабасы янына керә. Менә бүген дә ул, кояш баер алдыннан, йөгереп аларга керде. Әбисе Нуржамал табын әзерләп йөри, бабасы әнә, чәчәкле намазлыгын җәеп куеп, намаз вакытын көтә... Гөлжиһан исә, тәрәзәгә капланып, зур, кызыл кояшның Караболак ярыннан тәгәрәп төшеп китүен күзли, чөнки әби-бабасы шул чакта гына өстәл янына утырачаклар... Юк әле, алар чеметеп тоз капканнан соң, башта намаз укыячак, аннан соң ашый башлаячаклар... Менә монысы Гөлжиһан өчен иң кызык, иң күңелле вакыт, ул да алар белән иң тәмле әйберләрне авыз итә...Менә шуңа күрә Гөлжиһан, тәрәзәгә капланып, бик тырышып кояшны күзәтә, ә ул һаман күздән югалырга ашыкмый... Менә ул инде Караболак елгасына якынлаша, менә яр читенә килеп житә, анда тоныктак утлар чәчеп бераз эленеп тора, һәм менә...тәгәрәп, яр астына ук төшеп китә!

—Нәнәй! Карттай! Кояш суга төшеп китте!—дип кычкыра Гөлжиһан бар көченә.

Бабасы: "Шулаймыни, кызым?"—дигән була, бармак башы белән генә чеметеп тоз каба да дога кыла. Әбисе дә шуны ук эшли. Гөлжиһан исә барысын да жентекләп карап, сеңдереп тора, алар артыннан догалар кабатлаган була... Аннан алар, аллы-артлы басып, намаз укый башлыйлар...

Гөлҗиһан исә, зур түземсезлек белән, аларның укып бетерүләрен көтә, өстәлдәге тәмле әйберләргә бик үреләсе килсә дә, үзен тыя. Менә әби-бабасы, намазларын укып бетереп, урыннарыннан кузгалалар. Менә алар ашыкмый гына өстәл янына киләләр, ризыктан бигрәк, ин беренче эш итеп, сабыр гына чәйгә үреләләр... Әйтерсең, алар коне буе ач тормаган, әле генә ашап кузгалган кеше кебек, һаман чәй эчәләр дә чәй эчәләр... Алардан узып, Гөлҗиһан тәмле әйберләргә үрелергә ояла, моны күреп, әби-бабасы аны кыстый-кыстый сыйлый башлыйлар... Әйтерсең, ул монда иң зур кунак, иң кадерле кеше... Бу, бәлки, чыннан да, шулайдыр, Гөлҗиһан моны аңлап кына бетермидер... Гөлҗиһанга алар янында шундый рәхәт, аның мәңге-мәңге шулай яшисе килә... Әби-бабасы белән, әти-әнисе белән, беркая китмичә, гел Караболакта гына яшисе килә. Ул аның шулай буласына чын күңелдән ышана, чөнки алар авылында бөтен кеше шулай яши, барысының да инәй-нәнәйләре, атай-карттайлары бар...

Гөлҗиһан шулай дип уйлап өлгермәде, бөтен өй эче кинәт яктырып китте. Бөтен дөньяга—өйләргә, урамнарга, авыл өстенә әллә нинди көмеш нур таралды... Өй эче шул хәтле якты булып китте—Гөлҗиһан хәтта идән ярыгында кысылып яткан мәрҗәнгә хәтле күреп өлгерде. Нурҗамал карчык белән Ярулла карт ашаудан туктап калдылар, әсәрләнеп, төнге якты урамга карадылар.

—Күк кабагы ачылды! Аллаһның рәхмәте белән, күк кабагы ачылды, теләк теләргә кирәк,—диде Ярулла карт, тизрәк намазлыгына тезләнеп.

—Күк капусы ачылды, балам, теләкләреңне телә,—диде әбисе, Гөлҗиһанны үзенә таба тартып.

Күк кабагы? Ә нәрсә соң ул—күк капусы? Гөлҗиһан аны аңламый, әмма аңа шул хәтле рәхәт, әйтерсең лә күктән төшкән ул якты нур Гөлҗиһанның күкрәгенә, күңеленә тула, тәнен иркәли... Колагына әллә нинди сәер моң ишетелгән кебек була... Бу наз һәм моңнан Гөлҗиһанның хәтта елыйсы килә... Гөлҗиһан, бар дөньясын онытып, тагы тәрәзәгә каплана... Анда, яп-якты күккә карап, нигәдер, этләр елый... Урам шул хәтле якты һәм тыныч, Гөлҗиһан туфракта үзенең көндез калдырган тәпи эзләренә кадәр күрә... Бу көмеш яктылыктан күк шундый тирән һәм ерак булып күренә, анда мәңге барып җитә алырлык түгел кебек... Гөлҗиһан сокланулы карашын тагы җиргә төшерә һәм урам буйлап бу якка таба йөгергән әнисен күрә... Колагында әбисенең сүзләре яңгырый: “Күк капусы ачылды, балам, теләкләреңне телә...”

Гөлҗиһанның гел-гел әнисе янында буласы килә, әтисе, әби-бабасы янында да... Алар гел исән булсын, алар гел бергә булсыннар... Тагы нәрсә теләсен икән Гөлҗиһан? Әлбәттә инде, авыл гел булсын, Караболак мәңге-мәңге яшәсен...

Гөлҗиһан шулай дип уйлап өлгермәде, нурлы урамнан әнисе йөгереп килеп керде һәм кызын кочаклап алды. Аңа да дөньяда шушы нәни кызы, бары ул кирәк! Ире, гаиләсе кирәк, шушы авыл кирәк... Ана белән бала, кочаклашып, могҗиза күргәндәй, төнге яктылыкка карыйлар... Аларга аннан моң коела, наз агыла, нур инә... Әллә кайдан, әллә—күктән, әллә—җир астыннан, карт белән карчыкның пышылдап әйткән сүзләре ишетелә:

—Күк кабагы ачылды, ыланнар... Теләк теләп калыгыз...

Ул арада яктылык әкренләп сүнә, тарала башлый... Менә ул өй эченнән шуып чыгып китә, менә ишек алдыннан сытылып урамга чыга, менә урамда күкләр белән тоташа да, эреп тарала... Көмеш нур, Караболак өстендә бераз эленеп тора да, инде мәңгегә хушлашкан кебек, Урал таулары артына китеп югала... Авыл өстенә янадан кап-кара төн килә... Өй эче кинәт кенә караңгыланып кала. Әбисе, капшана-капшана, сукыр лампаны кабызып

жибәрә. Өй эчендәгеләрнен әсәрләнгән йөзләренә аның сүрән яктысы төшә...

—Әнкәй, нәрсә булды бу?—дип сорады Хәбирә, Гөлжиһанны һаман кочагыннан чыгармыйча.

—Күк капусы ачылды, кызым, күк капусы,—дип җавап бирде Нуржамал карчык, монсу гына елмаеп.—Бу—Аллаһның рәхмәте инде... Мондый хәлне гомерендә бер генә күрергә мөмкин, яки бөтенләй күрмәскә... Андый чакта теләк теләргә кирәк, балам... Теләкләребез кабул булсын инде...

—Бәлки Аллаһның безгә бер-бер кисәтүе булгандыр бу,—дип әйтеп куйды Ярулла карт, әкрен генә.—Заман ахырының бер хәбәре... Таһирҗаннан сорарбыз әле, ул белә... Ни булса да, бик зур хикмәт инде бу, балалар... Аллаһның җиһан капкалары ачылды, анда кем нәрсә белән керә...

Өй эче тагы тынып калды. Стенадагы герле сәгатьнең тек-тек итеп йөрүе, өстәлдәге самавыр борынынннан чынаякка тып-тып итеп су тамганы гына ишетелеп торды. Бу гадәти, тыныч авазлар өйдәгеләрне янадан җир тормышына—Караболакка алып кайтты. Алар, җәйге чилләдә көне буе ураза тоткан кешеләр, шушы могҗиза сәбәпле, әле рәтләп ашап та өлгермәгәннәр иде.

—Әйдә, килен, безнен белән утыр, әле син авыз да ачмагансыңдыр?—диде Нуржамал карчык, тиз генә өстәл өстен рәтләп.—Нәбиулла кайтмагандыр әле?

—Юк шул, бүген ерак җәйләүгә китте бит ул,—дип җавап бирде Хәбирә, өстәлгә якынрак килеп.—Бергә авыз ачарбыз дип көтеп торган идем, бу галәмәт башлангач, ничек монда кереп җиткәнемне сизми дә калдым... Дөнья бетә икән дип торам...

Алар шулай сөйләшә-сөйләшә, янадан чәй эчәргә утырдылар. Сүзләре күк капусыннан янадан Караболакка, Караболактан тагы үз хәлләренә кайтып төште. Күңелләре белән дә, телләре белән дә барысы да Нәбиулланың кайтып керүен көтәләр иде.

—Исән генә йөри күрсен инде,—диде Нуржамал карчык, барысының да уйларын сизгәндәй.—Теге елны тәмам котны алдылар бит, утыртып куя яздылар... Ураза икәнен дә бик сиздермәсен иде, төрле кеше бар хәзер авылда...

—Дөньясы әллә нәрсәгә әйләнде шул,—дип сүзгә кушылды Ярулла карт та.—Караболакта гомердә мондый хәл булганы юк иде... Бөтенесе тыңлана, бөтенесе күзәтелә, бөтенесе әләкләнә...

—Авылга чит кешеләр кереп тулды, шуннандыр ул,—дип дәвам итте килене дә.—Мәктәбендә дә әллә кемнәр эшли, хәтта колхоз кырларында да әллә нинди вәкилләр, шикле кешеләр кайнаша... Кеше әйтә, болар барысы да шул Иртәштәге төзелеш белән бәйле икән, ди... Атом бомбасы ясыйлар, имеш, ди бит анда, халык шулай сөйли... Анда эшкә кергән кешене янадан чыгармыйлар икән бит, Караболактан киткәннәр дә кире кайта алмаганнар...

Нуржамал карчык, тиз генә урыныннан торып, тәрәзәләрне томалап килде, ишекне келәсенә элеп куйды.

—Кеше сөйләсә дә, син сөйләмә, килен,—диде ул, пышылдап кына.—Нәбиулла белән нәрсә булганын онытма... Алла сакласын, әнә Якупның гаиләсен нәрсә эшләттеләр бит...

Аларның шулай медер-медер сөйләшкәннәренә Гөлжиһан эреп йокыга китте... Аны әле генә күктән төшкән көмеш нур чорнап-чолгап алды да, үзе белән күтәреп, югарыга алып менеп китте... Шул югарылыктан Гөлжиһан Караболак өстенә карый икән... Аларның авыллары биредән нинди зур булып күренә! Караболак елгасы да әллә кайлардан башланып, әллә кайларга барып чыга икән... Әнә Гөлжиһан әбисе белән җиләк җыя торган урманнар,

чәчәкле болынлыклар, әнә серле Биташ күле... Бирedән күлләр бик күп булып күренә, аларның берсе бетә, икенчесе башлана, барысы да зәп-зәңгәр сулы... Алардан соң—кара урманнар, урманнардан соң биек таулар башлана... Алар шул хәтле күп, шул хәтле биекләр, Гөлҗиһан аларның очлы түбәләренә егылып төшүдән курка башлый һәм кирегә очып китә... Әнә аста, дингез кебек зур күл буенда, бик күп кешеләр кайнаша... Алар шул хәтле күп, Гөлҗиһанның сабантуйда да бу кадәр халык күргәне юк... Анда әллә нинди биек-биек йортлар, шуларның берсендә Гөлҗиһан да яши икән... Ләкин ул инде бәләкәй Гөлҗиһан түгел, әнисе кебек, зур үскән икән, янында нindидер балалар да бар... Бу—Гөлҗиһанның үз балалары икән... Янында кара күзлекле ир-ат та бар, бу—Гөлҗиһанның ире икән... Менә кинәт кенә аларның барысы да юкка чыга, Гөлҗиһан тагы бер ялгызы кала... Нигәдер, аның бөтен җире авырта, шундый нык авырта, сызлануга түзә алмыйча, Гөлҗиһан ыңгырашып куя... Шул арада күктән тагы яктылык иңә һәм Гөлҗиһанны югарыга күтәрә башлый... Инде Гөлҗиһанның бер җире дә авыртмый, аңа инде рәхәт, бик рәхәт... Ул елмаеп, күзләрен ача—аны әтисе күтәреп алган икән бит!

—Бала җайсыз яткан, саташа...

Монысы—әнисенең йомшак тавышы, Гөлҗиһан аны иң биек күктән дә ишетә, таный...

—Әйдә, чыгыйк, әнисе, бала өйдә йокласын...

Монысы—әтисенең көчле тавышы, Гөлҗиһан аны җир астыннан да ишетер, таныр иде...

Менә алар, кечкенә Гөлҗиһанны күтәреп, әкрен генә чыгып китәләр... Бу мизгелләрдә Гөлҗиһаннан да бәхетле, аның әти-әнисеннән дә көчле кеше дөньяда юк... Бу төнге авыл, җәйге йомшак җил, Караболак буеннан ишетелгән бака тавышлары, төнге кошларның сайрап-сайрап җибәрүләре—болар барысы да аларның дөньясы, аларның байлыгы... Аңа хәзергә бары тик алар хуҗа...

Бу—нәни Гөлҗиһанның да яңа дөньясы... Иртәгә ул тагы шул су буена йөгереп төшәр, яшел чирәмнәрдә аунап уйнар, болынында—чәчәк, әрәмәдә—бөрлегән, урманнарда җиләк җыяр... Күк никадәр матур, нурга чумган булса да, Гөлҗиһан анда калмас, барыбер җиренә, Караболагына төшәр, бары тик шунда гына яшәр...

Караболак өстендә инде таң яктысы беленә... Гөлҗиһан әле белми—иртән бу җиргә йолдыз яңгыры явачак... Бу таңда ул әнисе белән сәхәргә дә тора алмас, күктән йолдыз яуганны да күрмәс... Бәлки күрмәве хәерле дә булыр, чөнки күктәге йолдыз җиргә төшкәч, кара ташка әйләнә бит... Моны сабый күңеле барыбер аңламас, үзенә сыйдыра алмас, куркыр... Шуңа күрә ул төшләрендә булса да, кичәге зәңгәр нур дөньясында калсын, җиһан капкаларыннан күккә менсен... Чөнки бу капкалар аның өчен ачылган иде бит... Аның нәселе өчен ачылган иде... Әмма моның шулай икәнлеген ул әле бик күп еллар үткәч кенә аңлар... Ә хәзергә ул, сабый йокысы белән, төшләр күрә-күрә, изрәп йоклый...

## Алтынчы бүлек

1949 елның 11 июнь көнне, иртән 8 тулып 18 минут киткәч, Чиләбе өлкәсенең Коншак районында "йолдыз яңгыры", ягъни, метеорит ява...

Башта, зәңгәр күкне урталай телеп, җир өстенә зур утлы таш—болид атыла... Җиргә житәрәк, бу янар таш, утлы чаткылар чәчә-чәчә, бернича кисәккә таркала... Иң зур метеорит Коншак тирәсендәге Чабаккүлгә атылып барып төшә... Ул шул хәтле зур була ки, аның авырлыгыннан күл өстенә

20 метр биеклектә су баганасы күтәрелә... Соңыннан күпме эзләсәләр дә, күктән төшкән ташны таба алмыйлар—ул төпкә китә... Бар тирә-як күктән яуган вак таш белән тула... Бу күкләрнен, әйтерсен лә, шул рәвешле тагын бер тапкыр кисәтүе була... Әмма кешеләр бу хәбәрне дә анламыйлар, үз башларына, җәннәт кебек җирләргә атом афәтен алып киләләр...

1948 елның 19 июнендә Иртәштә беренче атом реакторы эшли башлый, ул атом бомбасы өчен плутоний әзерли...

1949 елның язында инде беренче совет атом бомбасы әзер була...

1949 елның 29 августында коточкыч бу үлем коралын инде сынарга әзерләнәләр...

Күктән кешеләргә кисәтү арты кисәтү килә, әмма кешеләр аны анламыйлар...

Бөек Ватан сугышыннан соң, бөтен ил хәрабәләргә батып, ачлыктан, юклыктан, ятимлектән газап чигеп ятканда, СССРның барлык акыл көче, акчасы, эшче көчләр Чиләбе өлкәсендәге атом төзелешенә ыргытыла. Бу төзелеш илдә иң мөһим һәм иң яшерен эш була, анын белән турыдан-туры Сталин үзе житәкчелек итә. Кан косып һәм сенерләре шартлап өзелгәнче көчәнеп, радиация өлкәсендә тәжрибәсе булмаганлыктан, корбаннар бирә-бирә, 1949 елның жәенә Иртәштә беренче совет атом бомбасын ясап өлгерәләр. Бу хакта шунда ук Сталинга хәбәр бирелә. Һәм 1949 елның 29 августында, төрки казах далаларында, СССРның беренче атом бомбасы сынала... Моның өчен Мәскәүдән Берия үзе очып килеп житә, атом шәһәреннән Курчатов, Ткаченко һәм башка галимнәр, генераллар жыела...

Бу гаять житди һәм яшерен эшкә казах далаларында ел буе әзерлек бара. Атом бомбасын сынау урыны итеп татарлар күпләп яшәгән Семипалатинский шәһәреннән 120 километр ераклыкта булган буш даланы алалар. Атом-төш коралын урнаштыру өчен 30 метр биеклектәге тимер каланчалар төзелә, бу сынауларны күзәтү өчен жир астында да 30 метр тирәнлектәге базлар казыла... Галимнәр һәм генераллар өчен иң мөһиме—атом бомбасының шартлау нәтижәләре булганлыктан, моны өйрәнү өчен жир өстенә махсус шәһәрчек төзелә. Шартлау буласы жирнең үзәгеннән бер чакырым ераклыкта өч катлы таш йортлар үсеп чыга, тимер юл төзелә, анда ягулык тулы цистерналар урнаштырыла... Шулар янәшәсендә генә тимер-бетон күпер салалар. Атом үзәгеннән чакрым ярым ераклыкта исә дизель-генераторлардан эшли торган электростанция дә төзеп куялар, ике чакырымга житкереп, тимер чыбыклар сузалар... Болар барысы да атом бомбасы шартлагач, аларның ни хәлгә киләсен белү өчен кирәк була...

Ул гына да түгел, төрле урыннарга тимер-бетоннан аэродром мәйданчыклары төзиләр, аларга төрле модельдәге чын самолетлар, танклар, артиллерия, ракета җайланмалары, хәрби корабльләр урнаштыралар, бу тирәне корал белән тутыралар... Болар барысы да атом бомбасының көчен сынау өчен кирәк була... Үзәктән бер чакырым ераклыкта, һәр 500 метр саен, ун "Победа" машинасы тезеп куялар... Сынау мәйданы тирәсенә окоплар, жир асты куышлары һәм юллары ясала. Даланы һәм махсус яшеренү урыннарын сарык, дуңгыз, дөя кебек мал-туар, эт һәм күселәр белән тутыралар... Бу жан ияләре дә атом бомбасының, бигрәк тә радиациянең тәэсирен, көчен өйрәнү өчен кирәк була. Соңыннан дүрт аяклы бу мәхлукларны Караболак халкы алыштырыр, чөнки кул астында тере материал булганда, хөкүмәт аны читтән эзләмәс... Атомны алга таба кешеләр өстендә сынауны күздә тотып, полигонга күп итеп азык-төлек тә кертеп тутырырлар, далада өем-өем колбаса, шоколад, эчемлек һәм төрле ризыклар аунап ятар... Галимнәр соңыннан аларда радиация микъдарын билгеләрләр һәм Иртәш тирәсендә дә шушы тикшеренүләрдән чыгып эш итәрләр...

Шулай итеп, 1949 елның 29 августы, иртәнге сәгать җиде...

Япониядәге атом бомбасы шартлауның коточкыч нәтиҗәләрен яхшы белгән совет разведкасы сынау вакытында үзләрен саклау өчен бөтен чараларын күрә. Алар хәтта амбразуралардан күзәтү мөмкинлегеннән дә баш тарталар, киресенчә, шартлау вакытында җир астындагы тимер бункерларына кереп качалар. Өстә бу мәхшәрне кинога төшерергә махсус җайланмалар куела, бу эшләрне гади хәрбиләр башкара... Ә Берия, Курчатов, Ткаченко һәм башка югары түрәләр, шартлау вакытында стена буеннан читкә китеп, уртага өеләләр... Башкалар өчен үлем әзерләсәләр дә, үзләренең җаны бик кадерле була...

Менә көтелгән вакыт килеп җитә. Хәрбиләр секундларны саныйлар... Менә җир селкенеп, сикереп куя һәм коточкыч көчле шартлау тавышы янгырый. Өстә нидер дөберди, чатырдый, уһылдый, улый-үкерә башлый... Аннан барысы да кинәт тынып кала... Бераз вакыт үткәч, махсус җайланмалар киеп, барысы да өскә чыга. Ерактa, атом полигоны булган урында, күккә багана кебек утлы гөмбә күтәрелгәнне күреп, алар барысын да анлый... Димәк, сынау уңышлы үткән! Күккә, нәкъ Хиросима һәм Нагасакидагы кебек, кызгылт-кара атом гөмбәсе күтәрелә... Тирә-якта җансыз табигать җәйрәп ята... Алар шушы нәтиҗәгә ирешү өчен ничә еллар баш күтәрми эшләде бит—таулар актардылар, урманнар кистеләр, сазлыкларны киптерделәр, юк җирдә шәһәрләр салдылар, җир астында заводлар төзеделәр, ураннан плутонийны аерып алып, атом бомбасы ясарга өйрәнделәр! Һәм ясадылар! Аларның күз алдында шуның нәтиҗәсе! СССР тагы Американың борынына сукты, аның кулында хәзер атом бомбасы һәм ул бөтен капиталистик дөньяны тезләндерәчәк! Дөньяга алар хуҗа булачак! Чиновник-генераллар бу мизгелдә әнә шул хакта уйлыйлар иде...

Икенче көнне генераллар һәм атомчы галимнәр, махсус киемнәр киеп, сынау булган урынны карарга киттеләр. Алар күргән күренеш котны алырлык иде... Атом шартлавы көченнән, өч катлы таш йортлар шырпы тартмасы кебек ишелеп төшкән, "Победа" машиналарының тимеренә хәтле янып беткән... Ялкынлы атом дулкыны тимер юлларны һәм бетон күперләрне бау кебек бәйләп, 30 метр читкә алып бәргән... Вагоннар һәм төрле җайланмалар, изелеп-сытылып, дала буйлап сибеп ташланган... Танклар әйләнеп капланган, пушкалар янган тимер өеменә әйләнгән... Алар янында, аякларын сузып, этләр, сарыклар аунап ята, аларның эчәкләре актарылып чыккан, күзләре агып ята... Үлгән дөяләрнең өсләреннән тиреләре кубып төшкән... Бар тирә-як үле һәм үлек белән тулган. Әйе, бу төрки далаларда 20 мең тонна тротил көченә ия булган беренче совет атом бомбасы шартлатылган иде... Һәм бу үлем коралы адәм балаларын юк итү өчен эшләнгән иде...

СССР Американы узып китәргә омтылып, котырып корал җитештерергә тотынды. 1950 елның мартында Иртәш күле буендагы җир асты заводларында икенче атом реакторы эшкә җибәрелде. 1951 елның апрелендә—өченче реактор, шул елның октябрендә—дүртенче, декабрь аенда бишенче атом казаны эшли башлады. Караболак, Мәшәләк, Теча-Дениз, Синара елгаларын, Иртәш, Әбиташ, Кояш, Карачай, Кызылташ, Олыагач күлләрен, урман-суларны, йөзләгән татар авылларын атом сөреме каплап китте, тирә-якка күзгә күренмәс үлем—радиация тарала башлады...

Атом реакторлары атлаган саен ватылды, җиһазлар шартлады, куркыныч атом калдыклары суга, һавага таралды, туфракка сеңде... Атом цехларында эшләүчеләр, зур дәрәҗәдә радиация алып, мизгел эчендә сукырайдылар, аларның каннары агуланды, үпкәләре янып чыкты, тән-тиреләре терелэй чери башлады... Кешеләр арасында моңа кадәр күренмәгән яна авыру—

яман шеш килеп чыкты, ул халыкны чалгы белән еккан кебек кыра башлады...

Бу зәхмәтләр, жир астына яшерелгән тимер чыбыклы шәһәрләрне дә бәреп чыгып, тирә-юньгә, авылларга, шәһәрләргә таралды...

Гөлжиһаннар авылы бу үлем юлынын нәкъ өстендә ята иде...

## Җиденче бүлек

1957 елнын 29 сентябре кояшлы, жылы якшәмбе көне иде...

Караболак авылында якшәмбене "урыс атнасы" дип йөртәләр, чөнки күрше урыс авылында бу көнне берни эшләмиләр, бәйрәм итәләр. Менә бүген дә Урыс Караболагы авылы кырына эшкә Татар Караболагы халкын жыеп алып киттеләр, ял көне булуга карамастан, хәтта мәктәп балаларын да кырга чыгардылар. Менә хәзер баласы-чагасы, яше-карты—барысы да колхоз кырында, бәрәнге, чөгендер, кишер, кәбестә ала... Караболак татарларын эш белән куркытып булмый, эш үзе алардан курка, тагы берничә көннән бу кырларнын ялт итеп каласын бөтенесе дә яхшы белә...

Унбер яшьлек Гөлжиһан да халык арасында кайнаша. Ул үзенен гаять терелеге, үткенлеге, янып торган сирәк матурлыгы белән барысыннан да аерылып тора. Гөлжиһанга барысы да кызык, ул барысын да булдыра, кайда куйсан да, эшен ялт итеп эшләп ташлый, шаянлыгы, чаялыгы белән беркемгә дә тынгылык бирми. Анын ике бите һәрвакыт ут булып янып тора, зур яшькелт күзләре тирә-якка нур чәчә, кырны янгыратып көлгәндә, анын кынгырау тавышыннан танып, әти-әнисе дә ялт борылып карый... Аны бөтен кеше ярата—өйдә дә, авылда да, мәктәптә дә, кырда да... Яратуларын Гөлжиһан үзе дә белә, шуна күрә бераз үсенеп тә китә, иркәләнеп, арттырыбрак та жибәрә... Әнә хәзер дә әтисенен атлы арбасына менеп баскан да, үз белдеге белән кырнын бер башыннан икенчесенә су таратып йөри... Бригадир Нәбиулла кызы булгангамы, Гөлжиһан үзе бик сөйкемле бала булганы өченме, әллә чынлап та бик эчәселәре килгәнгәме, аны кем янына килсә дә, шатланып каршы алалар, рәхмәт әйтеп озаталар... Инде картаеп килгән туры айгыр да Гөлжиһанга берсүзсез буйсына, ул дилбегәне кайсы якка тартса, тыныч кына шунда борыла... Заманында ирләр дә тынлата алмаган туры айгырны Гөлжиһан песи баласы кебек кенә уйнатып йөртә...

Тузанлы бәрәнге буразнасына кереп баткан классташлары аннан бераз көнләшәләр дә, әмма ачулары килми, чөнки Гөлжиһанга барыбер ачуланып булмый. Аны бары тик яратып кына була... Ул алар арасында ин башлы бала, бишенче класска житеп, әле анын хәтта бер тапкыр "дүртле" билгесе алганы да юк, гел "бишле"... Ул класста ин матур кыз, юк, мәктәптә, хәтта Караболакта ин матур кыз, бөтен кеше шулай ди... Ул үз яшенә караганда күпкә гәүдәле, сылу, күз явын алырлык бәхетле бала... Анын белән дуслашырга теләүчеләр бик күп, әмма ул барысына да тигез карый, тик класстагы ин оялчан, сүзсез кыз Рәшидәне генә аеруча якын итә, кызгана... Чөнки Рәшидә бик кыюсыз, яшереп кенә шигырьләр яза, шунамы, малайлар аннан көлә, рәнжетә, ә Гөлжиһан аны ярсып яклый... Хәзер дә әнә, атын-арбасын онытып, Рәшидәне бәрәнге арасына төртеп еккан малайлар белән пыр тузып сугышып ята... Малайлар, атаман кызга буйсынып, берәм-берәм качу ягын карыйлар...

Ә Гөлжиһаннын бүген тизрәк өйгә кайтасы килә. Чөнки бүген аларда кунак бар! Аларга, улы белән бергә, Якуп абыйлар килде... Әтисенен әйтүе буенча, ун ел элек аларны авылдан Урал арьягына сөргән булганнар, хәзер менә нигез карарга кайтканнар... Гөлжиһанны бигрәк тә анын Фәргать исемле улы гажәпләндерде—ул бөтенләй Караболак малайларына охшамаган иде. Ул инде

малай да түгел—җиткән егет кебек, үзе гәүдәле, үзе әллә нинди матур, сөйкемле... Үзе гел Гөлҗиһанга карап утыра... “Хәтерлисеңме, мин сине бәләкәй вакытта күтәреп йөрткән идем бит?”—ди... Кызык малай инде бу Фәргать, ул вакытны кайдан хәтерләсен инде Гөлҗиһан? Ул үзенең тормышын күк капусы ачылган көннән генә хәтерли... Бөтен Караболакны яктырткан зәңгәр нурны хәтерли, идән ярыгындагы сыңар мәрҗән хәтеренә уелып калган... Әбисенең кулындагы чынаяк калтыравын, бабасының сузып-сузып намаз укуын бүген дә ишетә кебек... “Күк кабагы ачылды, кызым, теләк телә...” Һәм үзенең теләгән бик яхшы хәтерли Гөлҗиһан, ул әти-әнисенең, әби-бабасының, Караболакның гел-гел булуын, мәңге булуын теләде... Ул вакытта Гөлҗиһан Фәргать дигән күрше малаен белми дә иде әле...

Аннан Гөлҗиһан бик сәер төш күрүен хәтерли—ул Караболак өстеннән, Иртәш буйларыннан очып йөри икән... Аста—зур-зур таш йортлар, бик күп кешеләр һәм шулар арасында Гөлҗиһан үзе дә... Әмма ул инде зур үскән, әнисе кебек булган... Аның янында балалары да бар икән һәм ниндидер бер чит ир-ат... Тукта, аның йөзен Гөлҗиһан инде кайдадыр күргән иде бит! Бәй, бу бит Урал аръягыннан кунакка килгән күрше егете Фәргать бит! Тик Гөлҗиһанның сабыйчак төшендә ул, нигәдер, кап-кара күзлектән иде...

Шушылар исенә төшкәч, Гөлҗиһан арбасыннан егылып кала язды. Нишләп ул вакытта аның төшенә керде икән бу күрше абый? Бәлки бәләкәй чагында кулларына күтәреп йөргән өчендер? Әнисенең сөйләве буенча, ул бит Гөлҗиһанны үз туганын караган кебек караган, алардан чыгып та тормаган... Менә шуңа күрә төшенә дә аның белән янәшә кергәндер... Боларны уйлагач, Гөлҗиһанның болай да мәрҗән кебек битләре ут булып яна башлады. Ул нигәдер оялып китте, аның бу халәтен кемдер читтән күзәтеп торадыр төсле тоелды. Шул уңайсыз хәленнән котылырга теләгәндәй, кыз арбага аягүрә торып басты, дилбегәсен баш очында уйнатып, туры айгырны куа башлады. Карт атка да дәрт кергәндәй булды, ул буш кыр буйлап тузан туздырып чабып китте. Гөлҗиһан салкын су бидонын тез арасына кысып тотты, су, чайпалып, аның тузанлы аякларын чылатты... Күзгә йомшак, җылы җил аның уттай янган битләреннән сыйпап үтте, авыл баласының тыгыз тәнен, ихлас җанын иркәләде... Гөлҗиһанга бу мизгелләрдә бик-бик рәхәт иде, бу кырлар, бу күлләр, бу авыл, бу дөнья аныкы, бары тик аныкы гына иде...

Әнә, кыр башында, һаман нидер үлчәп, һаман нидер оештырып, әтисе йөри... Гөлҗиһан янына килмәсә дә, ул күз кырые белән генә аны гел күзәтә, бәла-казадан саклый кебек... Әнә, хатын-кызлар арасында аның әнисе бәрәңге чүпләп йөри, ул да бу якка борылып, Гөлҗиһанга карап-карап ала... Ул да күңеле белән Гөлҗиһанны бәла-казалардан саклый... Әнә авылның әүлиясе Таһир бабай, Караболакта Гөлҗиһанны иң нык яратучы кеше... Ул—Ярулла карттайның энесе, авылның иң абруйлы кешесе, халыкча итеп әйткәндә, изгесе... Ул үзе тракторда эшли, әмма гел намазын укый, хәтта кырда да аңа вакыт таба, Гөлҗиһанның үзенең күргәне бар... Моннан берничә ел элек Таһир бабай мәрткә киткән булган. Бу хәл зиратта җеназа укыганнан соң булган. Караболак гадәте буенча, кабер саклап калган Таһир бабайны икенче көнне чак табып алалар... Ул аңсыз яткан була, аны үлгән дип беләләр, күмәргә хәзерләнәләр, ә ул мәрткә генә киткән икән... Аңына килгәч, Таһир бабай кеше белмәгән телдә сөйли башлый, картларның әйтүенчә, бу—гарәп теле була. Шуннан Таһир бабай Коръән ятлап уяна, “Миңа, мәрткә киткәндә, җәннәт белән җәһәннәмне күрсәттеләр, тик барысын да сөйләмәскә куштылар”, ди... Шуңа күрә аны авылда “әүлия” дип йөртәләр... Таһир бабай авылда мулла да булып йөри, гаетләр укыта,

совет власте аның белән бернишли алмый, ул: "Мина тегендә шулай куштылар",—дип кенә җавап бирә... Таһир бабайны тагы әллә нәрсәләр белә, диләр, тик ул үзе бу турыда сөйләми... "Чиктән узарга ярамый",—ди... Ә Гөлжиһанны бик ярата, ана бик күп нәрсәләр сөйли, яшереп, догаларга хәтле өйрәтә... "Синең хәтерең бик яхшы, кызым, өйрән, болар әле барысы да кирәк булачак сина",—ди... Гөлжиһан хәтта намаз сүрәләренә хәтле өйрәнеп килә инде, Таһир бабай аны Коръән укырга да өйрәтергә булды әле...

Әмма Гөлжиһан өчен ин кызыгы—Таһир бабай сөйләгән Караболак тарихы булды. Мәктәптә аларга бөтенләй башка төрле аңлатканнар иде. Дөресрәге, аларга мәктәптә татарлар турында да, Караболак тарихы турында да берни сөйләмиләр, гел революция, Ватан сугышы, СССР тарихын гына сөйлиләр... Гөлжиһан аларын да бик яхшы белә, әмма анын Караболак турында, татарлар турында күбрәк беләсе килә бит! Ә тарих китапларында бу хакта берни язылмаган... Укытучылар да сөйләми... Әллә белмиме? Ә Таһир бабасы әллә нәрсәләр белә булып чыкты, болар хакында Гөлжиһанның беркемнән дә ишеткәне булмаган иде, хәтта әтисеннән дә...

Быел җәй Таһир бабай аны Биташ күле буена алып барды. Олылар бу күлне Аллакүл, ди, балалар Әбиташ яки Биташ дип кенә җибәрә... Гөлжиһанның монда элек тә булганы бар иде, алар монда балалар белән уйнарга бик яраталар. Тау куышының иң аргы башына кереп китәләр дә, беркем таба алмаслык булып качалар... Аннан тау башыннан күлгә сикерәләр, куллары белән су төбендәге салкын ләмгә хәтле төшеп җитәләр... Су өстенә чыккач, учларындагы ул ләм зәңгәргә әйләнә, кулларын җылытып тора башлый... Яр буенда да шундый ук зәңгәр ләм тулып ята, авыл халкы аны өшкереп, тәненә сөртә, шунын белән дәвалана... Әле тау куышыннан салкын чишмә агып чыга, анын суы тешләрне камаштыра, әмма тундырмый... Караболак халкы аны да, шифалы, ди, картлар исә өшкереп эчәләр... Таһир бабай биредән гел шуларны ташый, кайвакытта Гөлжиһан да аңа ияреп бара...

—Бабай, нигә бу күлне Аллакүл дип тә, Әбиташ дип тә атыйлар, Биташ бит инде ул?—дип сорады Гөлжиһан бу юлы Таһир бабасыннан.

—Аның сере бик еракларда инде, кызым, Нух пәйгамбәр заманнарына ук барып тоташа,—дип башлады сүзен Таһир карт.—Әнә мәгарә каршында зур ташны күрәсенме? Туфаннан сон Алып бабай шунда басып намаз укыган, дип сөйлиләр иде безгә...

—Ә безгә укытучы: "Туфан—әкият ул",—диде...

—Дөньяны су басу турында Коръәндә бар, кызым,—диде Таһир карт, сабыр гына.—Ә Коръән әкият була алмый... Дөньяны су басканнан сон, Нух пәйгамбәрнең нәселе генә исән кала... Безнең бабайларның сөйләүләре буенча, алар Урал тауларында Туфан үткәнне көтәләр... Аннан аска төшәләр... Безнең авыл ул урыннардан ерак түгел, әнә, Урал таулары күренеп кенә тора бит... Алып бабай менә шул ташка басып, исән калганы өчен Аллага рәхмәт әйткән, намаз укыган, диләр, шуна күрә күлнең исеме дә башта Аллакүл булган... Алып бабай шушында яшәп калган, авылга нигез салган, аның кабере дә, әнә, моннан биек булып күренеп тора, сезгә аны курган дип өйрәтәләр инде...

—Ә нигә соңыннан Әбиташ дип атала башлаган сон, алайса?

—Кешеләр акрынлап Алланы онытканнар, кызым, менә хәзерге кебек... Күл тирәли унике сын ясап куеп, шулар ярдәм итә, дип белеп, аларга табына башлаганнар...

—Хәзер Ленин бабайга һәйкәл куйган кебекме?—дип сорады Гөлжиһан, шунда ук чагыштырып карап.

Таһир карт ерак оныгының бик зиһенле, хикмәтле бала икәнлеген белә иде, бу чагыштыруны бик дөрес дип тапты. Әмма бу баланың әле шушы дөньяда, шушы кешеләр арасында яшисе бар, һәр уйлаганны ачып салмаска да өйрәнергә тиеш ул...

—Шулай, кызым,—диде ул.—Әмма бу хакта син бүтән кешегә әйтмә, яме?.. Кайда калдым әле мин?

—Нигә Әбиташ, аннан Биташ булган? Шуны сөйлисе иден, бабай...

—Әйе... Монысын халык сөйли инде... Әби дә, Би дә бер үк тамырдан чыккан—"кайнана" дигәнне аңлатырга мөмкин... Бер йомшак килен белән усал кайнана килешә алмаганнар да, кайнана киленен "Ташка әйләнсен",—дип каргаган, имеш... Һәм үзе шул минутта ук ташка әйләнгән, ә килененә бернәрсә булмаган... Кешене каргарга ярамый, кызым, ул каргыш үзеңә төшәргә мөмкин икән... Менә бу таш сыннар шул хакта да сөйлиләр... Бу күлләр турында халык арасында элек башка төрле сүзләр дә йөри иде... Имеш, Туфан таралганнан соң Уралтаудан төшкән Алып кешеләр бу куе урманлы җирләрдә бер-берләрен югалтканнар... Берсе—Иртәшкә, икенчесе—Әбиташка килеп чыкканнар, ягъни, бу күлләрне үз исемнәре белән атап йөртә башлаганнар...

—Алар бер-берләрен таба алганнармы соң?

—Юк, кызым, алар бер-берләрен таба алмаганнар... Аллаһы Тәгаләдән хәбәр килгән, шушы күлләрнең сулары яңадан бергә кушылгач кына сез күрешә аласыз, дип... Бу—заман ахырында буласы икән... Һәм аңа инде озак калмаган...

Гөлҗиһанга ул вакытта бик куркыныч булып киткән иде... Чөнки Таһир бабай да бик шомлы сөйли, күл буендагы җимерек сыннар да аңа бөтенләй башкача күренә башладылар... Теге күрешә алмаган Алып кешеләр дә бик кызганыч...

—Алар күрешә алмагач, монда кемнәр яшәгән соң, бабай?—дип сорады ул, уйларының очына чыга алмыйча.

—Әй, кызым, кемнәр генә яшәмәгән бу тирәләрдә,—дип җавап бирде Таһир карт, бер ерактагы Урал тауларына, бер Караболак ягына карап.—Монда иң борынгы кешеләр, Алып бабалар, ханнар-патшалар яшәгән, кызым... Мәрткә киткәндә миңа аларның барысын да күрсәттеләр... Мин Караболакны уч төбемдәге кебек күрдем—үткәнен дә, киләчәген дә...

—Таһир бабай, миңа шуларны сөйлә әле! Сөйлә, сөйлә?!—дип аңа ялына башлады Гөлҗиһан, сулышына кабынып.

—Боларны сиңа сөйләргә бераз иртәрәк әле, кызым,—диде Таһир карт, Гөлҗиһанның шомырт чәчләреннән сыйпап.—Бераз гына үс әле, сөйләрмен, иншаллаһ!

Гөлҗиһанның, авызын турсайтып, үпкәләп утыруын күреп, Таһир карт кызганды, ахры:

—Менә мин сиңа хәзер шунда ишетеп кайткан бер шигырьне сөйлим алайса,—диде ул.—Бәлки бу шигырь дә түгелдер, әмма анда барысы менә шигырь белән сөйли... Я, тыңла...

Әй син, милләтнең сылу баласы!
Дөнья тетрәткән Алып Хан бабасы!
Ханынны—барча гаскәреңне
Дошман узып китте...
Куәтле, шәүкәтле чакларың
кайларга китте?
Җыелыгыз, түгелгән канлы күз яшьләр...
Атлагыз алга! Күрсен көндәшләр...

Чәч гайрәт! Баһадир баһалы Жан Син!
Фикерен—бер мәмләкәт,
син ана жансын...
Гайрәтле бер милләт житәкчесе бит без,
Ялкынлы милләтнең аркасы бит без!
Яшәде дөньяда баһадир бабаң,
Диде ул: якты тормышта яшәсен балам!
Яшә син дөньяда, ал Коръән кулга,
Шул—тугры юл,
карама унга да сулга!
Дөньяны гизеп йөр, бар алга таба!
Гиздe бит дөньяны һәм Чыңгыз бабаң...
Арма син, Алып Хан нәселе, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Гөлжиһан бу шигырьне шунда ук күңеленә алды. Ул аны, дәфтәр битенә күчереп язып, Казанда һәм Уфада чыга торган татарча газеталарга да җибәреп карады, әмма алардан: "Бу әле шигырь булып бетмәгән", дигән хәбәр генә алды. Һәм быел, 1-нче сентябрь көнне, бөтен мәктәп тантаналы рәткә тезелгәч, Гөлжиһан Караболакны яңгыратып, шушы шигырьне сөйләп җибәрде. Ул партиягә, совет властена рәхмәт укыган шигырь сөйләргә тиеш иде. Гөлжиһан тотты да Таһир бабасының шигырен сөйләде. Әй, мәхшәр башланды мәктәп ишегалдында! Укытучыларны умарта корты чактымыни—гөж киләләр, арлы-бирле чабулыйлар, Гөлжиһанны ничек туктатырга белмиләр... Туктатырсың Алып Хан нәселе Нәбиулла кызын бер сөйли башлагач! Әле ярый районнан килгән вәкил татарча аңламый икән, ничек тә йолып калдылар Гөлжиһанның Коръән турындагы, Хан бабалар турындагы шигырен... Мондый саташуны башка бер җирдә дә укымаска куштылар, хәтта әти-әнисен дә кисәтеп маташтылар...

Шушылар исенә төшкәч, Гөлжиһанның, бөтен Караболак кырын яңгыратып, тагы шул шигырьне укыйсы килеп китте. Бик нык охшады ул аңа, аның бөтен күзәнәкләрен уятты, җанын уятты... Бу шигырь ана үзе турында язылган кебек тоелды, чөнки алар да бит Алып Ханнар нәселе кушаматын йөртәләр, фамилияләре дә—Хановлар... Бу шигырьне әле яшь вакытта ук Таһир бабай үзе язган дип тә әйтәләр, чөнки революциягә хәтле ул бераз Казанда укып йөргән...

Гөлжиһан, арбасына басып, күзләре белән Таһир бабасын эзли башлады. Әнә бит ул, ирләр белән бергә, бәрәңге тутырылган капчыкларны арбаларга төйи... Шушы шигырьне сөйли-сөйли, Гөлжиһан хәзер аның янына барып җитәчәк, инде кайтыр вакыт та якынлаша, алар авылга бергә кайтып китәчәкләр... Ә өйдә кунаклар көтә, әбисе бүген тавык суйгандыр, канатын, һичшиксез, Гөлжиһанга бирәчәкләр. Ул бит өйдән очып китәсе кыз бала, әбисе гел шулай ди... Ә кайда очар Гөлжиһан—ул аны үзе дә белми, хәзергә аның Караболактан бер җиргә дә китәсе килми. Ул хәзергә менә шушы Караболак кыры буйлап оча, кояшка, җилгә таба оча!

Әй син, милләтнең сылу баласы!
Дөнья тетрәткән Алып Хан бабасы!
Арма син, Алып Хан нәселе, дошманнан калма!
Алга бас, татар, алга бас, алга!

Башындагы ак яулыгын байрак итеп кулына тотып, Гөлжиһан Караболак кыры буйлап оча... Аңа таба зәңгәр күк оча, кояш үзе оча, кешеләр оча...

Кинәт шунда әллә нәрсә була... Туры айгыр очып барган жиреннән чүгеп куя да, дөньяны янгыраткан гөрселдәү авазыннан шашып, кыр буйлап чабып китә. Су бидоны жиргә тәгәрәп барып төшә, аның артыннан Гөлжиһан үзе дә жиргә тәгәри... Шул вакытта Иртәш ягында тагы көчле гөрселдәү ишетелә, аяк астындагы жир селкенеп, сикереп куя... Берни анламыйча калган Гөлжиһан аягына басарга тырыша, әмма әллә жирнең селкенүеннән, әллә башы әйләнүдән, тезләренә генә калка ала... Ул аяк астындагы жирнең гүләп улаганын ишетә... Гөлжиһан гажәпләнеп тирә-ягына карый—башкалар да кайсы чүгәләгән, кайсы тезләнгән, барысы да Иртәш ягындагы күккә төбәлгән... Ә анда—ике кояш... Кан кебек кызыл кояш... Юк, бу—кояш түгел бит, бу—гөмбә кебек утлы багана—сузылып Иртәш өстенә күтәрелә... Гөлжиһан Караболак өстендә, Уралтау буйларында көпә-көндез ажаган уйнаганын күрде, жансыз зәңгәр нурлар бөтен тирә-якка шомлы хәбәр тараталар иде...

Шул вакыт салкын, зәһәр жил исә башлады, ул Иртәш өстендәге утлы баганаңы йолыккалап, Караболак ягына таба куды... Авыл өстенә, кырда эшләгән балалар һәм олылар өстенә үлем болыты килгәнлеген әле беркем дә белми иде... Ул арада күк йөзе караңгыланып китте, Иртәш ягыннан искән жил борынга сасы йомырка исен китереп бәрде. Кем—яулык, кем күлмәк итәге белән битен-йөзен каплый башлады, кайбер балалар, бу искә чыдый алмыйча, укшып ук жибәрделәр...

Гөлжиһанның да күңеле болгана башлады, күз аллары караңгыланып китте, башы чатнап-чатнап авыртырга тотынды. Олыларның да рәте юк иде, ахры, алар башлаган эшне тәмамларга ашыктылар. Капчыкларга тутырган бәрәңгеләрне авылга озаттылар, көшелдәгеләренен өстен капладылар да, кичкә таба кайтырга кузгалдылар. Барысының да телендә Иртәш ягында ишетелгән көчле шартлау һәм күккә күтәрелгән утлы багана иде... Ул арада кыр өстенә әллә нинди сәер томан таралды, ул авыраеп, авыл һәм агачлар өстенә, елга-суларга төшеп утырды, кешеләргә кагылып үтте... Кешеләр моның үлем томаны икәнлеген белмиләр иде әле...

Гөлжиһан исә бүген авылга әтисенең атында кайтты. Әле генә ут кебек очынып йөргән баланың кинәт кенә сүрелеп, боегып калуын күргәч, әтисе үзе килеп, аны янына утыртты. Авырлы әнисенең дә кәефе юк иде, ул гел алъяпкычына капланып, укшыды, йөз-битенә тимгел-тимгел таплар чыкты... Алай да аның бөтен игътибары кызы Гөлжиһанда иде, ул аны алдына яткырып, гел башын тотып кайтты. Ә Гөлжиһанның башы, дөньяда әле беркайчан булмаганча, чатнап-чатнап авырта иде... Юк, аның башы гына түгел, колаклары да шаулап тора, күзләре дә атылып чыгарлык булып сызлый... Әмма ул еларга ояла, авыртуга чыдый алмый, әнисенең алъяпкычын тешләре белән кыса, уртларыннан хәтта кан чәчрәп чыга... Аннан ул әллә йокыга китә, әллә аңын жуя... Шул хәлендә, саташа-саташа, авылга кайтып житә... Иртән өйдән шаян тай кебек чыгып чапкан оныгының ансыз хәлдә әтисе кулында кайтып керүен күреп, Нуржамал карчык өнсез кала, баланы тизрәк үзләренә алып кереп сала... Гөлжиһан өчен яшәү белән үлем арасында көрәш башлана...

Бала берничә көн тоташ ут эчендә ята...

Аның авыз-борынынннан, хәтта колакларыннан шаулап кан китә, башындагы чәчләре коела, туктаусыз эче китә... Авылда врач юк, булса да, ул барысын да карап өлгермәс иде, чөнки һәр йортта диярлек шушы хәл... Бигрәк тә балалар интегә, хәтта күзләре сукырайганнар да бар, барысының да авыз-борынынннан кан килә, чәчләре коела... Кайберләре, баш авыртуга чыдый алмыйча, идәндә аунап-тәгәрәп йөриләр... Гомерендә мондый хәлне күрмәгән авыл халкы курка калды, чөнки олылар арасында да баш

авыртулар, канлы эч китүләр күбәйде... Һәркем үзе белгәнчә дәвалана, кем өшкереп, Биташ чишмәсе суын эчә, кем мунча ягып керә, кем—бал белән, кем төрле үләннәр белән сихәт табарга тырыша... Ашыгыч рәвештә Коншак, Чиләбе больницаларына барып ятучылар, кинәт кенә үлеп китүчеләр дә күренә башлады... Караболак халкы авыл белән чирләп китүнең сәбәпләрен белми, ә белгән кешеләр дәшми... Чөнки болар барысы да атом белән бәйләнгән, дәүләт сере булып тора иде... Әмма Караболак өчен бу әле зур афәтнең башы гына, бу атом аждаһасы авыл халкын тәмам кырып бетермичә туктамаячак иде... Тик Караболак халкы бу турыда да берни белми иде...

Таһир бабасының догалары, карттай-нәнәенең теләкләре, инәй-атаеның өзелеп яратуы Гөлҗиһанны бу юлы үлем тырнагыннан алып кала... Ул үзенә билгеләнгән гомерне яшәп бетерергә, атом казаннарында кайнап та, исән калырга, атом аждаһасына каршы бер ялгызы тинсез көрәшкә күтәрелергә, кешеләрне бу бәладән кисәтеп өлгерергә тиеш була...

## Сигезенче бүлек

Ул көнне Иртәш буйларында да гаҗәеп матур көзге көн иде...

Сталин үлгәч, атом бомбасы ясый торган шәһәр дә бераз иркенәеп, төрмә чикләреннән чыгып яши башлаган чак иде... Дөрес, ул әле һаман "ябык зона" дип йөртелә, аны һаман коралды сакчылар саклый, дәүләт серен ачкан өчен һаман да үлем җәзасы—трибунал көтә... Әмма хәзер шәһәрдә хакимият бар, шәһәрнең 1954 елда хөкүмәт биргән чын исеме бар, аны хәзер рәсми кәгазьләрдә Озерский дип йөртәләр... Әмма халык өчен ул һаман—"Сороковка", бу—почта бүлегенең адресы, һәм шәһәргә хатлар һаман шулай языла... Сталин үлгәч, атом атаманы Берия атып үтерелгәч, биредәге Ткаченколар да койрыкларын бераз кыстылар, шәһәр бугазындагы тимер кулларын ычкындыра төштеләр... 1954 елда Озерский-Иртәштә беренче тапкыр сайлаулар булып үтте, элек, кеше санын ачмас өчен, шул ук Ткаченколар, атом шәһәрендә сайлаулар да уздырмыйлар иде... Нәрсә анда сайлаулар—биредә хәтта бәйрәм демонстрацияләре уздыру да тыелган иде, имеш, дошман, Америка очучылары, күктән карап, биредә ничә кеше яшәгәнен белә һәм аларның нәрсә ясаганнарын чамалый! Ә биредә атом бомбасы ясап яталар...

Һәм Ткаченконың "режимная службасы", дәүләт серен саклау өчен, ин кыргый алымнарга хәтле барып җитә... Биредә бөтен нәрсә, бигрәк тә химик элементлар, серле шифр белән генә йөртелә, әйтик, уран—"А-9", водород—"17" һәм башка шундый яшерен билгеләр... Бөтен эш кәгазьләрендә плутонийны—"продукт", реакторны—"аппарат", ә радиацияне—"грязь", ягъни, пычрак дип атыйлар... Хезмәткәрләргә болар хакында бер-берләре белән фикер алышмаска кушыла, алар хәтта бер-берләренең эш бүлмәләренә дә керергә тиеш булмыйлар... Плутоний ясый торган цехтан чыкканда, Ткаченко таләбе буенча кешеләрне шәп-шәрә калдырып чишендерәләр, чәч араларын җентекләп капшыйлар, хатын-кызларның толымнарын сүттерәләр, колак эчләрен актаралар, бармак араларын тикшерәләр... Дәүләт сере булган плутонийны алып чыгулары мөмкин бит! Бу цехларга бары тик җир асты юлы белән генә үтеп була, атом аждаһасы дистәләгән чакрымнарга, җир астына җәелеп яткан... Ә өстә—мең еллык татар авыллары, зәңгәр сулы күлләр, шифалы чишмәләр, чәчәкле болыннар... Өстә—Караболак, Гөлҗиһаннар авылы, гасырлар буе үз көннәре белән көн итеп яткан татарлар... Алып Ханнар нәселе, пәйгамбәрләр, әүлияләр токымы...

Сталин үлгәч, атом шәһәре бераз җиңел сулап куя... Иң мөһиме—кешеләргә бу тимер читлектән тышка чыгарга рөхсәт ителә. Халык ял итәргә,

дәваланырга, туганнарын күмәргә шәһәрдән читкә чыгарга рөхсәт ала, ә читләргә монда керү барыбер тыелган килеш кала... Шәһәрдә кинотеатрлар, больницалар, мәктәпләр ачыла, зур-зур таш йортлар үсеп чыга. 1957 елның 29 сентябренә биредә инде 33 мең кеше яши. Атом шәһәрендә шулай ук иң пычрак, радиацияле урыннарда тоткыннар эшләгәнлеге һәм хәрби полклар торганлыгы да билгеле. Шәһәр үзенең зур фаҗигасенә менә шундый хәлдә килеп керә. Ял көн булганлыктан, кем—йорт тирәсендә, кем—күл буенда була, күпләр "Химик" стадионындагы футбол ярышын карарга китәләр... Халык ялда булса да, атом реакторлары бертуктамый эшләп тора, атом комбинаты, алны-ялны белмичә, үлем коралы җитештерә... Әмма чит илләрдәге дошманнар өчен әзерләнгән үлем СССРның үз халкына каршы юнәлә—1957 елның 29 сентябрендә Иртәш күле буйларын атом шартлавы тетрәтә... Соңыннан билгеле булганча, бу шартлау Чернобыльнекенә караганда ике йөз тапкыр көчлерәк була һәм дөньяга 200 миллион кюри атом калдыклары ыргытыла, көчле радиация тарала... Әмма бу хакта халыкка бернәрсә дә әйтмиләр, Иртәш фаҗигасенең ачылуы өчен әле тагы 40 ел вакыт кирәк була, бу вакытта инде миллионлаган кеше атом нурланышы алган, меңләгән кеше көчле радиациядән, рактан үлеп беткән була...

Әйе, кояшлы матур көзге көн була ул 1957 елның 29 сентябре...

Көндезге дүрт тулып, бишенчеләрдә, кинәт кенә бөтен дөньяны бик көчле шартлау авазы тетрәтә. Шартлау атом реакторлары ягыннан ишетелә һәм шунда ук күккә утлы-ялкынлы төтен баганасы күтәрелә... Күк йөзе кинәт кенә караңгылана, атомчылар шәһәре көпә-көндез дөм караңгылыкта кала... Күңелләргә шом салып, шәһәр өстендә атом аҗаганы уйный башлый... Аны күргән кешеләр шундук сукыраеп калалар...

Бу гайре табигый хәлдән кошлар сайрауларыннан туктый, этләр, киресенчә, караңгы күккә карап улый башлыйлар... Бернәрсә аңламаган, кая барып бәрелергә белмәгән кешеләр өстенә кисәк-кисәк радиоактив калдыклар төшәргә тотына... Алар өстенә үлем яңгыры ява, әмма моның шулай икәнлеген әле күпләр белми...

Шартлау тавышы шәһәрдәге бөтен тәрәзәләрне коеп төшерә. Шәһәр өстенә таралып барган куе соры атом болытыннан кешеләр кая качарга белмиләр. Моның нәрсә белән бетәсен бераз чамалаганнар тизрәк йортларына кереп бикләнәләр, ватык тәрәзәләрен томалыйлар, базларына төшеп качалар... Әмма атом тузаны аларны аннан да эзләп таба, үлем элмәге булып, тәннәренә, бугазларына утыра, каннарына үтеп керә, аларга әҗәл тамгасын салып кала...

Атом реакторлары урнашкан мәйдан исә кыямәт көнен хәтерләтә... Атом калдыклары саклана торган корыч баклар көлгә әйләнгән, 160 тонна авырлыктагы бетон плитәләр, чәлпәрәмә килеп, теткәләнеп, күктә очып йөри... Атом радиациясенә манчылган тонна-тонна таш һәм тимер кисәкләре 150 метр ераклыкка очып барып төшә... Бөтен тирә-якка миллионлаган кюри атом калдыклары тарала... Атом болыты бөтен "Маяк" комбинатын, хәрбиләрнең шул тирәдәге казармаларын, әсирләрнең агач баракларын, шәһәрнең үзен, Иртәш күлен, тирә-яктагы урман-кырларны, авылларны каплап китә... Киңлеге 40 чакрымга сузылган атом болыты, Иртәш өстеннән күтәрелеп, татар җирләре буйлап 1000 чакрымга сузыла, Чиләбе, Свердловск, Төмән өлкәләрен басып ала... Иртәштән нибары 40 чакрымда яткан Татар Караболагы авылы атом аждаһасының беренче корбаны була...

Атом болыты үтеп киткән җирдә шунда ук агачлар саргая, кибә-корый, чыршылар энәләрен коя... Җир үлә... Су агулана... Бу зонага эләккән мал-туарларның тереләй тиреләре кубып төшә... Ялгышып атом аҗаганына караган кешеләрнең күзләре сукырая, авыз-борыннарыннан шаулап кан китә,

һәм алар, берничә көндә тиреләре кубып, итләре сөякләреннән аерылып, жан биреләр... Иң зур зыянны "Промплощадка" дип аталган жирдә яшәүче тоткыннар күрә—шартлау алар өстендә була... Могжиза белән исән калган тоткыннарны шунда ук атом пычрагын жыярга ташлыйлар, алар белән беркем хисаплашып тормый... Солдатларны да кайнап торган атом казанына—реакторларны чистартырга ыргыталар, аларның күбесе моннан исән чыкмый, исән калганнары соңыннан рактан һәм "нурланыш" авыруыннан зур газаплар белән үлә... Янгын сүндерүчеләр эшләгән урыннарда да радиацион нурланыш секундына берничә мең микрорентгенга житә... Бу кешеләр атом утында терелэй янып үләләр... Әмма кешеләргә моның атом фажигасе икәнлеген әйтмиләр, гадәти авариягә генә кайтарып калдыралар... Дәүләт бөтен нәрсәне яшерә, шундый зур фажигадән дә сер ясый... Мәетләрне тиз-тиз жыеп күмәләр, аларның төгәл санын беркемгә әйтмиләр... Мал-туарның үләксәсен жыеп яндыралар, радиацияле эш коралларын юк итәләр... Турыдан-туры атом болыты астында калган авылларны, торак пунктларын башка урыннарга күчерәләр... Атом болыты артыннан Караболакка да битлек кигән сәер кешеләр, хәрбиләр килеп тула... Тирә-як авылларда махшәр көне башлана... Караболак авылы да үзенең кайгылы һәм авырулы яңа чорына керә...

## Тугызынчы бүлек

Татар Караболагы авылына шом керде...

Иртәш буендагы көчле шартлаудан соң, авыл халкының түбәсенә күсәк белән кундырган кебек булды... Гомер буе чирнең нәрсә икәнен белмәгән кешеләр урынга ятты, авылда әллә нинди сәер авырулар күренә башлады... Әмма Караболак халкының шундый гадәте бар—алар үзләренә килгән чирне кешегә белдерергә яратмыйлар, аны яшерәләр һәм күпләрнең өендә ни белән авырып ятканын башкалар белмичә дә кала... Тик бу юлы хәл яшерерлек түгел иде, чөнки бөтен авыл берьюлы интекте, барысының да авырулары бертөрлерәк иде—кан косу, эч китү, чәч коелу, үзәккә үтәрлек көчле сызланулар һәм баш авыртулары... Авылда хәтта кисәк кенә сукыраючылар, баш авыртуына түзә алмыйча, акылга жиңеләючеләр дә булды... Гөлжиһаннар классыннан болай да сүз әйтергә куркып торган Рәшидә бөтенләй жиңеләеп, сакау булып калды... Һәр өй саен менә каләр күрелмәгән шундый бер хәл иде... Караболак авылына, гомер булмаганча, шом керде... Халык моның ахыры ни белән бетәрен көтә башлады... Әмма бу афәтнең очы-кырые күренми иде, ул әле башланган гына иде...

Әмма кем авыл халкының авыруына карап торсын соң?! Шартлауның икенче көнендә үк, үзләреннән сорап та тормыйча, аякта калган кешеләрнең барысын да яңадан кырга кудылар. Берничә көн уттай янып урын өстендә аунагач, боегып, ябыгып калган Гөлжиһан да мәктәп балалары белән яңадан Караболак кырына чыкты, дөресрәге, аларны анда милиция белән алып килделәр. Әмма бу юлы Гөлжиһан бәрәңге кырын танымады... Бөтен жирдә милиция, бөтен жирдә солдатлар һәм ниндидер сәер кешеләр иде... Алар йөзләрен битлек белән каплаганнар, өсләренә озын ак халат кигәннәр, кулларындагы таяклары белән нидер үлчәп, тикшереп йөриләр... Әмма иң гажәбе әле ул түгел, иң сәере—балаларга беркөнне генә алган бәрәңгеләрен яңадан жиргә күмәргә куштылар, сәбәбен әйтмәделәр. Менә укытучылар да, укучылар да бик аптырашты, яшелчә-бәрәңгене дә, үзләренең хезмәтләрен дә бик кызгандылар алар. "Нигә бу хәтле бәрәңгене әрәм итәсез?",—дип сораганга, милиционерлар: "Аны ашарга ярамый",—дип жавап бирделәр. Кыр уртасына тирән чокырлар казып, бәрәңгене дә, кишеркәбестәне дә яңадан жиргә күмделәр...

Ә Гөлҗиһаннар, милиция күрмәгәндә, ул бәрәңгене барыбер пешереп ашадылар, укытучылар да, авыл халкы да ашады... Елан кырда көне буе тагы нәрсә ашыйсың—эшләп аргач, пешерделәр дә ашадылар... Биташ чишмәсеннән алып килеп су эчтеләр... Авырудан балаларның күбесе бик хәлсезләнгән иде, тиз арыйлар, тиз ашыйсылары, эчәселәре килә... Җитмәсә, кыр өстендә әллә нинди соры-кара тузан, ул балаларның авыз-борыннарына керә, үпкәләренә утыра, аннан тагы да ныграк укшыта, костыра... Авыл балалары, ялан куллары белән, шул сәер тузан арасыннан бәрәңге җыялар, аларның нәни куллары канап, сыдырылып бетә... Бу балалар каннары, үпкәләре аша атом тузанын йотканнарын аңламыйлар әле, тән күзәнәкләренә мәңгегә радионуклитлар кереп утырганын белмиләр... Бу үтергеч атом калдыкларының тиздән аларның тәннәрен черетә башлаячагын, сөякләрен җимерәсен, каннарын агулаячагын башларына да китермиләр... Кая анда балалар, бу хакта аларның укытучылары, шул ук кырда эшләп йөргән әти-әниләре дә белми, авыл халкының мондый хәлне күргәне-ишеткәне юк, сорасаң, дөресен әйтүче дә юк...

Кырдагы бәрәңге, яшелчә шулай юк ителгәч, халык үз бакчасында эшкә тотына. Монда инде юк итәргә дигән әмер юк, бәрәңгене берәмтекләп җыеп, базларга салалар, яшелчәләрне дә урнаштырып бетерәләр. Аларны чыгарып атарга беркем җыенмый, чөнки халык аларның атомлы икәнлекләрен белми... Белсә дә нәрсә эшләр иде—чөнки аның бар карап торганы шушы бәрәңге дә, абзардагы мал-туары... Ә алда озын, салкын Урал кышы. Караболак халкы аңа әзерләнеп, ризыклы булып керергә өйрәнгән... Ә быел, әнә, барысының да асты-өскә килде... Авыл тулы милиция, хәрбиләр, битлек кигән сәер кешеләр... Барысы да нәрсәдер тикшерә, үлчи, эзләнә... Нәрсә кирәк аларга Караболакта, нигә халыкка дөресен әйтмиләр, ни көтә быел кыш Караболак халкын? Беркем берни белми...

1957 елның октябреннән башлап, Татар Караболагы авылында коеларны күмә башладылар. Халык монысына бөтенләй шашынып калды—авылда коесыз, сусыз ничек яшәмәк кирәк?!

—Бу суны эчәргә ярамый, чөнки моннан нефть таптылар,—дип ялганладылар аларга битлек кигән адәмнәр.—Һәм сезне тиздән башка урынга күчерәләр...

Бу хәбәр Караболак халкын өнсез итте. Ничек—башка урынга күчерәләр? Бөтен авыл беләнме? Кая күчерәләр? Ник күчерәләр? Нигә дип күчсеннәр алар Караболактан, кая күчсеннәр, дөньяда булмаганны!

Халык әнә шулай ярсыды, күтәрелеп бәрелде. Әмма авыл урамнарында һәр йөз метр саен мылтыклы сакчылар бастырып чыккач, халык сагаеп, тынып калды. Болайга киткәч, эшләр бик җитди булуын аңлады алар. Ул арада килгән битлекле кешеләр бөтен җиргә язулы такталар утыртып чыктылар—елга буена барырга ярамый, аннан су эчәргә ярамый, коеларны ачарга ярамый, кырда мал йөртергә ярамый... Ә ничек яшәргә авыл халкына—анысын беркем әйтми иде... Иң куркынычы—авылны төрмәдәге кебек чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алдылар, аннан кереп-чыгып йөрү тыелды. Районнан әллә кемнәр килеп, кемдә күпме мал-туар бар, каралты-курасы нинди, җан башы ничә—өй саен язып йөри башладылар... Моның барысын да күчерү өчен эшлиләр, имеш... Нефть тапканнар, дигән сүзгә Караболак халкы бик ышанып та бетмәде, чөнки нефтьне битлек киеп эзләмәгәннәрен беләләр иде алар. Бераз укыганнар, читтә йөреп кайтканнар, сугышта булганнар эшнең нефтьтә түгеллеген чамалыйлар иде... Болар барысы да Иртәш белән бәйләнгән, әмма нәрсә булган анда—әйтүче дә, белүче дә юк... Әйтерсең лә, ахырзаман купкан—әле теге авылны

күчергәннәр, дигән хәбәр килеп ирешә, әле бу авылны урыннан кубырып әллә кайларга илтеп ташлыйлар... Халык һәр көн нинди дә булса хәвефле хәбәр күтәреп яши...

Чын мәгънәсендә ахырзаманны Нәбиулла үзләреннән ерак түгел урнашкан Бирдәнеш дигән татар авылында күреп кайтты. Ул бу хәлне гомеренен ахырына хәтле онытмас, мөгаен... Нәбиулла хәтта сугышта да мондый вәхшилекне күрмәгән иде... Бирдәнешкә ул шул көзнен ахырында, колхоз эше белән барып чыккан иде. Караболактан чыкканда кырык кат тикшерелеп, Бирдәнешкә килеп кергәндә, тагы шунын кадәр тентелгәннән сон гына ул колхоз йомышын йомышлый алды. Хәзер район буенча, авыл араларында йөри торган түгел, бөтен җирдә тикшерү, бөтен җирдә сакчы, беркемгә бернәрсә әйтү юк... Бирдәнеш халкы да кырмыска оясы кебек актарылып ташланган, кайнап тора иде... Инде исән-имин вакытта кайтып китим, дип торганда, Нәбиулла авылны НКВД солдатлары чорнап алганны күрде. Ул авылдан чыгып китәргә өлгерә алмый калды, аннан халыкны чыгармый башладылар. НКВД солдатларына төрмә тоткыннары булыша, алар авыл халкын ирләргә-хатыннарга аерып, ат абзарларына таба куарга керештеләр. Авылда мәхшәр купты... Мылтыклы хәрби ул арада Нәбиулланы да җилтерәтеп арбасыннан тартып төшерде, этә-төртә аны ирләр төркеменә куып кертте... Нәбиулла, гарип кулын селтәп, үзенен бу авылныкы түгеллеген анлатырга тырышса да, аны тынлаучы булмады... Татар авылы урысча сүгенгән, татарча такмаклап елаган, гарәпчә сузып тәкъбир әйткән авазлар белән тулды... Күпләр, үлемебез шушы икән, дип уйлап, муеннарына кәфенлекләрен чорнап өйләреннән чыга башладылар... Ул арада авылнын бөтен хатын-кызын озын ат абзарына, ир-атларны ашлык амбарына куып керттеләр... Нәбиулла да Бирдәнеш ирләре төркемендә иде... Һәм татарлар өчен мәнге онытылмаслык хурлыклы мәхшәр башланды...

Аларнын барысын шәп-шәрә итеп чишендерделәр дә, өсләренә янгын машиналарыннан сасы салкын су сиптерә башладылар. Нәбиулла анын хлор икәнен сизеп алды... Бернәрсә анламаган халык шашынып кычкырырга тотынды, ак сакаллы намаз картлары ил алдында шәрә калу хурлыгыннан җиргә чүктеләр, ир балалар, котлары чыгып, аталарына килеп ябыштылар... Тазарак ирләр, яшь егетләр бикле ишекне дөбердәтә, картлар үлемгә хәзерләнә, балалар ярсып елый башлады... Салкыннан, бугазларга ябышкан әче истән, шәрәлек оятыннан һәм билгесезлектән татар ирләре күккә карап үкерәләр, сугымга бәйләп салган мал кебек бәргәләнәләр иде... Нәрсә сон бу, ни өчен? Аларны алга таба ни көтә—беркем берни белми... Картлар яхшы хәтерли—патша заманында бу якларда татарларны шулай авылы-авылы белән амбарларга бикләп ут төртеп яндырганнар, Себер сөргәннәр, мөселман булган өчен генә очлы казыкларга утыртканнар, телләрен, борын-колакларын кисеп алганнар... Әллә, Ходаем, шул заманнар кире кайттымы, алар, авылда ятып, белмичә калдылармы икән?

Ул арада өс-башларын сарай алдында ут төртеп яндырдылар, үзләренә бөтенләй ят, сасы исле киемнәр бирделәр... "Советча дезинфиксия" тәмам булды... Нәбиулла да боз булып каткан тәненә чит-ят киемнәр киеп, сарайдан тышка атылды... Исән калганына сөенгән халык, сарык көтүе кебек, бер читкә барып өелде... Хлорлы салкын судан исән чыккан авыл хатыннарын үз ирләре дә танырлык түгел иде, аларнын өсләрендә дә чит-ят сәләмәләр... Бу ике төркем, котлары чыгып, бер-берләренә якын килергә куркып, өелешеп бастылар...

Ә авылда...

Авылда тагы да куркыныч хәлләр... Ахырзаман үзе, мәхшәр мәйданы... Кешеләрнен күз алдында аларнын өйләрен ут төртеп яндыралар, кешеләрне

әйберләрен алырга якын җибәрмиләр... Бу хәлләрне күреп, кемдер үкереп елый, картлар тагы тәкъбир әйтә башлый, маллар акыра, солдатлар кычкыра, шарт-шорт һавага аталар... Бу өйләрдә кешеләрнең гомер буе җыйган мал-мөлкәтләре, нәсел тарихлары, китаплары, Коръәннәре дөрләп яна... Аларның бар "гаепләре"—Иртәштәге шартлаудан соң атом болыты астында калулары... Әмма халыкка моны әйтмиләр, кешеләр ни өчен өйләренең дөрләп януларын белмиләр, аларны, кыймылдатмыйча да, мылтыклы солдатлар саклап тора...

Ул арада авылдагы бөтен терлек-туарны җыеп, алдан казып куйган тирән траншеяларга атып төшерә башлыйлар... Үлем исен, кан исен сизгән маллар аяк терәп үкерә, авыл буйлап хуҗаларын эзләп чаба башлый, аларны кыйный-кыйный янадан тирән чокыр буена куалар... Нәбиулланың туры айгыры да шушы мәхшәргә эләккән булып чыкты, аны арбасы-ние белән үләт базына атып төшерделәр, аның үлем ачысы белән ярсып кешнәве Караболак буйларына хәтле барып җитте... Нәбиулла аның өчен берни эшли алмады... Бу мизгелләрдә ул үзе дә сугымга салынган мал хәлендә иде...

Бирдәнеш исә төрле баштан дөрләп янып килә... Әнә агач мәктәп яна, борынгы мәчет дөрләп яна, клуб, фермаларга ут каба... Мескен торткыннар, бер өйдән икенчесенә йөгерә-йөгерә, ут төртеп йөриләр, аларның артыннан мылтыклы солдатлар куа... Халык инде дәшми... Халык инде килешкән... Халыкның берни эшләргә дә чарасы юк... Хәзер инде еламыйлар да, берни сорамыйлар да. Барысы да бу мәхшәрнең ахырын көтә... Берни аңламаган, шашынган кешеләрне алдан әзерләнгән йөк машиналарына төяп, ашыга-ашыга Бирдәнештән алып чыгып киттеләр... Авыл аларны дөрләп янган өйләре, үләт базында үлә алмыйча үкереп яткан хайваннары белән озата калды...

Коншактагы бер агач казармага илтеп ташлагач кына, Нәбиулла бу төркемнән аерыла алды, шул көнне үк, җәяүләп, Караболакка кайтып китте... Ул авылны башка урынга күчерүнең нәрсә икәнлеген үз күзләре белән күрде, Караболакның алда торган язмышын уйлап, кара кайгыга төште... Бу күчерелүчеләр дә кая барасыларын, кайда торасыларын белмиләр, алар салкын кышка таба бер кат чит киемнән калдылар... Бу татарларның торырга өйләре юк, киергә киемнәре, ашарга ризыклары юк... Караболакка да шушы кара язмыш әзерләндеме икәнни?

Шулай итеп, атом шартлавыннан зарар күргән авылларны башка урыннарга күчерә башладылар...

Әмма бу күчерү халыкны берни алдырмыйча, өйләреннән куып чыгаруга әйләнеп калды... Аларны ялан кырда ашык-пошык әвәләнгән фанер-такта йортларга, баракларга кертеп тутырдылар, беренче кышта ук күченгән халыкның күбесе ачлыктан, төрле чирләрдән кырылып бетте. Чөнки атом болыты астында калган бу кешеләрнең барысына да диярлек инде әҗәл тамгасы салынган иде, алар бөтен чир-зәхмәтләрне үзләре белән башка урынга да алып киттеләр... Мәңгелеккә алып киттеләр...

Шулай итеп, тирә-юньдә йөзләгән чакрым араны атом тузаны каплап китте, әмма моның шулай икәнен аерым кешеләр генә белә иде... Халыкка бу хакта берни дә әйтмәделәр... Атом тузаны, үлем нуры булып, меңләгән, миллионлаган кешеләрне, мал-туарны радиация белән агулап узды, авыл һәм кырларны каплады, җиргә сеңде, һавага таралды, суга китте...

1957 елның 29 сентябрендә "Маяк"та шартлау нәтиҗәләре шулкадәр коточкыч иде ки, хөкүмәт каршына хәтта бу атом комбинатын ябу-япмау мәсьәләсе дә килеп басты. Шартлауның икенче көнендә үк Иртәштәге Озерский шәһәренә Мәскәүдән зур комиссия килеп төште, аның составында генераллар, министрлар, галимнәр һәм врачлар бар иде. Тикшерү нәтиҗәләре

шуны күрсәтте—шәһәр һәм комбинат радиоактив калдыклар белән бик пычранган, бөтен җирдә көчле радиация... Әмма иң куркынычы—шартлау вакытында радиоактив калдыклар саклый торган җайланмалар нык какшаган һәм аларның теләсә кайсы вакытта көлләре күккә очарга мөмкин... Аларның гына түгел, бөтен шәһәрнең, бөтен Урал буйларының атом шартлавы астында юкка чыгу куркынычы бар иде... Бередә күпме атом бомбасы ятканын, күпме үлем коралы ясалганын, күпме радиоактив калдыклар сакланганын яхшы белгән комиссия зур проблема алдында калды... Илгә, кешеләргә зур куркыныч янавын истә тотып, СССР яки атом промышленностеннән, атом бомбасыннан баш тартырга, ягъни, "Маяк"ны ябарга тиеш иде, яки барысын да ничек бар—шулай калдырырга...

СССР Машина төзү Министры Е.П.Славкин приказы нигезендә, 3 октябрь көнне үк хәрбиләрдән ике зур отряд төзелә, алар шәһәрне һәм комбинатны атом калдыкларыннан чистартырга тиеш булалар. Әмма—ничек итеп? Моңа кадәр беркемнең дә мондый хәлне күргәне юк, күзгә күренмәгән атом нурын ничек тотарга, ничек чистартырга—моны СССРда беркем дә белми... Әмма бу илдә кеше сансыз һәм кадерсез, аны теләсә нинди үлемгә каршы җибәрергә була... Хәтта атомга каршы да... Һәм солдатларны, исән калган тоткыннарны, көрәк һәм чүкеч тотырып, атомга каршы җибәрәләр... Аларга янгын сүндерү машиналарында һәм бульдозерларда эшләүче эшчеләр, төзүчеләр килеп кушыла... Күбесе бу атом казанынннан исән чыкмый, күзләре сукыраеп, тиреләре кубып, кан күзәнәкләре шартлап, шунда ук үлүчеләр була... Солдатларга һәм тоткыннарга исә, авария нәтиҗәләрен бетергәннән соң, өйләренә кайтарып җибәрергә вәгъдә бирәләр... Алар, радиоактив нурлар арасына кереп, зарарланган биналарны җимерәләр, атом нурыннан корыган агачларны, радиацияле бөтен чүп-чарны җыеп, атом каберлекләренә күмәләр... Атом дулкыны үткән җирләрдән 20 сантиметр калынлыкта туфрак кырып алына һәм тирән чокырларга күмелә... Бу куркыныч эшләрнең барысын да солдатлар һәм тоткыннар башкара... Аларның һәр көн саен өс-башларын, резин итекләрен алыштырып торалар һәм җиргә күмәләр, чөнки алар да меңләгән микъдарда радиация сеңдергән булалар... Әмма бередә эшләгән кешеләр барысы да диярлек берничә ел эчендә нурланыш авыруыннан һәм рактан үлеп бетә...

Ул вакытта "Маяк" та һәм Иртәш күле буйларында меңләгән кеше кинәт үлем белән үлә, әмма моның атом шартлавы нәтиҗәсе икәнлеген күпләр белми...

Тирә-як авылларда кешеләр һәм мал-туар урам уртасында егылып үлә башлагач кына, хөкүмәтнең кулы аларга да барып җитә—шул елның октябрь аенда ук 23 авыл башка урынга күчерелә... 102000 кеше радиацияле өйләреннән чыгарыла... 267000 квадрат километр җир яраксыз дип табыла, меңәрләгән тонна авыл хуҗалыгы продукты юк ителә... Әмма хөкүмәт, белә торып, "Маяк" тирәсенә урнашкан һәм көчле радиациягә эләккән зур-зур татар авылларын, башка урынга күчермичә, үле зонада утыртып калдыра... Ул вакытта бишәр мең татар яшәгән Мөслим, Үзбәгәрәк, Татар Караболагы авыллары атом зонасында тәҗрибә үткәрү өчен калдырган кебек калдырыла... Халыктан басу-кырлар, көтүлек җирләре тартып алына, елга-суларга кораллы сакчы куялар, бу авылларда бөтен төзелеш эшләре тыела... Ә ничек яшәргә мондый шартларда—анысын беркем аңлатмый... Аның каравы, атом шартлауга, Чиләбе, Мәскәү институтларыннан галимнәр һәм врачлар килеп, бу татарларны тикшерә, өйрәнә башлыйлар... Юк, бу мескеннәргә ярдәм итү өчен өйрәнмиләр аларны, ә бәлки атом сугышы була калган очракта, кеше организмының кайсы якка үзгәрүен белү өчен тикшерәләр...

## Тугызынчы бүлек

Татар Караболагы халкы, утка төшкәндәй, авылны күчерүне көтә...

Күчүең яхшымы, күчмәвең яхшымы—беркем аңламый, чөнки беркем дә күчерүнең сәбәпләрен белми... Күрше авыллардан берсеннән-берсе куркыныч хәбәрләр килеп тора, күчерү вакытындагы хәлләрне сөйләп бетерә алмыйлар... Халыкны, бернәрсәләрен алдырмыйча, колхозның ат абзарларына куып кертәләр икән дә, сасы салкын су белән шлангтан сиптереп юдырып, больница киемнәре кидереп, машиналарга төяп кырга чыгарып ташлыйлар икән... Нәкъ Нәбиулла күргәнчә... Өйләрен шунда ук ут төртеп яндыралар, ди... Мал-туарны атып үтерәләр икән... Инде Татар Караболагын да шушы көн көтәме икәнни?

Күчерелмичә калган авыллардан да шомлы хәбәрләр килә—берәү кара янып, кырда егылып үлгән, икенче берсенең күзләре агып чыккан, тәненнән тиреләре кубып төшкән... Өченчесе кинәт кенә сукырайган, ишетми башлаган... Берсеннән-берсе куркыныч хәлләр, куркыныч хәбәрләр... Тирә-күрше авылларда бу хәлләргә түзә алмыйча акылдан язучылар, асылынып үлүчеләр күренә башлады... Бүген-иртәгә күчерүне көтеп яткан Татар Караболагы авылына шом керде, һәркемнең эченә ут төште... Килгән-килмешәк авылны ташлап кача башлады, төп халык нәсел-нәсел, күч-күч киңәшмәгә җыелды... Нишләргә? Гомер иткән ата-бабалар нигезен ташлап, ничек кузгалырга, кая барырга? Әнә күчкән кешеләр дә бер дә сөенмиләр бит—бернәрсәсез как кырга илткәннәр дә ташлаганнар... Кемне—җир землянкаларга, кемне—такта алачыкларга куып керткәннәр... Ә алда—салкын Урал кышы, ничек чыгар алар бу кышны? Татар Караболагы авылы халкын да шундый язмыш көтәме? Меңәр ел шушы җирдә яшәгән борынгы халыкны, затлы Хан нәселләрен буш далада ачтан бетләп үлү, тереләй кабергә керү көтәме? Миллион еллык күл-сулары, меңәр еллык курган-каберләре булган Татар Караболагы авылын юкка чыгу көтәме? Һәркем бүген шул сорау алдында калган иде...

Нәбиулланың олы нәселе дә киңәш-табышка җыелды. Карттайлар һәм картнәйләр, атай-инәйләр, абзый-җиңгиләр, бала-чагалар берсе дә бу сөйләшүдән читтә калмады... Ярулла картның бертуган энесе Таһирҗан әзине дә чакырдылар, чөнки нинди заманда да намазын ташламаган ир уртасы бу кеше үзенең зирәк акылы, әдәп-әхлагы белән бөтен тирә-якта аерылып тора иде... Аны, үзе югында, "Караболак әүлиясе", дип йөртәләр иде...

—Йә, нишлибез, әзиләр?—диде Нәбиулла, бөтен туган-тумача җыелып беткәч.—Галикәй, Бирдәнешләр кебек, авылга ут төртеп чыгып китәбезме, монда калып бетәбезме? Әйдә, киңәшик, нинди фикергә килсәк, шулай эшләрбез...

Кинәт куелган бу куркыныч сораудан барысы да телсез-өнсез калды. Әйе, күпме генә сузсаң да, хәл шундый иде—китсәң дә бетәсең, калсаң да—бетәсең... Ә ничек яшәргә соң алай булгач, ничек нәселне саклап калырга?

Бу якларга күзгә күренмәгән куркыныч зәхмәт килгәнен алар аңлаганнар иде инде, Иртәштән Хәбибулла туганнары үләргә кайтып егылгач, бу афәтне үз күзләре белән күргән кебек булдылар...

Хәбибулла армия хезмәтен Иртәштә генә үтте, төзелештә иң авыр эшләрдә эшләде ул. Ул вакытларда әле шәһәргә кереп-чыгып йөрү ирекле түгел иде, Хәбибулланың бөтен гомере, төрмәдәге кебек, биктә үтте... Армия хезмәтеннән соң да Хәбибулла шушы ябык шәһәрдә калды, Таифә исемле татар кызына өйләнде, һәм алар яшәргә дә Иртәштә торып калдылар...

Заманалар бераз үзгәреп, шәһәрдән читкә чыгарга рөхсәт булгач, Хәбибулла гаиләсен, ике баласын Караболакка алып кайтып күрсәткән иде... Ата-ана берни әшли алмады, төп нигездә калырга тиешле төпчек малай Хәбибулла шулай итеп яшерен шәһәрдә урнашты да калды... Әкренләп Хәбибулла Иртәш читендә үзенә агач йорт житештереп куйды, анда яшәргә генә насыйп булмаган, күрәсең...

Менә шул Хәбибулла, Иртәштәге теге шартлаудан соң, авырып авылга кайтып егылды. Әзмәвер кебек ир-ат, кипкән балык хәленә калып, ябыккан, беткән иде... Аның башында бер бөртек чәче калмаган, йөзе саргаеп кипкән, күзләренә кып-кызыл кан сауган, еласа да, кан агып чыгар кебек... Үзе берни сөйләми, кайда мондый хәлгә калганлыгын әйтми, көннәр буе түшәмгә карап, сызланып ята... Хәбибулланың мондый хәлгә килүе бөтен нәсел өчен кара кайгы булды, атом афәте бу нәселдә дә үз исәп-хисабын ачып җибәргән иде...

—Нишлик, энекәш?—диде Нәбиулла, үлем көтеп яткан туганына карап.—Китикме, калыйкмы? Анда ни сөйлиләр? Бу афәтне туктатырлык хәлләре бармы Иртәштә?

Хәбибулла—дәүләт серен ачмаска 25 елга кул куйган кеше... Дөрес, ул андый зур дәүләт серләрен белми, әмма мәхшәрне үз күзләре белән күреп кайтты. Әле ярый аларның өйләре "Маяк"тан шактый еракта, шәһәр читендә иде, балалар белән базларга, идән асларына качып котылдылар. Промплощадкага якын торучылар исә кырып салган кебек булды, үлүчеләрнең санын хәтта әйтеп тә тормадылар... Ул тирәдә җимерелмәгән бер йорт, бер бина калмаган иде... Халык төрлесен сөйләде, кем, реакторлар шартлаган икән, диде, кем, атом бомбасы шартлаган, диде... Махсус сынау уздырганнар икән, диючеләр дә булды... Шартлауның икенче көнендә үк аларны бригадалары белән шул җимерекләрне чистартырга җибәрделәр. Менә шунда күрде инде Хәбибулла дөнья бетүнең нәрсә икәнен, менә шунда алды инде ул әҗәл чирен...

Әле дә күз алдында аның—атом шартлаган урында җирнең үзәге, эче актарылып чыккан, таш-тимерләр эрегән иде... Бөтен нәрсәгә кул яссуы агулы тузан утырган... Солдатлар һәм тоткыннар белән берлектә, төзүче татарлар да әнә шул агуны җыештырдылар, атом тузанлы нәрсәләрне кайсын җиргә күмделәр, кайсын ут төртеп яндырдылар... Күпләр шул көнне үк кан косып ауды, күпләрне носилкалар белән алып киттеләр, алар урынына яңаларны куып керттеләр... Анда беркем сорап тормады, эшләргә телисеңме, юкмы, дип... Нинди куркыныч булуын да әйтмәделәр... Эшкә чыкмасаң—төрмә, ә анда утыручылардан сорап та тормадылар, аларны атом казанының эченә үк ыргыттылар...

Хәбибулла бу мәхшәрдән могҗиза белән генә исән калды, әмма чирнең катысын эләктерде. Шунда ук бетмәвенә авыл тазалыгы ярдәм иткәндер инде, аннары ул үзе дә сак булырга тырышты... Әмма ул гарасаттан сакланып бетеп буламы соң—һавада, суда, туфракта шул агу булганда? Димәк, бу зәхмәт Караболакка да килеп җиткән икән... Иртәштәге хәлләр монда да башланырга мөмкин, андагы чирләрнең бирегә дә килеп житүе бар... Трактор белән коеларны күмеп йөриләр икән, димәк, аның суын эчәргә ярамый, ул агулы... Көтүлекләргә мал керттермиләр икән, димәк, туфрак та агулы, анда үскән үсемлекләр дә агулы, аны ашаган мал-туарның ите-сөтен дә кулланырга ярамый... Димәк, бирездә яшәргә ярамый...

—Иртәштә мәхшәр, туганнар,—диде ул, шушыларны искә төшергәч.—Кыямәт көне анда... Әмма мин аларны сезгә сөйли алмыйм, ярамый... Син, әзи, солдатта булган кеше бит инде, сугышны күргән... Менә шундый хәл анда... Атом сугышы узган кебек...

Ирләр бер-берләренә карашып алдылар. Хатын-кызлар, хәвефләнеп, аларның нинди карарга килүләрен көттеләр, чөнки алар ничек әйтсә, шулай булачак иде... Авырудан яңа терелеп килгән Гөлҗиһан да шомланып калды, йөзе җитдиләнде, уйчанланды. Караболакны ташлап китү уе аның котын ала иде. Ничек Караболакны ташлап китәргә мөмкин инде, мондый авыл башка бер җирдә дә юк бит! Биташ күлләрен, аның шифалы чишмәләрен, борынгы тау куышларын, Алып Ханнарның кабер-курганнарын кемнәргә калдырып китәсең?! Кая китәсең? Гөлҗиһанның бер җиргә дә китәсе килми Караболактан, ул үлсә дә шунда калырга риза... Күк капусы ачылганда да ул бары тик шуны гына теләде бит—Караболак мәңге булсын, әти-әнисе, әби-бабайлары гел исән булсын, дип теләде, аның бу теләге кабул булмадымы икәнни?

Гөлҗиһан, мөлдерәп, Таһир бабасына карады, чөнки ул ни әйтсә дә, дөрес әйтә. Аны бөтен авыл әүлия дип атый, ул белергә тиеш бит инде нәрсә эшләргә кирәклеген...

—Алай икән...—дип куйды Таһир карт, Гөлҗиһанның уйларын сизгәндәй.—Мәхшәр, дисең алайса, Хәбибулла энекәш... Монда әле алай ук түгел-түгелен, әмма дөнья үзгәрде монда да... Бу хәзер элеккеге Караболак түгел инде... Кешеләр үзгәрде... Холык-фигыльләре үзгәрде... Авылда хәвефборчу күп... Чирләр күбәйде, әллә нинди ят чирләр... Кинәт үлемнәр күренә башлады... Бу—шуның тәэсире инде, шуның...

"Нәрсәнең тәэсире?",—дип сорыйсы килсә дә, Гөлҗиһан тынып калды. Ул бала акылы белән дә сизенә иде—Иртәштәге шул шартлаудан соң бөтен авыл авырый башлады бит инде, коеларны күмделәр, кырдагы бәрәңгеләрне юк иттеләр... Сорасаң, "Ярамый!"—гына диләр, ә нигә ярамаганын әйтмиләр... Хәтта укытучылар да берни әйтми, бәлки алар үзләре дә белмиләрдер әле... Таһирҗан бабай да әйтмәгәч, чынлап та әйтергә ярамыйдыр инде аны...

—Нишлик соң, Таһирҗан әзи, китәргәме, калыргамы безгә Караболакта?—дип туп-туры сорап куйды Гөлҗиһанның әтисе.

—Җибәрә башласалар, калам дисәң дә кала алмассың, Нәбиулла энем,—диде Таһир карт, сабыр гына.—Бирдәнешне ничек күчергәннәрен үзең кайтып сөйләден бит, теләсәләр, безне дә бер сәгатьтә шулай кырга чыгарып ата алалар... Әнә күрше Урыс Караболагын бер көндә шулай күчерделәр, өйләрен ут төртеп яндырдылар, ялкыны монда күренеп торды... Элек чума чире, ваба вакытында шулай кыланалар иде... Димәк, бу аннан да куркынычрак зәхмәт инде... Калсаң да куркыныч, китсәң дә ул сиңа кагылып өлгергән инде... Нишләргә дә белгән юк, балалар... Аллаһтан хәерлесен сорыйк... Китәргә язган икән—китәрбез, калырга язган икән—туган туфракта җан бирербез...

—Нигәдер безгә кагылмыйлар әле,—дип сүзгә кушылды Ярулла карт та.—Югыйсә, Урыс Караболагы безгә терәлеп кенә тора бит инде... Әллә безне күчермәскә булдылармы икән соң? Кышка каршы кая куйсыннар мондый зур авылны? Бәлки хәзергә кагылмаулары да хәерледер, белүче Аллаһы Тәгалә генә...

—Күчерәбез, дип әйттеләр шул, әти,—диде Нәбиулла.—Коншакка барганда, ишеткәләп кайтам—бу тирәдәге бөтен рус авылларын анда-монда таратып бетергәннәр инде, берничә татар авылын да күчергәннәр... Ә нигәдер Мөслим, Үзбәгәрәк, Татар Караболагы кебек зур-зур авылларга һаман тотынмыйлар... Бәлки шул зурлыклары куркытадыр, кая куеп бетерсеннәр кышка каршы бу хәтле халыкны... Бәлки әле бөтенләй күчермәсләр дә, шул килеш калдырырлар...

Гөлҗиһан, сөенеченнән, урыныннан ук сикереп торды. Әйе,

күчермәсеннәр шул Караболакны, Гөлҗиһаннар да монда калсыннар! Ул хәзер авырмый бит инде, терелде, аның, Караболакны ташлап, бер жиргә дә китәсе килми.

—Бу зәхмәт бөтен тирә-юньгә таралды инде, ыланнар,—диде Таһиржан карт, уйчан гына.—Кая күчсәң дә, ул безнең белән ияреп барачак... Кая барсаң да, шушы хәл булуы мөмкин... Галикәйләрне 5-6 чакырымдагы ялан кырга илтеп ташлаудан ни үзгәрер икән соң алар өчен? Бу күчерү дигәннәре дә күз буяу өчен генә булырга охшаган, ягъни, "күчердекме—күчердек"... Ә бу зәхмәтне кая куясың, тамгасы һәр кешедә инде аның хәзер...

Таһиржан картның ни әйткәнен аңлап бетермәсәләр дә, барысы да, тын алмыйча, аны тыңладылар. Ул ни әйтсә дә, җаен белеп, ипләп әйтә, бөтенесен уйлап сөйли... Ул үз тәкъдиренә дә, авыл язмышына да ышана, шуңа күрә Аллаһтан да үзләре өчен хәерлесен сорый... Ә адәм баласына нәрсә хәерле икәнен бер Аллаһ кына белә...

—Мәҗбүри кумасалар, нигез ташлап, авыл ташлап йөреп булмас, ыланнар,—дип дәвам итте Таһир карт, төпле бер карарга килгәндәй.—Шушы шартларда яшәргә, исән калырга өйрәник... Бу безгә Аллаһның бер сынавы яки җәзасыдыр, мөгаен... Авылдан дин чыгып бара, кешеләрдән иман китә, шуңа җавап инде бу хәлләр, әмма моны күпләр аңламый шул, аңламый... Җирдәге шушы газаплар аша бәлки халык иманга, тәүбәгә килер, ахирәт көнендә җәннәтләргә ирешер... Югыйсә, пәйгамбәрләр аяк баскан җир бит бу Караболак тирәләре, сәхәбәләр, әүлияләр яшәгән изге җир... Җәһәннәм уты да шушында бәреп чыгар, дип кем уйлаган...

Аның бу сүзләреннән карт-карчыклар авыр гына көрсенеп куйдылар, ирләр тынып калды, хатын-кызның, бала-чаганың эченә шом керде... Таһиржан карт, серле сөйләсә дә, белеп сөйли ул... Һәрвакыт дөресен сөйли... Шуңа күрә аны "Караболак әүлиясе", дип йөртәләр дә инде... Ул шулай уйлый икән, димәк, шулай була—Гөлҗиһаннар бер җиргә дә китми, Караболакта кала... Караболак та үз урынында кала, чөнки Таһир бабай, аны күчерәләр, дип, өздереп әйтмәде бит. Димәк, Таһир бабай әйткәнчә, шушы шартларда яшәргә, исән калырга өйрәнергә кирәк...

Шулай итеп, Алып Ханнар нәселе, җыелып киңәш иткәннән соң, моңа кадәр ничек яшәгәннәр, шулай яшәргә ният иттеләр. Бәргәләнмичә-өзгәләнмичә, вәсвәсәгә бирелмичә, шул ук вакытта саклык чаралары да күреп, үзләренчә яшәп карарга булдылар. "Ни күрсәк тә, ил белән бергә күрербез", дип уйлады алар. Ә Караболак халкының берсенең дә каядыр күчәргә исәбе юк иде, туган илдән, туган җирдән мәңгегә аерылып китү алар өчен үлем белән бер иде...

Шулай итеп, билгесезлек эчендә 1957 елның коры көзе үтте, Караболак халкы озын салкын кышка керде...

Кар төшкәнче, олысы-кечесе кырда булды—бар бәрәңгене, яшелчәне җыеп, тирән чокырларга күмделәр, атом тузаны утырган эскерт өсләрен төшереп яндырдылар, бушап калган җирләрне тирән итеп сөреп чыктылар. Ниһаять, ноябрь урталарында беренче кар яуды, атомлы кырлар, яндырылган авыллар, җимерек хәрабәләр барысы да ак кар астында күмелеп калды... Әмма Караболак халкына эш бетмәде, алар кыш буе кырга эскерт өстен төшерергә йөрделәр, аннан күтәрелгән яшелле-зәңгәрле төтенгә тончыгып, аннарын югалтып егылучылар, хәтта үлүчеләр дә булды... Монда да авыл халкын хәрбиләр карап торып эшләтте, колхозчылар аларның әмеренә буйсынырга тиеш иде. Караболак халкы эскертнең өске—агулы өлешен ут төртеп яндыралар иде дә, көлен җиргә күмәләр иде. Калган саламны исә хәрбиләр колхозчыларга бушка алырга рөхсәт итәләр иде...

Авыл халкы ул чагында үз куллары белән абзарларына кырдан радиацияле печән-салам ташыганнарын белми, әлбәттә, ә белүчеләр аларга бу хакта берни дә әйтми... Шулай итеп, Караболак халкы үз куллары белән кыш буе кырдан үзенә үлем ташыды...

1958 елның маенда, җир кардан арыну белән үк, Татар Караболагы авылы халкын тагын мәҗбүри эшкә куа башладылар. Бу юлы Урыс Караболагы авылын атом пычрагыннан чистартырга тиеш иде Караболак татарлары... Хәрбиләр бар халыкны—олысын-кечесен, мәктәп балаларын, хәтта авырлы хатыннарны, мылтык астында Урыс Караболагына куып китерделәр. Ниндидер сәбәп белән бу эшкә чыкмаган кешеләрнең утырткан бәрәңгеләрен сукалатып ташладылар, малларын көтүгә чыгартмадылар. Авылга хәрбиләр хуҗа булып алды, тыңламаучыларны төрмә көтә иде... Мондый хәлне гомерендә дә күрмәгән авыл халкы ике ут арасында калды—Урыс Караболагына эшкә барып, тагы чирләп кайтыргамы, әллә бармыйча калып, бер хокуксыз кешегә әйләнергәме, төрмәдә черергәме? Шулай башбаштакланган берничә гаиләне, әнә, авылдан куу белән үк яный башладылар... Һәм авыл халкы, аяклары тартмаса да, Урыс Караболагы авылына эшкә китәргә мәҗбүр булды. Ташландык урыс авылы аларны җимерек хәрабәләре, иясез этләре, шыксыз, кешесез урамнары белән каршы алды... Әйтерсең бирелә зур сугыш булып үткән иде...

Урыс Караболагы авылы халкын, көзге шартлау белән үк башка урынга күчергәннәр иде инде. Биредә агач өйләр шунда ук яндырылып, мал-туар атып-үтерелеп бетерелгән иде. Әмма монда таштан һәм кирпечтән салынган берничә нык йорт, кирпеч мәктәп һәм таш чиркәү, кибет биналары бар иде. Караболак татарлары менә шуларны сүтеп, җимереп, чүп-чарны авыл буйлап казылган тирән чокырларга тутырырга тиешләр иде... Яхшырак кирпечләрне чистартып, Татар Караболагы авылына алып кайтырга куштылар, чиркәү ташларыннан анда дуңгыз фермасы төзеделәр... Әмма ул дуңгызлар бик тиз үлеп беттеләр, моның радиация тәэсире икәнлеген авылда белүче булмады...

Гөлҗиһан да бөтен мәктәпләре белән Урыс Караболагы авылы хәрабәләрендә эшли... Монда балалардан да, укытучылардан да сорап тору юк, Урыс Караболагына мылтык белән төяп алып китәләр, мылтык астында кайтарып куялар... Гөлҗиһанның әти-әнисе дә биредә, Таһир бабай да монда, эшкә чыкмасаң, бәрәңге бакчаңны сукалатып ташлыйлар... Шуңа күрә бөтен авыл Урыс Караболагын чистарта... Олылар кайда—лом, кайда техника ярдәмендә, таш биналарны җимерәләр, ә балалар, хатын-кызлар шул таш-кирпечләрне аерып, яхшыракларын кырып-чистартып, төрле өемнәргә өеп баралар. Хәрабәләрдән яшелле-зәңгәрле төтен күтәрелә, ул күзләргә, борыннарга керә, бугазга утыра, укшыта башлый... Моңа түзә алмаган балалар, йөгереп барып, Караболак елгасына ятып су эчәләр, бит-кулларын юалар... Елга ярларында, “Эчәргә ярамый!”—дигән кисәтү торса да, хәрбиләр моны күрмәмешкә салына... Көне буе җимерекләр арасында эшләгән кешеләр кайдан су эчәргә, нәрсә ашарга тиешләр соң? Кемдер, кайдандыр табып, учак ягып бәрәңге пешереп ашый, кемдер юл читендә котырып үскән әнис, какыларны өзеп каба... Гөлҗиһанга Таһир бабасы моннан бернәрсә ашамаска кушса да, ул, кызыгып, какысына да, әнисенә дә үрелә... Балалар белән бергә, Караболак елгасына барып, коенып та килә... Чөнки бу суларда, бу үләннәрдә Гөлҗиһан бернинди үзгәреш күрми, элек ничек тәмле-татлы булсалар, алар хәзер дә шундый...

Гөлҗиһанны иң гаҗәпләндергәне кибет һәм чиркәү биналары булды. Кибетнең эче тулы әйбер, хәтта прәник-конфет та бар, әмма аларны ашарга ярамый икән—мылтыклы солдат саклап тора. Кибеттәге әйберләрне дә

ташлаячаклар икән, чокырга күмәчәкләр, ди... Ничек инде шул хәтле әйберне чокырга күмәргә була? Анда ялтырап торган туфлиләр, шундый матур күлмәкләр, пәлтәләр дә бар бит! Их, шуларны Гөлжиһанга һәм башка балаларга бирсәләр! Юырлар иде дә, киерләр иде әле... Прәникләрен дә "ә" дигәнче ашап бетерерләр иде, барыбер бу авылда нәрсә бар—барысын да ашыйлар бит... Әмма авыл балалары кибет тирәсендә күпме генә бөтерелеп йөрсәләр дә, аларга бернәрсә дә эләкмәде—кибетне каядыр төяп алып киттеләр. Аның каравы Гөлжиһаннар чиркәү складларында бал белән тулы умарта кәрәзләре таптылар! Һәм аны бик тиз бүлешеп ашап та бетерделәр, аннары су эчәргә тагы Караболакка йөгерделәр...

Бу чиркәү инде күптән чиркәү түгел, анда колхозның складлары булган икән. Халык аны җимерә алмыйча иза чикте, ул шул хәтле нык иде. Башта көрәкләр, ломнар белән атна буе чокып карадылар—чиркәү ташлары селкенмәде дә... Аның измәсе моннан йөз ел элек йомырка сарысыннан эшләнгән булган икән, шул катырган ташларны... унбиш ир-ат атна буе ломнар белән бәреп, тракторлар белән эттереп тә булдыра алмагач, солдатлар килеп, чиркәүне шартлаттылар. Чиркәү гөмбәзләренә, стеналарына утырган атом тузаны, шартлап, һавага очты, шунда эшләп йөргән татарларның башларына, өсләренә кунды... Кирпечләрне чистартырга мәктәп балаларын куйдылар, Гөлжиһан да алар арасында иде... Алар, берни белмичә, ялан куллары белән радиацияле кирпечләрне күкрәкләренә тереп, бер кырыйга ташыдылар... Анда аларны кырып чистарттылар, начарларын ирләр чокырга күмделәр, яхшыракларын Татар Караболагына озаттылар... Халык иртәдән-кичкә кадәр атом тузаны арасында эшләде, тагы авыручылар, чирләп егылучылар күренә башлады... Әмма Урыс Караболагын тәмам чистартып бетермичә, татарларны моннан җибәрмәделәр...

Инде эш тәмам бетте, дигәч тә, янасын уйлап табалар—мәктәп балаларын Урыс Караболагына агач утыртырга йөртә башлыйлар... Авылның буеннан-буена утырта алар аны... Чиләбе-Сверлау олы юлыннан бу җимерек хәрабәләр күренеп тормасын өчен, чокыр-чакырлар каплансын өчен, буйдан-буйга яшь карагайлар утырталар Караболак балалары... Гөлжиһан да алар арасында була... Алар яланаяк, ялангул көенчә, берни белмичә, атом тузаны арасында йөгереп йөриләр... Шунда Караболак елгасына ятып су эчәләр, кырда бәрәңге пешереп ашыйлар... Бу җирләрдә үлем нурланышының мең тапкырга күбрәк икәнлеген белми алар... Соңыннан билгеле булыр—Гөлжиһаннар эшләгән Урыс Караболагы җирләрендә ул вакытта радиация бер квадрат метрга 1000 кюри туры килгән, нурланыш сәгатькә 1000 микрорентген булган... Гөлжиһаннар классыннан монда эшләгән 29 баланың алдагы елларда 18е рактан һәм нурланыштан үлеп бетәр... Гөлжиһан могҗиза белән исән калыр, шушыларны дөньяга чыгару өчен аның исән калуы кирәк булыр... Әмма ул да авылдашлары үткән газаплы юлны ахыргача үтәр, бу авырулардан ахыргача газапланыр...

Хәзергә әнә ул, йөгерә-йөгерә, агач үсентеләре ташый... Аның да кул-аяклары сыдырылып беткән, күзен-башын аксыл тузан каплаган... Әле ярый Таһир бабасы ана иртә белән яулык бөркәтте, чәчләре чиста калды... Рәшидә белән Рабига да яулыктан, чөнки аларның чәчләре бөтенләй коелып беткән... Малайлар Рәшидәне үртиләр, яулыгын тартып төшермәкче булалар, ә ул гел Гөлжиһанга сыена, аннан ярдәм көтә... Бу авырулардан Рәшидә бөтенләй сүзсезләнеп, телсезләнеп калды, аның нәрсә әйткәнлеге дә аңлашылмый... Аны көздән мәктәпкә алмаслар инде, йә Чиләбедәге тиле балалар йортына җибәрерләр, йә авылда укымыйча калыр... Әнә хәзер дә бу эчкерсез дивана кыз гел Гөлжиһан тирәсендә йөри, ничек тә аңа ярарга, иш булырга тырыша... Ә Гөлжиһанның бүген иртәдән бирле башы әйләнә, күз аллары

томаланып-томаланып китә... Теге вакытта, Иртәштә шартлагач та шулай булган иде—эче борып-борып авыртты, авыз-борыныннан кан китте... Хәзер дә Гөлҗиһанның башы шундый нык авырта, әйтерсең, тимер кыршау белән тарттырып куйганнар! Аның авыртуыннан җиргә ятып тәгәрисе, үкереп елыйсы килә, әмма ул башкалардан ояла... Эшләрлек хәле дә юк... Менә ул, укытучы абыйсыннан сорап, Караболак буенда битен-күзен юып килергә уйлады... Бәлки хәле бераз җиңеләеп китәр, чөнки әбисе, авырганда, гел юына, су эчә... Кичкә хәтле түзсә, өйдә әбисе дәвалар иде инде аны, әмма кичкә ерак шул әле...

Ул акырын гына су буена атлады, Рәшидә дә аның артыннан иярде... Гөлҗиһан аны күрмәде дә, чөнки ул инде беркемне, бернәрсәне күрерлек хәлдә түгел иде... Башта аяклары тыңламый башладылар, камыр кебек йомшардылар, һәм Гөлҗиһан тизрәк яшь карагайлар арасына кереп чүгәләде. Көчле авыртуга чыдый алмыйча, ул укшып җибәрде... Шул чак күзен-башын кемдер үткен пычак белән телеп җибәргән кебек булды, көчле авыртудан Гөлҗиһан агач арасына тәгәрәп китте... Башта аның күз алды "гөлт" итеп яктырды, каршында нәкъ теге вакытта күк капусы ачылган кебек булды... Әмма ул вакытта мондый авырту юк иде... Аннан кинәт кенә күз алды караңгыланды, һәм Гөлҗиһан шул караңгы базга ава башлады... Аң бетте, авырту бетте, җан менә чыгам, менә чыгам, дип, кызның күгәргән ирен читләрендә тибрәнеп тора башлады... Зәңгәр күк астында, яшел чирәм өстендә, Гөлҗиһан атлы татар баласы җан биреп, үлеп ята иде...

Җаны аның тәненнән аерылып, туп-туры Караболак өстенә менеп китте...

Гөлҗиһан ап-ачык итеп үзләренең өйләрен, әби-бабасын, әти-әнисен күреп өлгерде... Алар барысы да Гөлҗиһанны көтәләр иде... Аннан ул зур тизлек белән Иртәш ягына таба оча башлады, анда үзенең булачак гаиләсен, ирен һәм балаларын күреп калды... Алар да Гөлҗиһанны көтәләр иде... Ул каршында ут һәм нур күрде, шулар арасыннан сызылып үткән сират күперен күреп калды... Шул турга җиткәч, җан кире борылды, чөнки Гөлҗиһанга аннан үтәргә әле иртә иде... Гөлҗиһан үкереп янган уттан бик курыкты, моның җәһәннәм икәнлеген аңлады... Каршында җемелдәп торган зәңгәр нур, киресенчә, аны үзенә тартты, әйтеп бетергесез рәхәтлек, ләззәт бирде... Гөлҗиһан аның җәннәт икәнлеген аңлады, нигәдер, шунда керәсе, бөтенләйгә шунда каласы килде... Әмма җаны, аны тыңламыйча, томырылып аска очты, яңадан җиргә төште...

Башта аның янына буйга озын бер бабай килде... Ул Таһирҗан бабасына бик охшаган, әмма ул түгел, чөнки бу зат бик биек... Ул, Гөлҗиһан янына тезләнеп, нидер укый башлады... Нәкъ карттае, картнәе Коръән укыган кебек... Ә тавышы Таһирҗан бабасына охшаган... Ул укыган саен, Гөлҗиһанның хәле җиңеләя бара, күкрәгеген басып торган авырлык юкка чыга, ул тагы иркен сулыш ала башлый... Менә озын карт, аның өстенә ныграк иелә дә, нидер әйтә... Ә тавышы нәкъ Таһир бабайныкы кебек... "Су эчмә... Ризык ашама... Монда торма...",—ди... Шул сүзләрне әйтә дә, озын бабай юкка чыга... Гөлҗиһан берни аңламый, зәңгәр күккә карап тик ята... Нигә елгадан су эчәргә ярамый икән? Монда ашарга да, яшәргә дә ярамый, ди... Ә кайда ярый? Шуны сорарга теләп, Гөлҗиһан күзләре белән озын картны эзли башлады, әмма ул юкка чыккан иде... Ә янында, тезләнеп, Таһир бабай утыра, аның янында елап беткән Рәшидә басып тора...

—Теге бабай кайда?—дип сорады Гөлҗиһан, телен чак әйләндереп.

—Нинди бабай, кызым? Монда синнән башка беркем юк... Рәшидә эзләп табып, мине монда өстерәп алып килде, әле ярый машина белән үсентеләр китергән вакытым иде... Кай төшең авырта соң, балам?

—Теге вакыттагы кебек...—диде Гөлҗиһан, хәлсез генә...—Башым бик авырта, бабай...

Гөлҗиһан шулай диде дә, тагы укшып куйды. Таһир карт аның мангаена кулын тидереп карады—Гөлҗиһанның башы ут булып яна иде... Аннан бу ялкын кызның битләренә күчте, тәнен чорнап алды... Ул инде янында беркемне күрми, бары тик нидер әйтеп саташа гына иде... "Моннан су эчмә... Ашама... Яшәмә... Озын бабай..." Моны күреп, Рәшидә тагы үкереп елый башлады, кырга, укытучылары янына торып йөгерде... Таһир карт Гөлҗиһанны тиз генә кулларына күтәрде дә, машинасына таба китте. Лесник хатын Мария белән бергә алар Гөлҗиһанны авылга алып кайтып киттеләр... Гөлҗиһанның инде тын алганы да беленми, тәненнән ут бәреп тора иде... Шушы хәлендә аны өйләренә алып кайтып салдылар... Кайтып кергәндә, аның тәненнән тиресе куба башлаган иде инде... Моны күреп, әнисе аңын җуеп егылды, әбисе елап җибәрде... Ир-ат мәет күмәргә әзерләнә башлады, чөнки Караболакта мондый авырулар берсе дә исән калмый иде... Таһирҗан карт аларга ашыкмаска кушты, "Баланың гомере бетмәгән әле...",—диде... 12 яшьлек Гөлҗиһан яшәү өчен үлем белән көрәшә башлады... Бу көрәш кырык көн, кырык төн дәвам итте...

## Унынчы бүлек

Татар Караболагы авылын тагы көне-төне ак маска-халатлар, противогазлар кигән сәер кешеләр тикшерә башлады...

Аларның приборлары радиациянең биредә йөзләрчә, хәтта меңнәрчә тапкыр артык икәнлеген күрсәтте... Авылда тагы кинәт кенә кешеләр чирли һәм үлә башлады, әйтерсең лә, Караболакка үләт кергән... Бу мәетләрне Чиләбегә алып китәләр дә, эч-башларын ярып, күмәргә буш гәүдәләрен генә кайтаралар... Хәтта сөякләренә хәтле суырып алалар... Халыкның нидән шулай кырылганлыгын беркемгә дә әйтмиләр. "Тикшерәбез",—дип кенә җавап бирәләр...

Хәзер Татар Караболагы башында көн-төн милиция тора, авылга беркемне рөхсәтсез кертмиләр дә, чыгармыйлар да... Коелар күмелде, елгага юл ябылды, инде чират иген кырларына да җитте... Чиләбе өлкәсе башкарма комитеты карары белән, Татар Караболагы авылының 3995 гектар җирләре, моннан тыш 3217 гектар авыл хуҗалыгы җирләре, 2374 гектар сөрү җирләре, 727 гектар печәнлекләр, 29 гектар көтүлекләр, радиация белән агулану сәбәпле, файдаланудан алына, ягъни, халыкка бу җирләрдән файдалану тыела... Караболак авылы кергән Жданов колхозы бөтенләй бетерелә... Чиләбедә, Караболакны күчерергә, дигән катгый карарга киләләр...

1959 елның 29 сентябрендә, "Маяк"тагы атом шартлавыннан соң нәкъ ике ел үткәч, Чиләбе өлкә башкарма комитетында яшерен бер документка кул куела...

546 нчы номерлы бу карар радиациядән көчле зарар күргән Татар Караболагы авылын башка урынга—өлкәнең Әшир, Тахталым авылларына күчерү турында була... Бу күчерүнең 78 миллионга төшәчәге әйтелә...

Әмма атомчылар моның белән ризалашырга теләмиләр... Чөнки алар бу тирәдә яшәүче бөтен халыкның да шулай кузгалуыннан, күчеп китәргә теләүләреннән куркалар... Алар уйлавынча, бу, беренчедән, атом белән бәйле дәүләт серенең таралуына китерергә мөмкин икән, икенчедән, "Маяк"тан зур чыгымнар сорый... Өченчедән—"Маяк"тагы очсыз эшче көчләр читкә тарала... Дүртенчедән... Монысын инде бары тик Ткаченколарның яшерен оешмалары, шушы оешмаларга хезмәт итүче галимнәр генә белә...

Шулай итеп, авыл күчерелмичә кала... Мәскәүгә: "Караболак күчерелде",

дигән белешмә җибәрелә... Кайсы Караболак—урысымы, татарымы—моны беркем тикшереп, җентекләп тормый... Ул арада, бик сәер шартларда, авылда урта мәктәп һәм авыл советы янып китә... Битлек кигән нindидер чит кешеләрнең, бу биналарга ут төртеп, урманга кереп качуларын күреп калучылар була... Шулай итеп, колхоз юк, авыл советы юк, андагы бөтен документлар янган, мәктәп янган, балаларның исемлеге юк... Димәк, авыл үзе дә юк? Ягъни, кешеләре бар, ә авыл үзе юк... Иртәштәге шартлаудан соң Татар Караболагы нәкъ менә шундый сәер хәлдә кала—ул яшәп килгән авыллар исемлегеннән сызып ташлана... Карталардан алына... Урыс Караболагы белән бергә, Татар Караболагы да күчерелгән, дип исәпләнә башлый...

Гөлҗиһан кырык көн, кырык төн буе яшәү белән үлем арасында бәргәләнде...

Башындагы бөтен чәчләре коелып бетте, тәнендәге тиресе урыны-урыны белән кубып чыкты... Авыз-борыныннан, хәтта колакларыннан шаулап кан китте, эче тотмады... Каршы йортта әтисенең энесе Хәбибулла нәкъ шундый хәлдә ята, ул инде бөтенләй кибеп-корып бетте... Күренеп тора—аларның икесендә дә бер үк авыру, әмма аның нинди чир икәнлеген берәү дә белми... Еллар үткәч, мондый авыруларга "нурланыш", ягъни, "лучевая болезнь", дип диагноз куярлар, әмма илленче еллар ахырында кем белсен аны татар авылында? Ә белгән кешеләр әйтмиләр... Район үзәге ерак, Чиләбе исә аннан да ары, үлсәң дә, калсаң да, белүче юк... Шуңа күрә бу зәхмәттән һәркем үзенчә котылырга тырыша, котыла алмаганнар кинәт кенә зиратка күчә... Авылның Караболак елгасы буендагы Сәкәлин дип аталган урамыннан әзмәвердәй ничә яшь-яшь ир-ат шулай тәгәрәп үлде инде... Бүген—бар, иртәгә юк кеше, үлем сәбәбен белмичә дә калалар... Менә Гөлҗиһанның Хәбибулла әзие дә, атна-ун көндә үпкә-бавырларын косып, утыз яше дә тулмыйча, күзгә карап үлеп китте... Иртәштәге яшь хатыны да, берсеннән-берсе кечкенә балалары да, шәһәр читендәге яңа салган өе дә—барысы да торып калды... Төпчек улларын төп йортта калыр дип өметләнеп яшәгән карт ата-ана да утырып калды—әзмәвердәй ир бала китте дә барды...

Нәбиуллаларның зур нәселендә бу беренче олы югалту, көтелмәгән фаҗигалы үлем иде. Улының күзгә карап тилмереп үлүен Нурҗамал карчык бигрәк тә авыр кичерде. Ул ике йорт арасында—оныгы Гөлҗиһан белән улы Хәбибулла арасында бәргәләнде, аларны үзенчә карарга, коткарып калырга тырышты. Өшкерде дә, кот та койды, төрле үлән төнәтмәләре дә эчереп карады, әмма зәхмәт каты ябышкан иде... Таһирҗан карт та аларга Биташ чишмәсе суын эчереп карады, тән яраларына зәңгәр балчык сөртте, әмма Хәбибулланың гомере беткән иде инде... Гөлҗиһан, яшь җан, үлем авызыннан үрмәләп диярлек чыкты, ә Хәбибулла бу газапларга түзә алмады—өзелде... Ул соңгы мизгеленә хәтле үлем белән тартышты, гел терелер кебек тоелды... Ярулла карт белән Нурҗамал карчык аның яныннан китмәделәр, бала караган кебек карадылар, аның өчен балалар кебек утырып еладылар... Ун баладан иң төпчеге, иң газизе, иң таза-савы менә шулай җан биреп ятсын әле...

Үләр алдыннан Хәбибулла аңына килде, янында "тәһлил" әйтеп торган ата-анасына, туганнарына карады... Аның аларга әйтәсе бик зур сере, сүзе бар иде, әмма теле аңа буйсынмады, авызыннан сүзләре чыкмады... Ул, газапланып, авыз эченнән генә нидер пышылдый, мыдырдый башлады... Аның ни әйткәнен ишетергә теләп, Таһир карт якынрак иелде, колагын Хәбибулланың көйгән иреннәренә куйды... Ул: "Атом...Үлем...",—дип пышылдый иде...

—Шәһәдәт кәлимәсен әйт, энем, “Ләә иләһә иллалаһ”, дип әйт,—диде Таһир карт, аның соңгы мизгелләре җиткәнен сизенеп.

Хәбибулла ана тутырып бер карады, иреннәрен чак кыймылдатып, абыйсы артыннан: “Ләә иләһә иллалаһ”,—дип кабатлады да күзләрен йомды... Аның йөзе кинәт кенә тынычланып, йомшарып калды, ирен читләрендә зәгыйфь кенә елмаю күренде... Ул җирдәге газаплардан котылган иде...

Хәбибулланы юып, күмәргә алып чыгып киткәндә, Нурҗамал карчык җиңеләю хәленә килгән иде инде... Әле ярый килене Хәбирә аның яныннан чыгып тормады, үзе авыру булса да, авырсынмыйча, ике йорт арасында бөтерелде. Ирләр Хәбибулланы күмәргә алып чыгып киткәч, берара Нурҗамал карчык ялгызы гына калды... Аның бернәрсәгә дә кулы бармады, ике “рәкагать нәфел” намазы укып алгач кына бераз тынычланган кебек булды... Карчыкның күз алдыннан бөтен гомере, ун баласы тезелеп үтте... Барысы да ир балалар, барысы да Алып батыр кебек, гәүдәлеләр, тазалар, сәламәтләр, бөтен тирә-якка дан нәсел... Менә шул асыл гәрәбәсе өзелеп китте Нурҗамал карчыкның, әҗәл исәп-хисапны аның төпчегеннән башлады... Аларның нәселе ике яктан да туксанга, йөзгә хәтле яшиләр иде, мондый хәлне күргәне булмады аларның, инде башка күрергә дә язмасын, Раббым...

Шушы теләгенә ияреп, Нурҗамал карчыкның күнеленә берәм-берәм шигъри мөнәҗәт юллары килә башлады... Караболак авылында шундый бер гадәт бар—биредә халык нинди кайгы килсә дә, бәет чыгара... Хәтта кеше үзе үлгәнче үк, бәетен чыгарып калдыра, аннан соң аны бөтен туганнар, Караболак халкы елый-елый укый... Хәбибулла, өрлектәй ир, үзенең шулай тиз үләсенә ышанмады, бәет тә чыгармады... Аның хакында мөнәҗәт-бәетне соңыннан әнисе карчык чыгарды... Менә ул, ялгызы гына калып, зират ягындагы тәрәзәгә карап, әле генә улы яткан караватбашында, күңеленнән шул мөнәҗәтне әйтә... Бөтен йорт, урам, Караболак, карт ананың хәсрәтен тынлый, аның белән бергә кайгыра, елый... Балалары Караболак зиратына күчеп яткан барлык аналар аның белән бергә шушы мөнәҗәтне әйтәләр кебек иде...

Тугыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач та сөтемне бирдем.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран,
Баламның хәсрәтен күрдем...

Бишекләрдә тибрәткәндә
Тала иде беләкләрем.
Сезләр тыныч булмасагыз
Әрнер инде йөрәкләрем...

Бала дигән асыл агач
Ананың карнында ята.
Баланың канлы хәсрәте
Ананың йөзен саргайта...

Бәгырь балам, газиз балам,
Ике күземә бер кара.
Синең ялкынында янам,
Сабырлык бир, Раббым Алла...

Нурҗамал карчык ишектән килене Хәбирәнең килеп керүен дә сизмәде, зират ягына карап, үзәк өзгеч моң белән мөнәҗәт әйтүен дәвам итте... Аны ишеткәч, Хәбирә, үксеп елап җибәрмәс өчен, куллары белән авызын каплады, әкрен генә ишек янындагы урындыкка килеп утырды. Көзге эңгер иңә башлаган буш йортта карт ананың йөрәге телгә килеп сөйли иде...

Йөрәкләрне утлар алган,
Бәгырьләрне шулар ярган.
Бу хәсрәтнең ачылары
Рәсүлуллаһбыздан калган...

Исемен язып калдырдым
Яна торган яфракларга.
Түзмәенчә ни хәл итим
Үзең биргән хәсрәтләргә...

Анадан туа бер бала,
Дөнья утларында яна.
Шул утларда яна-яна,
Кара туфрак чорнап ала...

Хак Тәгалә хәсрәтенә
Үз рәхмәткәйләрен биргәй.
Һәр адәмнең язмышында
Ходаның тәкъдире бар, кый...

Бу сүзләрне ишеткәч, Хәбирә түзә алмады, урындыкка капланып, елап җибәрде. Аннан кайнанасын килеп кочаклап алды, хәзер инде алар бергәләп елыйлар иде... Һәркем үзенекен уйлады: Нурҗамал карчык—кара жир куйнына кереп яткан улын, Хәбирә—үлем белән көрәшеп яткан кызын... Алай да Хәбирәнең өмете бар иде—Гөлҗиһан бүген күзләрен ачты, кеше таный башлады, картнәен сорады...

—Гөлҗиһан күзен ачты, әнкәй,—диде ул, бераз тынычлангач.—Сине сорый, "Картнәй нигә керми?",—ди...

Нурҗамал карчыкның сүнеп барган күзләренә җан кергән кебек булды, туңып барган йөрәге янадан тибә башлады... Үз хәсрәте белән тулышып оныгын исеннән дә чыгарган бит, югыйсә, ул да хәл эчендә ләбаса, үлем белән көрәшеп ята...

—Сөйләшә башлады, дисеңме, килен?

—Әйе, әнкәй, бераз тавык шулпасы да йотты бүген...

—Әй, рәхмәт яугыры... Әйдә, килен, алып чык мине тизрәк Гөлҗиһан янына... Картнәен көтеп ята икән бит, сабыем...

Килен белән кайнана, шушы шатлыклы хәбәрдән дә яңадан тугандай булып, Гөлҗиһан янына ашыктылар... Алар өчен яшәү мәгънәсе хәзер шушы бала иде...

Ничә көннәр ут эчендә кан косып яткан Гөлҗиһанны, инде терелмәс, дип уйлаганнар иде... Алар классыннан Урыс Караболагында эшләгән берничә бала шулай кисәк кенә үлеп киткәч, Гөлҗиһанның әнисе, елый-елый, кызы өчен кәфенлекләр әзерләп куйды... Шулай итеп, бер елда ике баласын күмәргә туры килерме икәнни? Кап-кара мазутка чорналып, үле туган баласын күмде бит инде ул бу җәй... Ул, авырлы килеш, кыш буе басуда төтенләп торган эскерт өсте төшереп йөрде, укшып, ак кар өстенә ауган вакытлары күп булды... Яз җитүгә, мәҗбүриләп, Урыс Караболагына

кудылар, авырлы дип тормадылар, мылтык астында чиркәү кирпечләре ташыттылар... Ул, борынына житкән корсагына терәп, аларны машинага төяде, Гөлжиһанга авыр булмасын, дип, анын өлешен дә күтәрергә тырышты... Кирпечләр өстенә утырган аксыл тузан авыз-борынына, күкрәгенә тулды, укшытты, костырды... Анын радиация тузаны булганлыгын Хәбирә кырык елдан соң гына беләчәк... Эшли алмыйча кире чыккан саен, кораллы сакчылар аларны янадан шунда кудылар... Үле бала табуынын сәбәбен Хәбирә әнә шунда тончыга-тончыга эшләвеннән күрде... Балага, "Галия" дип исем кушып, юып-кәфенләп күмделәр... Инде Хәбирә менә икенче баласына—олы кызы Гөлжиһанга кәфенлек әзерләде... Бары тик Таһиржан карт кына бу кайгыга бирешмәде, Гөлжиһаннын үләренә ышанмады, шул барысына да бераз көч-өмет бирде... Таһиржан карт Гөлжиһан яныннан китеп тормады, ана бары тик Аллакүл чишмәсе суын гына өшкереп эчерде, шунын белән бит-кулларын, бөтен тәнен юдырды, тагы үзе генә белгән әллә нинди хикмәтләр, әллә нинди догалар кулланды... Ул Гөлжиһанны теге дөньядан үз куллары белән тартып чыгарды, чөнки әле анын гомере бетмәгән иде...

Гөлжиһан, барысын да таң калдырып, аңына килде һәм картнәен сорады... Бу—Хәбибулланын үлгән, Гөлжиһаннын янадан яши башлаган көне иде... Кызы янында кайнанасын калдырып, Хәбирә ире каршына шатлыклы хәбәр житкерергә ашыкты... Башта үзе озаклап авырып ятып, аннан кызы, кайнәнесе белән ике арада бәргәләнеп йөреп, Хәбирәнен шактыйдан Караболак урамнарына чыкканы юк иде... Ул, читәнгә сөялеп, жанга газиз бу күренешкә озак карап торды, янадан тугандай, өзелеп, сагынып карады...

Хәбирә—ятим бала, аның ата-анасы 1921 нче елгы ачлыкта Галикәй авылында үлеп калган... Ул кечкенәдән Караболакта, ерак туганнарында тәрбияләнде, шуна күрә, Караболак аңа туган авылы кебек якын, кадерле... Ул шушында авылның иң матур, иң булган егетенә—Алып Ханнар нәселеннән Нәбиуллага 16 яшеннән кияүгә чыкты, аны сигез ел армиядән, сугыштан көтеп алды... Беренче балалары туу белән үлде, Нәбиулла аны күрмичә дә калды... Икенче балалары Гөлжиһан, озак еллар үткәч, Нәбиулла сугышлардан исән-сау әйләнеп кайткач, 1946нчы елны гына туды... Һәм, шуннан соң, нигәдер, тагы озак еллар баласы булмады Хәбирәнең, бу елларда авылда, нигәдер, балалар аз туды, туганнары да гел чирләшкә була башлады... Моның сәбәбе—үзләреннән кырык чакырым ераклыкта эшли башлаган атом реакторлары икәнлеген авыл халкы әле башына да китерми иде... 1957 елгы шартлауга хәтле үк, Иртәштәге дистәләгән атом казаны ун ел буе йөз чакырымдагы бөтен тирә-якка үлем нуры тарата башлаган иде инде... Шартлау шушы кырылышнын дәвамы гына булды... Әмма Караболак халкы болар турында кырык елдан соң гына дөресен белә алды... Ул вакытта авыл халкы шушы атом нурыннан кырылып бетә язган иде инде...

Әле хәзергә кырык яше дә тулмаган Хәбирә, читәнгә сөялеп, Караболакка карап тора... Авыл, монсу гына саргаеп, үзенең алтын көзенә кереп килә икән инде... Дөнья хәвеф-хәтәр белән тулы булса да, табигать барыбер үзенекен итә—вакытында жәе-көзе килә, вакытында кошлар кайта, үз вакытларында китеп тә баралар... Әнә, Караболак өстеннән дә, тезелешеп, торналар очып бара... Бакчаларда инде бәрәңге ала башлаганнар, яшелчә өлгергән, алмалар коелып, тәгәрәшеп ята... Исән кешенен яшисе бар, шуна күрә беркем дә үлем көтеп ятмый... Караболак халкы, гомумән, дөньяга бераз өстен торып, фәлсәфи күзлектән карый, авызы тулы кан булса да, аны кешегә күрсәтми... Караболаклыларны аңламаган башка авыллар моның өчен аларны тәккәберлектә гаеплиләр, имеш, әллә кем булып, борын

күтәргән булалар... Ә Караболак халкына әллә кем булырга кирәкми, ул үзенең кемлеген бик яхшы белә, шуңа күрә, бугазларына үлем басканда да сер бирмиләр, кеше кебек яшәп калырга тырышалар... Хәбирә үзе дә хәзер алар кебеккә әйләнеп бетте инде, шуңа күрә Караболак турында беркемнән дә начар сүз әйттерәсе килми...

Ире Нәбиулла каршына елга буйлап кына барырга булды Хәбирә. Яр буйлап сузылган тимер чыбыкларны күреп, ул тагы сискәнеп китте. Куркыныч, ямьсез иде бу күренеш, Караболак өчен бөтенләй чит-ят иде... Әмма халык аңа бик игътибар итми, күрәсең, кем кайдан тели, шуннан йөреп торалар, суын алалар, балыгын тоталар... Ә балык һичкайчан булмаганча күп хәзер Караболак суында. Авыл халкының мондый хәлне әле беркайчан да күргәне юк иде. Алар бүрәнәдәй озын, симез, итләре ашап туйгысыз... Әмма Караболак халкының элек-электән балыкка артык исе китмәде,—ул ит белән яшәп өйрәнгән халык, шуңа күрә балыкны да читтән кайткан яшьләр генә тота... Хәбирә күреп калды, әнә хәзер дә яр буенда балык тотып йөрүчеләр бар, барысы да кайткан халыкка охшаган... Кызыксынып, Хәбирә ярга якынрак килде һәм имәнеч хәлне күреп, чак кычкырып җибәрмәде. Бу кешеләр тотып чыккан балыклар дөм сукыр, аларның тәннәре тишкәләнеп беткән, хәтта үлекләп тора иде... Хәбирә шул чакта су буендагы кешеләрнең дә битлектән һәм ак халатлардан икәнлеген күреп алды һәм тизрәк ярга үрмәләде... Бу чирле балыкларны читтән килгән белгечләрнең тикшереп, җыеп йөргәннәрен аңлады ул...

Зират ягыннан кайтып килгән ирен Хәбирә әнә шул хәлдә каршы алды. Ул аңа башта Гөлҗиһанның терелүен хәбәр итте, аннан Караболак ярында күргәннәрен сөйләп бирде. Нәбиулла бу хакта белә икән инде, авыл халкы да тәннәре тишек сукыр балыкларны күргән, хәзер беркем елгага якын бармый икән. Кемнәрдер авыл башындагы Бугай сазлыгыннан эт башы зурлыгындагы бакалар да күреп кайтканнар, алар эт өргән тавыш чыгарып, кычкыралар, имеш... Кемдер бу көзне урманда кеше башы зурлыгы гөмбә тапкан, кемдер ике башлы төлке күргән... Үз гомерендә мондый хәлне күрмәгән-белмәгән Караболак халкы, чын мәгънәсендә, шомлана калды, су буена төшмәс, урманга кермәс булды...

Шулай итеп, атом шартлавы астында калган татар авылы үзенең фаҗигалы яңа тарихын башлады...

Инде аларны каядыр күчерү турында беркем сүз кузгатмый, киресенчә, бөтен чәчүлек, көтүлек җирләрен янадан аларның үзләренә кайтарып биргәннәр иде... Мең елга җитәрлек радиация белән агуланган җирләрдә халык яңадан иген игә башлады, малын йөртте, яшелчә-бәрәңгесен үстерде... Ә алар котырып үсте, гомер күренмәгән уңыш бирде, Караболак халкы иген-икмәген, яшелчә-бәрәңгесен кая куярга белмәде... Чөнки, Караболак кырларында үскән игенне, яшелчәне беркая да кабул итмәскә, дигән яшерен әмер бар иде... Караболак халкына хәтта абзардагы тиресне дә авылдан читкә чыгарырга ярамый иде... Аларны күршедәге урыс совхозы Кояшка кушып куйдылар һәм тынычлыкта калдырдылар... Кәгазьләрдә күчерелгән, гамәлдә үз урынында утырып калган Татар Караболагы авылы яшәү өчен көрәшнең яңа чорын башлады...

*Ахыры киләсе санда.*



## Эльмира Шәрифуллина

# АЙ ЙӨЗЕНДӘ АЛТЫН АЛКА...

### Килеп җиттем

Дәрьялардан, упкын арасыннан
Исән калып чыккан бәхетем,
Тәкатьлегә, эшле, кадерлегә
Дип куелган ошбу тәхетем—
Җиттем сиңа мең бәлане җиңеп,
Егыла-тора атлап, үрмәләп.
Мин ханбикә бүген биләмәмдә,
Баш иялэр гөлләр, чүгәләп.

Килеп җиттем, мөлдерәмә тулы,
Түм-түгәрәк ямьле яшемә.
Җиккән атым саз, су ерып килде,
Тиргә батты (һәм күз яшемә!)...

Качам, дидем, ташлап бу арбаны
(Җен-пәриләр, ахры, төялгән...).
...Ризалаштым тагын:
Бар рәвешем—
Авырлыкка инде көйләнгән...

Тарттым шулай,
Телем тешләп тарттым,
(Каршыгызда—булган исем-атым!..)
Килеп җиттем бүген, иншалла!
Коелыгыз, җен-пәриләр, җәһәт,
Кузгал, арбам,
Атым, на, алга!

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА — *шагыйрә; "Яңгыр җиле", "Сөюемнән мин бер чибәр идем" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

**...Чоңгылларсыз, киртә-сикәлтәсез**
**Тигез юлдыр, бәлки, алдымда?**
**...Гомер—дөмбер,**
**Бөек Ихласлыкка**
**Менәр юлда, Шагыйрь, абынма!**

## Атка мәхәббәт турында кыйсса

*Шәкүр карак ярлы-ябыга малына тимәгән. Аның исеменнән ат урлаган бер төркемгә, искиткеч акыллы атка юлыгып, көтүне иреккә җибәрткән, имеш.*

Халык телендәге риваятьләрдән.

**...Үрчеделәр заман шәкүрләре—**
**Көтү белән атны урларлар...**
**Ә Шәкүр ул иң кәттәсен әзли,**
**Барон аты анда,**
**Йә паннар!..**

**...Гамбургка сәфәр чыкмак иде...**
**Ташлап барлык мөһим эшләрен,**
**Карак законнарын бозучының**
**Үзе коймак булды "тешләрен".**

**"Мин атларны төсе белән түгел,**
**Исе белән хәтта аерам.**
**Беренче кат,—диде, Шәкүр карак—**
**Кеше ышанмас хәлгә тарыгам.**

**Атларның гел асылларын "чирттем",**
**Асылларда кодрәт, ялкын бар!**
**Хилафланып куган бу көтүдә**
**Ниндидер сер,**
**Гайре шаукым бар.**

**Килгән көннән башлап күзәтәмен**
**Арандагы ярсу Байталны.**
**Йә хуҗасы,**
**Йә ат үзе изге—**
**Җибәр, үрдәккәем[1], бу малны".**

**Аратадан чыккач мәгърур Байтал,**
**Ат патшасы Шәкүр каракка**
**Башын какты...**
**Аннан кешнәде бер**
**Ат көтүе торган тарафка.**

**Йөгереп килде Бурлы бия белән**
**Алмачуар сылу колыны.**
**Әмер булды,**
**Чыкты алары да...**
**Чап та кит бит,**
**Табып юлыңны.**

---
[1] Шәкүр Рәхимовның яратып әйтә торган сүзе.

Күз яшенә чумган Байтал шунда
Ни эшләде диеп, уйлыйсың?
Тезләренә чүгеп башын орды,
Өйрәтелгән ат дип, торырсың!

Горур башын чөеп, Шәкүрнең ул
Күзләренә тутырып карады.
Абзаңны бу тәмам уйга салды:
Ат теленме әллә аңлады?

Сакчыларга тагын ым ясады,
“Чыгарыгыз,—диде,—
Барсын да!
Рәнҗетсәң, йә әллә ни күрерсең.
Кеше акылы бар монысында...
Насыйп булса, кайтып җитәрләр шәт,
Ара ерак инде ерагын.
...Дөньядагы җиде могҗизаның
Берсе кебек булган бу “фал”ның
Сере нидә икән?
Белеш әле”,—
Диеп, мине юлга чыгарды...
Һәммә атның исәнлеген күреп,
Юлаучыбыз күңелен “тугарды”:
—Мәхәббәт ул әнә шундый була!
Ә кешенең соңгы атына?..
Юк, юк,
Киресенчә, ярдәм кулы суза
Ятим-җилпе, сырхау бахырга.

Ат җанлы ул,
Сөйгән атларының
Алтын-көмеш нукта башында.
Караклыктан өстен Сөю хисе,
Комсызлык—чүп Сөю каршында!

## Саклый авыл

Кара яз—
Карлы көзгәчә
Иген игә авыл халкы,
Куныш басуында ята,
Ял итәргә юктай хакы...

Акыл, зиһенкәен җыеп
Уйлаганы—фәкать иген.
Ипекәйгә табынганга
Белә яхшы—яман чиген.

Шушы авыл саклап килә
Кан хәтерен, биеклекне,
Тамырлардан җәйрәп аккан
Татардагы бөеклекне!

Саклап килә ничә гасыр:
Өметләрне, хыялларны,
Кыйблабызны югалтмаслык
Иман, ныклык догаларын.

Илгә ак нурларын сибеп,
Яшәешне дәвам итеп,
Милләтемнең асыл йөзен
Киләчәккә, алга илтеп,

Кара яздан—карлы көзгә
Баш күтәрми тарап кырын,
Ымсынмыйча һичнигә—Ул
Суза һаман
Яшәү җырын!

## Ипи пешә

Кичке авыл мичләрендә,
Утын яна эчләрендә:
Дөрли генә яркалары,
Сикерә ут алкалары,
Очып-очып китә шартлап,
Бабам тора мичне мактап.
Сырхау әбием терелә,
Йөзкәеннән нур түгелә...
Кинәндереп һәр күңелне,
(Мәшәкате дә күңелле),
Бар кайнарлыкны сеңдереп.
Ипи пешә—йөзе килеп!

## Соңгы чиктә

И, и генә,
И, сез генә.
И, без генә, туганнар!
Кан-яшь түгеп
Гомер сөрә
Туганнарын җуйганнар.

И, и генә,
И, сез генә,
И, без генә, җаныйлар.
Кадерлесен җуйган җаннар
Бирчәйгәч тә каныйлар.

И, и генә,
И, сез генә,
И, без генә, якташлар.
Соңгы чиктә
Туган җиргә
Кайтып ята күп башлар.

## Хыялыма уелып

Йөрим кайчак кара коелып,
Күңелкәем төшә кыелып.
Гомер үтте, яшәп булмады
Калын җилкәләргә сыенып.

Йөрим кайчак кара коелып,
Бәгырьләрем чыга суелып.
Бәйрәм ясый кемдер үзенә,
Минем кайгыларда коенып.

Йөрим кайчак кара коелып,
Йөгерәм дә... Калам тыелып.
Өмет кенә оча гарешкә—
Хыял-хисләремә уелып...

## Буй җитмәслек җиргә

Ай йөзендә моңсу шәүлә күрдем—
Мин үземме?
Әллә өермәм?..
Күңелемне китеп алганның да
Кайгы-хәсрәтенә сөенмәм.

Ай йөзендә якты очкын күрдем—
Шатлыгымнан янам, сибеләм.
Яннарыңа очып барыр мәлдә
Кире чабам, кире йөгерәм.

Ай йөзендә алтын алка күрдем,
Алам диеп, әмма үрелмәм.
Үрелепләр буем җитмәслеген,
Сүзем үтмәслеген бик беләм...

---

## *Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

### "Безнең юл"
### журналына абунә дәфтәре ачык

**"Безнең юл"**да даими язышучылар: Галимжан Ибраһимов, Гасыйм Мансуров, Фәтхи Бурнаш, Сәлах Атнагулов, С.Йәнәкәй, Фатыйх Сәйфи, Гаяз Максудов, Шәһид Әхмәдиев, Шамил Госманов, Әминә Мөхетдиния, Исхак Рәхмәтуллин, Галә Ходаяров, М.Гали, Кәрим Әмири, Садрый Жәлал, Г.Рәхим, Г.Газиз, Фатыйх Әмирхан, Ф.Әмирхан-II һәм башкалар.

**"Безнең юл"**ның программасы:
1) гыйльми-сәяси мәсьәләләр;
2) революция һәм партия тарихыннан материаллар;
3) партия һәм совет төзелеше;
4) пропаганда;
5) кәсептәшләр *(профсоюз)* хәрәкәте;
6) Шәрыкне өйрәнү;
7) әдәбият һәм сәнаигы нәфисә *(сәнгать)*;
8) Татар Җөмһүриятендә иҗтимагый-икътисади хәлләр;
9) нәүбәттәге мәсьәләләр;
10) рәсми бүлек (партия һәм советның мөһим карарлары, тәгълиматлар);

**"Безнең юл"**га абунә бәһасе: 3 айга бер сум, бер айга 40 тиен (алтын бәһасе белән).

*("Безнең юл". – 1922. – N 1.)*



**Динә Әхмәтова**

## ТӘТЕ

ХИКӘЯ

—Сиңәйтәм, сугым ашына кемнәрне чакырырга икәнен янәдән барлап чыгыйк әле, берәүсе дә онытылып калырлык булмасын. Үртәлеп, мәсхәрә йотып йөрерсең аннан.

Ире эндәшмәгәч, Энҗүдә, бармак буыннарын бөгә-бөгә такмаклап, өстәл артында турсаеп утырган малай алдына дәфтәр бите куйды:

—Яз, улым, әйдә... әйдә, җәтрәк...

Әле мөгезләнеп кенә килүче көр Буянны суйганнары өчен бернәрсәгә дә, беркемгә дә буйсынырга теләмәгән малайның үз кайгысы: нинди кансыз, хәтәр бу тормыш!.. Яраткан бәбкәләреннән мендәр ясадылар, бәтиеннән киез итек бастылар, хәзер инде Буянны ашыйлар. Истәлеккә бары тик кыңгыраулы муенчагы гына калачак...

Авыл җирендә ашка чакыру ул үзе бер сәясәт. Берәрсе онытылып калсамы?.. Әшнәлек дипломатиясе—бик нәзберек нәрсә. Имин яшим дисәң кануннарны сакла, язылмаган кануннарны...

Малай, колынга охшап бөгәрләнгән постауны уңаена сыпырып алды һәм авыр сулап язарга кереште.—Минһаҗ абый, Гөлминәч апа... Хәмзә абый, Бикә апа...

Күршеләрне беренче итеп язасын ул үзе дә чамалаган иде.

—Сиңәйтәм, Тимер!—дип кече яктагы иренә эндәште Энҗүдә.

Ул ирен ишетми дип уйлады күрәсең.

Әз сөйләшеп күп эшләүче Тимер, ишетәм бит инде, дигәндәй, теге яктан тамак кырып кына тавыш бирде. Аның Тимергалиме, Тимерҗанмы, Тимерханмы икәнен инде хәтта хатыны да оныткан һәм белергә дә теләми иде. Тимер һәм бетте китте.

—Ут күршеләребез Гөлминәч белән Минһаҗ... Хәмзәне, Бикә белән... Җайлы кешеләр, Аллага шөкер. Бу юлы да ничек булыштылар...

Күршелек күренеше шулай ук сәясәт. Хәл кадәри хөрмәт күрсәтеп түр башына утыртып, күнелләрен күрергә исәп тота иде Энҗүдә. Аллага шөкер,

---

Динә ӘХМӘТОВА — *яшь язучы; хикәяләре вакытлы матбугатта даими басыла. Чувашстанда яши.*

йомыш төшкән чакта да, төшмәгәндә дә керешеп йөрештеләр. Бәтиләре туса да бер-берсенең хәл-әхвәлләрен белештеләр, табыклары күкәй салса да кучтәнәч итеп керттеләр, буш савыт белән йөрмәделәр. Шөкер, сынар шырпы да бирмәстәй күршеләр алардан ерак яши иде.

Алданрак берсендә угыз ашында булдылар Энҗүдә белән Тимер. Менә киләсе җомгага икенчеләренә кашка тәкә чалу хөрмәтенә чакырулы. Гел шулай, ашка—аш, гел кара-каршы...

—Бәкедә эчәк тапташкан Әфүзә белән Зәмзәмне язып куй...

Бу аналы-кызлы ике тол хатын һәрбер сугымның алыштыргысыз булышчылары. Эшкә талымсыз, күнелгә-тәнгә пакь, куллары алтын.

—Үзегезгә иптәшкә ятимә кызларын да чакыр. Бераз билдәмә биреп җибәрербез, инәкәй белән әтәй өчен сәдака булыр. Безгә рәнҗеп ятмасыннар... Бу юлысы безнең белән куана алмыйлар шул инде.—Энҗүдә авырткан сүзләрен кабатлый-кабатлый түбырча эчендәге сурәтләргә барып орынды:

—Түр башындагы бизәкле сандыкка язгы боз калынлыгы түшәк җәеп утыртып куйган булыр идем үзләрен...

Бу матур күренешләрне беравык күз алдына китергәндәй туктап калды хуҗабикә. Туганнарны дип тә әйтер иде, туганнары калмады шул. Хәйдәр абыйсы якты дөньядан киткәнгә биш былтыр. Җиңгәчәсе Свердлауда, кайтса балалары белән Сабан туе вакытларында гына кайтыштыргалый.

Энҗүдә тома ятим кеше сыман яулык чуклары белән күзләренә тигәләп алгалады һәм кинәттән нәрсәдер исенә төшкәндәй, иреннәрен тешләп туктап калды... Бераздан, туктап калган вакыты әрәмгә киткәндәй, Тимергә тукый-тукый тезеп китте:

—Кара аны, салып алдыңмы—артыгын “кыйлана” торган алама гадәтең бар. Кунаклар “кый” дип утырырлык булмасын. Кордашлар килде дип мылтыгың белән мактана күрмә тагын... Кара аны...

Тимер дәшмәде. Бу аның “ярый-ярый” дигән җавабы иде инде. Авылда артык күп сөйләшкән ир-атларның дәрәҗәсе, абруе булмый. Ир-ат өчен күп сөйләшү—начар сыйфат. Тумадан килгән шәхси исеме дә анар әз сөйләшүне мәҗбүрили иде.

—Булдымы жиде... Үрәтник Дамирны да чакырабыз Гөлкәе белән. Аларсыз булмас. Сигез, тугыз...

Язып куй, дигәндәй, Энҗүдә улына ым какты. Нидер буласын алдан ук сизенгәндәй, ул авыл түрәсенең килүен бик тели иде. Хөрмәт күрсәтү үзе бер нәрсә. Ә менә алай-болай тавыш-мазар чыга калса, аның белән тынычрак булачак. Һәм гомумән, түрә кечкенәме, зурмы, ул-бу дан саклануның иң яхшы чарасы... Ни дисәң дә өйдә Тимернең тимер мылтыгы бар бит...

Энҗүдәнең, быел, беренче кар төшү белән үк бу ак дөньядан бер-бер артлы бакыена күчкән, гомергә кулыннан биш инә төшмәс инәкәен, ярчык яраларыннан гына торган әтәен искә алып сызлануына тагын мылтык кайгысы да килеп өстәлде. Булса да булыр икән кайгы... Нәзер буләген, ядкарьне ташлап, юк итеп тә булмый, саклап тоту да хәвефле, куркыныч хәл.

Әтисе (аны авылда Чатан Вәли дип йөртәләр иде) булган бөтен сугышларны да үткән кеше, гомер буе чормада, борыска чокып ясалган чокырда саклаган мылтыгын, үләр алдыннан Тимергә үз куллары белән биреп калдырды. Гомер буе юмарт булды мәрхүм. Булдыра алса бөтен нәрсәсен бушлай өләшер иде. Шулай юмарт дигән исемгә өлгәшкән кешенең дә әле кешегә бирмәгән әйберсе, күрсәтмәгән нәрсәсе калыр икән Ходаем. Өрфия җаны менә чыгам-менә чыгам дип дерелдәп торганда мулла кебек мәкамләп сөйләде:

—Кара аны... үзем, яулар тынгач, ялгыш сынар куян да атмадым... атасы

булма... тыңла сүземне...—дип, ул соңгы тапкыр гәрәбә саплы түтәне сыпырды. Шома көпшәдә—гүр суыклыгы, ә түтәдә әле кул җылысы. Соңгы сүзләр, васыять—тел очында.—Күңелем тыныч булыр, тәтесен суга ташлый күр, зинһар... Шулай тынычрак, ышанычлырак булыр.

Шулай итеп, көзнең соңгы караңгы төнендә, Энҗүдә, белгәннәрен укый-укый, тәтене Фазлый коесына томырды.

Иртәгәсен ишеп ак кар яуды. Шуны гына көткәндәй, Чатан Вәли җан бирде. Гәүдәсе йомшак булды, дип әйткән ди юучы. Җидесеннән соң, ак намазлык өстендә дога кылып утырган җиреннән оеп кына инәкәе дә китеп барды.

Юк шул инде алар, түр башына башкаларны утыртырга туры килә...

—Түгәрәк апаң белән Юнысны да язып куй,—дип телгә килде кече яктан Тимер, бергә амбарда эшләүче сабакташын чакыртасы итеп. Ярамый калдырырга. Әвендә гел бергә әвәрә киләләр, амбар ширкәте үзе бер дәүләт бит ул.

Түгәрәк апаның да чын исеме Зәйтүнә булып, ул да халыкта онытыла бара һәм аны инде беркем дә искә төшереп мәшәкатьләнми иде.

Энҗүдә дә үз әшнәләрен кыстырырга ашыкты:

—Ун, унбер... Алайса Сүсән Сәгыйтьне Ханәсе белән...

Ханә аның иң якын ахирәте: кыш буе ферма тирәсендә йөренәләр, җәй буе төрле эштә дигәндәй... Кичләрен бергә биләмгә йөриләр. Тормыш тәҗрибәсе дә күбрәк аның, чөнки, Сүсән Сәгыйть кияүгә бик иртә урлап алып кайткан бит үзен. Кем колгадай озын булганы өчен Сузан, кем салам кебек сары булганы өчен Сүсән дип буташтыргалыйлар. Ханәнең үз исеме дә бик буталчык булып чыккан әле менә. Олы малайларын армиягә озатканнар иде, Байкал ягына ук барып олаккан. Ата-анасының исемен сорагач “Мама—Хана” дип әйткән ди. Әнисе юк дип уйлаганнар имеш.

—Унике, унөч... Бер дә матур сан түгел... Тагын кемебез чакырылмыйча калды?

Чапырыш Мөхәммәтне, дөресрәге “Тузмөхәммәт”не хатыны белән култыклаштырып чакырмасаң тузыначак инде... Урамнан үткәрмичә туктатып теңкәңә тиячәк.

Ә чакырсаң?.. Әгәр чакырсаң тагын да яман. Бигрәкләр дә килешсез кылана шул. Эчеп, тузып, холыксызланып бөтен бәйрәмнең бәрәкәтен җибәрәсен көт тә тор!

—Ярый, булсын яхшылык. Мөхәммәт абыең белән Җәмилә апаңны да язып куй... Ундүрт, унбиш... Үзебез белән уналты, унҗиде, балалар белән—егерме.

Егермеләп кеше җыелу инде ул ярты авыл дигән сүз. Әле аның артыгын өйгә дә сыйдырып булмас.

—Йа рабби бер Ходаем, йа Аллам, тыныч, хәвефләрсез генә үткәрергә язсын инде, үзеңә тапшырдык,—дип, йомышчы малаен озатып калды.—Кара аны, фәтуасыз булма, яхшылап чакыр. Кичке сәгать бишкә диген.

Әлегә кадәр “кәҗәләнүе” бетмәгән малай актыгы атылып чыгып йөгерде. Кайвакыт кечкенә кешегә дә мәсьәләне зурларча чишәргә туры килә. Барысын да чакырды малай. Тик Тузмөхәммәтләрне чакырмады. Этләре кертмәде дип сылтау тапты.

Шулай да коега суга төшкәндә Энҗүдә үзе Тузмөхәммәтләрне күреп дәшмичә кала алмады. Димәк, шулай кирәк булган.

Үсмер кызы белән бәлешләр бөгеп, ашка токмачлар кисеп, нигъмәт-ганимәтләр әзерләп, вакыт сизелми дә үтте. Гел бәлеш төбе дә бәлеш төбе диярлек булмасын дип, чамасыз тырышты хуҗабикә.

Энҗүдә чоланга кырык чыгып кырык керде. Чыккан саен бизәкле тимер

сандыкка авыр карашлары текәлеп җәфа чикте... Кайда да махы бирергә өйрәнмәгән Тимер эчеп алгач кордашлары алдында гайрәтләнмичә калмас. Икенче урынга яшереп куярга кирәк дип, сандыкны ачты, алъяпкычын салды, сандыктагы капчыкка инде кирәкмәгән уклауны сонды, ә мылтыкны алъяпкычына урады.

Кызы пөхтәләп постауны өстәлгә җәйгән арада, чүпрәк аша салкыны белән чеметеп торган мылтыкны җәһәт кенә мич башына, чаршау артына шудырырга өлгерде. Белгән булсачы... Белгән булсачы иренен инде мич башында сырахәнә ясаганын...

Чакырылган кунаклардан тыш, чакырылмаган кунаклар да килә торган гадәтләр бар бу авылда. Йомычканы йомыш итеп, кичке энгер-менгер җитмәс борын тәбә белән кысыр аштан гайрене күрмәгән Фатыйма—исәр Патый "аман гына торасызмы?.." дигән булып, тәмле аш-бәлеш тансыклап ишек какты.

Үзалдына көлеп куйды Энҗүдә. Көлке инде. Кешеләр мунча кереп беткәч, аны качып-урлап мунча кереп йөри икән дип сөйлиләр.

Кытлык вакыты түгел әле. Исәр Патый килде дип кайгыга батар хәл юк...

Бераздан, ягъни чакырылмаган кунаклардан соң, чакырылган кунаклар да килә башлады.

Энҗедәй тешләрен ялтыратып барысын да елмаеп каршы алырга тырышты Энҗүдә.

Матур сүзләр, шаян тостлар белән гөж килеп мәҗлес дәвам итте. Бетмәс бәрәкәтләр, киселмәгән бәхетләр, ишле маллар теләделәр. Гел шулай ярдәмләшеп, бәйрәмнәргә дәшеп яшәү хөрмәтенә бертуктаусыз бокалларны чәкештерделәр.

Соңгарак калып, култыклашып, Түгәрәк хатыны белән Юныс сабакташ та килеп житте. Түгәрәккәй бәлеш чите кебек итеп өскә түгәрәкләп үргән чәчләрен төзәткәләп алды. Кунакка бару йоласының бөтен нечкәлекләрен үтәгән: сизелер-сизелмәс кенә хушбуй бөркегән, сөрмә тарткан, әле энәдән генә төшкән купшы бөрмәле зәйтүн төсендәге күлмәгенә брошка калаган, муенында яхут муенса, кулында көмеш беләзек, колагында тулы бер колониясе белән ишле асылташлы алка, бармагында зәркән йөзек...

Бәхет йөзлеге белән туган дип сөйлиләр аны. Шуны гел үзе белән йөртә икән... Менә ичмасам бәхетле кеше. Унды Юныс хатыннан, ну унды... Тормышта моңарчы булган шатлыкларын тартып алмыйча, тагын да яна шатлык-куанычлар гына өсти бара кебек ул. Була бит шундый хатыннар да, беренче көннән үк ирен үзгәртә башлый.

Таза кеше юмарт, йомшак күңелле була диләр. Түгәрәк апа дип йөртелгән Зәйтүнә дә күнеле белән шулкадәр эчкерсез, саф, ул шатлыкны гына түгел, кайгыны да бәхеткә әйләндерә беләдер кебек иде. Шул арада, хәтта почмакта үз көннәрен үзләре күреп утырган балалар белән дә кәнфитләнеп алырга өлгерде.

Мәҗлестәшләр Бавыр Юнысны штрафлап кинәнделәр.

Өредән генә торган шулпаларда үзенең чалымын тоеп ул торып басты. Шаян тост буласын сизенгән кунаклар шунда ук, әле ул сүз башламас борын ук көлешеп куйдылар.

—Ни бит, сабакташ... Нитеп ятырга туры килде...

Халык тагын да отыры кубып көлеште.

—Син мине теге ни, бик нитмә инде... Яме. Инде дә килеп безне шулай зурлап ниткәнең өчен бик зур рәхмәт. Ниләрең гел шулай кәр булсын, күп булсын. Безгә барыбызга да, тагын да шулай нитеп, нитешеп яшәргә язсын. Менә шуларның барысына да кушылып ниләрегезне нитеп җибәрүегезне үтенәм...

Бөтен кеше егылышып көлгән мәлдә, мич арасында йөрәген тотып яртылаш катып калган Энҗүдәне берәү дә шәйләмәде. Онытыла башлаган мылтык тагын исенә төшеп җанын әчеттереп узды.

Аның күз яшьләре елауданмы, әллә көлүдәнме икәнен аерып карарлык кеше табылмады. Барысы да кызган, мәҗлес тәмам югары ноктасына якынлашып килә иде.

Энҗүдә башын күтәреп яшьләрен күзләре белән кире йотты. Кеше алдында йөрергә кирәк бит әле. Ичмасам Дамирлар да килмәде... Ничек итеп урынына утыртасы булыр инде Тимерне кызып китә калса?!.

Болай булгач килмәделәр инде болар...

Дамир турында сүз чыккач, кемдер аның вельвет чалбарын киеп басу капкасыннан чыгып китүен әйтеп алды. Вельвет кигәч килбәт үзгәрә инде ул.

Кемнәрдер мәҗлестә тирләп-пешеп утырганда Дамирны колхоз рәисе Әмирҗанов "пешерә" иде бу минутларда. Шушы ямьле өстәлне калдырып җиде чакрым җиргә тетмәсен теттерергә китү рәхәт түгелдер...

—Булат улым, нәрсә дип әйтте Дамирҗан абыең ашка чакырырга кергәч?

Дүртесенә дүрт дурчмак тотып утырган малайларны ашауларыннан бүлделәр.

—Мәшәкать ясап йөрисең, энем, диде!—дип җавап бирде иптәшләре янында хуҗа булып утырган малай.

Тагын көлештеләр. Нишлисең инде, мич чыгаручы малае белән мичкәче кызы, ягъни Тимер белән Энҗүдә, Дамирның даирәсенә туры да килеп бетми торганнардыр...

—Ишеттегезме, теге буран көнне Мәчти чокырында биш багана ауган...

Кунаклар гапьне колхоз радиоэлемтәсенең сафтан чыгуына бордылар:

—Язгы җир чыкмыйча яңа баганалар утыртып булмас бу суыкта. Кышкы чилләдә, җүләркәем, җир казулары уен эш түгел.

Энҗүдә тагын дерт итеп китте. Аның да җир казып мылтыкны яшерәсе бар бит... Яз җиткәч... Хәзер дөрестән дә казып булмас. Кары бозлы, җире туң...

Кунаклар, үч иткәндәй, һаман багана тирәсендә сүз куерттылар.

—Илла да рәхәт иде Әмирҗановка радио эшләгәндә!..

Һәр сазлыкның үз бакасы, дөресрәге баш бакасы... Калган бакалар да аңа охшатып бакылдарга тырыша.

Колхозчыларның һәр мәҗлестә тәмләп сөйли торган темасы—рәис булып кылану. Әмирҗанов бу минутларда очкылык тоту өянәге белән җәфаланыр дип тә җәлләмиләр. Бавыр Юнысның көлдерүеннән авызын җыеп ала алмаган Сүсән Сәгыйть сузылып торып басты, түрә кебек шәм бармагын өскә күтәрде:

—Туктагыз әле, җәмәгать, үзем сөйләем,—диде ул сөйләмгә шулай ук сәпәрәй кеше буларак.

Озакка китте инде болай булгач.

—Шулай бермәл кычкыра бу радиодан, сыйлаган моны кемдер, яхшылыклары өчен...

Аңа охшарга тырышып Сүсән кулына микрофон итеп чәнечке тотты:

—Хөр-р-рмәтле калхудчылар-р-р!.. Каднаның көче житмәү сәбәпле, үдегеднең ит, сөт, май, җөн, күкәй һәм шуның ише нәмәкәйләрегедне калхуд идарәсенә алып килеп тапшыруыгыд сорала...

"Үзегезнең" сүзенә аеруча басым ясагач, ул, аңлыйлар микән дигәндәй, бераз туктап карап торды. Кая инде ул аңламаган, егылышып көлделәр...

Сәгыйть тагын чәнечкесен өскә күтәрде:

—Гапсаттар апа!.. Маһруйбикә абый!.. Седгә боерык, әмер, теләсәгед фәрман... Нәмәшләп седдән сөт тә юк, җөн дә юк, ит тә юк... Ну он ясыйм үдегеддән... Штубы...

Аварга яратканнар авып көлде, утырганнары—утырган килеш...

—Әйдә әле ашаң... эчең әле... Син, Сәгыйть, гел юкә чөй кагып утырма әле сүз белән алдап,—дип янабаштан кыстарга керешә Энҗүдә.

Сыйланып арыган кунаклар җырны тансыкладылар.

—Эх, бервакытлар бар иде-е-е,—дип Юныс тагын үзе белән кыстырып килгән күрегенә үрелде.

Бәдәннәрдәге көрлек җыр булып сузылды, аларга нәфис хатын-кыз тавышлары кушылды. Гармун күрегенә тулган җырларны түктеләр дә түктеләр.

Энҗүдә кушылып җырлый ала идеме соң мондый җырларга?.. Нәрсәдер эзәрлекли иде аны. Җыр кайгысы түгел, суга томырган тәте, һаман шул мылтык хафасын уйлап җәфа чикте ул.

Житмәсә, кунаклар, гөр килеп үзен җырларга кыстый. Үлем белән бер аларның бу кыланышлары.

—Әйдәгез әле... Җингәччәйне җырлатабыз... Теге җырны... "Су өстен"...

—"Озын су өсте"нме?..—диде ул куркынып, эзәрлекләүнең минут, секунд саен көчәйгәннән-көчәюен тоемлап. Бу бит тиккә генә түгел... Су төбендә яткан гөнаһ үзен искәртеп эзәрлекли...

Ләкин кунаклар кызмача, бугазга басып сорыйлар. Нишләсен, күнде, күзләрен күрсәтмәде. Күзләрен йомып көй сузды. Үз-үзен ишетмәс өчен куллары белән колакларын каплады, ләкин көй барыбер тагын да көчлерәк яңгырап кара кайгысын яңартты.

Утырдым ла сунын әй читенә,
Карадым ла сунын төбенә.
Карадым ла сунын төбенә.
Су төпләре лә ай караңгы ут,
Язмышларны күрми чара юк,
Язмышларны күрми чара юк.

Кунакларның күңеле булды. Энҗүдәнең күңелендә беркемнең дә эше юк иде шул.

—Җәмәгать,—дип баш бармагын тырпайтты, кызмача хуҗа,—сезгә дигән бер ганимәтем бар... Ну ... анысы соңрак, башта биеп урын бушатыйк, ал әле әргәненне Юныс...

Дәррәү кубып ишек алдына чыктылар. Бушанып хут алгач, биеп дөньясын ду китерделәр. Кем көйрәтеп торды, кем өйрәтеп торды, кем кул чапты, кем күрек уйнатты, кем бүрек уйнатып биеде. Ишле бию дә биеделәр, бишлесен дә...

Тәялгән ризыклар, шулай итеп, бераз бастырыкланды. Саф һава сулап, бер очтан айны карап керүләр—башларны айнытып җибәргәндәй булды. Көчкә өстерәлеп чыкканнар да аякланып керделәр.

Тик тә кулы кычытып торган хуҗа үзенең табышын күрсәтергә вакыт җитте дип уйлады. Изге иде теләге... Җиде төрле үлән кушып, җиде ирне җиде көн исертерлек итеп ясалган көмешкәсен, табынга чыгарып, дуслар белән бер бәлзәм эчү иде хуҗаның теләге.

—Җәмәгать... Җәмәгать...

Шул сүзләр белән хуҗа, барысы да күрсен өчен, мич янындагы эскәмиягә менеп басты.

—Монау нәрсәне...

Ул уң кулын мич башының чаршау эченә шудырды. Ләкин, эзләгәнен тиз генә таба алмыйча, мыгырданды:

—Кая инде, шайтан?!.

Ул бала итәкле пәрдә эчендә чиреклe шешәне эзләп тәмам буталып бетте. Хәтсез эчелгәнгәме—капшану сизгерлеге шактый тупасланган иде аның.

Салкынча озын әйбергә кулы орынгач ниндидер аңлаешсыз күренештән үзалдына сөйләнеп куйды:

“Бастырып куйган идем бит, ауды микәнни? Агып бетмәгән булса ярый...”

Шундый житез уйлар белән җәһәт кенә кулындагы хәзинәне тартып чыгарды: көмешкә түгел, көпшә иде аның кулында—мылтык көпшәсе...

—Бәй, чоланга яшергән идек бит, ничек килеп эләккән бу монда?.. Энҗүдә?.. Энҗүдә дим?..

Авыл җирендә агач корык, кер бәләге яисә уклау, иң шәбе дигәндә сабына елан кабыгы кидерелгән озын чыбыркыдан гайре корал күрмәгән халык мондый көтелмәгән хәлдән соң кайсы яртылаш урыныннан торган, кайсы кем артына поскан хәлдә өнсез калган иде.

Бер килсә килә бит ул... Җитмәсә, озын көпшәне тартып алганда лампага тиеп китте, куык шунда ук челпәрәмә уалып төште. Әйтерсең, шул гына кирәк иде бу мәҗлескә?!.

Чаршау артындагы сыңар утлы шәмдәл ниндидер бер ярымкараңгылык белән мылтыкның гәрәбә тутәсен күз явын алырлык итеп ялтырата иде. Кайсы ир-атның тотып карыйсы килмәс иде икән аны!

Ишектән ашыгып килеп кергән Энҗүдә өрәк күргәндәй катып калды.

Кайгысының көн түгел, сәгать түгел, минут саен, секунд саен зурая баруыннан тәмам гаҗиз булган хатын аһлап такмакларга кереште:

—Булса да булыр икән бәла казасы... булса да булыр икән Ходаем... И, Раббым...

Бәлзәмгә закуска кирәкми диләр. Кирәк булып чыкмады шул. Тимернең әфсенләп җиде төрле үлән кушылган көмешкәсендә кеше гаме калмады. Урамга чыгып айный алмаганнар да инде тәмам айнып киткәндәй булдылар.

Күзләрендә гәрәбә түтә чагылышын ялтыратып кунаклар “аһ” итеп, урыннарына утырды. “Әстәгъфирулладан” ары әйтер сүз таба алмадылар.

Тузмөхәммәт кенә инде, үз вакыты житкәнне сизеп ахрысы, чайкала-чайкала торып басты. Моңарчы үзенә игътибар булмаганга рәнҗеп утырган идеме? Умрау сөяген кашып куйды. Иңсәсендә мылтык атканнан соң кире бәрә торган рәхәтлек дулкынын тойды бугай. Ирексездән куллары селтәнеп китте:

—Бир-р әле монда ... берданканы!..

Бугаз төере бер менде, бер төште. Бирчәйгән куллары белән җиңнәрен үк сызгана башлады.

—Тузга язмаганны сөйләмә, Мөхәммәт җизнәкәем... Үпкәләмә дә, сорама да... Уенчык түгел, бирәүгә дә бирмим,—дип, Энҗүдә Тимердән тәтесез мылтыкны кабаланып тартып алды.

Салкын чоланга чыгып киткән Энҗүдәгә күлмәкчән генә Түгәрәк тә иярде.

—Дуңгызга да жизни дип әйтә торган чак,—диде ул мыгырданып. Тузмөхәммәт кулына эләксә тәтесе булмаса да атар Тимереннең тимере!

Кая яшерергә белмичә азапланды. Нишләсен, кире сандыкка сонды.

Алар урап кергәндә Тузмөхәммәт тәмам тузына башлаган иде инде:

—Һе, үтил бит ул... тәтесе дә юк бугай... Рәешкә китерә торган булса бер хәл иде...

—Кызма әле Мөхәммәт абзыкай!.. Мылтык күрсәтү түгел иде теләгем. Әйе, тәтесе дә су төбендә. Нәрсә булды соң инде бу җәмәгать?!. Туктагыз әле...

—Ш-ш-шул тәтесе белән үзен дә суга томырасың калган!.. Маңка тәре, шапырынган була тагын...

Хрущев җепшегеннән соң амнистия белән котылганда башка аның

ише нәрсәгә орынмаска ант иткәннәре инде исеннән чыкты. Жизнәкәй тезепме тезә!

—Малай актыгы... Абыеңа житәргә әле сиңа... Һ-е-е!—Комарлы уен уйнагандай ул кызып-кызып үсенде. Чөнки үзеннән башка бүтәннәрдә дә мылтык бардыр дип уйламаган-көтмәгән иде бугай ул. Юк... мылтык анда гына булырга тиеш. Ут-коралның тагын кемнәрдәдер булуын кичерә алмый иде ул. Әчтән иблис токымы, тәмуг кисәве дип тиргәсәләр дә мәжлестәш хатыннар ягымлырак булып кыландылар.

—Туктале жизни, утырып кына тор зинһар, хәзер бәлеш чыга,—дип, бөкеле бәлешне мактарга керештеләр.

Кузы кадәр күзләрен киереп, кулына асылынган хатыныннан арынырга теләп кулларын ныклап ук бутый башлады Тузмөхәммәт.

—Шапырынган була тагын... Менә миндә ул ичмасам!.. Бирәү генәме!.. Һе-е... Үтиле белән мактанып торган була.

Куркытыр өчен генә әйтелгән сүзләрне халык чынга алды. Шулай хәерлерәк. Мөхәммәт тагын да кәпрәя төште:

—Дөрес куркасыз,—диде ул гамьле йөзләргә карап.—Шулай тиеш... абыегыз барда... Жае чыкса бирәрсеңә күрсәтермен дигән идем, алып килеп һушыгызга китерим... Хәзер, күрмәгәнегезне күрсәтәм әле мин сезгә...

Ул кабалана-кабалана, аякларын дугалатып, ишеккә юнәлде. Тузаннан тубал ясавы белән канәгать иде Тузмөхәммәт. Ярты мәжлеснең күңел тынычлыгын алып кайтып китте. Мондый бәрелеш аның өчен гадәти генә булса да, башкаларга уен эш түгел иде шул. Дөрес, усалны үстермәс өчен кунаклар юмалап-юмалап озатып калдылар.

—Ышанабыз, болай да ышанабыз жизни, күрсәтеп торма!—дип, жаена гына торып, салпы ягына салам кыстырып жибәрделәр.

Борчуларны бераз жинә төшкән Түгәрәк бәлешләрне янартып чыгарды.

Мәжлес кителгән иде инде. Хужалар күпме генә кыстап карасалар да, сөмсере коелган кунаклар ни ашый, ни эчә алмады.

Һәркемгә Тузмөхәммәт мылтыкларын асып килер дә аларны атып үтереп бетерер, кырып салыр кебек тоела иде. Фажигале картиналар, канлы күренешләр, аркылы-торкылы яткан мәетләр булып күз алларына килеп басты.

Сүнгән Тимер, Энжүдәнең яшь тоелгән күзләренә туры карарга базмыйча гына кунак халкы рәхмәт әйтергә дә онытып, кайсы ындыр артлатып, кайсы тыкрык аша гына таралышты да бетте.—Монда күргән монда калсын дип озатып калдылар... Кинәт бик тә ямансу булып китте. Өелеп калган ризыклар атна буе малларга ашатырлык иде.

Бәлешнең иң тәмле жире—кәтермәч белән куанып утырган балаларның жанны пакьлый торган саф, самими карашлары алдында оялыр өчен аеруча оят иде ата-анага.

Шулай итеп, самавыр егылмыйча калды. Тимер кайгысыннан берүзе, жиде үлән кушып төнәткән, жиде ирне жиде көн исертерлек итеп ясаган көмешкәсен көпшәсеннән голткынлатып эчеп бетерде дә колмактан ясалган колак мендәрен кочаклап, корама юрган белән язгы боз калынлыгы ястык арасына кереп ауды.

Ә Энжүдә? Кая йоклау!.. Жиле котырынган котып кебек урамны озак тыңлап ятты ул. Берьюлы өч тегермән чарыгы кебек гырлаган исерек ире белән төне буе әйткәләшеп чыга ала идеме соң ул? Уятып та карады ул аны!.. Ачуы басылганчы яңаклап та алды.

—Туктале,—диде ул ниһаять, тәпәләп тә уята алмагач,—белмәгәне, күрмәгәне яхшырак, димәк шулай кирәк булган... Тимер белмәскә тиеш...

Берәр баланы ияртсәм кайчан да булса атаена әйтер, әләкләр дип тә шикләнде. Әйе, бүген, нәкъ менә бүген жир куенына тапшырырга... Яз

житкәнне күтәп тормаска... Яренгә калдырырга ярамый... Бу хәвефне бүген үк юк итәргә... Бүтән бимазаларлык булмасын...

Башта кырыкмаса кырык ямаулы киндер капчыкны алып кереп аңа мылтыкны төрде, чәнчеп-чәнчеп вак җой белән типчеп каеды.

Чарасызлык хатын-кызны ир-ат итеп тә киендерә... Һәм кайбер очракта хатын-кыз ир-аттан көчлерәк тә була икән... башына төшкәч! Кануннарың хаклы түгел тормыш... Хаклы түгел... Менә бу очракта...

Иске сырма киде, аягына чүчинкә, башына кырпулы бүрек. Аркасында мылтык биштәре. Үч алучы шәһид кебек җәһәннәмгә юл алды... Куркуыннан парә-парә килгән йөрәген кысып, сөрлегә-сөрлегә сызадан гына сыпырды.

Ичмасам, Ходайга инанса да юньләп дога укый белми. Нәрсәләр генә укыйлар икән соң мондый вакытларда?.. "Эшләрне бетереп исән-имин йөреп кайтсам, Фәрхикамал абыстайга кереп догалар өйрәнер идем", дип үз-үзенә нәзер дә әйтеп куйды.

Курыкканга куш күренәме—янәшәдә генә меңнәрчә күзләр эзәрлекли төсле тоелды аңа. Бу "убыр утының" яшьле күзләрендә йөзгән йолдызлар чагылышы икәнен абайларлык түгел иде инде Энҗүдә.

Мәңгелек кыш коллыгында яшәгән котыпларың бер читтә торсын! Ягылган, җылы өй тойгысы, аның рәхәтлеге, кадере шушындый чакта гына беленә икән. Кемнәрдер кайнар юрган астында бичәләре белән сөелеп биһуш булып ятканда нишләп әле ул кырда кырын эшләр эшләп йөри?.. Кәбисә елында жиде айдан туган өченме?..

Бер явып, бер кибеп, бер катырып, бер жебеп үткән катканаклы көз үзенекен иткән, кар астында бөтен нәрсә тоташ туң иде. Житмәсә, жәйдә куе булып үсә торган ат кәстәнәсе төбенә туры килде ахрысы, тирләп-пешеп казыса да артык тирән төшә алмады. Әтәчләр өченче кычкырганда эшен бетереп, ашыга-ашыга, зират коймасы аша сикереп өркәчле көртләр өстенә башаркан төшеп капланды. Коймага сөяп куйган колашалар чәчрәп барып төште. Бу калай тавышына авылның бар этләре ду килеп кушылды.

Кем төшенә нәрсә керәдер, хур кызлары белән саташып гырлаган Тимер, төш белән өнне бутап уянып китте... Энжүдәсе янында юк... Тәрәзә артындагы әче жил Тимерне хурлый кебек тоелды... Ниндидер кәккүкләр зарланып кычкыра... Кыш уртасында нинди кәккүк булсын да, кем белән исәп-хисап башкарсын ул?!

Жиде төрле үләнле көмешкә үзенекен итте—Тимер тагын каядыр чумды, адашты, саташты... Ниндидер упкынга очты...

Чәче генә түгел, башындагы бүреге дә чаларган Энжүдә зираттан качкан әрвах кебек бәсәреп кайтып керде. Бетмәс сыкы иде бу өрәктә... Үткәннәрен онытты, тирәнгә яшерде ул...

Иртәнчәрәк ире мылтыкны эзләгән иде, Тузмөхәммәт чыгып киткәндә алгандыр, дип кырт кисте Энжүдә. Мылтык суга төшкән кебек юк булды. Бу турыда артык сүз була алмый. Бетте-китте. Тузмөхәммәт бер алса кире бирә торган кеше түгел.

Иртәгәсен дә, аннан соң да кар өстенә карлар яуды. Үткәннең тавышлары авылның көндәлек вә чуар хәяте астында калып капланды. Кышкы чиллә житте. Аннан давыл дөньясына әверелгән кыш ахыры...

Энжүдә, күнелендәгеп күпме генә яшерергә тырышмасын, үзендә ниндидер аңлатып була алмастай халәт тойды. Шулай итеп, мәрәкә йомылды. Көннәр, айлар үтә торды... Ләкин Энжүдәгә жинеллек килмәде... бары тик жинеләю генә килде...

Әллә теге вакытта салкын тиеп калды, әллә өзлегүе булды, төннәрен ул хәзер тирләп, ыңгырашып чыга, тын кысылу өянәге бимазалый. Төшендә

әле сыртланнар, әле ярык каберләр күреп җәфа чикте. Үзе йокласа да, күзләре йокламады—ачык калды. Бөтен борчуларын онытып рәхәтләнеп йоклый алганнардан көнләште ул. Энҗүдәнең йокысы йокы түгел—черемнәрдән торган өзек-өзек төшләр иде. Ниндидер шәүләсез тавышлар ээрлекләп интектерде, нәрсәдер җанын борчыды, күзләреңнән төсе унды, сөйләшкән сүзләре сүнде. Җан саулыгы әкренләп тәненнән сызды.

Суырылды, үз-үзенә, уйларына бикләнде. Йөзенең төсен генә түгел, кием төсен дә югалтты Энҗүдә. Юа-юа эштән чыккан, киптерә-киптерә кояш ашаган күлмәгеннән гайре башка кием кияргә теләмәде, чәй тәмен тоймас, аш бәрәкәтен белмәс булды. Шатлык хисе үлде. Хәтта Тимерҗанына да битараф калды, кәнсәләрдә эш хакы биргән көннәрдә аның гәләфи чалбар кесәсен капшарга ярата иде, бу гадәтне дә онытты. Яшәү түгел иде инде бу...

Эчтән кайгы кимерде Энҗүдәне. Көтмәгәндә-уйламаганда зыянлы кыланышлары пәйда булды. Инде теләсә-нәрсә сөйли, колак та, йөрәк тә кабул итә алмастай сүзләрне уңлы-суллы сибә, озак дәшми йөрүенең әҗерен кайтара кебек иде. Һәм ни гаҗәп, үзе мылтык турында бер сүз дә ычкындырмый.

Әйе, ул дәшмәгәндә акылдан язганын яшереп була иде әле, хәзер инде үз авылы гына түгел, бөтен тирә-як авыллар да хәбәрдар булдылар. Аларның ихатасын үләт базы кебек читләтеп үтә башладылар. Йогышлы авыру белән авыргандай аларга кеше кермәс булды. Инде бәла-казадан аралар өчен Энҗүдәне өйдә бикләп китә торган булдылар.

Яланаяклы авыл халкының бәхетенә ышанмаган уллары үсеп кеше булырга дип Чаллы каласына юл алды. Кызлары, әнисен терелтәм дип, Казанга врачлыкка укырга китте. Өметләрне яшереп, хыялларны күгәртеп авылда калырга теләмәгән яңа буын үсеп житте. Өрәккә әйләнгән хатыны белән Тимер япа-ялгызы калды. Үзенең гаепле икәнен тою ана икеләтә авыр иде. Ул туктаусыз үзен битәрләде. Нәрсәләр булганын, ни булганын гөманлады, фаразлады, юрады... Барысы да бер нәтиҗә бирә... Шуңа кайтып кала... Мылтык белән берәр нәрсә эшләгән бу!..

Күнеленең һәрчагы көйсез булган холыксыз да, тәмләп ризык пешерә белмәгән, хәтта пешмәгән хатын белән дә торырга була. Чәүчәләк хатынны да ятарырга була... чөнки ул ятарканда кайнар булырга мөмкин. Хәтта ирдәүкәне, җилбәзәкне дә тотып тыеп торып була... Җаны сау булган барлык хатыннар белән дә яшәргә була, түзәргә була. Яши алмыйсын икән инде, һич югында ана да юл биреп, үзенә дә яңа юл эзләп калдырып китеп була... Ә менә акылдан язган хатынны ни калдырып, ни аерып булмый... Хәсрәт капчыгына әйләнгән Тимерҗан яшәүнең сере, яме булган, инде кабатлап булмый торган мизгелләрне күз алдыннан кичереп кенә юанды. Кайтса каршы алучы, китсә озатып калучы булмады. Әйтер сүзләрен әйтәлмәде... Авыр иде ана мондый тормыш белән яшәү. Хәер, инде ана җиңел тормыш кирәк тә түгел иде. Язмышының языклы булуын ул аңлый һәм боларны шулар өчен тиешле җәза итеп кабул итә иде. Ул гына гаепле ич, бары тик үзе... Тимер язмышын Тимер хәл итәргә тиеш иде...

Шулай да үзе белгәннәрен эшләде Тимер. Баш очына, ятакка җен-пәриләрне куркытырга дип димәшкъ корыч куйды. Фатиха сүрәсен яздырттырып өйнең почмакларына кыстырды. Яшәргә, ни генә булса да яшәргә кирәк... Соңгы чиккә килеп терәлгәч тә, аңа бераз вакыт кушып көтеп карарга кирәк... Бу бит әле тормышның ахыры түгел, ахырзаман да түгел, ә язмышның китереп кысрыклаган бер почмагы гына...

Һәр язны инде терелмәс микән, инде терелмәс микән дип көтте Тимер. Бөреләр кояшка узып бүртенгән, агач-куакларга яңа җан ингән, бөрешкән бөҗәкләр яңадан терелеп килгән бер мәлдә ул уйлап аптырый иде: ничек

инде шулар янәдән терелә алганны, кеше булып кеше хастадан терелә алмасын ди?!.

Гөләпләр терелгәнне?..

Элек эчкән һәрдаим дарулары алышынды. Инде гәрәнкә маен граммлап эчерде, дуләнә төнәтмәсен дүрткә бүлеп, кына гөле сутын кырыкка бүлеп эчерде. Йөзьяшәр төнәтмәсен эчереп тә җинеллек килмәде. Меңъяфракны меңгә бүлеп эчердәй булды Тимер. Сабырлык дарулары үзенә дә кирәк иде. Уйлардан ялкынсынган баш мие чатнады. Ир-атның җан әрнүен нәрсә белән басканы яхшы билгеле...

Йөрмәгән хастаханә, күренмәгән табиб калмады. Оҗмах бакчасыдай алма бакчасы буш дару шешәләре белән тулды. Ул дару исеннән агуланган алмачияләр бу елны бөтенләй кысыр калдылар... Яз килмәде алар бакчасына, җимешләр тагын төймәләнде...

Ничәмә-ничә мыскал дару ашап та файдасы тимәгәч табибларның сүзләрен мыскыл итеп кабул итте Тимер.

Хорафатларга, им-томга мәңге ышанмас Тимер, ахыр чиктә ат җигеп, Әби патша юлыннан Түмерҗәдәге кәрамәтче Нажия әбигә барып Энҗүдәне бактырмакчы булып сәфәр чыкты.

Җәйге челләнең рәшәле бер көнендә, ул бәләкәй әбинең бәләкәй өе капкасына атын китереп бәйләде. Нәрсә теләгәнемне белдерә алмый тилмерермен дигән иде Тимер. Изге кеше иде шул бәләкәй әби. Башында нурлы кайма да бар кебек тоелды. Әле сылулыгын салмаган—чүбек кебек чәчле Энҗүдә янында матур, күпкә матур күренә иде әби.

Ул Энҗүдәнең чытырдатып кысылган йодрыгын сыйпап ачтырды. Үз кулына алып сабыр гына тыңлагач: "Җаны җир астында моның... зәхмәте бик каты... тимер зәхмәте"...—диде. Бу сүзләрне әйткәндә җитмеш яшьлек әбинең җитмеш җиде сыры хәрәкәткә килде кебек.

—Ап-ак җирдә кара эш эзе. Җиде төн уртасында зәһәр каты җиргә-туфракка зәһәр каты нәрсә күмгән. Тимер дип уйларга кирәк... Каты әйбер күмгәнне билгеле бер вакытка кадәр төзәтеп була. Йомшак нәрсә күмгәнне төзәтеп булмый... Зират туфрагы булуы бар... әрвахлар рухын рәнҗеткән... Тизрәк эш итегез. Эшне яренгә калдырырга ярамый. Айлар-атналар түгел, көннәр, сәгатьләр санаулы... Сонга калмагыз, балакайларым... Череп бетмәсен... Череп бетсә, эш харап... Үзен зиратка якын китермәгез... Хатын-кыз йөри торган урын түгел ул... Гелән зәңгәр кием киендерегез. Зәңгәр җимешләр ашасын: инҗир, слива, йөзем... Урын-җирне дә зәңгәргә алыштырырга кирәк. Су да зәңгәр бит, күбрәк су янында булсын... Күмгән нәрсәсен табып, шуңа йортыгызга иң якын коеның суын түгеп юыгыз!.. Авыр булыр... Шулай тиеш... шуларны эшләгәч тапкан әйберегез белән кабат миңа килерсез... Бары тик шуннан соң гына савыгыр, ипләнер, сихәтләнер, Алла боерса.

Әби кат-кат догалар кылды. Өшкерде, Энҗүдәнең түшләренә сулышын өрде, колакларына пышылдады. Көн сүрелгәч укый торган сүрәләрен дә тыңлатып җибәрде.

Ашыкты, атыннан ак күбекләр чыкканчы, Чытыр-Буләк әрәмәсенә җиткәнче чаптырды Тимер. Каршы искән җил тынга капланды. Өзәнгеләр өзелер дәрәҗәгә житте. Ул сихәтләнү әмәленә сонга калудан курыкты... Ә үзе чарасызлыктан бары тик бер генә сүзне тәкрарлады:

—Әйт зинһар!.. Кайда күмдең мылтыкны?.. Кайсы төшкә?..

Рухы сүнгән Энҗүдә тагын сәер дәшмәү белән җавап бирде.

Җәяүлеләр килеп җитмәс җирдә туктарга булды Тимер. Башта күз күреме житкән кадәр офыкны—Зәңгәр Таудан Терпеле дуңгәләгенә кадәр булган араны карап чыкты. Беркем, бер җан иясе күренмәде. Кичке кояш инде тотылгандай юкка чыккан...

Алар бераз тын утырдылар. Ничек итеп башларга белмәде Тимер. Соңгы чара шул гына иде. Шулай да тәвәккәлләргә булды… Гомергә булмаганны, җүнгә китермәк булып, угры сыман аулакта—кеше күрмәгәндә кул күтәреп карарга булды… Авыру кешегә алай итмиләр… Кул белән ору… Нишлисен, шулай кирәк… Ныклап әйттерергә… Бу, соңгы чара…

—Әйт, кайда күмден мылтыкны?..

Энҗүдә, ни буласын сизенгәндәй, карышыпмы карыша, арбадан төшмәскә итенә… Гомер буе тавышсыз гына елаган хатын кыргый тавышлар чыгарып Тимернең изүенә ябышты, тәненә тырнакларын батырды. Бер талпынуда Тимер аны арба карынынннан суырып та чыгарды, көпшәк яшел көшел өстенә чәчрәп барып төшкән хатын үзен-үзе белештермичә, әҗәле житкәнне сизгәндәй, күзләрен киереп аңа текәлде, өзек-өзек кыргый-бума тавышыннан куркып дәррәү кошлар очып китте…

Киерелеп берне сугарга дип күтәрелгән алап кул һавада асылынып калды…

Ниһаять, Энҗүдә акылы бар кеше сыман яклау эзләп, ава-түнә ат янына өстерәлде… Аны муеныннан барып кочты, инде кыргый кыланышларыннан оялгандай дәшми генә елавын дәвам итте. Ат та ничектер үпкәләгән төсле тоела, күзләре юеш иде…

Нишлисен, ир-атның мантыйгы икенче төрле корылган, теләгенә ирешмичә туктарга исәбе юк, тагын барып Энҗүдәне артка өстерәде.

—Шулай кирәк… бүтәнчә булмый… Әйт, дим, яшисен килсә, кая күмден?

Инде икенче тапкыр яшел көшел өстенә чәчрәп барып төшкән Энҗүдә кул астына эләккән бер учма ат кәстәнәсен йолкып алды да ярсып-ярсып Тимерне пиннекли башлады. Үзе бертуктаусыз ысылдады да ысылдады.

Янагына ярылып калган яра эзләреннән кан саркып чыкты, ләкин төкле йодрыгы тагын һавада асылынып калды Тимернең…

Шулчак Кара урман ягыннан качмый калган бердәнбер кош—кәккүк кинәт телгә килде:

—Кәк-күк… кәк-күк… кәк-күк…

Әдәм баласы кайгысын табигать сизми кала димени?.. Әйтерсең лә кәккүк кем беләндер, кемнеңдер язмышы белән исәп-хисап башкара иде. Бәлки Энҗүдәнең гомерен саныйдыр?.. Күбрәк санасын, өркетмим берүк дигән уй йөгереп үтте ирнең башыннан, хәтта айнып киткәндәй ул башын чайкап куйды. Ерагая, һаман ерагая барган кәккүк тавышы бер төш кебек тоелды аңар… Туктале, бер күргән иде бит инде ул бу төшне… Кайда?.. Кайчан?..

…Күбрәк санасын… Ул кәккүктән еллар санаттырып калырга теләде… Кәккүк санады да санады, санады да санады… санап санын югалтты…

Аңлаган кешегә аңларлык, Энҗүдәнең җавабы әзер иде инде: син миңа ярдәм итә аласың әле Тимер, мин инде сиңа ярдәм итә алмыйм…

—Яшибез әле болай булгач, Энҗүдә!..—аның сүзләре җилгә очмады…

Бер кулына атын, икенче кулына Энҗүдәне җитәкләп сүзсез генә җәяү кузгалдылар. Берничә минут элек кенә кыйнарга дип күтәрелсә дә бу яклаучы кул иде…

Икенче көнне үк, иртән иртүк торып, зиратка китте. Алай инләде, болай инләде, зират әйләнәсенә сукмак салып бетерде. Ул-бу сизелмәгәч чалгысын алып бөтен зиратны чабып чыгарга уйлады.

Саланың бар гөлен җыйган зиратның куе үләнен бер янавыч эреп беткәнче чапты да чапты Тимер.

Зират күбәләкләре—гүя кемнәрнеңдер җаннары, ана юл күрсәтеп очкан төсле тоелды.

"Тәмуг монда, тәмуг өстә… анда оҗмах була күрсен инде берүк"—дип пышылдады ул бертуктаусыз.

Ингән каберләрне чабу тигез болын чабу түгел шул. Әле шуңа берөзлексез эзәрлекләгән кара шомны да өстәсәң... Куе булып үскән ат кәстәнәсе тирәсен чабу бигрәк тә кыен булды. Җире тигез түгел димәскә, тиз-тиз чабарга кирәк. Тизрәк кирәк диде бит имче карчык. Атналар, айлар түгел, көннәре, сәгатьләре хәл итә диде. Тиз дию генә җиңел!.. Әҗәткә каян көн алып торырга?.. Сәгатьләр-минутларны бурычка кем бирә?.. Кем?..

Бөтен зиратны чабып чыккач та бер ишарә, бер юнәлеш бирердәй, эз төшерердәй нәрсә шәйләнмәде!.. Ике кайгысының кайсын уйларга белмәде Тимер... Кара кайгысы белән кара төндә чәчәкләре кыркылган коточкыч каберстанда япа-ялгызы уйсыз калды. Зиратның астын өскә әйләндереп актарып ташламассың лабаса!..

Шул вакыт аны каракош каркылдавы айнытып җибәргәндәй булды, хәтеренә теге вакыттагы Энҗүдәнең сүзләре искә төште... Тузмөхәммәт алып киткәндер, дигән иде. Әллә шул дөрес микән?!

* * *

Берничә ел элек хатыны үлеп киткәч ялгызы яшәде Тузмөхәммәт. Яшәде дип тә әйтү дөрес булмас, җан асрады. Шунда ничә ел үтсә дә аның картлыгына карчык булырга теләүче толлар табылмады.

Ничек тә булса юхаланып, салпы ягына салам кыстырып (ә аның салпы ягы шул бер генә иде инде) ничек тә булса гәрәбә түтәле мылтыкны сорап алырга кирәк... Әгәренки, минеке юк икән... үзенекен бирсен,—дип өметен азындырды Тимер.

Бик иртә торса да тиз генә җыена алмады. Шулай да тәвәккәлләде. Чирканыч эш эшләгәндәй, җирәнеп кенә, башланмаган бер шешәне култык астына кыстырып Тузмөхәммәтнең тупсасына таба юнәлде.

Яманлык яманлыкка илтә икән.

Көпә-көндез ишек ачучы булмады. Тимер бакча ягына чыгып чүпле чүмәлә өстенә басып тәрәзәдән карады. Өй эчендә хәрәкәт юк. Бәләкәй Апуш кебек әле бер, әле икенче аягына авышып шактый көтеп торды... Үлем тынлыгы иде бу...

Сул як күршеләре малайларын авыл советына йөгерттеләр. Менге атка атланып түрә килеп җитте. Үз чиратында ул кире кайтып колхозның үзәк бүлекчәсендәге матайлы милиционерны чакыртып китертте.

Ишекне ватып ачтылар... Озак ваттылар ишекне...

Ыгы-зыгы, шау-шу китте... Эт үлеме белән дөнья куйган...

Кемнәрдер, кардәш-ырусыз дип әйтерлек Тузмөхәммәтнең читкә китеп олаккан балаларына ашыгыч хәбәр салу эшенә керешге. Берәүләр күмү хәстәрен әзерләделәр. Йөгерешкән халык арасында япа-ялгызы басып калды Тимер, өмет җебенең кулыннан ычкына баруы белән һич тә килешергә теләмәде. Аның аяк астындагы сукмак шуышты, җир катысын тоймады Тимер.

—Булса да булыр икән бәла казасы!.. Булса да булыр икән... Тузмөхәммәт аңа ярдәм итәргә теләмәүдән, аңа әйтмәс өчен үлеп киткәндер кебек тоелды. Ул кем кайгысы өчен кайгырырга белмәде. Башкалар ыгы-зыгысына кушылып, чоланга да кереп күз ташлады, чорманы да капшап төште, сарайга да кереп бакты:

—Бар ди, мә, хәзер! Элеп куйган сиңа!..—дип үчекләде ул үз-үзен.

Сәндерәдә дә күмәртәләп күкәй салып куйган чуар тавыктан гайрене күрмәде.

Соңгы өмет белән ул көрәк өстерәп кабер казучылар артыннан өстерәлде.

Җиләненә җил тутырып мулла бабай да менеп җитте. Ул кәҗүл итекләре белән, кеше йөзенә баскан кебек, сакланып кына юл күрсәтеп барды:

—Болай итәбез оланнар! Менә бу ат кәстәнәсе янында казырга кирәк булыр... Син башла Тимер, ипле генә итеп... Яшьләр дәвам итәр.

Олы кешенең сүзеннән чыкмадылар.

Шул вакыт Тимер, нәрсәдер исенә төшкәндәй, эсселе-суыклы булып китте. Энҗүдә ана кабаттан, теге вакыттагы кебек, юеш, каты ат кәстәнәсе белән китереп суккан кебек булды, хәтта ирексездән янагын тотып куйды...

Ул, ниһаять, анына килеп, кәсләрне кисеп-кисеп читкәрәк алып тезде, кабер якасын әзерләде. Үзе казыды, үзе бертуктаусыз Ходайдан үтенде, ялварды, шабыр тиргә батты.

Бәлане булдырмый калып була иде бит!.. Була иде булдырмый калып бәлане... Барысына да Тимер гаепле... Тимер язмышын Тимер хәл итәргә тиеш иде.

Мәгъдәнче кебек казыды да казыды Тимер. Көрәк озынлыгы казып килгәндә чыкырдап нәрсәгәдер орынылды. Тагын көрәгеен тыкты, тагын ныклап чыкырдады. Кинәт ул нидер күреп җиргә тезләнде, күпереп яткан кара җирне куллары белән аралый башлады, ашыгып-ашыгып тимер кисәген арчып чыгарды.

Мылтыкны күреп башкалар аһ итте. Тимер таныды бабай мылтыгын... Гади генә мылтык... тәтесез... Кайчандыр гәрәбә төсле булган түтәсен кортлармы, суалчаннармы нәкышьләп бетергән...

Язмышы язылгандай кытыршы түтәне күреп, кемдер, ниһаять телгә килде:

—Валлаһе Әгъләм... Тузмөхәммәтнең үзенеке түгелме?.. Бер салып алгач ике мылтыгын да капка баганасы төбенә күмдем дип ычкындырган иде... Монда күмгән икән!.. Тагын берсе булырга тиеш, карагыз әле!.. Кырын эшләрне кылган каплап киткән булган бит.

—Юк... мылтык бабайныкы,—дип акланырга ашыкты Тимер,—тәтесез... Бәланең асылы менә шунда инде, авылдашкайларым... Шушы кирәк иде миңа... Күпме гомер эзләдем бит, күпме гомер!..

Кабер казучылар икенче мылтыкны тапмадылар.

Сәгатьләре, минутлары санаулы иде Тимернең. Ике кайгының берсе турында уйларлык кына вакыты калганын аңлап ул өенә таба ашыкты.

Тимерҗан тимер кебек кызган иде. Ләкин кабер суыклыгын үзенә сеңдергән көпшә җылынырга теләмәде, киресенчә үзенең суыклыгын аңа биреп бизгәк тоткандай дерелдәтеп азаплады. Бирешмәде, тиз кыланды Тимер, кайтып Энҗүдәне генә ияртте дә Фазлый коесына ашыкты... Ни гаҗәп, аңгы-мингә килеп йөргән хатын карышмады.

—Яшибез әле болай булгач Энҗүдә!.. Тереләбез әле болай булгач!.. Күп калмады инде... Күп калмады!.. Бары тик бер кое суын гына түгеп бетерәсе бар!.. Шушы мылтыкны коендырасы бар. Җан саулыгы кабердә булган икән бит... Җан саулыгы кабергә күмелгән булган...

Шундый уйлар белән ул шомарып беткән кое капусын килеп ачты. Төбендә ниндидер авыр нәрсә яткандай суы алагаем тулы, күп. Эчәсе килсә дә эчәргә базмады бу юлы Тимер. Әрәм булыр кебек тоелды аңа. Тамчысына кадәр мылтыкка коярга диде бит имче.

Энҗүдә нәрсәдер сизеп торган кебек көтә бирде. Тимер капчыкны чиште, мылтыкны тартып чыгарды, киндер өстенә сузып салды...

Хатын мылтыкны таныпмы, танымыйчамы, һәрхәлдә күрмәс өчен башын кинәт читкә борды, сулы упкын каршына килеп басты. Мөлдерәмә тулы кое суына тамган яшьләре аның йөз сурәтенә тагын да җыерчыклар өстәде... Җил ашап бетергән ике йөз бер-берсенең коедагы сурәтенә карап тора бирделәр. Ир-ат еламый диләр... Елый икән ир-ат та, башына төшкәч... Еларга тиеш...

Тимер күтәрелеп карарга базмады. Анын, Энжүдәнен күзләренә төбәп карап, күнеленең сәламәтләнүен танийсы килә иде. Ләкин үзе танымам дип курка, шөлли иде... Иртә иде әле.

Шушы кичке эңгер тулган уйсулыкта, бисмилласын әйтеп, Тимер чылбырлы чиләк белән су өслеген яньчеде. Тавышсыз гына чәлпәрәмә килгән салкын су томырылып чиләккә ашкынды. Энжүдә, суга батучы саламга ябышкандай, бердәнбер коткару чарасы булган чылбырга чытырдап дүртенче кул булып ябышты. Мылтыкны "әшһәдәнә..." иткән беренче чиләкне алар икәүләп бушаттылар.

Жиргә сарылып аккан гөрләвек чуерташларның куныкланган битләрен юып үтте. Кырык ел буе яңгыр күрмәгәндәй такыраеп яргаланып беткән, коргаксыган сукмакны туендыру өчен генә дә ярты кое су киткәндер...

Ярый әле кое әвернәле түгел. Ничәмә ел эшсезлектән иза чиккән сиртмә түбәсе күккә тиярдәй булып сикерде дә сикерде. Бертуктаусыз офыкны кыеп туймады.

Сиртмә сыкравы өн-аваз булып аяк астындагы су шавына кушылды, Энжүдәнең сырхавын куды.

Бераздан тәмам ерганак ерылды—ургыл инешкә сузылган айлы юл булып аска акты. Ташып, ярсып, кар сулары кебек, дәрья суы кебек ташып акты алкын су...

Сиртмә башындагы кара таш кантары күк белән жир арасын айкады. Бертуктаусыз айга йодрык янады. Теге вакытта кырын эшләрне күреп торып та бер нәрсә дә кылмаганы өчен кирәген бирде...

Тора-бара инеш әкияттәге Зур Суга әверелде, Туфан суы булып дуенны басып китте. Шыртлакалы инеш танымаслык хәлгә килде...

Төн тиз генә үтәргә теләмәде... Аларга коедагы су бетмәс, иртән кояш чыкмас кебек тоела башлады.

Тимер бертуктаусыз белгән догаларын, сүрә-аятьләрен кабатлады. Һаман да зурая барган кое эче кайтаваз биреп, аның тавышын калынайтты, илаһи бер моң булып яңгырады:

—Колһу Аллаһу-у-у би рабил әннәс-с-с

...Илаһиннәс-с-с... илаһиннәс-с-с

Бөкресе чыкканчы эшләргә әзер бүген Тимер. Нишлисең, Хисап көне шундый була торгандыр инде... Мәхшәрдә дә шушылай сулар аккандыр...

Инде санап бара торгач Тимер чутын югалтты. Алар үзләре дә мондый озын-озак тәһарәттән соң лычма су иделәр. Тәмам чистарынып, пакьләнеп, берсе Алиһә, берсе Галиҗәнәб кебек булып калдылар... Таллар суга бөгелеп аларга сәждә кылды...

...Кайгыларның кара диңгезе шушы коеда булган икән бит... Шушында җыелып яткан...

Шәфәкъ куптән тугарылып, таң беленер-беленмәс вакыт якынлашкач, сулар үргә ага башлады... Бергә калырлар болай булгач... бергә калырлар...

Энжүдәнең чабарып суелган куллары яна, күбеге сытылган бармаклары үтереп әчетә, әрни иде. Шушы минутларда гына ул инде тәгаен генә нәрсә эшләгәнен аңлый һәм утның ни өчен көйдергәнен, суның ни өчен сүндергәнен янәдән төшенә башлады кебек...

Бераздан кое суы тәмам болганчыкланды. Шулкадәр суын югалтудан һушы алынган коедан аһылдау-ухылдау авазлары яңгырап торды... Әйтерсең лә аның җаны чыга, җаны чыга да адашырлык ак томан булып сугарылган жирдән күккә аша иде.

Иртәнге нурлар кое төбенә төшеп җиткән бер мәлдә чиләк ниндидер катыга орынып чыкылдап куйды. Өченче тапкыр чумырып алганда, болганчык суга ияреп, мылтык өстенә ниндидер тимер кисәге тәгәрәп төште—тәте иде ул!..

Шуны гына көткәндәй, Энҗүдәнең кулыннан эш төште. Ничәмә еллардан соң, ничәмә еллардан соң мылтыкка янәдән куркып-калтыранып орынды: бу мәрәкәнең икенче төрле чишелеше дә бар икән бит!..

Шул арада, аның үлгән хәтер күзәнәкләре янәдән терелә башлагандай тоелды. Сүзләрен ул аң аша кичереп, акыл аша сөзеп чыгара башлады. Энҗүдәнең үз-үзен тотышы ипләнгәннән-ипләнә бара, күзләрендәге элеккеге мәгънәсе аз-азлап булса да кире кайта кебек иде.

...Тагын Олы Юлның тузаны күтәрелде...

Кәраматче Нажия әби көченнән килгәннәренең барысын да эшләде: өшкерде, догалар янартты, нәрсәләрдер язып бирде, нindiдер төнәтмәләр эчерде...

Иртәгәсен әбиләр җәе башланды.

Ырым кодрәтенә инанып, Энҗүдәсе тәмам терелеп бетмичә, мылтыкны районга илтеп тапшырырга ашыкмады Тимерҗан. Шомартып-майлап гамәлгә керткәч ул әле һаман да ут асрарлык корал иде. Киндер капчыкка төреп, янә теге сандыкка ябып куйдылар. Авыл халкы бу яналыкка әвәл чамасыз шаулаган иде. Инде тынды. Алмашка яна хәвефләр килде...

Албасты эчеп бетергән Фазлый коесы янадан шомлы су белән тулды.

Карчыклар җәе беткәндә Энҗүдә тәмам терелгән иде инде. Ул хәзер дингә бирелде—нәзерен үтәде. Яна догалар ятлады.

* * *

Авыл кечерәйде, утырды. Балалар калада калды. Кырыкка житкән оныклар—байгура булды, бары тик табышлы эш белән генә шөгыльләнде. Ата-бабадан калган биләмәдә берсенең дә гаме булмады.

Ярым онытылган кечкенә авыл, бөтен җир шары белән бергә яна гасырга аяк атлады. Илдә, көндә булган үзгәрешләр аны да читләтеп үтмәде. Сугыш булган җирләрдән нindiдер качаклар гаиләсе Тузмөхәммәтнең тузган нигезенә кайтып урнашты. Җимерелә башлаган каралты-курадан саман йорт әтмәлләп яши башладылар. Ахырзаманда кушамат исем булып китәр ди. Бу диканнарның да исеме Бауржан белән Патимат булып чыкты.

Алар билдән билчән баскан бәрәңге биләмәсенә мәк чәчеп көн күрә башладылар. Ни өчендер яшь-җилкенчәк, бала-чаганың булган кадәр өлеше алар белән тиз уртак тел тапты... Иленә күрә авыл өстендә дә яна хәвеф болытлары куера башлады.

Энҗүдәсенең савыгып житүенә тәмам инанган Тимер, бәла-казадан баш-аяк дигәндәй, яшерелгән мылтыктан ирләрчә котылырга теләде. Аны, кичекмәстән, районның эчке эшләр бүлегенә илтеп тапшырырга кирәк иде.

Калай сандыкның алкалы йозагына кагылу белән капкачның кыек торуын сизеп алды Тимерҗан. Йозагы исән исәнен, тик тупсасын каерып ачканнар. Киндер капчык та шунда, мылтык кына юкка чыккан иде...



## Шәмсия Җиһангирова

## КОЯШ БЕЛӘН СЕРЛӘШҮ

* * *

Кеше гомере кызык кына икән...
Иртән, көндез, кичен...—мәңге эштә!
Дөнья ямен, яшәү хозурлыгын
Аңлар өчен вакыт җитми һич тә.

Эштән бушаганда зарланабыз
Дөньяда, дип, яшәү кызык түгел...
...Әкрен-әкрен генә җан тарая,
Йөрәк сула, кечерәя күңел.

Кеше хәлен түгел, үз хәлеңне
Белергә дә җаен табып булмый.
Шулай әкрен-әкрен вакыт-явыз
Алтын кебек гомеребезне урлый...

Авырып ятам... Эшләргә юк хәлем,
Укып булмый... Башым, күз авырта...
Ә урамда, юлга яфрак төшәп,
Кыш ягына икән көз авышкан.

Бу ни хәл бу?! Яңа май иде бит?
Бар агачлар иде шау бөредә!
Мин бит әле өлгерми дә калдым
Җәйне түгел, язларны күрергә.

Ә урамда, әнә, яфрак туе!
Күзләр генә түгел, уй камаша.
Кичер, дөнья! Авыру күз белән дә
Син бик гүзәл икәнсең ләбаса!

---

Шәмсия ҖИҺАНГИРОВА — *шагыйрә, прозаик; «Төсле моң», «Балачак кая китә?», «Җирсү» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Туган якка кайтып килим әле—
Көтә анда газиз әнкәем.
Миннән берни өмет итми генә,
Бары: "Кайтыр,—диеп,—бәбкәем".

Кай җирләрне барып бер күрәсең,
Гомерең буйларына шул җитә:
Кабат сагындырмый, табындырмый,
Уйга салып сине кич-иртә.

Ә туган як... Мәңге сагындырып,
Бар җаныңны синең җирсетә.
Төшләреңә кереп, исләреңә төшеп,
Оныттырмый үзен ничек тә.

Монда сиңа һәрбер үлән таныш,
Агач-куак, хәтта бөҗәге.
Монда гына—туган якта гына—
Бар һәркемгә синең кирәгең.

Һәрбер кылган эшең белеп тора
Гамәл китабыдай картлары.
Шул "китап"ны алып укыр өчен
Син вакытын гына тап бары.

Менә шулай, җае чыккан саен,
Шул "китап" битләрен актарам,
Диеп кабат-кабат юлга чыгам...
Күңегелгән... башка юк чарам.

* * *

Әгәр һич уйламаганда,
Әгәр һич көтмәгәндә
Яннарыңа килеп чыксам,
Бәгырем, үпкәләмә.

"Нигә?"—дип сорама миннән,
Күңелнең китек чагы.
"Бик шәп булган!"—дип әйтә ал,
"Яратам!"—диген тагы.

Әгәр сиңа бара алсам,
Син шулай әйтә алсаң,
Алдын-артын уйлап тормый,
Яныңда кала алсам,

Йөрәктәге сөю хисе
Димәк, сүнмәгән һаман.
Шул учактан утлар алып
Мин яңа утлар ягам:

Җыелсын учак янына
Мәхәббәттә янганнар.
Сөю хисен бар нәрсәдән
Өстен куя алганнар.

* * *

Уелып төшәрдәй булам,
Үз-үземә карыйм да:
Сөяр яр тапмый тилмерәм,
Сөелергә ярыйм да...

Кемгә ачыйм, кемгә сөйлим,
Кемгә түгим зарымны?
Каян эзлим тәнем түгел,
Җаным терәр ярымны?!

Җилләр исеп киткән саен
Төшә гомер кыелып.—
Үзасым килә калганын
Тиң ярыма сыенып.

"Булыр!" дисәң, була, диләр,
Минеке булмас инде.—
Тиң өлешем тумагандыр,
Туса да, тормас инде.

Хур кызлары бар икән ди,
Җәннәтләрдә—оҗмахта.
Хур егетләре бар микән?—
Ләм-мим бер сүз ул хакта.

...Барып карагач, әйтермен,—
Анда хәлләр ничектер...
Белеп торам—үз тиңнәрең
Анда да дефициттыр!..

* * *

Әллә ничек кенә үтте гомер.
Иртә киләм, дидем. Соңладым.
Рәхимсез бу вакыт күзем нурын,
Чәчләрем карасын урлады.

Миннән урлап, чәчем караларын
Бүләк иткән, ахры, төннәргә...
Ә мин менә ап-ак төсләр белән
Аклык өстим туар көннәргә.

"Күзләремнең нуры сүнде..." дим дә—
Кояш бит көн саен яктырак!
Үзең өчен иң-иң кадерлене
Кешегә өләшү—яхшырак!

* * *

Абау, Аллам, уф инде!
Китәм, бәгърем, хуш инде,
Берьялгызың каласың;
Инде кемгә карарсың
Күңелләрең тулганда?
Абау, Аллам, аһ кына,
Сабыр итим чак кына,—
Карап торыйм китмичә,
Ничек китим, көтмичә
Чын дөрес җавапларын?
Үзем эзләп тапмадым,
Син әйт, белсәң, көттермә.
Кем мин синең өчеңгә:
Вакытлымы, бакыймы?—
Шундый хисләр татыймы
Синең дә күңелләрең;
Яндырган, көйдергәнең—
Минекенә охшашмы,
Бәгырем, сөюләрең?

* * *

*(Кояш белән серләшү)*

**Саумы, Шәмс?! Без бит бер тамырдан,**
**Икәү бер нәселдән булмасак та,—**
**Икебез дә күңел җылыбызны**
**Һәр кешегә тигез юлласак та...**

**Син бер көнне әгәр чыкмый калсаң,**
**Иңри-шаша дөнья йолкыр чәчен.**
**Ялварырлар соры күккә карап:**
**“Чыкчы!” диеп, коя-коя яшен.**

**Ә мин бер көн әгәр чыкмый калсам,**
**Беркем сизмәс, искә алмас һичкем.**
**Берәр айдан кемдер әйтеп куяр:**
**“Күренмәгән иде... Үлгән икән... Мескен...”**

* * *

**...Мин бер кабат яшәгәнмен инде**
**Ерак әлмисакта.**
**Хәтерләмим ниләр кылганымны**
**Анда булган чакта.**
**...Инде менә тагын яшәп йөрим,**
**Кадерен белми генә...**
**Үз кадеремне үзем белмәгәнгә,**
**Кадер күрми генә.**
**Юл салмадым, мәчет төзетмәдем,**
**Утыртсам да агач.**
**Байлыгым юк—Ходай бирмәгәнгә,**
**Ир юк—Ходай алгач...**
**“Вакыт!” диеп, бер көн Газраил**
**Килсә минем арттан,**
**Кәфенлегем куеп янәшәмә,**
**Ятагыма ятмам.**
**“Юк!—диярмен.—Китмим әле пока,**
**Яшәп өлгермәдем!**
**Чыгып кит,—дип, моннан яхшы чакта!”—**
**Аягым тибәрмен.**
**Исбатлармын шулай, миннән куркып,**
**Хәтта**
**Үлем кадәр Үлем чигенгәнен!—**
**...Ә сез**
**мине:**
**“Син бик юаш!” дисез...**



# Лилия Газизова

* * *

Өч катлы борынгы өем.
Мин монда бәхетле идем.

Зәп-зәңгәр күлмәкле аһәң!—
Төннәрен гел безгә килдең.

Салкынча тынлык эчендә
Сурәтләр шыпырт күчендә.

Тартылып чыгарды өнен
Беренче кафиям минем.

Һәм безнең җырга шушындый
Өстәге ай да кушылды.

Тормыш—ирекле шигырь күк,
Икебезгә бер көләч күк.

Ул чакта шул белмәдем мин,
Нинди уеннар көткәнен.

Кагыйдә юк бу уенда.
Безләргә килә кыенга.

Җавап табалмассың төпле:
Кем хаклы да кем гаепле.

Үз йөзе юк икән монда
Кайгының да, шатлыкның да...

Син, өч катлы борынгы йорт!
Бәхетемне исеңдә тот.

Тормыш—азат шигырь иде,
Бәхетебез күккә сыйды.

Лилия ГАЗИЗОВА—*рус телендә язучы шагыйрә; "Черный жемчуг", "Поэма о беременности" һ.б. китаплар авторы. Г. Державин исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

* * *

Татарча фамилияле
Мин—өченче шагыйрә[*],
Урамнан өйгә иңгәндәй,
Әдәбиятка керәм.

Һәммәсе шат кебек монда.
Әйтерләр күк—түргә уз,
Без сине озак көттек бит...
Татар кыяфәтле кыз.

Игорь Северянин сыман
Мин үтәрмен бик кәттә.
Һәм сезнең берегезгә дә
Баш имәмен, әлбәттә.

Авыз итеп шөһрәт дигән
Суынган бәлеш төбен,
Гамьсез генә мин сузармын
Сезгә култамгам җебен.

Ә асылда күңелемдә
Бер өмет яшәр көйрәп,—
Миндәй кызга дан түгел һич,
Тик аз гына наз кирәк.

## Йокысызлык

Төштә юлым күрмәмме, дип,
Мин йокларга теләдем бик.

Ләкин юлым бик ерακта,
Йокы белмәгән якта.

Алданса да кайчак күңел,
Мин үзем дә монда түгел.

Сагалап торса да кинә,
Кире кайтасым да килә.

Аска өстери шул ваем,
Уем өскә очкан саен.

* * *

Иҗат йорты. Нигә шулай
Бик ямьсез килә соң...
Күккә тигән наратлардан
Бөркелә шикелле моң.
Кәгазьгә төшерәсе иде,
Тик мин рәссам түгел шул.
Алдымдагы ак кәгазьгә
Төшми хәтта сыңар юл.
Ап-ак кәгазь. Ап-ак, ап-ак!
Шаулама тышта, нарат,
Мин мөкиббән киткәнмен ич
Шушы аклыкка карап.

* * *

Автомобилем алдыннан
Ренгент сурәтен күтәргән
Бер-ир-ат үтте йөгереп,
Мин туктап аны үткәрдем.
Болай ук ашыкмас иде,
Авырыйдыр инде, мескен.
Минем якты күңелемне
Гүя кара мәче кисте.

[*] А. Ахматова белән Б. Ахмадуллина күздә тотыла.

* * *

Сүрелделәр беләзекләр,
Муенсаларның нуры да...
Гаиләм хакында язам мин,
Шук балаларым турында.

Мәхәббәт сүзен дә хәзер
Кулланам бугай бик сирәк.
Тыйнак кына дуслык сүзе
Хәзер миңа сөйкемлерәк.

Ләкин кайчак ишетәм аһәң:
Онытып буламыни аны.
Сәер, серле дулкынлану
Кинәт биләп ала җанны.

* * *

Һәр узган көн якын миңа,
Түгел көн үтсенгә генә.
Чишелмәгән табышмагы
Яшәгәнгә күңелемдә.
Җимелдәгән пәрәвездәй,
Төшкән алма тавышыдай,
Сорау белән җавап кебек
Хәтеремдә кавышалар
Мең дә бер төннең түрендә.
Һәм мин уянырмын, бәлки,
Вәсвәсәле күңел белән?
Кем белә...

* * *

Сиздермичә инде дә төн,
Җир өстендә тып-тын менә...
Бик еракта ишетелә
Исерекләр таушы гына.

Өстәлдәге лампа уты
Бу караңгы төнге йортта.
Берәр җавап таләп итеп
Сорауларымны яктырта.

Шул яктылык җанга иңә.
Дөньялыкта ни эшем бар?—
Якыннарым барсы өйдә,
Мыш-мыш килеп йоклый алар.

*Ркаил Зәйдулла тәрҗемәләре.*

* * *

Бу—эрегән кар бөртеге генә—
Дымлы күзләрегез.
Ни әйтергә сезгә,
Ни әйтергә сезгә?
Качты сүзләребез.

Бу—көн генә шулай иләсләнеп
Дөньяга ут яккан.
Әле вальс әйләндерә безне,
Әле генә—канкан...

Бу—күңелне алдап алгысыткан
Яз хикмәте генә.
Сез гашыйксыз миңа,
Бары гашыйк.
Язлар әйтми генә...

* * *

Елыйм дип уйлаган идем мин.
Чыкмаган яшем дә.
Төс җуйган фирәзә йөзегем
Кемнәрдән яшерәм?

Сиздерми, тын гына күземә
Төшкән лә күләгә.
Нишләптер кисәктән кадерле
Тоелды... үлән дә.

Шәфкатьле августым, китәсең.
Озатып каламын.
Йөземә пар сызык төшергән
Әйт, кемнең каләме?

* * *

Синең сөю саклап йөртә мине.
Тынычландыр, җылыт, кочакла.
Яратканым, ирем, каһарманым—
Мин үлемсез янда син чакта.

Ышанычлы барыр юлларым,
Синең учларыңда кулларым.

* * *

Көлке төсле никтер
Утыз яшьтә
Баш җуеп ярату турында язуы.
Мәшәкатьләр,
Дөнья гаме
Йота... йота җанны.

Як-ягыңа каранасың...
Их, шайтан алгыры!
Утыз яшьтә дә
Баш җуеп ярату турында
Килә бит язасы.
Һәм...
Хәтта шул хистә янасы!

* * *

Утыз җиде дә юк.
Түгел егерме дә.
Ачы сүзләремне
Төшермимен җиргә.

Мин яраткан җиһан
Мине аклап тора.
Якыннарым сөеп
Яклап, саклап тора.

Якты йолдыз минем
Юлыма нур сибә.
Һәм таләпчән Тәңрем
Гафу кыла килә...

*Илсөяр Иксанова тәрҗемәләре.*



# Мидхәт Садыйков

ПАРЧАЛАР

## Яңгырлы җәй

Инде ничәнче көн тапталган урында сарыклар өчен тамак туйдырырлык ризык булмавын белсә дә, Нурлыгаяз көтүне янә Чиялек ягындагы тау битенә куды. Малкайлар сибелешеп чемченергә керешкәч, тезгенен муенына урап, атын да иреккә җибәрде. Үзе исә төпләре бергә береккән каеннарның берсенә барып сөялде. Гамиләсен күрәсе килү, ул йөргән эзләргә басып үтү теләге аны тагын бирегә алып килде.

Вак кына сибәләгән яңгыр көзне хәтерләтсә дә, табигать җәйге матурлыгын җуймаган иде әле. Бар җиһанны каплап алган төссез күк гөмбәзенең бер ачылуына, кояш нурлары җылысыннан бер назлануга өмет өзелмәгән иде әле.

Нурлыгаяз күкрәк кесәсеннән, бик эчтән, азапланып кына папирос чыгарды, аны яңгыр тамчыларыннан учына яшереп кабызды. Болай да тартышып калган иякләрен чокырлатып, рәттән берничә кат шуны тансыклап суырды. Үтә тиз тәэсир итә торган дару диярсең, ике авыз тын алуда ук аның тәне авыраеп калды.

Тәмәке тартуын ташлаганына хәтсез булган иде инде югыйсә. Бүтән тартмам, дигән иде. Кесә төбендә йөргән "әҗәл даруын" инде алып ташларга да вакыт иде. Юк бит, булдыра алмады.

Нурлыгаяз үзе сөялгән каен төбенә чүгәләде. Кожан итәген җайлап тезенә салды. Тәмәкесен янә бер көйрәтеп уйга талды. Бик тә бәхетле, бик тә рәхәт булган чаклары күз алдына килде аның. Хәтта ирен читләренә елмаю да чыккандай булды.

Әле кайчан гына алар үзләре бер олы йөк булып, печән тутырылган арбага төялеп шушы урынга көтү көтәргә киләләр иде. Яңа гына тәпи баса башлаган кече кызлары белән бергә кояшлы, җиләкле җәйнең озын көннәрен урман кочагында үткәрергә, җиде эшен җиде якка ташлап булса да, елның шушы фасылында мул итеп табигать хәзинәсе җыеп калырга күнеккән телсез-чукрак Гамиләсе дә аларга иярә торган иде.

Тау битенә, агачлар арасына таралышып иртәнге сусыл үләнне ашап алган сарыклар төшке якта борыннарын күләгәле урынга төртеп тынып калгач, үзе учак тергезер иде. Малайлары белән әш-мәш килеп шалаш әмәлләр иде. Аннан соң Гамиләсе җыеп килгән яңа җиләктән авыз итеп, кайнар чәй эчәрләр иде. Көлдә тәгәрәтеп пешерелгән бәрәңгене баш бармакларын тырпайтып мактый-мактый ашарлар иде. Бүтән көннәрдә агач төпләрендә тәгәрәшү, каен башларына менеп мунча себеркесе өчен ботак сындыру кебек эшләр дә үтә бер рәхәтлек белән уза торган иде. Бигрәк тә малайлары әрсез, шук булды. Уйнашып-сугышып туймаслар кебек

Мидхәт САДЫЙКОВ (1952) *– журналист; хикәяләре һәм мәкаләләре вакытлы матбугатта даими басыла. Казанда яши.*

иде. Аларның үзара нидер сөйләшүләрен, нәрсәдәндер кызык табып көлүләрен күзәтү рәхәт иде Нурлыгаязга. Бәхетле иде ул, бәхетле! Чукрактелсез булуы аркасында гына ана яр булган, сөеп-сөелеп туйгысыз гүзәл сын—Гамиләсе белән бәхетле иде ул.

Еллар үтте. Балалары үсте. Үсте дә таралышты. Инде кечкенәсе дигәннәре дә унберенче яшь белән бара. Ярый әле анысы бар, анысы үз янында. Ул булмаса нишләр иде бүген Нурлыгаяз, нишләр иде?!

Әллә кайдан, еракта килгән тавышка каен төбендә үлән утлаган алаша беренче булып башын күтәрде, агачлар арасында чемченеп йөргән сарыклар куркышып бер жиргә жыелды. Бер мизгелгә янгыр да туктагандай булды.

Нәрсәдер барлыгын сизенеп, Нурлыгаяз да урыныннан кузгалды, урман сукмагына борылып карады. Сукмак буйлап көтүгә табан аның кызы Ләйсән йөгерә иде.

—Абыйдан хат бар!—диде ул сөенеп. Аның нәни куллары күз иярмәс тизлек белән жилкәдәге погоннарны сурәтләп алды, һавада дулкынланып таулы ил рәвешенә керде һәм ау мылтыгыннан аткандагы хәрәкәт ясап абыйсы Ильясның Әфганстаннан үз илебезгә кайтуын хәбәр итте. Атаның йөзе яктырып китте. Ул юешләнергә өлгергән хат кисәген кулына алды. Укый белмәсә дә, ана озак карап торды. "Мин беләм, мин беләм!" дигәндәй,бармагы белән берничә тапкыр хатка төртеп күрсәтте. "Тегесендә ул үзе язмаган иде, үз кулы белән түгел иде, мин беләм, мин таныйм аның язуын",—дигән ишарәләр ясады. Ул тиз генә кожан астындагы бишмәтен салып, кызының жилкәсенә каплады. Салкын тимәсен өчен аны шунда ук атка атландырып куйды. "Башка вакыт булса, күлмәкчән чыгып чапканың өчен кирәгенне бирер идем",—диде ата, кызының арт ягын чәбәкләп. Ярар, бу юлы кичерәм, дигәндәй, әчкерсез елмайды. Аннан соң кожанын да жылына алмый калтыранган кызы өстенә бөркәп куйды. Бер мизгел уйланып торганнан соң, Нурлыгаяз сәгатенә күз салды. Нәрсәдер исенә төшеп, кулларын чалбар кесәсенә тыкты һәм ул Ильясның хатын янә ачып, башыннан ахырына кадәр карап чыкты. Аннан соң жылынырга теләп атның аркасына сыенган кызына: "Әнкәннән хәбәр юк идеме?"—дигән ым какты. Кызы дәшмәде. "Юк!" дияргә теле әйләнмәде.

Их, әниләре дә өйдә булсын иде шул мизгелдә. Сөенсен иде бер шушы шатлыктан. Еласын иде бер шыңшып, көлсен иде... Юк шул, яннарында түгел, еракта...

Үз уйларына бирелгән ата белән баланың әле генә яктырып, нурланып киткән йөзләренә сагыш инде. Республиканың онкология хастаханәсенә дәваланырга дип киткән әниләреннән хәбәр булмау аларның бәгырен телде.

Яу кырыннан исән чыгып була икән. Яман чирләрдән дә котылып була диләр. Буладыр, буладыр...

Табигать баласының әллә кай жиренә яшеренгән яман бер чирен, шул нисбәттән туган кайгы-хәсрәтләрен юып ташларга теләгәндәй, янгыр ай буе ява да ява иде.

## Постта

Һәр Сабан туе бәйрәме үзенең кабатланмас бер вакыйгасы белән хәтергә уелып кала.

Үткән ел да шулай булды.

Мавыгып ат чабышын карыйбыз. Шундый кызык, шундый рәхәт. Күңелле тамашаны карарга меңләгән кеше жыелган. Мин дә шулар арасында. Алдагы рәттәгеләр жиргә утырган, дистәләгән кеше кечкенә балаларын күтәреп баскан, кайберәүләр киртәләргә таянган. Һәммәсе дә тамаша кыла, атлар турында гәп куерта, юктан да кызык табып көлешә. Ярты адым гына читкәрәк китеп баскан авыл апаеның да иреннәре кыймылдап-кыймылдап куя. Сүзләр, сүз тезмәләр, кайбер жөмләләр аермачык булып ишетелә:

—Зөлхәбирә апаның кызы кияүгә чыкты. Закир бабаң үлде. Жиңү

бәйрәме көнендә медальләрен дә тагып чыккан иде. "Тагын бер кат Берлинны алган кебек булдым",—дигән карчыгына. Шуннан соң озак яшәмәде. Өч сугыштан да исән-имин кайткан Җиһанша бабаң исән әле. Йөзгә житеп килә. Икенче карчыгы да үлгәч, атасын карарга дип кызы кайтты. Анысы да әби инде...

Ярым житди булып, вакыт-вакыт елмайгандай итеп, авыл хәбәрләренә хас яңалыкларны кемгә сөйли ул, белмим. Янында ире дә, бала-чагалары да күренми. Ә ул һаман үз алдына сөйләнә бирә...

Бераз күзәтә торгач, мин моның серенә төшендем. Иминлекне тәэмин итү ниятеннән ун-унбиш адым саен халыкка таба йөзе белән бастырып куелган солдатларның берсе—әлеге апаның улы булып чыкты. Анасы шатлыктан мөлдерәп тулган күзләрен улыннан ала алмаса да, улының карашы читтә алар—атлар чабышын карарга килгән тамашачыларга төбәлгән. Ул әле бер якка, әле икенче якка карангалап ала. Йөзе житди. Тез буыннарын йомшартудан гайре бер хәрәкәт тә ясамый. Аның өчен әнисе әллә бар, әллә юк кебек. Хәер, бу беренче карашка гына шулай. Постта торган солдатка эндәшергә, сөйләшергә ярамаганлыкны әнисе дә белә бугай. Шуңа да гел үзе сөйли, хатка язып бетерә алмаган яңалыкларны телдән житкерә. Улы өчен, әлбәттә, аларын ишетү дә бик рәхәт, тансыктыр. Ни әйтсәң дә, каршында газиз әнисе бит...

Сумкасыннан бәлеш, сумса кебек камыр исе аңкып торган, күзләре шатлык, сөю хисләре белән мөлдерәп тулган ананың уе—улы белән бергәләп бәйрәм итү, теләге—яшел чирәмле каен төбенә утырып баласы белән бер сыйлану булгандыр да бит, нишлисең, үз иркең түгел...

Вакыт дигәнең тиз үтә, кояш та иң биек ноктасыннан узып, көнбатышка таба авышып бара. Ярышлар да азагына якынлашып килә.

Юртаклардан, нәселле чабыш атларыннан соң, ниһаять, хуҗалык атларына старт бирелде. Өсләренә мәктәп укучылары, егет-җиләннәр менеп кунаклаган утызлап ат бу якка таба ком бураны туздырып чабып китте. Безнең янга житәрәк, жан-фәрманга чабып барган атларның берсе сөрлегеп егылды, жайдагы әллә кая тәгәрәп очты. Мәйдан ах итте. Ул арада ат сикереп тә торды, башын селкеп, пошкыргаланды, аннары башкалар артыннан юыртып китте. Хуҗасы да аксый-аксый аңа иярде.

Тамашачылар арасыннан: "Ярый әле берни дә булмады", "Малай жалкы", "Ат башы белән ир башы ни генә күрми"—дигән сүзләр ишетелде.

Ярышка нәтиҗә ясап, бүләкләр тапшырган арада, солдатларга: "Трибуна янына жыелырга" дигән әмер килде. Сәгатьләр буе безнең алда басып торган солдат та әнисенә: "Мин хәзер киләм",—дип жыелырга кушылган урынга китеп барды.

Халык таралды. Мин дә бәйрәмнең башка төр уеннарын, күңел ачу тамашаларын карау теләге белән сабантуй үзәгенә юнәлдем. Әмма жырлы-биюле уеннар да, баштүбән торып колгага менүче егет тә минем күңелемне әсәрләндерә алмады. Уемда да, күз алдымда да ана белән бала иде. "Кабат очраштылар микән?", "Озак көттермәде микән?"—дигән сораулар күңелгә тынгылык бирмәде.

Халык автобусларга утыру өчен озын-озын чиратларга баса башлагач, мин ат чабышы үткәрелгән мәйданны янә бер кат карап килү нияте белән каен урманы авызына чыктым да, тукталып калдым. Теге апа һаман да шул урында әрле-бирле йөренә иде әле.



## Нияз Вәли

# ҖИЛ ЧӘЧӘГЕ

***

**Хисләр җебеннән**
**Шатлык күлмәге тегә**
**Тонык ай яктысы...**

***

**Дүрт канаты очрашуның**
**Бер ояга ятты—**
**Яктылыкка омтылып...**

***

**Торналар чылбыры чайкала,**
**Ярга бәйләгән көймәне**
**Тотып торган шикелле...**

***

**Күләгәң башкаруында**
**Бу дөнья**
**Бию баскычларыннан төшә...**

***

**Кулыңдагы калган җылылыкка**
**Әле дә сыена**
**Песи баласы...**

***

**Тамчылар куенына**
**Үтеп кермәкче**
**Яктылык шәүләсе...**

Нияз ВӘЛИ (1955) *— шагыйрь; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы; "Тәрәзәле еллар", "Күңел ишеге", "Болытлы сагыш" һ. б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

***

Кар астында гөрләвекләр,
Болытлар эчендә
Сыерчыклар кайтуы...

***

Яланаяк бии,
Күзләреңә кереп,
Тормыш алиһәсе!..

***

Давыл итәкләрен
Җыеп куйды
Сез дөресләгән сүз...

***

Акчарлакланып
Дулкын-дулкын оча
Тау елгасы!..

***

Гел бертөслерәк уй
Ята шунда,
Хәтта филләр тавышында...

***

Ике манара арасында
Йолдыз—
Төн буе җемелди...

***

Каурый итеп так
Җилне
Эшләпәңә...

***

Суга ташлар атып уйныйммы—
Шулай сөйләшәм
Синең белән...

***

Эзеңнән өз
Хәрәкәтне—
Чәчәк иттереп!..

## Галәм

Без зурлыйбыз,
Ә ул омтыла
Чиксезлеккә...

## Ярату

Йөрәген тоткан:
Менә-менә егылыр кебек
Киләчәккә таба...

***

Аһ, син, бәгырь!—
Авырмаган нәрсә авырта,
Сызламаган—сызлый...

## Бәллүр арасында

Әй, бар иде лә
Читән аша сикергән вакытлар...
Кемгәдер кул болгый идем
Печән өстендә...

***

Яшерен таҗчыклар күренә
Синең йөзеңдә
Таң алдыннан...

***

Сине үткәннәрең борчый
Һәм шул чаклы мине—
Киләчәгем.

***

Әй без синең белән
Ерактан гына карарбыз
Аерылышканнарга...

***

Гашыйк ярлар бездән
Рөхсәт сорыйлармы
Утка керергә?!

***

Йөрәк публикасы—
Ул аерымдыр,
Иң кече залда...

***

Вакыт китсен,
Ә без калыйк
Кулларны кулга кушырып...

***

Чәчәкләр коела
Йөрәк өстенә,
Канатланыр алдыннан...

*Бу айда шагыйрьгә 50 яшь тула. Аңа яңа иҗат уңышлары, шигъри табышлар һәм исәнлек теләп калабыз!*

*Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

## Берничә сүз, берничә теләк

"Хәлләрнең гадәттән тыш авыр булуына карамастан "Безнең юл" журналын чыгара башладык... Бу мәҗмуга Русиянең төрле якларында яшәгән һәммә татар-башкорт халкына ярдәм итүне үзенә максат итеп ала. Менә шул авыр, зур бурычны үтәүдә без эчке, Волга-Урал, Сибириянең төрле почмакларында эшләүче әдипләр, шагыйрьләр, барлык гыйлем-әдәбият мөхибләренең *(сөючеләрнең)* ярдәменә ышанып эшкә керештек... Эшче-крәстиян гаммәсенең азатлыгы юлында эшләүче иптәшләр бу журналны үзләренең уртак хезмәтләре итеп карасыннар һәм шулай булышсыннар иде. 1922 ел, май".

"Безнең юл" журналын чыгара башлаганда аның 1 нче санына багышлап язылган мокаддимәдә *(керештә)* идарәдән шушы теләкләр ташланган, эш әсасына *(нигезенә)* шушы принциплар куелган иде. Хәзер генә ачлык фаҗигаләре үтүгә, аның шомлы нәтиҗәләре һаман да ил өстендә канат җәеп ятуга карамастан алга зур, киң максатлар куеп беренче һәм бик чамалы адымнар ясалган, киләчәккә камил ышаныч белән эшкә керешелгән иде.

Тарихи бу көндә табигый бер сөаль *(сорау)* килә: "Безнең юл"ның үзе, югарыда күрсәтелгән, аның таянган көчләре бу зур вазыйфаларны йөкләп бара алдылармы? Практик нәтиҗәләргә ирешә алдылармы?

Бу сөальгә бары иҗаби *(уңай)* җавап кына биреп була.

Кечкенә генә адымнан, гаять авыр шартларда башланган бер эш биш ел кадәр аз гына бер вакыт эчендә киң бер эзгә төште.

Бердән — әдәби, иҗтимагый фикерләрнең бердәнбер лабораториясе булу ягыннан көннән-көн үсә барып, хәзер инде үзенең нигезен, үзенең эш кысаларын яхшы ук ачык билгели алды.

Икенчедән, татарның яшь каләм көчләренә таяныч булу, аларның иҗади көчләрен сынаштыру, эшләтүдә үзәк булу җәһәтеннән ул биткә кызыллык китермәслек эшләр һәм аның нәтиҗәләрен бирде.

Һади Такташ, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Толымбайский, Кутуй, Гомәр Галиев, Ф.Әсгать (һәм башкалар) кебек "Безнең юл" чыга башлаган дәвердә яисә әле яна гына күтәрелеп килә торган, яисә бары матур әдәбият бусагасын аңларга гына торган көчләр "Безнең юл" журналы тирәсендә үзенең иҗат учагын, тәҗрибә стансасын тапты, шунда чарланды. Бик күбесе инде тармакланып, чәчәкләнеп, "яшьлек" буыннарын үтеп мәгълүм формаларга, билгеле әдәби нигезләргә басты, калыпланды.

Менә бу ике вазыйфа "Безнең юл"ны башлап җибәрү эшләрендә нигез итеп салынган төп шартлар, төп юнәлешләр иде.

Без бүген ул шартларның камил диярлек үтәлгән булуын күреп шатлык белән каршы алабыз.

Бәйрәм, тантана актлары күп сүзләргә мохтаҗ түгел. Тик алга бер генә теләк куясы килә:

Моннан соң "Безнең юл" төрле тармаклардан торган иҗтимагый адымнарга артык бирешмичә, үзенең мөндәрәҗә *(эчтәлек)* йөзен башлыча әдәбият, сәнгать, тәнкыйть, библиографияләрдән гыйбарәт булган хезмәткә юнәлдерсен һәм сәнгать, әдәбиятның иҗади, гыйльми, практик, тарих, теория мәсьәләләрен тагын да җитдирәк, тагын да ныгыганырак формаларга салып бирергә әһәмият бирсен иде.

Үзе белән беррәттән татарның башка гыйльми, әдәби, иҗтимагый күп кенә журналлары яшәве һәм төп нигезләрнең хәзерге көндә дә яхшы ук билгеләнгән булуы — алдагы тагын да авырырак, тагын да җитдирәк хезмәтләрне башкарып чыгарга камил ирек бирсә кирәк.

Журналның киләчәге тагын да яктырак, тагын да уңышлырак булачагына тулы ышаныч белән каласы килә. Бу һәм шулай булыр да.

Фәтхи Бурнаш.
17 / VI, 27.
*("Безнен юл"—1927, N: 6-7)*

Əd əbi tənqit
# Әдәби тәнкыйть

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

## ҮЗЕБЕЗНЕ САКЛЫЙК!

Белемем, эшем буенча гуманитарлыктан, аерым алганда төрле әдәби бәхәсләрдән читтә торсам да, үземне бу өлкәдә бөтенләй үк "сай йөзүчеләр" рәтенә куясым бик килмичә, милләтебез язмышына, әдәбиятыбызга битараф булмавымны да истән чыгармастан, журналда барган "Безнең заман герое" дип аталган дискуссиядә катнашудан, геройлар тикшерүдән бигрәк, жанны гажизләткән кайбер сорауларга җавап эзләп, кыска гына итеп сезгә үз фикерләремне бәян итәсем, җиткерәсем килеп шәрехлим бу язмамны.

Күптән андый әйбер укыганым юк иде. А. Хәлимнең бу елның 1, 2 саннарында басылган "Сез беләмсез кая барганны?" дигән мәкаләсен сокланып, сөенеп һәм яратып укыдым. Менә кайда ул чын, башбирмәс, агрессив татар зыялысы, язучысы! Менә кайда ул кәрәкәләрнең йокыларын качыручы күлдәге чуртан балыгы! Ни өчен башка язучыларыбызда Айдар абыйдагы шул яхшы усаллык, безне мең бәладән араларга, кисәтергә тиешле шундый чаң сугу, анардагы тирән эрудиция юк? Авторны бөтенләй белмәгән кеше дә, мәкаләне укып чыккач, бу шәхеснең үтә дә фидакарь милләтпәрвәр, халкыбыз, аның язмышы, киләчәге, әдәбияты өчен ут йотып йөрүче, кирәк булса бу юнәлештә, бу көрәштә малын да, җанын да кызганмаячак бер гыйсъянчы илаһи зат икәнен аңлар. Моны әлеге язмадагы чиксез хисселек тә, абзац саен диярлек булган фикер биеклеге (полет мысли) дә, кайнарлык, хәтта кайбер урыннардагы, әйтер идем, дуамаллык та раслап тора.

Иң лаеклы дип саналган язучыларыбыз да тәнкыйтьтән читтә калырга тиеш түгелдер дип уйлыйм мин. Беркем дә Алланың кашка тәкәсе түгел. Айдар абыйга үпкәләмәсеннәр иде алар. Кайбер язучыларыбыз арасында чиргә әйләнгән, аларны вакландырган кемгәдер ярарга тырышу, фальш, хилафлык бөтенләй юк "Сез беләмсез..."дә. Ярарга тырышса да Айдар Хәлим бары тик Аллаһы Тәгаләнең Үзенә һәм күпне күргән милләтебезгә генә ярарга тырышадыр. Һәр гамәлдән дивидендлар өмет итеп, заманга бөтенләй яраклашкан күп зыялыларыбыз бер-берсенә тел-теш тидерү генә түгел, ярыша-ярыша үз эшләрен мактап йөргәндә, кода-кодагыйлык чәчәк атканда, килешегез, мондый компромиссыз тәнкыйть ул чын мәгънәсендә батырлык, аны бары чын талант кына тудыра ала. Мондый язманың журналда чыгуын да вакыйга, йөрәккә сарымай, күңелгә хуш килүче бәлзәм итеп күрәм мин.

Мина калса, автор йөрәгеннән кан тамызып язган ул мәкаләнең беренче төп әһәмияте шунда, әлеге хезмәт дөньяга чыгу язучыларга гына түгел, ә барлык булган йокылы-уяулы татар зыялыларына, шул исәптән без—әдәбият яратучыларга да—җидедән үрелгән чуклы камчы белән китереп сугуга тиң. Айнып киттекме ул мәкаләдән соң! Киттек! Ешрак булса да начар итмәс иде. Бу яктан алганда каешланган сыртларыбызга ешрак тамызу өчен безгә бер Хәлим генә түгел, бәлки ун Хәлим кирәктер? Чөнки без хәзер шундый да калын тиреле, әдәбиятыбыз мөшкеллеген, милләтебезнең аяныч хәлен күрмибез, чеметкәләү-төрткәләүләрне генә гел дә сизмибез.

Р. Мостафинның журналның бишенче санында басылган һәм А. Хәлимгә җавап рәвешендә язылган "Төгәл булыйк" дигән язмасын да зур кызыксыну белән укыдым.

Язылганнарда күпмедер дәрәҗәдә үпкә сизелсә дә, ул мәкаләдә дә дөреслек юк түгел сыман. Тик нинди дөреслек? Дөреслек тә төрле була ич. Әйбер шактый салкын акыл белән, алны-артны бик нык карап, дәлилләр китереп язылган булса да, иң беренче күзгә ташланганы шул: Рафаэль абый Айдар Хәлимнең эре калибрлы артиллериясенә каршы бары тик автоматтан гына кыска зәгыйфь чиратлар (очередьлар) биргәли. "Сез беләмсез..."гә, аның авторына төбәп шактый кискен сүзләр язса да. Шунлыктан, бу бәхәстә аларның авырлык категорияләре нык аерыла дию дөрес булыр иде.

Әйе, абсолют дөреслек бары тик бәхәстә генә туа ала. Милләт исәнлегенә, аның янарышына өмет тоту, халкыбызны мәгънәле әдәбият белән тәрбия кылу, шуңа өндәү дөреслеге башка кыйблалардан, башка дөреслекләрдән өстен каралганда гына ул ниндидер әһәмияткә ия, миңа калса. "Төгәл булыйк"ны укып, Р. Мостафинның үз терминологиясен кулланып, минем авторны бүгенге көннең коеп куйган ашкын җәдитчесе дип атыйсым килә. Һәм бу кыйблада торучылардан татар язучылары арасында ул һич кенә дә ялгызы түгел, дип тә фаразлыйм.

Беренче карашка җәдитче булу, бер гасыр элек кенә түгел, бүгенге көндә дә бик яхшы да, актуаль да сыман. Күпчелеге манкортлашкан гади хезмәт кешесеннән башлап, иң эре чиновниклар да шул тарафка караган заманда бу—уңайлы да, конфликтсыз да, прогрессив та. Барысын да дөньядан артта калмау, анда нинди яңалык бар (яхшымы, начармы,—анысы алай ук мөһим түгел), шуны милләткә сендерергә тырышу, алгарыш, үсеш белән аңлатырга була төсле.

Катнаш никахлар бар җирдә дә бар, алар бездә күбәя икән, күбәйсен. Алар турында тәнкыйтьсез язып торалар икән, язсыннар. Беренче урында кеше хокуклары, мәхәббәт булырга тиеш. Аннан соң гына милләт язмышы, исәнлеге. Чөнки, Рафаэль абый сүзләре белән әйткәндә: "җәй артыннан барыбер кыш килә". Урыслашу бара икән, барсын. Глобализм килә икән, килә инде, кая китәсең? Бер безгә генә килми ич. Табигый процесс, тыелгысыз. Глобализм белән бергә үсеш, яңа технологияләр, яңача яшәү рәвеше, рәхәтлек (күпләр уйлавынча) килә икән бит. Ул процесс үзенең төссез, хиссез геройларын тудыра, алар белән мавыгучылар арта тора икән, бигайбә, булсын. Нигә ул дөньяда берничә йөз тел? Ахыр чиктә өч-дүрт тел калса, бик житкән. Нигә кирәк ул "артта калган" халыкларның "караңгы" культурасы, әдәбияты, сәнгате? Көнбатыш культурасының нигезендә яткан англо-саксларча яшәү, тормыш кору тәртибе калса бик житкән.

Болар хөрмәтле Р. Мостафин язган фикерләр үк түгел, ә бәлки анынча уйлаучы башка замандашларыбызның тел төбендә яткан карашлар, алар мантыйгы.

Шунлыктан җәдитчелек унтугызынчы гасыр азагы, егерменче гасыр башына гына карый, ул шул чорда яшәгән бабаларыбызның фикер сөреше генә дисәләр, мин һич килешмәс идем. Глобализмны, урыслашуны ашкынып чакырып тормасалар да, күнелләрендә ул нәрсәләргә, һәммә төсләребезне, үз-үзебезне җуйдырырга килүче ул туфанга протест, каршылык ятмаган татарларыбызны ничек дип атыйк соң? Әллә манкортлар дипме? Шушы без сөйләшкән өлкәдә күп нәрсәләрне аңламыйча агым уңаена йөзүчеләрне шулай атау бәлки дөрес тә булыр иде. Тик аңлап та Алла каргаган ул шаукымнарга кочак җәючеләр кемнәр? Яңа җәдитчеләр! Баштан ук шуны искәртәм, биредә сүз күбрәк А. Хәлим искәртеп киткән "ненормированный" җәдитчелек турында бара. Читтән килгәнне сортларга, яхшыга-яманга аермыйнитми "уптым-иллаһи" йотучылар турында. Көнбатышның үзендә үк комагайлыкка, акчага табынуга, азгынлыкка, рухи һәм әхлакый фәкыйрьлеккә корылган ул культураның, глобализмның ахыр чиктә кешелек дөньясын тупыйкка, бетүгә илтүен аңлаучылар артканнан арта барган вакытта акны карадан аерырга теләмәүчеләр хакында сүз.

Гади халык "караңгы" да булсын. "Нигә кирәк соң ул татар теле, урыс, инглиз телләре күпкә кирәгрәк", дип балаларын урыс, инглиз мәктәпләренә бирүче татар инженерлары, татар табиблары, укытучылары кем? Иҗтимагый үзәкләр эшләгәндә анда йөрмәү генә түгел, "йөрисез шунда коткы таратып, сугыш чыкса нишләрбез?" дип, милләттәшләренә "очып кунучы" югары белемле кичәге авыл балаларын ничек атарга? Сугышмыйча, тыныч юллар белән дә күп нәрсәгә ирешеп булганлыгын аларга ничек аңлатырга? Татар мохитендә туып-үсеп тә гомерендә бер татар газетжурналын алдырып карамаган, милли театрыбызның кайдалыгын белмәгән, телевизордан урыс яки чит ил киноларын, сериалларын калдырмаучы зыялы саналган

мина таныш технолог, конструкторларыбызны, чеп-чи татар булган цех башлыкларыбызны, өйләрендә балалары белән урысча сөйләшүче бүлек, лаборатория мөдирләрен ничек атарга? Бүгенге көннең ультраҗәдитчеләреме, әллә хәлне ахырына чаклы анларга теләмичә шул тегермәнгә су коючыларммы? Минемчә, икесе дә.

Һәрхәлдә татарның бүгенге шактый аянычлы язмышында, әдәбиятыбыз сайлыгында, геройларның мескенлегендә йөз дә ничә ел буе кирәгеннән артык җәдитчелек белән мавыгу, шул агым алып килгән фәлсәфә, шул караш тудырган битарафлык корбаны булу ятмый микән? Бәлки безгә шул элекке вакытлардан ук аз гына булса да кадимче дә булырга кирәк булгандыр? Һәрбер эштә ниндидер урталык, чама белү дигән нәрсә дә бар бит әле. Ни өчен йә акны, йә булмаса караны гына сайлыйбыз соң? Ак та, кара да булмаган төсмерләр, ярымтоннар да бар бит әле. Милли төсмерне, янарыш, ренессанска чыгаручы кыйбланы сайлап ала, сайлагач җуймый саклый белергә, көрәшергә генә кирәк. Безгә менә шул җитенкерәми ич инде.

* * *

Без—кытайлар да, инглизләр дә, индуслар да түгел. Без—шактый кечкенә, таралып яшәүче һәм иң аянычлысы—дәүләтсез милләт. Дәүләтсезлек—безне ассимиляциягә өстерәүче, ике катлы глобализмнан *(урыслашу һәм көнбатыш культурасы йогынтысына эләгү)*, яна җәдитчелектән иммунитетсыз итүче беренче сәбәп. Алар, ул халыклар, бәлки мең елдан соң да бүгенгедәй исән-сау, сәламәт булырлар. Гореф-гадәтләрен дә, мәдәниятләрен дә, әдәбият-сәнгатьләрен дә саклап калырлар. Ә безнең айлар-елларыбыз санаулы булырга да мөмкин. Без, кем дигәндә, татар җирләрен анклавта тоткан Урыс иленең сәгате суга башлаганчы тырышып җан асрарга, күпмедер дәрәҗәдә сәламәт булырга тиешбез. Бу *(сәгате сукканны көтик, дию)* гонаһлы сүзләр түгел, иртәме-соңмы барыбер шулай булачак. Гомер-гомергә эчке каршылыксыз, тавыш-гаугасыз, төрле гарасатларсыз яши алмаган гонаһлы Урыс иле мәңгелек түгел. Сез картадан аның территориясенең зурлыгын гына карагыз. Анда беркайчан да юньле идарә системасы булмаганын, аның башка империяләр кебек фәкать штыклар ярдәмендә генә таралмый торуын исәпләгез. Ә инде сәгать суга башладымы, безгә моментны тотып алырга, үзебезгә буйсындырып, аннан тулысынча файдаланып калырга кирәк. Мизгелне кулдан ычкындырсак бүтән шанс, бәйсез татар дәүләте торгызу шансы, бүтән булмаска да мөмкин.

Бу—киләчәктә. Ә бүгенге көндә безгә кирәгенчә уяу, айнык, бердәм булырга кирәктер. Баш өстебездә Домокл кылычы кебек асылынып торучы ассимиляциядән, глобализмнан, милли төсмеребезне югалтудан безне өзлексез, перманент көрәш, каршылык кына коткарып кала ала. Ә көрәштә калу өчен әйдәүчеләр, кем икәнебезне искәртеп камчылап алучылар бик кирәк. Көндәлек, четерекле, вак, кайчагында хәтта астыртын, хәйләкәр, әмма һәрчак үҗәт һәм эзлекле көрәш булсын иде ул. Ул көрәштә әдәбиятыбыз—татар халкының олылыгын, кешеләренең затлылыгын тасвирлаучы сыйфатлы әдәбиятыбыз—зур роль уйнасын иде. Тик кая соң ул безне югары күтәрергә тиешле бөек татар әсәрләре, татар геройлары? Мин күреп бетермим.

Алда санап кителгән явызлыкларга без корал тотып көрәшә алмыйбыз. Ул кирәкми дә. Андый очракта безне канга батырачаклар. Мисал эзләп ерак барасы түгел. Андый очракта юкка чыгу бернечә мәртәбә тизләнәчәк кенә. Мондый четерекле һәм изге көрәштә без кайчандыр Махатма Ганди гамәлгә кертеп калдырган "Явызлыкка көч кулланмыйча каршы тору" *("Непротивление злу насилием")* дигән тәгълиматны кулланып кына эзлекле көрәшә, милләтебезне саклый, кирәкле моментны эләктереп ала, ниндидер күркәм нәтиҗәләргә ирешә алырбыз төсле.

Мондый каршы торуда әдәбиятның роле дә әйтеп бетергесез. Ул көрәштә без тагын нәрсәләргә таянырга, нәрсәгә исәп тотарга тиеш соң?

Күп нәрсәләргә А. Хәлим анализ ясап чыккан, дөрес эшләнергә тиешле мәктәп дәресләкләреннән башлап, халыкара оешмалар, хокук оешмалары белән тыгыз контактта эшләүгә кадәр, барысына да! Безнең әлегә үзенчә бер югарылыкта торган театр сәнгатебез бар. Мәшһүр җырчыларыбыз, талантлы композиторларыбыз бар. Дөньякүләм биеклектә булмаса да, бай тарихлы әдәбиятыбыз, язучыларыбыз, шагыйрьләребез, ялкынлы публицистларыбыз бар. Бәлки әле кайчан да булса Милли университетыбыз да төзелер, әлегә чаклы булмаган дип әйтерлек татар

кинематографы эшләп китәр. Зыялыларыбыз, абруйлары, кыюлыклары артып, республика житәкчелеге белән эшләргә, аңлашырга, йокне бергә тартырга өйрәнерләр. Шул аңлашудан бәлки кайчан да булса ачык милли идея дә туар.

Таяныр нокталар, эшкә жигеләсе рычаглар күп. Тик әлегә аларның хәтсезе эшләми. Эшләгәне дә канәгатьләндерми.

* * *

Бәхәс әдәбият, андагы бүгенге заман герое турында баргач, башкаларына вакыт сарыф итми әдәбиятка кагылыйк инде.

Урысларда, христиан динендә "чистилище" дигән сүз, термин бар. Татарчасы аның "араф" дип атала бугай. Кайчандыр католик дине руханиләре гамәлгә керткән бу сүз теге дөньядагы чистарыну урынын, гөнаһларын юуу, йолу, тәүбәгә килү жирен аңлата.

Кисәк кенә: ни өчен ул "араф" дигәннәре бакый дөньяда гына, ник фаниенда юк дигән уй чагылып үтә. Әгәр дә андый чистарту урыны без яшәгән шушы жирдә булып, кешеләр вакыт-вакыт аның аша үтеп торсалар, жирдә нинди мәгънәле, камил тормыш булыр иде. Иманым камил, һәр нәрсәне сата һәм сатып алып була, дип өйрәтүче көнбатыш демократиясенең дә эзе суынып иде. Юк шул андый чистарткыч! Шунадыр инде жиребез гөнаһлы жаннар белән тулы. Яшәешебез дә шул сәбәпле гаделсезлек, шәфкатьсезлек, битарафлык белән сугарылган. Ләкин, яхшылап уйлаганда, күпмедер дәрәжәдә арафны алыштырырлык әйбер бар икән бит ошбу дөньябызда. Ул да булса мәгънәле әдәби әсәр, безне тетрәндерә, чын кеше булырга өнди, тормыш ваклыкларыннан арындыра торган китап, аның геройлары икән ул! Әйе, әдәби әсәрнең төп вазыйфасы—булдыра алганча кешене затлырак итү, пакьлау, жаннарыбызны чистарту, дөнья пычрагыннан аерып торудыр. Бу аның төп билгеләнеше, миссиясе. Хикәя, повесть язылганда ук шушы бөек таләпкә жавап бирерлек итеп язылырга тиештер дип уйлыйм мин. Башкача булганда, ул базар көнне поты бер тиен булган, бүген китап кибетләрен тутырган макулатура булыр иде. Кеше үзе дә ич дөньяга Аллаһы кушканча яшәргә, игелек эшләргә, камиллеккә омтылырга, булдыра алган чаклы дөньяны да камилрәк, гүзәлрәк итәргә дип килә бит. Бу—жирдә яшәүнең бердәнбер һәм тулы мәгънәсе.

Ә пакь булганда, ваклыклардан өстен торганда, татарда көчле милли вектор үзеннән-үзе яралачак. Ул яралмый кала алмый. Бөек максатка омтылган халык мескен булып кала алмый. Кайчан да булса бөек әдәбиятыбыз, телдән-телгә, китаптан-китапка, экраннан-экранга йөриячәк геройларыбыз буласына ышанам әле мин.

Ә бүген ни кызганыч: кешенең күнелен ачу, укып вакытын уздыру максатыннан язылган, бәндәдә кыргый инстинктларны уятучы әдәбият белән кибет киштәләре тулган. Чөнки безгә үтеп кергән шул глобализм чире, әлеге дә баягы көнбатыш яшәү рәвеше, алар культурасы, ана тиңдәш урыс психологиясе "Акча эшлә дә күнелеңне ач, акча эшлә дә бүксәңне тутыр. Яшәп кал, иң дөресе шул", дип тәкрарлый. Шул шаукымга каршы торырлык көчебез булмаганга да инде безнең милләт, безнең әдәбият шундый аяныч хәлдә, бүгенге хәлдә.

Бүгенге арафлыкка дәгъва иткән, дөньялыкта дөрес итеп яшәргә өйрәткән, кыйблаларны күрсәткән әсәрләр, геройлары белән бергә, дөньяга, татар дөньясына бармак белән санарлык кына туалар. Аларны А. Хәлим күрсәтеп үткән инде, кабатлап тормыйм. Детективлардан, мәхәббәт мажаралары язылган китаплардан аермалы буларак, андый әсәрләрне укыр өчен азмы-күпме әзерлек кирәклеген дә искә алсак, сурәт шактый өметсез төсмерләр ала, китап культы, яхшы әсәр культы, аңа табыну, аныңча яшәү турында хыялланырга гына кала. Тик кешене хыял яшәтә бит. Хыялланыйк без. Һәм хыялларны тормышка ашырыйк.

Аннан соң татар язучыларының мин белгән күптәнге чире, ул да булса сыйфат артыннан түгел, сан артыннан куу да бар бит әле. Бу күренеш тә татар әсәренең абруена гел сугып тора...

* * *

Таяну нокталары, эшләмәгән рычаглар хакында әйттек инде. Шуңа өстәп үзебездәге кимчелекләр комплексы, кая барсак та артыбыздан калмас "кара сакал", татардагы "дефицит" турында берничә сүз.

Безгә А. Хәлим кебек ялкынлы публицист, язучылар җитми. Мәскәү белән, үзебезнең ультраҗәдит, ярымурыслашкан манкорт чиновниклар белән һәрчак бәхәстә торучы, үз тиреләрен, сыртларын кызганмаучы чын диссидентлар җитешми. Безгә чөелгән борыннарын аска төшереп, әдәбиятыбызны дөньякүләм аренага чыгара алырдай мәшһүр каләм ияләре, хөсетлектән, куркаклыктан азат зыялылар кирәк. Безгә газет-журналларның тиражлары кимегән саен йокылары кача, кимүенең сәбәпләрен эзли, чаралар күрә белүче, тәнкыйть белән ныклап мавыгучы зирәк журналистларга олы кытлык. Безгә "Нигә һаман милли университетыбыз юк?" дип, *(гуманитар-педагогика университеты аны алыштыра алмый)* мәйданнарны шыплап тутыручы актив зыялыларыбызны әле эзләп йөрергә кирәк. Күп каләм ияләребезгә үз согында үзе кайнап, үзен даһига санап, "мин бүгенге татар әдәбиятының кендеге бугай" дигән сабыйларча беркатлылыктан да, нарциссизмнан да арынырга кирәк. Үзара мактау, макталу, канәгатьлек ул, гомумән, чикләнгәнлек билгесе. Үз-үзеннән, башкалардан, тормыштан канәгать кеше бервакытта да чын талант була алмый.

Ә талантлар—үзен генә түгел, милләтне дә хөрмәт иткән усал талантлар—фидакарьләр безгә кирәк, бик кирәк!

**Наил ШӘРИФУЛЛИН**

---

# ФӘЛСӘФӘ ҖИТМИ БЕЗГӘ

Айдар Хәлимнең "Безнең заман герое" турындагы бәхәскә катнашуы әдәбият сөючеләр өчен бер бүләк дисәм дә арттыру булмас. "Казан утлары"ның ике санында басылган "Сез беләмсез кая барганны?" язмасын кат-кат укыдым. Мәгълүмат күплеге, фикер тыгызлыгы, язу осталыгы укучыны җәлеп итеп, исеме аталган әдәби әсәрләргә кайту теләге уята. Айдар Хәлим үзенең чыгышын фәлсәфи бәхәс дәрәҗәсенә күтәреп, галим-голәмә, зыялылыр алдына бик күп сораулар куя. Мондый чыгышның кайтавазы озак янгырар кебек. Кемдер А.Хәлим күтәргән сорауларның тирәнлеген, кирәклеген аңлап аны дәвам итәр, кемдер шикаять тә яза торгандыр. Кайнар, бәхәсле чыгыш бит, ә безнең кайбер агайлар бәхәсне турыдан-туры йодрык белән өстәгеләрнең хәл иткәнен ярата.

Сөйләшеп аңлашу – ирек-иркенлек тоеп, тормышның тәмен-мәгънәсен белеп яшәгән кешеләргә генә хас. Без сөйләшеп аңлашудан күп вакыт мәхрүм халык. Ирексез без. Тоталитар режимның сүзсез-телсез, хәерче, көндәм бер эш атына әйләнгән милләтебезгә Заман герое булып күтәрелү – бинаһая кыенлыкларны җиңеп кенә мөмкин. Заман безне төпкә этә. Туп ите, эш аты, сәрхүш көтүче "дәрәҗәсенә" генә күтәрелә ала татар кешесе. Саламторханлык—аның бар кылган гамәле. Матбугат битләрендә бик мактап күтәрергә теләгән түрә катлам да җепкә бәйләгән курчак кебек, шул тоталитар сөремгә манчылган уенны уйнарга мәҗбүр. Ирек-иркенлек—гамәлдә булсын, уйда-сүздә булсын—түрә катламга да хас түгел.

Айдар оста Заман герое булып күтәрелү өчен төп шарт итеп милләт мәнфәгатьләрен яклауны куеп үлчәмне бик дөрес ала. Милләт тудырган илаһи байлыкларны каты кысу, битарафлык шартларында җыйган, саклаган, үстергән Нәкый Исәнбәт кебек ил агалары—заман Алыбының иң гүзәл бер үрнәгедер. Тик нигәдер Салих Сәйдәш, Нәкый Исәнбәт кебек халкыбызның асыл уллары түгел, һаман чит бөекләр җинел генә Казан урамнарын яулый. Һәйкәлләр белән рәттән безнең календарьда "Идегәй" дастаны көннәре", "Милли каһарманнар көннәре" кебек бәйрәмнәр дә булырга тиештер бит? Бәлки Хәтер көнен тулаем милли каһарманнарыбызга багышлап үткәрергә кирәктер?

Китап турында сүз барганда китапның да безнең ирексез язмыш дулкыннарына бәйле икәнен онытмыйк. Бүген җирне-суны гына түгел, электрон элемтә, компьютер тудырган мөмкинлекләрдән файдаланып һәр кешенең күңелен яулау бара. Берәүләр

- гадәттә хәллерәк, баераклар - ялтыравык журналлар ятьмәсенә эләгеп "патшаларча" яшәүгә күчәләр—күңел ачалар, казино-фәхешханәләргә, төнге клубларга агылалар, икенчеләр телләрен алыштыралар. Уен шундый — аулау бара. Бу уенда безнең катнаш юк диярлек. Заман элек тә безнең заман түгел иде. Урыс интеллектуаль дөньясы коммунизм "төзегән" чорда да безнең башларга дыңгычлап тутырган "ВКП(б) ның кыскача курсы" белән генә яшәмәде. Ул төрле ябык оешмалар өчен (Чит илләр министрлыгы, КГБ, МВД һ.б.лар) дөнья әдәбиятын, фәлсәфәсен тирәнтен өйрәнде, тәржемә итте, фәнни хезмәтләр (ябык) язды. Аның кайберләре элита өчен генә китап булып бастырылып, ябык кибетләрдә сатыла да иде. Менә бүген элеккедән килгән эзләнүләр, тәржемәләр, фәнни хезмәтләр, КГБ һәм башка ябык оешма архивлары электрон дөньяның бөтен өстенлекләрен (сыйфат, тизлек, мәгълүмат күплеге) файдаланып, күз-ачып йомганчы китап киштәләрен тутырды. Кемнәр генә юк бу иксез-чиксез китап дөньясында—Рим папасы, Жохар Дудаев, фәйләсуф һәм көрәшчеләр, байлар һәм авантюристлар, политиклар һәм поп йолдызлар. Тик без юк.

Китап үлмәде. Ул тагын да затлы, зәвыклы булып безнең күңелләрне үзенә тарта. Әйе, китап татарча түгел. Чөнки үткәндә дә безнең эзләнүләр тар кысаларда, рөхсәттән рөхсәт алып кына мөмкин иде. Читкә чыгулар, дөньяны башка биеклекләрдән күзаллаулар—монда татар зыялысына юл ябык булды. Бүген хәл тагын да аяныч. Бүген нәшриятта китап чыгаруны җайга сала алмаганга аптырап эшен ташлаган татар мөхәррирләре барлыкка килде. Үткән белән чагыштырганда безнең мөмкинлек тагын да кечерәйде. Ә бит милләт сүз белән яши, әйтер ие-сүзе беткәч ул инде юкка чыгарга мәҗбүр.

А.Хәлимнең кайбер фикерләре сискәндереп тә куйды. Татарны сүкмәгән татар язучысы юк бугай инде ул. Безнең халык көнчел, хөсетле, үзара талашка баткан һ.б.лар. Бу әле йомшак әйтелгәне. Менә Айдар абый да татарның биш миллионнан "мәҗүсиләшкән өч миллионын җиңел генә коеп калдырып " дөньяның күркәм милләтләре исәбенә басарга уйлый. Мондый фикер бәлки чарасызлыктан тугандыр. Әмма хатын-кыз, әни кеше буларак миңа һәр милләттәшем газиз. Һәр татарның язмышында минем дә катнашым бар, уртак тормыш гаделрәк, чистарак, төзегрәк булсын өчен мин дә нәрсәдер эшләп бетермәгәнмендер төсле тоела. Әгәр кеше минем белән килешми, яки мин куйган максатка омтылмый икән, бигайбә, аның шулай итәргә хакы бар. Кеше хакы—Тәңре хакы. Айдар абый үзе дә әлеге хәлне таный кебек. Сорауны башкача куясы килә—без милләтебезнең чын йөзен, холкын-фигылен, омтылышын беләбезме? Бармы бездә татарны аерым шәхес буларак тикшергән хезмәтләр? Әллә һаман Карл Фукска гына ишарә ясарга туры киләме?

Буыннан-буынга халкыбызны тормыш шартлары шундый китереп кыскан, бүген дә күпчелек җан асрау өчен тырмаша. Шуңадыр каударланабыз, бәргәләнәбез, өзгәләнәбез. Укмашып яшәр өчен бер миллионга калырга түгел безгә, ә җитмеш миллион татар булырга кирәк. "Ил белән",—ди бит татар кешесе. Бу сүзләрнең мәгънәсе бик тирән. Хыялдагы Илнең сыйфатлары—уртак тормышта алдашу-урлашуга юл куймау, кеше хакын хаклау, ышаныч нигезендә оешу. Булганмы халкымның үткәнендә хыялындагы Иле, әмма телендә һәм теле аша канында саклана ул Ил сурәте. Шул хыялдагы Бөек Ил сурәте тоныкланмасын, һәркемнең күнеленә бөтен максаты, яктылыгы белән кереп утырсын өчен фәлсәфә җитми безгә. Үз телебез тудырган, фәлсәфә сандалында чүкелгән уй җитми. Айдар Хәлим шул уйны күрер-күрсәтер өчен вакытын, осталыгын җәлләмәгән.

**Зәрия ХӘБИПОВА**

## Тәлгат Галиуллин

# БИЗМӘНДӘ—ШИГЪРИ РОМАН

Шагыйрь Ренат Харисның һәр яңа әсәре, үзенең эчтәлеге, сурәтләү чараларының яңачалыгы, һич югында күренеш-хәлләргә шәхси бәясе белән хис күзәнәкләрен сискәндереп җибәрә, аннан йөрәккә, күңелгә үтеп керә, уйландыра, нәтиҗә ясата. 2004 елның соңгы көннәрендә Татарстан китап нәшриятында зәвыклы бизәлеш белән дөнья күргән, "шигырь-роман" дигән ачыкламышлы "Исемсезләр" әсәре дә шундый катлаулы фикерләр уята. Шигъри романның иҗат үзенчәлеген һәм татар поэзиясенә алып килгән яңачалыгын аңлау өчен нечкә тоем белән сурәтле фикерләү байлыклары дөньясына үтеп керергә тиешбез, ул шунда гына үзенең сихри көчен ачар. Авторның күңел дөньясын, катлаулы структур төзелешне аңлау өчен фәлсәфи аң югарылыгына күтәрелү зарур.

Иң әүвәл сүзне исемне шәрехләүдән башлыйк. Тоталитар система үзенчәлекләреннән хәбәрдар кешеләр аңында "Исемсезләр" тәхәллүсе үзе үк төрле хисләр өермәсе тудыра. "Әлегә ул исемсез йөри" дигәндә космонавтлар, төрле илләрдә хәзер "террорист" дип аталган, чынында үз халкының мәнфәгатьләре өчен төрле батырлыклар кылып йөрүче чекистлар, разведчиклар, милләтпәрвәрләр күз алдына килеп баса. Аларның исемнәре соңрак, еш кына вафатларыннан соң гына, җәмәгатьчелеккә мәгълүм була. Икенчедән, безнең чорда бер зур җинаятьне дә ача алмаган яисә ачарга теләмәгән тикшерүчеләр, мәхкәмә әһелләре "эзләнүләр төгәлләнгәнче ("в интересах следствия") исем-фамилияләре әйтелми" дигән сылтау белән һәм беркайчан да мәгълүм булмаячак аңлатма-ялганнарга күнегеп беткәнбез. Ягъни "Исемсезләр"нең шул рухтагы "детектив" әсәр булуга дәгъва итәрлек мөмкинлеге бик бар. Әлбәттә, тормыш "сюжеты" әдәби кысаларга сыешып бетмәскә дә мөмкин.

Әсәрнең жанрын кабул ителгән теоретик яссылыкта "шигъри роман" дип кенә билгеләмичә, "шигырь-роман" буларак бәяләүдә автор үзе генә аңлый торган тирән мәгънә, яисә "шаккаттыризм" галәмәте бардыр. Иҗат җимешенең жанрын билгеләүдә автор тулы хуҗа. Әйтик, "Жизнь Клима Самгина" дигән дүрт томлык роман эпопеясын М. Горький "повесть" дип атаган. Гоголь "Мертвые души" әсәренә поэма дип өстәгән, өлкән буын рус символистларының "атасы" В. Брюсов "О, закрой свои бледные ноги" дигән берьюллыгына бер дә оялмыйча "поэма" дип куйган, үткән гасыр башының бөек символисты А. Блок "Стихи о Прекрасной Даме" исемле шигырьләр бәйләмен "мәхәббәт романы" дип атаган. Димәк, Р. Харисның да әсәренә теләсә нинди исем биреп күзләрне камаштырырга тулы хакы бар.

Автор романының беренче юлларыннан ук максатын, әхлакый-фәлсәфи кредосын калкытып куя: "Герой эзлим! Герой эзлим күз бетереп, җир ертып!". Шунда ук бу олы бурычның ифрат авырлыгын, дөнья классикларының да шуның белән интеккәннәрен искә төшерә:

*Әйтерсең лә татарда мин*
*Байрон, Пушкин, Лермонтов!..*
*Әлбәттә, татарны эзлим,*
*Шуңа эзлим татардан—*
*таба алсам, яза алсам,*
*татарга да булыр дан.*

"Татарга дан" булырлык геройны эзләп табуы җиңел шөгыль түгел. Кибән зур, инә бәрәү генә. Чагыштыру, сикерү таягы югары кимәлдән куелган. Татар матбугаты инде ничәмә еллар дәвамында заманабыз өчен үрнәк-өлге герой эзли, мәгәр һәммәбезнең күңеленә хуш килердәй, эше, гамәле, әхлагы белән күңелебезгә сары май булып ятардай каһарманны таба алганы юк. Социалистик реализм тантанасы заманындагы һәръяктан

камил, үрнәк, эштә алдынгы, идеал гаилә башлыгы, тотнаклы коммунист герой, соңгы орлыгын колхоз амбарына илтеп бушатучы Нәфисәләр дә үзләренең тормышчанлыклары ягыннан шикләндерә башлады. Герой яшәешендә ялгышлар җибәрергә, үз хатынын яраткан хәлдә дә чибәркәйләргә дә борылып карарга, тормыш кирәк-ярагын кайгыртырга хаклы, ягъни ул шомартылмаган, балта белән генә юнган булырга мөмкин дип тә карадык. Юк шул, зәвык-караш, мөнәсәбәтләрне, әхлакый үлчәмнәрне көзен кырда калган иске саламны яндырган төсле генә юкка чыгарып булмый икән. "Казан утлары"нда 2004 ел дәвамында дәррәү кубып, барабаннар кагып, күнегелгән типаж геройны эзли башладык. Алар әдәбиятыбызда юк икән инде, аның урынын канатсыз акчарлаклар, күл балыклары, сихерче карчыклар, эштән куылган милиционерлар, мафиозниклар, алыпсатарлар, Алып батырлар, албастылар, Сәмруг кошлар алган... Ягъни әдәби дөньяны икенчел геройлар баскан. Әдәбият теориясенең әдәби процесстан артта калып баруын аңлагач, кәефебез кырылды, сүз сәнгатенең үзен заман героен тудыра белмәүдә гаепли башладык.

Чынлыкта әдәбиятыбыз үсә, баганага бәйләп куелган тышаулы ат кебек бер урында таптанмый, хәленнән килгәнчә, язучыларыбыз өлгереп җиткәнчә, рухи дөньяларны, җан күтәрелешләрен яктыртуны, тормышчан детальләр белән шартлы символларны кушып үсешен дәвам итә. Яңа гасыр башында татар поэзиясендә *(башка әдәбиятларда мондый феномен барын хәтерләмим)* жанр таләпләренә җавап бирердәй, бай эчтәлекле, катлаулы структуралы, камил телле шигъри роман пәйда булган икән, бу хәл үзе үк изге традицияләрнең яшәве, дәвам итүе турында сөйли.

"Исемсезләр"гә язган кыска гына, гамьле тәкъдир сүзендә профессор Ф. Галимуллин шигъри роман жанрының оеткыларын "Кыйсса-и Йосыф" белән "Хөсрәү вә Ширин" кебек узган гасырларда татарның күз яшен мул агызган колачлы әсәрләрдә үк таба. Бәлки алар янына Р. Харисны шул исемдәге мөстәкыйль поэма язуга рухландырган "Идегәй" дастанын өстәү мәгъкуль булыр. Поэма кысаларын үтеп, аралаш жанрга тартылып торган әсәрләр Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗин, Ш. Маннур, Н. Баян иҗатларына да хас. Поэма жанры таләпләрен-кануннарын тарсыну Р. Фәйзуллинның "Сәйдәш", З. Мансуровның "Ике егълау", Ә. Рәшитовның тарихи поэмаларында да сизелә.

Сугыштан соңгы татар поэзиясенең йөзек кашлары булып ике шигъри роман тора: Салих Батталның "Чирмешән ярларында"сы һәм Әнвәр Давыдовның "Йокысыз төннән соң"ы. XXI гасыр башында "без әле яшибез, үсәбез" дип өченче шигъри роман да үзе турында чаң сукты. Вакыйгалар агышы буенча "Исемсезләр" тәүге кардәшләренең дәвамы, ә инде үзгә сыйфатлары белән бөтенләй башка, яңа чор казанышы.

Беренче ике әсәрдә сүз XX гасырның уртасына чаклы булган хәлләр турында, яклаучысыз татар кешесенең башына төшкән бәлаләр, Октябрь борылышы, колхозлашу, сугыш һәм аннан соңгы авыр чорлар, дөньясы, тәрбия нигезләре белән җиргә береккән игенченең аякларын чуер ташларда каната-каната, терсәкләрен кара урманнарда тырната-тырната яшәү, нәсел калдыру өчен җан атуы турында барса, Р. Харис романы укучыны үткән гасырның икенче яртысына, бигрәк тә соңгы чирегенә алып кайта. Ирекле композиция, сыгылмалы структура авторга үзен тар кысалар белән чикләнмәскә, ерак тарих белән беррәттән бүгенге көнгә, мифологик катламнарга һәм заманча модернистик алымнарга мөрәҗәгать итәргә дә мөмкинлек бирә. Үзәктә кайта-кайта искә төшерелгән герой эзләү проблемасы ята. "Исемсезләр" дигән атаманы да, мөкиббән китеп, туры мәгънәдә генә кабул итәргә ярамый. Тарих шәхесләрсез, гасырлар теленә кереп калган затлар исемсез була алмый. Дөнья гомер-гомергә ике— вертикаль һәм горизонталь *(югары һәм туры)* юнәлешләрдә—үскән. Мәскәү кунакханәсе каршында инде мәхәббәт тә, нәфрәт тә уятмыйча, бары тик дәвамлылык идеясен искә төшереп, Карл Маркcның символик фигурасы басып тора. Явызлар галереясын Батый хан, Бородино янында борынына томау төшкән Наполеон Бонопарт, КПССның генсеклар образлары тулыландыра, шулар янына, алар өчен оялгандай, Икенче Бөтендөнья сугышы герое маршал Жуков килеп кушыла.

СССР дип аталган империянең хуҗалары-генсеклары турында сүз чыкканда ироник карашның өстенлек итүе табигый. Алар яшәү рәвешләре, хәтта үлемнәре белән дә халыкка борчу гына тудыралар.

*Үлеп китте олуг Генсек—*
*йолдыздай якты җисем.*
*Яр Чаллыга бүләк итеп,*
*Үзенчә "яр"лы исем.*

"Яхшы патша" турында хыялланып, шуңа табынып яшәгән мәҗүси халык Брежневны алыштырган генсекның каты куллы һәм гадел булуына өметләрен баглый. Әмма хыяллары буш куык булып чыга. Яшәп килгән системаны нигездән үзгәртми, ватып ташламый торып, әзерне "сипләү, ишекләргә яңа бикләр, Тоткалар" куеп кына тормышны яңартып булмаячак, ди шагыйрь. Тел бистәсе Горбачев йомшаклыгы нәтиҗәсендә ясалма ил ташка төшкән бәллүр савыт кебек кисәкләргә таркала. Мөстәкыйль дәүләтчелекнең ни икәнен дә белмәгән, читтә урнашкан халыклар тулы бәйсезлек алып куйдылар. СССР таркалудан "авыз эченә" урнашкан татар халкына гына әлләни файда булмады. Халкыбызның милли дәүләтен торгызуга юнәлтелгән хыяллары, өмет-ниятләре тормышка ашмады. Вакытлыча бушаган дилбегә янәдән соң нык тартыла башлады. Поэзиядә пессимизм, төшенкелек мотивлары, булмаганны эзләү, шәкли мавыгулар көчәйде. "...ил мәнфәгате Татарстанныкыннан өстен" дигән элеккеге уртак ватан, уртак байлык сәясәте янәдән алгы нәүбәткә чыкты. Татар нефте акча булып тоташ агып торганда да, ил хәерчелектән тернәкләнә алмады. Сугышларда "җиңелгән илләр" бездән күп тапкырлар алга киттеләр.

Автор Мәскәүнең торгынлык елларында азынуы, һәр нәрсәне үзенә суырып алып, төбәкләрне мескен хәлгә төшерүе хакында, ироник мөнәсәбәт аша *("Мәскәү рөхсәтеннән башка чебен дә очмый иде")*, төрле чорларны чагыштырып бик төгәл бәяли. Ул заман түрәләре чәкчәккә, утта янмый торган Васильево пыяласына да (чәйнек) риза иде, ә хәзерге түрә "яшелкәйне чәкчәктән артык күрә". Хәер, шагыйрь дөнья татарлары башкаласы Казанны да рәнҗетми, аның "уңай" якларына тиешле бәясен бирә.

*Казан евро-азиялек*
*Мәркәзенә әйләнде:*
*Европадан—яшеренлек,*
*Азиядән—хәйләлек.*

Казан тулы бәйсезлеген югалтып, Мәскәүгә буйсынганчы, бәлки, шулай булгандыр. Хәзер исә "их шулай булсачы, Казаныбыз ике континентны үзенә каратып торган шәһәргә әверелсәче", дип хыял дөньясында чайкалырга гына калды.

Мәскәү түрәләрен, бигрәк тә илне хәерчелектә ташлап киткән генсекларны "биеткәннән" соң, Р. Харис үзебезнең мохит дәрәҗәсенә төшәр, үз хуҗаларыбызны кызган табага ташлаган борчак хәленә төшерер дип көтәсең. Кызганыч, шагыйрь татар матбугатында кабул ителгән традицияләрдән читкә чыгып китә алмаган. Мәскәү хуҗаларының, бигрәк тә хакимияткә килеп киткәннәренең, язганыңны тәгаен укымасын белеп, тетмәләрен тетәбез, ә җирле түрәләребезгә (Аллам сакласын) тел-теш тидермибез, безнекеләр гел яхшы, изге, ләббәйкәгә генә өйрәтелгән. Бер урында гына автор үзе эшләп киткән парламентка: федераль законнарны тәңгәлләштереп кенә утырабыз, дип керпесен кабартып ала билгеле.

Батыйларны "уяткач", генсекларның тетмәсен теткәч, хакимияттән киткәннәрен булса да, үзебезнең түрәкәйләрне дә чеметкәләп алу объективрак булыр иде. Әйтик, элеккеге фирка җитәкчесе Г. Усмановның Гаяз Исхакый исемен һәм мирасын туган иленә кайтармаска тырышуын, Әфган сугышы "батыры" Ф. Табеевның "Татария" исеме безгә бик җиткән, суверенитетның кирәге юк дигәнрәк фикерен, латиница тирәсендә барган ыгы-зыгыны бәхәс үзәгенә кертеп җибәрү соралып тора кебек. Проблемалы роман татарның бик күп моң-зарын күтәрер иде. Республиканың элекке түрәләреннән Рәис Беляев кына мактап телгә алына. Роман "Исемсезләр" дип аталса да, әсәрне бизәүче бик күп мөхтәрәм фамилияләр телгә алына. Сөн егете композитор Фәрит Яруллин янәшәсендә урын алган артисткалар Зилә Сөнгатуллина, Рузилә Мотыйгуллина, Алсу Гайнуллиналар белән беррәттән, ЦДЛ рестораныңа бәйле рәвештә, русның хәзерге күренекле шагыйрьләре Белла Ахмадуллина, Николай Старшинов, Вадим Кузнецов исемнәре рифмалаштырыла (татар шагыйрьләрен телгә алмый дип үпкәләштән түгел: Зөлфәт белән МөдәррИснең үзләре белән кабакта утырырлык акча алып килмәгән вакытлары булгандыр!).

Тарихи шәхесләр "исемсезләр" белән бәйләнештә корылган сюжет бoҗрасына килеп керәләр, һәркайсы үз вазыйфасын үтәп, әйләнештән чыгып та китә. Исемсезләр галереясы бик бай: мин, үзем, хатын, абзый, кода, нефтьче, тәэминатчы, дуслар, 1- җиңги, 2 - җиңги, официант, егет, кыз, шагыйрь, тостчы һ. б. Вакыйгалар Мәскәүдә, Ташкентта, Әлмәттә, Казан белән Оренбург шәһәрләрендә бара.

Шул рәвешле роман үз эченә бик олы төшенчәләрне, XX гасыр ахырын, яңа гасыр башын тетрәткән вакыйга-хәлләрне иңли, шагыйрь үзен тар урын-җирлек белән

чикләми. Хәзерге чор, җанлы вакыт тарихның мәңгелек ритмнары белән кушылып китә.

Р. Харис шома кешеләр, шома идеяләр, шома образлар эзләми, киресенчә, ул тормыш катлаулыгын сизеп, матди байлыкка ирешеп тә рәхәт дөньяга чыга алмаган, ике хатын арасында буталып, бәхетен тапмаган шәхесләр язмышы турында уйланырга чакыра. Димәк, ул уңай бетемле, арзанлы, мавыктыргыч сюжет сызыгы белән бизәми, тормыш дөреслегенә хилафлык итеп, ярашу юлына басмый.

Төп герой булуга дәгъва иткән абзыйның үз хәсрәте үзенә җиткән. Заманында Ширин Фәрһадны сөйгәннән дә ныграк яраткан хатыны, аралары бозылгач, ире турында Үзәк Комитетка "алдакчы, милләтче, мазохист" дип, хатлар юллап, сөеклесенең партбилетын алдырткан. Абзыйның бар хыялы янәдән фиркале булу: шул ниятен тормышка ашыру өчен ул үзен дә, акчасын да җәлләми. Шул арада малае үсеп җитә, улын Казанга кайтарып, шунда белем бирәсе килә. Бүгенге катлаулы рухи яшәешебездә яңа гасырга аяк баскан буын милли азатлык өчен көрәштә таяныч була алырмы? Үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәмәсме? Төскә-биткә чибәр егет нәкъ замана баласы икән:

*Урысчасы—урыс кебек,*
*Үзбәкчәсе—чамалы.*
*Татарчасы—өч-дүрт сүзгә*
*бер урысча—җамаулы.*
*Татар министры кебек,*
*йә бер район башлыгы.*

Студент исә, атасы шикелле үк, шәхси омтылышларында өлгер булып чыга, мәгъшукасы балага узгач, килен сорап, Әлмәт якларына барып чыгалар. Ягъни автор кода булып, кыз сорарга бара. Яшьләр бер-берсен ярата, һавада шатлык хисе. Туфанның башлангыч чор поэтикасы үрнәгендә ясалган образ тудырып *("Болыттан котлет кыздырган факеллар")*, автор булачак кодалар йортына уза. Бу фани дөньяда "кайгы-шатлык, уен-уймак һәрвакыт янәшә" йөри икән шул. Кызны сорау турында сүз башлаганчы ук, хуҗаларның йөзендә "шатлык чаткысын баскан караңгылык" күреп алалар: кызның туган абыйсын кизү офицер цинк табутта Әфганнан Әлмәткә җирләргә алып кайткан икән! Бу олы һәм авыр тема үзеннән-үзе роман битләренә килеп керә. Ә без кемне яклап газиз балаларыбызны "пушка итләре" булырга җибәрәбез? Ерак пушту халкы таулары арасында безгә нәрсә калган? Автор "Әфганда нинди Ватан?" дигән риторик сорау элеп куя. Ул гына да түгел. Килеп чыга "аннары арабызда Корея һәм Вьетнам ветераннары". Шул хәбәрләр җитди аналитик нәтиҗәгә алып килә. "Рәсәй сугышсыз тормый." Әлеге җөмләдән соң бер дә юкка һәлак булган корбаннарны кызганып элеккеге атеист *(бәлки, тыштан гына шулай күренгәндер)* Алланы искә төшерә, Аңа сыена.

*Үзләрен дә шундый язмыш...*
*Юк, юк, Ходай сакласын.*
*Һәр солдатның тере килеш*
*Килә өйгә кайтасы.*

Үзләре ни өчен икәнен белмәгән, ялган идеяне якларга мәҗбүр ителгән егетләргә җан яктылыгы сибеп, аларны юкка чыгарган сугышларны каһәрли әсәр.

XX гасырның иң олы, тетрәткеч проблемалары уртасыннан атлаган шагыйрьнең, шулай ук кан саркып торган Чечня проблемасына килеп чыгуын, үз позициясен, мөнәсәбәтен белдерүен көтәсең! Кавказда барган вакыйгалар, азатлык өчен көрәшне бастыруларның кайтавазы, киленем сиңа әйтәм, кызым син тыңла дигәндәй, барлык милли регионнарга да кагыла. Ул безгә дә кисәтү түгелме?

Шул рәвешле роман үз эченә чорыбызның олы төшенчәләрен, илне, хәтта дөньяны тетрәткән вакыйга-хәлләрне иңли. Бу күчешләр табигый килеп чыга. Бер караганда кечкенә генә күренгән деталь ерак тарихка алып керә. Антик дөнья әдәбиятында ук "күчеп йөри" торган сюжетларның берсе—бала табу, аны югалту, тану, шуның нәтиҗәсе—ата-ана, туганнар арасында катлаулы мөнәсәбәтләр. Бу алым хәзерге әдәбиятта да яши. Р. Харис романына бу момент "әгәр ана сайлау бала ихтыярында булса, ул үзенә кемне сайлар иде икән?" дигән сорау-мотив булып килеп керә. Әлбәттә, баланың анасы итеп тарихи шәхесне күрәсе килүе табигый. Бәлки, иң газиз кешесе итеп җибеп калган ирләрне азатлык өчен көрәшкә күтәргән француз кызы Жанна д' Аркны яисә Рәсәйне мәгълүм тәртипкә салган, Казанда беренче таш мәчет корырга

рөхсәт иткән Әби патшаны (Екатерина II) сайларга? Әле бит үзебезнең легендалар күрке, гүзәл патшабикәбез Сөембикә бар! Кайсын сайларга? Соңгы хәбәрләргә караганда, Жанна д' Арк гади крестьян баласы булмыйча, бер вельможа кызы булган, янгынга да башка хатын эләккән икән дигән фикер яши. Сөембикә үзебезгә якынрак, газизрәк. Аның хакында да төрле версияләр туа тора. Бер яшь галим авызыннан автор, "нидер уйлап, уйны буйлап", шактый шөбһәле, "көфер", йөрәкне тырнап үтәрдәй сүзләр әйттерә. "Әйтик, Казанны Мәскәүгә биргән шул Сөембикә. Сөембикә ул гомумән татар булмаган икән".

*Шаһгалигә хатын булган...*
*Һәм ире белән бергә,*
*Грозныйларга кушылып*
*Казанга ул да кергән.*

Бу имеш-мимешне китерә дә, шагыйрь: ханым "ил өчен булган корбан, ил өчен!"—дип чәйнектәй кайный. Сөембикәне каралтырга тырышу белән килешмәсә дә, автор мәңгелек хакыйкатьләрнең булмавын, замананың бәһаләрне үзгәртә, яңарта килүен, дилбегәнең яңа буынга күчүен искәртә. Һәм шунда ук барыбызны да борчыган, йокысыз төннәргә салган сорауны калкытып куя:

*Кая таба китәр икән*
*Татар төялгән олау?*

Әлбәттә, алдынгы халыклар ирешкән, демократик, "матур, җайлы тормыш" ярларына килеп чыга алсак, бик шәп булыр иде. Әмма бу әлегә хыял гына. Тарихи үсешкә аек караш җиңә. Җентекле, тәфсилле сөйләмне бер төгәл метафора алыштыра; "без авыз эчендә яшибез! Шуны онытма, татар!" Күпме генә сикеренсә дә тел авыз эченнән чыгып китә алмый. Нәтиҗә үзе соралып тора: "Татар бик еш оныта шул күп эшләрдә чаманы".

Романда герой эзләү бара, аның умыртка баганасын татарның авыр тарихы, бүгенгесе, томан эчендәге киләчәге, менталитеты, гореф-гадәтләре, телен саклау проблемалары тәшкил итә. Герой, бәлки, Әлмәт якларында табылыр. Шул арада өйләнергә тиешле малайның чын анасы, чибәр, әмма бер куллы икенче җиңги сурәткә килеп керә. Дөньялар куба, үзара аңлашулар, рәнҗешүләр, көрәшүләр, антик әдәбияттагы кебек "танулар" ыгы-зыгысы башлана. Сүзгә һәрвакытта уңышлы килеп кысылган, арка терәге биреп торган үз хатыны ярдәмендә автор вакыйга агымына тиешле юнәлеш бирә. Тормыш без теләгәнчә генә бармый шул. Инде зур көчләр түгеп, ярты Мәскәүне сыйлап партбилетын кайтарган, баласының чын анасы, яраткан хатыны белән кушылган абзый инфаркттан үлеп китә. Роман дәвамында "герой эзлим", "героем шул булырга тиеш", дип хафаланган иҗатчы, шигъри әсәр мөмкинлек биргәнчә төрле образларга керә: бер очракта җитди бәяләүче булса, икенче урында ироник күзәтүче ул. Чөнки автор замана ритмы белән яши. Дөнья зур. Серле. Каршылыклы һәм катлаулы. Аны аңлау һәм аңлату җиңел түгел. Шуңар да тормыш "сюжеты" әдәби роман "сюжеты" белән тәңгәл килмәскә дә мөмкин. Әдәби герой булырга тиешле кеше партвзнос түләгәндә кысылып кала: чөнки "намусы белән кесәсе килә пычакка пычак".

Әсәрнең буеннан-буена татарның гасырларны иңләгән тарихы, татарлыгы килсә *("беләсезме—мин бит татар")*, икенче яктан, бөтен вак-төяге, шатлыгы-хәсрәте, сөенече-кайгысы белән без яши торган, реаль чынбарлык. Яшәү мәгънәсенең серен эзләүдә, аңлату-шәрехләүдә беркадәр гадиләштерү дә бар сыман. Һәрхәлдә, "югары коммунистик әхлак" тәрбиясе узган кешеләр өчен чынлыкта шулай булса да, фикерне болай кистереп әйтү сәеррәк тоела.

*Инандым: кеше дөньяга*
*Килә ич яшәр өчен,*
*Тик шуны тәэмин итәм дип*
*Хезмәткә сала көчен.*

Бәлки, югары материяләр турында сөйләшеп, бер-беребезне алдап, шомартып яшәүдән туктап, асылыбызга кайтып, ашау өчен яшибез дигән прагматик дулкынга төшәргә, алга киткән илләрдәге кебек, көндәлек тормыш ихтыяҗларын хәл иткәч кенә безгә дә якты киләчәк турында кайгыртуларга күчәргә кирәктер? Әллә "якты киләчәк" дигәннәре шул көндәлек тук, тыныч, рәхәт, итагатьле тормышмы икән?

Яңа әсәрендә дә Р. Харис психологик анализ остасы булып кала, шул юнәлештәге эзләнүләрен, фәлсәфи җирлеккә күчереп, тапталмаган юллар эзли. Хәсрәтнең олылыгын, кешенең аптырау катыш югалып калуын шул ук абзый образында күрсәтергә

ихтыяж булганда, автор күпертү, градация алымына мөрәҗәгать итә. Хыянәтне күтәрә алмаган ата сагышын ул түбәндәге юлларга тапшыра:

*Абзый елый арка белән,*
*Җилкә белән, бил белән.*
*Елый бөтен гәүдә белән.*
*Җиргә күккә карамый.*

Ирләр затына караган гомуми күзәтү: "Елаган чакта ирләрне юатырга ярамый". Чөнки "Ирләр сирәк елый, алар бушанганда вакыт туктый", чын ир "бөтен Җир шарын, күк гөмбәзен кочаклап елый".

Кешенең фәлсәфи-әхлакый кичерешләрен, рухи дөньясын ачуда Р. Харис матди дөньядан, иң гади күренгән төшенчәләрдән, чакма чагып, көтелмәгән натуралистик җанлы сын тудыра: "Савылмаган җилен кебек наз куерган күңелгә", "конфет урынына Брежнев дигән исемне чәйнәп".

Элекке елларда язылган "Хисемнең исеме", "Өч үбешү" кебек әсәрләрендә шагыйрь мәхәббәт, хатын-кыз, гаилә мәсьәләләрендә җанын, ихтыярын, "белемен" ачып бетергәндәй тоелган иде. Юк икән. Р. Харис яңа әсәрендә дә кабатланмыйча: "Есенин ук булмаса да, күрсәтер әле абзаң..." дип кәперәеп тә ала, порнография кимәленә төшмичә, сөю-сәгадәт хисләренә чәчәк бәйләмнәре өсти.

*бала Ир итә ирне,*
*хатын-кызны Ана итә—*
*ача бөек асылын.*

Бу фикеренә алдагы юлларда ул тагын ачыклык кертә:

*Әни дигән түбә сүз һәм*
*Әти дигән нигез сүз!*

Туган телнең язмышы, халыкның киләчәгендә тоткан урыны турында автор саллы мәгънәви тирәнлек, Дәрдмәндләрдән килгән коеп куйган төгәллек белән уйлана. Халыкның үткәнен, киләчәген аның теле аша гына аңлап була. Чөнки тел ул—Ана, язмыш, идея, азатлык өчен көрәш байрагы, чын кеше булуның югары күрсәткече.

Мәхәббәт—бәяләп бетергесез изге, көтеп алынган, кешене бизәүче, күтәрүче гүзәл хис. Ул табигатькә тиң нәзакәтле серле көч. Бу илаһи серне аңлаган, бөтен нечкәлекләренә төшенгән кеше әлегә юк. Иң соңгы дәреслеккә дәгъва итмичә, Р. Харис болай ди: "Мәхәббәт—ул кешедәге Кешелеклелек билгесе". Ә кешенең кешелеклелеген ничек һәм ни рәвешле танып була икән соң? "Сөюенә генә кара Җаны күренеп тора".

Көтмәгәндә-уйламаганда, аяз көнне ялтырап алган яшен кебек җанын, бөтен барлыгын биләп алган мәхәббәт хисе алдында югалып калган ир заты болай бәяләнә:

*Еланнарга карышучы*
*Куян күк басып тора.*

Яңа туган тойгыдан аның качасы, яшеренәсе килә, әмма инде ул көчсез, ихтыярсыз, башка сыеныр урын да таба алмый. Ә хатын-кыз (елан) куянның-ирнең югалып калуыннан ләззәт ала:

*Нинди бәхет—сөйгәнеңне*
*бәхетеннән елату.*

Р. Харис акмеистлар яратып кулланган прозаик, хәтта натуралистик тәфсилләү алымыннан да баш тартмый. Тормыш агышына ифрат якынлык, шуны турыдан-туры кабатлау иллюзиясе туа һ. б. Бу хыял—алдаучан, куркыныч. Ул шартлауга әзерли:

*Тукталдык кунакханәгә,*
*юындык, ыспайландык,*
*буфетка төшеп тиз генә*
*тамак та ялгап алдык,*
*һәм сузылган гына идек,*
*ял биреп умырткага,*
*кемдер уч йомшагы белән*
*безнең ишекне кага.*

Булачак килен абыйсының Әфганнан үле гәүдәсе кайтуын хәбәр итәргә килгән икән.

*Тораташтай катып калдык...*
*Телне өянәк тотты,*
*Бәхет тудырырга килдек,*
*Ә безне кайгы йотты.*

Контрастлылык алымы Р. Харис поэзиясенә хас ысулларның берсе.

Авыр язмышлар, кара кайгылы көннәр... Әмма алар вакыт агышын туктата алмыйлар. Андый көч дөньялыкта юк.

*Шулай көннәр туа торды,*
*кояш ашап тукланып.*
*Көннәр исә атналарга*
*гаҗәеп тиз тупланды.*

Дөньяга фәлсәфи караш, фәлсәфи фикерләү Кеше—вакыт—Табигать образлары белән бәйле. Вакыт та, табигать тә әдәби әсәрдә үзмаксат булып яшәмиләр, ә кешенең уй-кичереш дөньясын, рухи һәм гамәли эшчәнлеген аңлауга ачкыч ролен, хәтта кичереш үсеше функциясен үтиләр. "Исемсезләр"дә кешенең эзләнүе, шагыйрьнең замана героен табу турындагы хыяллары табигатьнең төрле фасылларында ачыла. Биредә дә табигать сурәте метафорик күзаллау аша тасвирлана. Көзге табигать матурлыгын, ямен, сурәтләү юк, нибары бер метафора:

*Алма исеннән исереп*
*йөрегән вакыт иде.*

Менә авыр җил-давыллары, көрт-бураннары белән кыш килеп җитә:

*Бездә буран бурый иде,*
*авыр февраль бураны.*

Буран юкка гына котырынмый икән, илдә өмет катыш кайгы, сагыш аша ироник хәсрәт хуҗа. "Тагын Генсек үлеп китте". Яңа түрә килгәч тә әле кыш үзенекен итә. Көчле ихтыярны да санга сукмый, үз законнарын сөрә:

*Ак ялыннан көртләр сибеп,*
*арып бетте ак юрга—*
*тәмам күмелә яздылар*
*төлке уйнаган урлар.*

Фламанд рәссамчыларына лаеклы кышкы этюдтан соң сурәткә "Март аеның дәртле тыны" килеп керә. Ә җәй башын шагыйрь ничек күңелдә калдырыр икән? Аңа бу очракта рәссамлыгы ярдәмгә килә:

*Җәйнең балалар рәсеме*
*кебек беркатлы чагы иде.*

Табигатьне сурәтләү юнәлешендә кайбер нәтиҗәләр ясыйк. Табигать аның өчен—яшәү чыганагы. Шул ук вакытта табигать диалектикасы шәхесләрнең холкын, рухи дөньясын ачуга буйсындырыла.

"Исемсезләр" романында автор "кемне татар язучысы дип атап була?" дигән бәхәсле һәм ифрат четерекле проблемага да кагыла. Бер яктан ул, киң күңеллелек күрсәтеп, Диас Вәлиевтан башка рус телендә язучы барлык әдипләрне татар җанлы, милләткә хезмәт итүче затлар рәтенә тезә. Ташкентта яшәп, русча язып, татар булганы, хакыйкатьне алга чыгарып салганы өчен кимсетелгән сүз остасыннан: "Беләсезме—мин бит татар", дигән сакраменталь сүзләр әйттерә. Шул ук вакытта автор татар язучысы дип саналу өчен катгый таләпләрне дә калкытып куя:

*Ә бит шагыйрь булып була,*
*ин-иң-иң ким дигәндә,*
*Телең—Ана, үзең—Бала*
*булып сөтен имгәндә!*

"Тел ул—җан кыйбласында!" диюе белән Р. Харис хаклы; чит-ят төбәкләрдә туып, татарлыгын яшермәгән милләтебез вәкилләрен, иҗатында татар психологиясен, җанын ача алган шәхесләрне читкә тибәрү дөрес булмас. Әйе, Зөфәр Фәтхетдинов, Рауль Мир-Хәйдәров кебек Казанга тартылып торган каләм ияләренең рухын күтәрү безнең бурыч, тарлык күрсәтү безне бизәмәс. Шул ук вакытта Татарстанда туып, шунда югары белем алып, Ренат Суфиевтан (нинди гүзәл фамилия) бөтенләй читкә, Себергә (башкалага булса бер хәл) китеп, Роман Солнцевка әйләнгән шәхесләрнең әсәрләрен бастырырга кирәк булганда гына Казанны искә төшереп килеп чыгуларыннан мөкиббән китеп, ниһаять, "ул килде", дип сөенешеп утырмыйк әле. Татар әдәбияты иншалла бик бай, киң колачлы һәм андый "спонсорлык" ярдәменә һич мохтаҗ түгел. Һәрхәлдә бу мәсьәләдә кыйблабыз анык булырга тиеш.

Чын татар язучысы бабаларының киндек каны тамган туфракның (кайсы төбәктә яшәсә дә) җылысын тоеп, шатлыкта да, кайгыда да үз милләтенең мәнфәгатьләре белән яшәргә тиеш. Бу әле безнең әдәбият дөнья мәдәнияте казанышларына битараф булырга, кытай стенасы артына кереп яшеренергә тиеш дигән сүз түгел. Милли рухлы, сизгер

йөрәкле әдип киң эрудицияле, белемле, сәяси дөньяга сизгер булганда гына гавам артыннан ияреп бармый, ә үзе аның үсешенә, азатлык өчен көрәшенә юнәлеш биреп бара, коллык психологиясеннән арындыру юлларын күрә, сизә, иҗатында чагылдыра белә. Миргазиян Юныс мисалы—безгә чын милләтпәрвәрлек үрнәге. Аның иҗатын русча башлап, шул телдә шактый уңышлы үрнәкләр биреп, аннары туган телен үзләштереп, үз телендә язып дәрәҗәгә ирешүе ни тора! Әнә, Василь Быков русча язса да, каһарманнары һәрдаим Белорус партизаннары булды, халкы азатлык даулаганда көрәшчеләрнең беренче сафында торды. Олжас Сөләйманов та рус теле аша бөтен төрки халыкларының мәнфәгатен яклый, Чыңгыз Айтматов иң гүзәл әсәрләрендә "кыргызлыгыннан" баш тартмый, Җәмиләләрне күтәрә. Әмма аның соңгы еллардагы Понтий Пилатлары, яңа дин эзләүләре бирәүгә дә—кыргызга да, урыс белән яһүдкә дә—кирәк түгел. Ул хәзер планетар язучы булу уе белән саташып йөреп, әмма үз йөзен югалта баруы күз алдында.

"Исемсезләр" сәхнәдән уку, трибунадан яңгырату максаты белән иҗат ителгән әсәр түгел. Ул—үзең генә калып, авторга ышанучанлык илә, фикереңне туплап, уйланып утыруга исәп тотып язылган кыйсса. Бер караганда гадәти күренгән хәл-вакыйгаларны икенче ягы белән сикертеп кую, көтелмәгән кискенлек, фәлсәфи мәгънә чыгара белү Р. Харис фикерләвенең бәхетле хасияте. Халыкта "Чирен яшергән үлә" дигән әйтем яши. Авторның бу мәсьәләгә үзгәрәк карашы бар: "Чирен белмәгән—яши. Һәм яши ул янындагы өмет белән берләшеп". Биредә медицинаның гомуми торышына киная дә, кешенең бары тик үзенә генә таянырга тиешлегенә төрттерү дә бар. Шагыйрьнең үзенә генә хас хикмәтле әйтемнәре, җор җөмләләре, билгеле мәкальне Шомбай бүреге кебек кире якка әйләндереп куюы да шигъри эффект бирә.

Романның сурәтләү чараларына гаҗәеп байлыгы һәм яңача иканлегә бәхәс уятмас кебек. Ләкин әле бу аның һәр сынландыруы хуплап кабул ителә дигән сүз түгел.

Җөмләдән, "ул—күләгә кебек назлы" гыйбарәсе бәхәс уятырга мөмкин. С. Есенинның "Черный человек" поэмасында күләгә куркыныч шәүлә рәвешен алып, назлылыктан ерак тора. Еш кына күләгә куркыта, шомлы хисләр уята. "Нур" образы романда еш очрый торган ачкыч сүзләрнең берсе. Кеше җаны нурдан яратылган, фани дөньяны ташлап киткәндә дә йөзендә якты нур уйнап торды, диләр яхшы кеше хакында. "Нур" шигъри романда еш кына караңгы төс ала.

*Ләкин аның күзләрендә*
*Караңгы нур чагылды.*
*Ул нур безгә дә кагылды,*
*басты шатлык чаткысын.*

Икенче урында "нур" куркак төскә керә. "Күзләрендә куркак нурлар бер эри, бер бозыла". Димәк, аның күзендә нур уянмаган, кайгы-хәсрәт аны кабыза алмаган, хиснең башкарак төсмер-нюансын табу кирәк булгандыр. Ягъни, Р. Харис каләменнән роман битләренә төшкән барча образ-сурәтне дә камил дип булмый. Исемсез шагыйрь белән бәхәскә керүе дә югары эстетик зәвыклы, элитар поэзиянең күренекле вәкиле булган Ренатны бизәми дип саныйм:

*Аяклы әбрәкәй сыман*
*"хуш исле" шагыйребез*
*бу темага бер гәзиттә*
*әйткән шактый эре сүз:*
*"Татарда урысча уйлап,*
*татар сүзләре белән*
*шигырь язулар күбәйде"*

Шәхси үпкәң булганда, бәхәскә керәсең килгәндә, исемне әйтеп сөйләшү зарур. Курыксаң, сүз куертма, димәк, ул синең тәнкыйтеңә лаек түгел. Шулай ук шагыйрь романның буеннан-буена имзасыз хат язучылар белән көрәшә.

*Анонимка язучының*
*Бармагы корый торсын...*
*Без, сәмруг кошка утырып*
*Ташкентны урап кайтыйк.*

Шагыйрь әләккә, яла ягуга каршы күтәрелеп, дөреслекне яклый, аның ахыр җиңеп чыгачагына ышана.

*Җирдәге иң авыр гөрзи,*
*Үзем беләм, әләктер!*

"Исемсезләр" романында эзмә-эз, бер калыпка салынган сюжет хәрәкәтеннән бигрәк, фикер энергиясе үзенә җәлеп итә. Нәкъ менә шул юнәлеш яшәеш кыйтгасының әхлак, язмыш, әдәбият, сәнгать, хәтта шигырь төзелеше мәсьәләләрен күтәрергә, һәр кайсына шәхси мөнәсәбәтен калкытып куярга мөмкинлек бирә. Реальлекне—фантастика, юморны символика алыштырганда да шагыйрь кеше аңының аргы "мәркәзләренә" чыгып китми, чама хисен югалтмый. Җанлы вакыт тарихның мәңгелек ритмнары белән кушылып китә, кеше нинди генә хәлләрдә дә җирдән аерылмаска кирәклекне аңлый. Бу халәтне шагыйрь афористик төгәллек белән әйтеп бирә:

*Җир тамыры, эчкә үтеп,*
*Йөрәкне учлап тоткан.*
*Әти, әни кабередер*
*Җир тамыры дигәнем.*

Үз уй-фикерен ул "абзый" авызыннан әйттерә:

*Рифмасыз шигырьләрне мин*
*шигырь дип танымыйм.*
*Ритм прозада да бар ул!*
*Рифма—шигырь кануны.*

Төгәл, катнаш, сузык аваз белән тартыклар ярашуына корылган ачык, нәзакәтле рифмалар тарафдары (андый үрнәкләр романда тулып ята) Р. Харис колакны иркәли торган рифмага мәдхия яудыра.

*Рифмага ияреп, фикер,*
*челтәрләр үрә-үрә,*
*ир куйнына кергән кыздай,*
*хис кочагына керә.*

Автор рифманы юлларны, строфаларны бәйләүче шәкли алым, яңгыраш, аһәң күрке дип кенә бәяләми, ә аны кичереш, хис киеренкелеген тәэмин итүче, фикер җебен тартып баручы чара буларак бәяли. Бу—татар поэзиясе классиклары карашына тәңгәл.

Роман тәмамлана, ә герой һаман юк та юк. Кемне генә атаса да, кайсын гына искә алса да, берсе дә әдәбият теориясе аңлаткан каһарман таләпләренә җавап бирми, шагыйрьнең күңеленә хуш килми, "китек" җире күренеп тора. Персонажлары кояшның тылсымлы нурларында коенып, үзләренең эреле-ваклы мәшәкатьләре белән яши бирәләр. Геройлыкка дәгъва иткән, ярты гомерен беркемгә кирәкмәгән партбилет артыннан йөгереп уздырган абзыйсы да йөрәк авыруыннан кинәт үлеп китә. Автор романын: "һәр кешенең язмышын берсе белән берсен бәйләү" мәҗбүриме икән, чөнки язмышлар, вакыйгалар әзер калыпка сыеп бетмичә, үзләренчә яшиләр, киләчәкләрен сайлыйлар, тормыш "ул—иректә хәрәкәт", дигән фикер белән төгәлли. Гыйбрәтне яисә үрнәкне герой исеменә дәгъва итмәгән исемсезләр арасыннан табып була, ди автор.

Шигъри романда ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, ахыр чиктә герой ролен бик күп вазгыятьләрне үзенә җыйган, XX гасырның иң кайнар әдәби һәм сәяси вакыйгалары эчендә кайнаган автор үзе үти. Эреле-ваклы хәлләрнең шаһиты буларак ул күп функциональлеккә ия. Алдарак әйтелгәнчә, герой эзләүче—автор, хикәяләүче—вакыйгаларга юнәлеш биреп, алып баручы, вакыт бизмәнен уч төбендә тотучы, Сәмруг кош кебек мифик затлар белән аралашучы, әдәби хәрәкәткә бәя бирүче, тарих битләренең кабул ителгән кануннарына тәнкыйть белән карый алучы, аналитик фикерле, киң карашлы шәхес булып калка. Төрле юнәлешләрдәге эзләнүләрдән баш тартмыйча, шул ук вакытта реализмга өстенлек биргән шигъри роман кинәт ялтырап алган ачык метафораларга да бай, биредә тыгыз фикер югары накалны тәэмин итә. Киң тематикалы, катлаулы структуралы "Исемсезләр" бер тын белән һәм вакыт—ара яссылыкларын оныттырып укыла торган әсәр. Ул—яңа, XXI гасыр поэзиясе казанышы.

Sәngәt
Сәнгать

# ҖЫР–МОҢ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН ГОМЕР

"Исемеңне эшең данласын",—ди безнең халык. Эш дигәнең иҗади хезмәт булса, бу бигрәк тә шулай. Күренекле татар композиторы Алмаз Закир улы Монасыйповка әлеге сүзләр бик тә туры килә. Аның сиксән еллык тормыш юлы җыр-моң белән үрелгән. Ул иҗат иткән музыкаль әсәрләр шул хакта сөйли. Татар музыкасын аның әсәрләреннән башка күз алдына китерүе дә кыен. Алмаз Монасыйпов—танылган композитор-симфонист, бик күп җырлар һәм романслар, инструменталь көйләр авторы. Ул—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Республикабызның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, чын мәгънәсендә мәдәният кешесе.

Алмаз Закир улы Монасыйпов Казан шәһәрендә туып-үскән. Биредә аның яшьлеге үткән, иҗат иткән әсәрләренең күбесе беренче тапкыр биредә яңгыраган, ул монда беренче уңышларын татыган, лаеклы танылу алган.



Композиторның нәсел-нәсәбе Казандагы атаклы зыялылар—бертуган Шәрәфләргә барып тоташа. Бертуган Гыйльми һәм Борһан Шәрәфләр XX йөз башында ук хөрмәтле наширләр булып танылганнар. 1906 елда алар нигезләгән "Матбагаи Шәрәф" типографиясендә ике миллион данәгә якын китап—татар язучыларының әсәрләре, рус һәм чит ил классикасы тәрҗемәләре, дәреслекләр, календарьлар, халык иҗаты җәүһәрләре нәшер ителгән.

Язмыш Шәрәфләр гаиләсен аямаган: бертуган биш ир-ат һәммәсе дә утызынчы елларда шәхес культы корбаны булганнар. Аларның кыз туганы Фатыйма Шәрәф – Алмаз Монасыйповның әнисе. Әтисе Закир Монасыйпов типографиядә эшли. Ул җырга-моңга һәвәс, скрипкада сыздыра, күпмедер вакыт Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының оркестрында уйный. Оркестр белән аның якын дусты Салих Сәйдәшев җитәкчелек иткән заман бу. Закир Монасыйпов та Сталин лагерьларында ун ел буе газап чигә. Аны кулга алганда, улы Алмазга нибары тугыз яшь кенә була, ә котылып кайтканда, Алмаз инде фронтта...

Кечкенәдән җыр-моң дөньясында үскән Алмаз Монасыйпов, 1945 елда фронттан кайткач, әле яңа гына ачылган Казан консерваториясенә, профессор Браунның виолончель классына укырга керә. Консерваторияне тәмамлагач та шактый озак үзендәге иҗади сәләтне сиземләп кенә йөри. Ниһаять, булдыра алырына ышанып, ул янадан студент билеты ала—композиторлык факультетының Альберт Леман классында укый башлый. Шунда ул беренче әсәрләрен иҗат итә. Әхмәт Ерикәй шигырьләренә ике романс яза, инструменталь пьеса, скрипка өчен соната, балет сюитасы кебек әсәрләре дә озак көттерми.

Алмаз Монасыйповның иҗаты татар музыка сәнгатенә ургылып килеп керә, аның үзенә генә хас моң-аһәңнәре беркемне дә битараф калдырмый. Шул чордагы тормышның гаделсезлеге, рухи ирексезлек мотивлары көтелмәгәнчә кыю яңгыраш ала. "Халык-халык" дип авыз суы кортып йөрүчеләргә караганда, аерым шәхесләрнең язмышына игътибарлы булу, үз тормышын әсәрләрендә чагылдыру Алмаз Монасыйпов иҗатына җәмәгатьчелекнең игътибарын көчәйтә, кемнәрдер аны аңлап бетерми, ул еш кына тәнкыйть утына да эләгә. Кешеләрнең каршылыклар белән тулы эчке дөньясы ул заманда хөкем сөргән ясалма дәртлелек-күтәренкелек белән яраша алмый. Композиторның фронтларда күргәннәре, озак еллар консерваториядә укуы, шул рәвешле тормыш тәҗрибәсе туплавы заманның катлаулы мәсьәләләрен чишәргә ярдәм итә.

Алмаз Монасыйпов—композитор-симфонист, дидек. Бу музыкаль форманы хәрәкәтләргә бай образлы, үзенчәлекле характерлы драма әсәрләре белән чагыштырырга буладыр. Симфонияләр гадәттә, исемсез килеш, "беренче, икенче" дип кенә аталып йөртеләләр. Әмма аларда кешенен төрле хәл-халәте, эчке көрәше ачык сурәтләнә. Алмаз Монасыйповнын дүрт зур симфониясе, "Идел-йорт" дигән симфоник поэмасы, симфоник оркестр өчен язылган "Салих Сәйдәшевка музыкаль мәдхия" дигән әсәрләре бар.

Алтмышынчы-житмешенче елларда татар музыка сәнгатендә симфоник әсәрләр аз язылмады, әмма алар күбесенчә жыр-бию көйләренә нигезләнгән, халык авыз ижатына таянган тормыш-көнкүрешне чагылдыра иделәр. Алмаз Монасыйповның симфоник әсәрләре исә хиссияте һәм бирелеше, янгырашы белән ниндидер шартлауга тин вакыйга булды. Ул, гадәтләнелгән кануннарны жимереп, милли симфонизмнын үсешенә яна юллар ачты. Гадәти пентатоникадан—биш тавышлылыктан аермалы буларак, егерменче йөзнең катлаулы композиторлык ысуллары белән баетылган әсәрләрдә һәрвакыт Монасыйповнын үзенә генә хас сыйфатлар ачык сизелеп тора иде. Алмаз Монасыйповнын симфонияләргә караган ижатын икеләнмичә ике бөек композитор—Дмитрий Шостакович белән Густав Малер ижатларына тинләргә буладыр. Алар шикелле үк, Алмаз Монасыйпов та кискен драматик хәлләр, образларның бәрелеше белән мавыга, ул—үткен сатирик юнәлеш тарафдары. Анын симфонияләрендәге образлылык һәр нәрсәне себерепә түгәрдәй көчле янгыраш таба. Шул ук вакытта аларда саф-ачык лирик авазлар да ишетелә. Тыныч-имин тормыш, әмма һич тә идиллия түгел ул.

Композиторнын әлеге сыйфатлары бигрәк тә анын Икенче симфониясендә *("Муса Жәлил")* ачык күренә. Бер генә бүлектән торган зур булмаган бу әсәр композиторның әйтергә теләгән максатын анык билгели—анда герой шагыйрьнең шәхси фажигасе, Ватан һәм үз язмышы өчен әрнеп ачынулары сурәтләнә. Муса Жәлил, жирәнгеч хыянәтче битлеген кисә дә, горурлыгын һәм намус сафлыгын саклап кала. Бу әсәрдә татар музыкасында беренче тапкыр әрнү, нәфрәт, каһкаһә, мыскыллау аһәннәре янгырый. Әсәрне сонрак балетмейстер Дина Арипова "Үлемсез жыр" дигән исем белән Татар дәүләт опера һәм балет театрында балет итеп сәхнәләштерде.

Композиторнын уңышлы Өченче һәм Дүртенче симфонияләре турында да күп сөйләргә мөмкин булыр иде. Анысын музыка белгечләре хөкеменә калдырып, авторнын бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган "Тукай аһәннәре" дигән вокаль-симфоник поэмасына кинрәк тукталмакчы булабыз.

"Тукай аһәннәре"—Алмаз Монасыйповнын кин танылган әсәрләреннән берсе. Аның Тукайга карашы да үзенчә: шагыйрьне ул һәйкәл итеп пьедесталга бастырып куймый, ә үз кайгы-кичерешләре булган тере кеше буларак сурәтли. Көчле хиссиятле музыкада нечкә күнелле лирик, ачы каһкаһәле сатирик, ялкынлы трибун шагыйрьнең тавышын ишеткән кебек булабыз. Әсәрнең жиде өлеше дә бер тын, бер сулыш белән язылган. Тукайның шәхесенә һәм ижатына композитор хәзерге заман кешесе күзлегеннән, үз тормыш тәжрибәсеннән чыгып карарга омтыла. Поэманың гажәеп бай сурәтләү чаралары да шунын белән анлатыла. Анда татар халык жырлары белән шәркый аһәннәр тыгыз үрелеп бирелгән. Буйдан-буйга шагыйрьнең атаклы "Пар ат" һәм "Туган тел" шигырьләренә жырлана торган халык моннары янгырап тора. Әсәргә кертелгән джаз элементлары, эстрада оркестрына хас электрогитара һәм бәрмә музыка кораллары аерым бер үзенчәлекле үстерелеш биреп торалар. Шунда ук орган тавышы кушылып, Тукайның үз чорыннан югары күтәрелүен, аның бөеклеген искәртә. Шуңа күрә дә бу әсәр инде утыз ел халыкны үзенең тирән сәнгатьчәнлеге белән жәлеп итә.

"Тукай аһәннәре"нең ижат ителү тарихы кызыклы. "Бер заман мин чынлап торып Тукай белән авырый башладым,—дип сөйли Алмаз Монасыйпов.—Һәрвакыт анын шигырьләрен үзем белән йөртә идем, хәтта трамвайларда да укып барам. Мине аның шигырьләрендәге ритмик аһәң, гажәеп музыкальлек гашыйк итте".

Беренче мәртәбә бу әсәрне тыңлау Татарстан Композиторлар берлегендә үткәрелә. Фортепианога кушылып, аны композитор үзе башкара. Әсәр югары бәя ала, аны

композиторларның чираттагы пленумында башкарырга тәкъдим итәләр. Әмма "Тукай аһәннәре"нең язмышы җинелдән булмый: аны программага бер кертәләр, бер төшереп калдыралар. Кемнәргәдер Тукайның тәүге шигырьләрендәге гарәп сүзләренең күп булуы ошамый, кемдер аның "Белмәдем" шигырендәге ачы сатирик яңгыраштан курка. Әсәрнең ул кисәген гомумән төшереп калдырырга да телиләр. Шигырь Тукай заманындагы ишаннарга каршы юнәлтелгән булса да, аны бүгенге түрәләр үзләренә кагыла дип кабул итәләр. Күренекле әдип Нәкый Исәнбәт шул вакыт: "Кызыл чапанлы хәзерге ишаннарга каршы бу",—дип ярып сала. Әмма А. Монасыйпов бирешми, үз сүзендә нык тора. Казанда: "Алмаз Монасыйпов Тукайны яңача ачкан икән",—дигән хәбәр тарала. Инде күпләр танышып өлгергән әсәрне халыкка тәкъдим итүдән башка чара калмый. Поэма 1975 елның көзендә шыгрым тулы халык алдында башкарыла. Аны тыңларга Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин һәм башка әдипләр җыелалар. Композитор үзе дирижерлык итә, Эмиль Җәләлетдинов җырлый, органда Рубин Абдуллин уйный. Әсәр искиткеч зур уңыш казана: башта "Туган авыл" җырын кабатлаталар, аннары икенчесен, өченчесен... Шул рәвешле яңадан тулаем диярлек җырлап бетерәләр. Сибгат Хәким: "Безнең әдәбиятчы галимнәребез Тукайны ничә еллар өйрәнеп тә анлап бетерә алмыйлар. Ә Алмаз шалт итеп аның кем икәнлеген күрсәтеп тә бирде",—ди. Әмма шуннан соң—тынлык. Әсәрне радиога да зур кыенлык белән генә яздыралар. Төрле кысу-рәнҗетелүләргә дучар булган Алмаз Монасыйпов Мәскәүгә үк китеп бара. Башкарырга тәгаенләнгән әсәрләре дә төрле сәбәпләр белән тыела тора. Кемдер бу кара эшне бик оста оештыра шикелле. Әмма композитор төшенкелеккә бирелми. Ул башы-аягы белән иҗатка чума: Дәрдемәнд шигырьләренә җырлар яза, симфоник оркестр өчен "Салих Сәйдәшевка музыкаль мәдхия" дигән әсәрен (1980) иҗат итә.

"Муса Җәлил" симфоник поэмасын, "Тукай аһәңнәре", "Салих Сәйдәшевка музыкаль мәдхия" әсәрләре композиторга зур уңыш китерә. 1990 елда ул шул әсәрләре өчен Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Алмаз Монасыйповның иҗаты "милли композитор" дигән төшенчәгә генә сыеп бетми. Аның өчен миллилек теге яки бу җыр-аһәңнәрне эшкәртеп баетуда гына түгел. Аның өчен сәнгать дөньясы—төрле чорлар һәм төрле милли мәдәниятләрнең аралашуы, үрелеп үсүе ул. А. Монасыйпов музыкасында татарлык бөтен төрки дөньядан аерылгысыз. Шуңа күрә дә аның әсәрләрендә шәркый мөселман аһәңнәре һәм ритмнары даими рәвештә яңгыраш таба. Ул үз иҗатында беренче булып "китапча җырлау"га, ягъни мөнәҗәтләрнең аһәңи мөмкинлекләренә игътибар итә, шигъри-музыкаль ислам мәдәниятен тулаем тасвирлый, дип исәпли. Аның күп кенә симфонияләре, Дәрдемәнд шигырьләренә язылган әсәрләре, "Яңа Рамай" җырлары әнә шундыйлардан. Төрки халыкларда яшәп килгән риваятьләргә таянып, ансамбль өчен соңгы елларда иҗат ителгән сюитасы—"Чал Болгардан килгән аһәң-хикмәте" дә "монасыйповча" яңгырый. Бу әсәрдә Сөләйман Бакыргани, Габделҗаббар Кандалый һәм "Бәдәвам" китабындагы шигырьләр дә файдаланылган.

Алмаз Монасыйповның тагын бер яраткан жанры—джаз музыкасы. Аны студентлык елларыннан ук илебездә джаз музыкасының "атасы" Олег Лундстрем белән дуслык җепләре бәйли. Композитор аның коллективы өчен беренче джаз пьесасы да яза. Аннары Гаранян, Деринг оркестрлары белән хезмәттәшлек итә, ә соңгы елларда Татарстан радиосы һәм телевидениесенең Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге эстрада оркестры белән нәтиҗәле эшли. Бу җәһәттән татар радиосы аша еш яңгырый торган "Хыяллар" әсәрен атап үтәргә мөмкин.

Шәркый музыкадан тыш, А. Монасыйпов иҗатында Европа традицияләрен дә абайларга була. Моның шулай икәнлеген артык шәрехләп тормастан, "Муса Җәлил" симфониясендәге матәм маршын гына искәртеп үтү дә җитә.

Композиторның иҗади йөзе аның дирижерлык эшчәнлегеннән башка тулы булмас иде. А. Монасыйпов еш кына симфоник әсәрләренә үзе дирижерлык итә, ун ел дәвамында ул Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет театрының дирижеры булып эшләде. Яңадан консерваториягә укырга кереп, симфоник

дирижерлыкка белем алды, профессор Шерманда укып чыккач, аспирантура тәмамлады. Анын катнашы белән театрда Гунонын "Фауст"ы, Прокофьевнын "Дуэнья" һәм "Үги кыз" спектакльләре куелды. Ул "Русалка", "Борис Годунов", "Катерина Измайлова", "Җәлил" кебек кин танылган опералларга дирижерлык итте.

Алмаз Монасыйпов хәзер Мәскәүдә яши, әмма ул үзен туган Казанынннан аерып карый алмый. "Тукай аһәннәре" әсәренен үзегенә дә ул Тукайнын:

*Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,*
*Хәтеремдә мәнге калыр туган җирем,—*

дигән атаклы юлларын алган.

Күренекле татар композиторы Алмаз Монасыйпов әнә шундый кызыклы иҗади шәхес ул.

**Гөлнур ГОБӘЙДУЛЛИНА,**
*сәнгать фәннәре кандидаты.*

---

## *Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

### Культура элемтәсе экскурсиясе

Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе һәм татар совет язучылары оешмасы быел август башында берничә көнчыгыш җөмһүриятенә культура элемтәсе экскурсиясе оештыралар.

Экскурсия 10 нчы августларда Казаннан чыгып, айдан артык вакытка тартылачак һәм түбәндәге маршрут буенча булачак: Казан—Әстерхан—Махачкала (Дагыстан)—Баку—Ереван—Тифлис—Батум—Симферополь—Харьков һәм Мәскәү. Экскурсия әнә шул күрсәтелгән җөмһүриятләрне Татарстан Җөмһүриятенең культура-экономика барышы һәм гыйлем, әдәбият, сәнгатьләрнең үсешләре белән таныштыруны, шулай ук ул җөмһүриятләрнең дә шул өлкәләре белән танышып кайтуны үзенең төп максаты итеп ала. Экскурсиянең эш планнары турында хәзер үк Дагыстан, Әзәрбәйҗан, Грузия, Әрмәнстан һәм Кырым җөмһүриятләренең тиешле органнарына хатлар җибәрелде. Экскурсиядә барлыгы 15-18 кеше катнашачак. Татарстан хөкүмәте экскурсиянең матди ягын каплауны үз өстенә алды.

Экскурсиянең эш юлы түбәндәгечә булачак: аерым иптәшләргә Татарстанның культура-экономика яки гыйлем-әдәбият-сәнгать эшләренә багланган берәр маузугта *(мәсьәләдә)* тиешле материаллар хәзерләргә һәм барган җирләрдә шул маузугларда доклад, лекция һәм утырышулар юлы белән шул турыда мәгълүмат бирү эше тапшырыла.

### Рус телендә татар әдәбияты альманахы

Мәскәү пролетариат язучылары ассоциациясенең татар секциясе тарафыннан быел көз рус телендә татар әдәбияты альманахы чыгарылачак. Альманах 10-15 табаклар чамасында булып, тик татар пролетариат язучыларының гына әсәрләрен эченә алачак. Альманахка керә торган әсәрләр арасыннан Кави Нәҗминең "Иң соңгысы" русчага тәрҗемә ителеп рус пролетариат язучыларының "Кузница" оешмаларында укылып, атаклы рус язучылары тарафыннан гаять яхшы каршы алынган.

*("Безнең юл".—1929.—N: 6-7.).*



**Равил Әмирхан**

# ТАТАР МАТБУГАТЫ ҮТКӘН ЮЛ

Октябрьгәчә гамәлдә булган татар вакытлы матбугаты, аның гыйбрәтле тарихы—чын мәгънәсендә үзенә бер дөнья. Бу олуг дөньяны тиешенчә, дәрәҗәсенә муафыйк күзаллау һәм тикшерү—зур күләмле фәнни хезмәтләр сорый. Әлеге тема, үзенең колачына, зарурилыгына карамастан, бүгенгәчә ныклап, җиренә җиткерелеп эшләнмәгән, бик күп хасиятләре басма сүз, әдәбият, тарих белгечләре тарафыннан өйрәнелмичә, күләгәдә кала килә. Ә бит революциягә кадәрге татар басмасы барлык төрки халыклар даирәсендә үтә күренекле урын тота, гәзит-журналлары исә, гомумән, төрки кавемнәр тарихының горурлыгын, якты сәхифәсен тәшкил итә. Фәкать бу сәхифә әле бөтенләй диярлек укылмаган. Әйтик, татар зыялыларының 1808 елдан башлап ана телендә матбугат ачу өчен көрәше беркадәр яктыртылса да, царизмның гомуми ээзәрлекләү механизмы, милли фаҗигагә тиң кыерсытуы, басма сүзгә булган ихтыяҗны, аның гайәсен (идеясен) яралгы хәлендә үк буарга омтылышы һ.б. тенденцияләр киң вәсикый (документаль) җирлектә бөтен тулылыгы белән ачыклауны һәм тикшеренүне таләп итә.

Икенчедән, коточкыч җәберләү, кысрыклау шартларында туган телдә гәзит-журналлар барлыкка китерә алмасалар да, татар укымышлылары тугандаш төрки телләрдә чыккан басмаларда турыдан-туры катнаша, аерым алганда, алардагы беренче хәреф җыючылардан санала. Патша хөкүмәте, мәгълүм колониаль максатларны күздә тотып, 1830-1870 елларда үз башлангычлары белән мәйданга куйган фарсы (башта) һәм төрки телле (урысчасы белән параллель рәвештә) басмаларны ("Фарсийские ведомости", "Кавказның бу тарафының хәбәрләре", "Акмолинские областные ведомости"га "Кушымта", "Туркестанская туземная газета", "Туркестанские ведомости", "Игенче", "Зыя", "Кәшкуль", "Зыяи Кавказия" һ.б.) яшәтүгә дә татарлар үзләреннән өлеш кертә. Чөнки хөкүмәтнең реакцион омтылышларына карамастан, бу гәзит-журналлар әлеге шивәләрдә сөйләшүче халыкларның билгеле дәрәҗәдә милли мәнфәгатьләрен дә чагылдыра.

Өченчедән, инде үз сөйләшендәге матбугатның шаулап үсеп китүе шартларында да татарның зыялылары гарәп һәм тугандаш төрки халыклар телендә дә байтак гәзит-журналлар оештыра яисә гамәлгә куюда төп башлап йөрүчеләрдән хисаплана. Мәсәлән, Габдерәшит Ибраһимов (Рәшит казый) С.-Петербургта гарәпчә "Әт-Тилмиз" ("Укучы", 1906), казакъча "Сиркә" ("Житәкче", 1906), Истанбулда (1910) Ә.Тажетдин белән берлектә төрекчә "Тәгареф мөслимин" ("Мөселманнарны таныштыру"), Берлинда (1916) Г.Идриси илә әсир мөселманнар өчен төрки телдәге "Әл-Ислам" гәзитләрен вөҗүдкә китерә. Татар эшлекләләре (Г.Баруди, И.Габиди, Г.Баттал, К.Бәкер, Ә.-З.Вәлиди, Б.Салиев, Мөнәүвәр кари һ.б.) ике тугандаш: татар вә үзбәк телләрендәге "Кинәш", "Ил байрагы", "Шураи ислам", "Олуг "Төркестан" кебек басмаларны житәкли яки аларны мәйданга куюда зур роль уйный.

Равил ӘМИРХАН (1946) *—тарих фәннәре докторы; төп хезмәтләре XX йөз башы татар вакытлы матбугаты һәм иҗтимагый хәрәкәт тарихына карый. Казанда яши.*

1908 елдан башлап Троицкида казакъ телендә нәшер ителгән сатирик "Ай-кап" журналының сәркәтибе, ягъни басманы гамәлгә куючыларның берсе "Чала татар" псевдонимы белән чыгыш ясаган татар Ә.Галимов була. 1908 елда Каһирәдә И.Гаспринский гарәпчә "Ән-Нәзәхат" ("Чисталык") журналын нигезли. Татарның һәм төрекнең олпат җәмәгать эшлеклесе Й.Акчура Истанбулда "Төрек йорды" журналының инеш башында торучылардан. Әмма бу юнәлештәге бәрәкәтле эшчәнлек тә үзенең әтрафлы тикшеренүчесен көтә.

Дүртенчедән, үзенең барлык эшчәнлеге дәверендә татар басмасы, кавеми йомыклыктан йөз чөереп, Россия, Аурупа, хәтта ки бөтендөнья халыклары хәятын, мәдәниятен дә үз итә, аларны армый-талмый яктыртып вә пропагандалап, милләтнең тәрәккыяте юлында гаять игелекле эш башкара. Әмма бу башлангыч әдәбиятта шулай ук шактый кысыр чагылыш тапкан.

Бишенчедән, йөз елга якын тигезсез көрәш нәтиҗәсендә туган татар вакытлы матбугатының нигези үсеш баскычлары, аны матди яктан тәэмин итүчеләре, басмаларның профессиональ юнәлеше, сәяси кыйбласы, географик таралышы, халыкның төрле катламнарына үтеп керү үзенчәлекләре, гомумтөрки яңгыраш алуы, ниһаять, милли органнарның татарның рухи, мәдәни һәм иҗтимагый тормышында биләгән урыны да бөтен тирәнлеге белән хәзергәчә өйрәнелмәгән.

Алтынчыдан, шул ук хөкемне татарның үз телендәге басмалары барлыкка килгәнче хөкем сөргән һәм "шималь төрекләре"нең (ягъни татарларның) рухи тормышларында күренекле роль уйнаган гомумтөрки матбугат эшчәнлеген өйрәнү хакында да чыгарырга мөмкин. Сүз беренче нәүбәттә Кырымның Бакчасарай шәһәрендә бөек мәгърифәтче Исмәгыйль бәк Гаспринский чыгарган "Тәрҗеман" гәзите турында бара. Элгәресе "Тунгыч" ("Беренче бала") тәҗрибәсеннән дә унай файдаланган "Тәрҗеман" 1883 елның 11 апреленнән чыга башлый һәм үзенең заманы өчен киң колачы, саллылыгы, кавеми-дини вә мәгариф мәсьәләләрен шактый кыю күтәрүе белән Россиянең төрки дөньясында тиз абруй казана, җитди милли матбугаты булмаган, географик җәһәтттән таркау мөселман-төрки халыкларны үзенә күрә рухи яктан туплаучы, идея ягыннан берләштерүче көч сыйфатын үти башлый.

Кырым басмасының Казан татарлары арасында киң таралуына үз вакытында урысча "Казанский телеграф" гәзите дә игътибар итә. Үзенең бер санында, мәсәлән, ул болай ди: "Берникадәр вакыттан бирле шәһәребездә китап, рисалә һәм гәзит таратучы мөселманнар пәйда булды. Китап һәм рисаләләрнең күпчелеге дини эчтәлекле. Гәзитләр арасында иң сорала торганы—Кырымда нәшер ителүче "Тәрҗеман"[1].

1905 елга кадәрге чорда Идел буе татарлары "Тәрҗеман"ны аеруча күпләп алдыра, укый, Казандагы "Мөхәммәдия" кебек мәшһүр мәдрәсәләрдә аның белән танышып, шәкертләр милләт мәнфәгатьләре өчен интеллектуаль көрәшкә рухлана. Шәкерт, булачак әдип Ф.Әмирхан, мәсәлән, беренче иҗади тәҗрибәләрен "Тәрҗеман" үрнәгендә ясый, 1901 елдан ул чыгара башлаган "Әл-Мәгариф", 1902 елда оештырылган "Бәнд" кульязма гәзитләре һ.б. күп яктан И.Гаспринский басмасы белән авазлаш.

Татарның күренекле каләм ияләре, сүз осталары "Тәрҗеман"да үз язмалары белән дә катнаша. Мәсәлән, Г.Исхакый бу гәзиттә бөек мәгърифәтче Каюм Насыйриның вафатына багышланган "Мәшһүр мөхәррир" исемле мәрсиясен бастыра[2]. "Тәрҗеман"ның егерме еллык юбилее уңаеннан шул ук Исхакый гәзитнең һәм мөхәрриренең эшчәнлеген хуплап: "Исмәгыйль мирза безнең үлгән милләтебезгә хәят бирде ... караңгы йөземезгә мәгариф нуры чәчте"[3],—дип язып чыга. 1905 елда пәйда булган беренче татар гәзите "Нур" да әүвәлге чорында "Тәрҗеман"нан алып даими төстә хәбәрләр биреп килә.

Әйе, соңрак, 1905-1907 еллардагы инкыйлаб чорында, Казан сөйләшендәге гәзит—журналлар куәт алгач, "карт" гәзитнең "базары төшә", йогынтысы бермәбер кими, иң шыксыз дәверләр, сөремле вазгыятьләр җимеше булган басма хөррият шартларына яраклаша алмый, башкалар фонында инде бик искергән, консерва-

---

[1] Казанский телеграф., 1894, 14 июня.

[2] Тәрҗеман, 1902, 15 сентябрь.

[3] Шәркый рус, 1903, 25 апрель.

тив булып күренә. Ләкин "Тәрҗеман"ның 1905 елга кадәр эшчәнлеге Россиядәге төрки һәм мөселман дөньясының бәхәссез казанышы дип бәяләнергә хаклы. Гәзитнең яшәү чыганакларына килгәндә исә, аның матди нигезен тулаем Идел буе татарларының мөлкәт ияләре тәэмин итә.

Татарның саф ана телендәге үз матбугаты булмаган заманда әзәрбайҗан төркисендәге "Шәркый рус" гәзитенең *(Тифлис, 1903-1904)* әһәмиятен зикер итү дә фарыз булыр. Инде күрсәтелгәнчә, Г.Исхакый "Тәрҗеман" шәрәфенә багышланган юбилей мәкаләсен нәкъ менә шул гәзит битләрендә бастыра. Биредә байтак кына татар зыялылары каләм чарлый, аерым алганда, Ш.Мөхәммәдов "Хан кызы" исемле хикәясен, "Татар угылы" имзасы белән "Безнең имамнар", "Җәһаләт вә нәтиҗәсе" кебек мәкаләләрен, төрле фасыллдагы башка язмаларын урнаштыра.

Россиянең төрки дөньсында сан ягыннан да, зыялылык җәһәтеннән дә иң күренекле урын биләгән татар халкы үз матбугаты туганнан соң чын мәгънәсендә рухи ыргылыш ясый. Йөзләгән исемдәге гәзит-журналлар милләтнең яңа гасыр таңындагы үсешен билгели, сыйфат ягыннан биниһая югары баскычка күтәрелүенең күрсәткече булып тора.

Әйе, күп гасырлар әүвәл үк шанлы дәүләте, мәгърур дәүләтчелеге булган халык үзен икенче сорт милләт итеп күрәсе килми. Йөзләрчә еллар буена калыпланган, ләкин хөкүмәт тарафыннан аяусыз томаланып, басылып килгән рухи-интеллектуаль егәрен татар милләте үзенең яңа гына мәйданга килгән матбугаты аркылы гамәлгә ашырырга омтыла, халыклар гаиләсендә үзенең лаеклы урынын даулый башлый. Шу ук вакытта, берничә гасырлык мәдәни тәҗрибәсенә таянып, Россиянең төрки-мөселман дөньясына билгеле бер юнәлеш, аһәң (тон) бирүне дә дәгъва кыла.

Әлеге язмада без үзебезгә әлләни зур бурычлар йөкләмичә, бик кыска һәм гомуми шәкелдә генә татар матбугатының барлыкка килү, аякка басу, үсеш этаплары, таралу даирәсе, һөнәри һәм сәяси-иҗтимагый юнәлеше хакында сүз йөртергә, гәзит-журналларның милли-мәдәни яссылыктагы эшчәнлегенә караш ташлап узарга, иң йөгерек фасылда татар басма сүзенең төрки халыклар гаиләсендәге урынын билгеләргә, Россия, Аурупа вә дөнья цивилизациясе казанышларын ни рәвешле үзләштерү һәм алга сөрү хосусистләренә орынып китәргә ниятлибез.

Бу максатларны өлешчә булса да тормышка ашыру өчен сүзне, мөгаен, милли матбугат өчен көрәш сәхифәләреннән, басмаларның беренче адымнарыннан башлау мәслихәт булыр.

Татар милли матбугатын гамәлгә кую өчен көрәш нигездә түбәндәгеләргә кайтып кала. XIX гасыр башында Казанның алдынгы карашлы галимнәре, халыкны бөтенрусия иҗтимагый һәм мәдәни хәяты белән таныштырып бару максатында, татарча басма сүз тарату чараларына керешә. Шундый галимнәрнең берсе, Казан университеты профессоры И. Запольский 1808 елда рус һәм татар телләрендә "Казанские известия" гәзите бастыру проектын тәкъдим итә. Әмма хакимият рус галименең игелекле башлангычын тормышка ашырмау өчен барысын да эшли. Запольский, максатына ирешә алмыйча, 1810 елда кинәт вафат була.

Икенче тапкыр татарча гәзит ("Бәхрел-әхбар", ягъни "Хәбәрләр дингезе") чыгару омтылышын 1834 елда Казан университетының шәрекъ разряды тәрбияләнүчесе М.Никольский ясап карый. Никольский ниятен университет профессоры, танылган шәрекъ белгече А.Кәзим-Бәк һәм шулай ук Казан уку-укыту округы назыйре М.Мусин-Пушкин хуплый. Кәзим-Бәк гәзитне гамәлгә куюны үтенеп, Эчке эшләр министрлыгына мөрәҗәгать итә. Әмма үтенеч канәгатьләндерелми, ә проект тәкъдим итүчене, университеттагы эшеннән бушатып, ашыгыч рәвештә Әстерхан губернасына озаталар.

1864 елда тагын бер адым—"Файда" исемле журнал чыгарырга омтылыш ясала. Монысының башында йөрүче—П.Пашино, коллегия асессоры, ул вакытта Эчке эшләр министрлыгында татарчадан тәрҗемәче булып эшли. Журналның С.-Петербург цензура комитетына тәкъдим ителгән махсус проекты башкаланың күренекле галимнәре һәм алдынгы карашлы сановникларында да яклау таба. Ләкин әлеге галиҗәнаб шәхесләрнең Пашино журналын бастыру җаваплылыгын үз өсләренә алулары да нәтиҗә бирми. Журнал чыгарылмый.

Шул ук 1864 елда Азия департаменты тәрҗемәчесе, христиан динендәге гарәп И.Нафаль да С.-Петербургта "Шәрекъ" исемле татарча гәзит чыгарырга тырышып карый. Әмма әлеге миссионер, чын монархист, тәхетнең тугрылыклы хезмәтчесенең дә гозере кире кагыла.

1865 елда рус гаскәре капитаны В.Курочкин, матбугат эшләре буенча Баш идарәгә мөрәҗәгать итеп, "Файда" дип исемләнгән гәзит чыгарырга рөхсәт сорый, тагын нәтиҗәсе булмый.

Әлеге эшлекләләр үз проектларында бөекмәмләкәтчелек һәм хөкүмәт идеяләрен алга сөрәчәкләрен белдерсә дә, патша хөкүмәте "татар-мөселман гаммәсенә урысларга якынаю юлы белән дөньяга сәламәт төшенчәләр һәм кешечә караш" үтеп керүен теләми. Самодержавие татар халкының йомык шартларда һәм рухи яктан бикләнгән көе җан асравын өстен күрә.

Идарәче даирәләр кулы астыннан чыккан бер рәсми вәсикада турыдан-туры болай диелә: "Россиядә гомер сөрүче инородец кабиләләре арасында татар әдәбиятының һәм вакытлы матбугатының тәрәккъый итүе бу кабиләләрнең урыс халкына якынаюына һәм аның белән кушылуына хезмәт итүе икеле: татарларда үзләренең диненә һәм теленә мәхәббәт үтә көчле, һәм Россиядә тереклек итүче барлык инородецлар арасында татарлар руслар белән кушылуга барыннан да аз бирелә; әдәбиятның туган телдә үсеш алуы исә инородецлар арасында фәкать үзаң һәм—аннан да бигрәк—сәяси хыяллар гына уятуы мөмкин"[1].

XIX гасырның 60 нчы елларыннан башлап, татарлар үзләре дә ана телендә вакытлы матбугат булдыру өчен көрәшкә кушыла. 1863 елда бөек мәгърифәтче К.Насыйри һәм литография хуҗасы М.Яхин, татарча гәзит чыгарырга рөхсәт сорап, югары даирәләргә мөрәҗәгать итә. Тик аларның да үтенече кире кагыла. К.Насыйри соңгы көннәренәчә гомерлек хыялын тормышка ашырырга, ягъни татарлар өчен туган телләрендә даими басма булдырырга тырыша. Әмма күпме көч түксә дә, үзе теләгән "Таң йолдызы" гәзитен гамәлгә куя алмый.

С.-Петербург университетының төрки телләр укытучысы Х.Фәезханов та, башка кеше исеме астында, туган телдә гәзит чыгарырга омтылыш ясый. Тик бу талпыныш та, әүвәлгеләре төсле үк, уңышсызлыкка дучар була. 70 нче еллар башында "Дәфтәре мөҗдәвәр" ("Хәбәрләр җыелмасы") гәзите бастырырга җыенган унтер-әфисәр А.Котлыяров һәм сәүдәгәр угылы Х.Бикбулатов үтенече кире кагыла.

70 нче еллар уртасында С.-Петербург почтамтының станция күзәтүчесе Т.Котлыяров башкалада "Мөҗдәвәр" ("Хәбәрче") исемле гәзит чыгару өчен бер-бер артлы ике үтенеч бирә. Гәзит проекты "Коръәнне шәрехләүчеләргә" каршы көрәшүне, Россия һәм чит мәмләкәтләрдә фән һәм мәдәният үсешен куәтләүне, татарларга "үзләренең рус гражданлыгы хокукларын" бәян кылуны күздә тотса да, рөхсәт барыбер бирелми.

Бу җәберләүләрнең асыл сәбәбе түбәндәге документта шактый ачык гәүдәләнеш таба: "Татар телендәге гәзит татарларның табигый кызыксынуын канәгатьләндергән һәм аларга иҗтимагый тормыштан барлык кирәкле мәгълүматларны биргән хәлдә, татарлар тарафыннан дәүләт телен өйрәнү зарурлыгын озакка кичектерәчәк һәм ... татарларның рус халкы белән мәдәни кушылуыннан битәр милли сепаратизмга хезмәт итәчәк"[2].

1885 елда Казан губернасының Спас өязе крәстияне С.Әхмәров та татарча гәзит чыгарырга омтылыш ясап карый. Ләкин нәтиҗә шул ук була. Татар драматургиясенең инеш башында торган Г.Ильяси 1887 елда "Казан" гәзите чыгарырга талпыныш ясый. 1891-1895 елларда Г.Баязитов "Һәфтә" ("Атна"), "Чишмә", "Нур" исемле гәзитләр ачарга рөхсәт сорап мөрәҗәгать итсә дә, үзенең гозерләренә бер-бер артлы тискәре җаваплар ала. Югыйсә, Г.Баязитов—драгоман, ягъни тышкы эшләр министрлыгында тәрҗемәче, надворный советник, С.-Петербург ахуны, егерме елдан артык дәүләт хезмәтендәге кеше хисаплана. Язучы-публицист М.-З.Бигиевның да шундый ук үтенече канәгатьләндерелми. Шәрекъне өйрәнү буенча Император

[1] РГИА, 776—эш, 12—тасв., 14—эш, 10 б.
[2] ТРМА, 1—ф., 4—тасв., 1109—эш, 5 б.

җәмгыятенең фәхри рәисе О.С.Лебедеваның да ("Гөлнар ханым") шушы хосустагы үтенече кире кагыла (1893 ел).

Патша хөкүмәте, татарча басма чыгару җаваплылыгын үз өстенә алган һәрбер шәхескә, яисә аларның җитәрлек дәрәҗәдә әзерлекле түгеллеген, яки татар телендәге вакытлы матбугатка даими цензура күзәтүе ясап булмау кыенлыгын сылтау итеп, катгый төстә тискәре җавап бирә килә. Тик гәзит-журналлар чыгарырга омтылыш барыбер сүрелми. Самодержавиенең милли мәдәнияткә кагылышлы кыерсыту сәясәтен какшатырга өметләнеп, Казан Татар укытучылар мәктәбе инспекторы Ш.Әхмәров 1894-1895 елларда матбугат эшләре буенча Баш идарәгә ике тапкыр мөрәҗәгать итә: "Казан" гәзитен чыгарырга рөхсәт сорый. Университет белеменә ия булган һәм "ышанычлы" шәхесләр җөмләсенә кергән Ш.Әхмәров, һич шөбһәсез, уңышка ирешергә тиеш иде кебек. Әмма хакимиятнең: "Басма сүз ярдәмендә милли рухиятне тәрәккый иттерүнең дәүләт өчен файдасы юк", дигән хөкеме бу очракта да үз көчендә кала.

Эчке эшләр министрлыгына, матбугат эшләре буенча Баш идарәгә, С.-Петербургның цензура комитетына, Казан губернаторына һ.б. югары даирәләргә, туган телләрендә вакытлы матбугат басмалары ачарга рөхсәт сорап, татарлардан дистәләрчә үтенеч кәгазьләре юллана. Әмма патша чиновниклары, татар телендә матбугат булдырырга ярдәм итү түгел, хәтта ул хактагы идеяне үзен дә буып ташларга әзер тора.

XX гасыр башында милли матбугат ачу буенча яңа башлангычлар мәйданга килә. Бу хыялны җәмәгать эшлеклеләренең яңа буыны тормышка ашырырга алына. Әмма гәзит-журнал ачарга омтылучыларның башына әлеге дә баягы "рөхсәт юк!" күсәге төшә тора. 1903 елның язында мәгърифәтчеләр Һ.Максуди белән И.Терегулов татар һәм рус телләрендә "Йолдыз" гәзите ачарга омтылыш ясап карый. Тик хакимият бу башлангычны да инде чәйнәлеп беткән, беркемне дә инандырмый торган чираттагы "дежур" сылтау белән кире кага. Һ.Максуди белән И.Терегулов та үзсүзле булып чыга: бер елдан соң алар Баш идарәгә яңадан мөрәҗәгать итеп, "Көндез" дигән гәзит ачарга рөхсәт сорый. Кабат тискәре җавап алына. Әмма әлеге фидакярлар 1904 ел ахырында Баш идарә "капкасын" шакып, "Казан" гәзите чыгару мәсьәләсен кузгата. Бу юлы инде, гозерне тагын да нигезлерәк итеп кире кагу өчен, властьлар Һ.Максудины барлык татарча прокламацияләрне "әмәлләүдә" гаепли. Аңа карап, Максуди да чигенергә уйламый, максатына баруны дәвам итә. 1905 елның язында ул, яңадан "Йолдыз" журналы мәсьәләсен кузгатып, хакимият алдына татар басмасының зарурлыгын дәлилләп күрсәтә. Әмма юкка гына. Патша чиновниклары "алдан сизгерлек күрсәтеп", Максудины "үз журналында панисламизм идеясен тарату" ихтималында гаепли һәм аның үтенеченә бу юлы да киртә сала.

Идарәче даирәләр гамәлдә татарча матбугат ачу мөмкинлеген һәм аның максатка ярашлылыгын бөтенләй үк инкяр иткән дип булмый. "Чөнки,—дигән алар,—бөтен татарлар да диярлек үзләренчә укый-яза белә ... һәм туган телләрендәге гәзит киң таралып кына калмыйча, аларның фикер йөрешенә дә көчле йогынты ясый алачак". Шул ук вакытта, властьлар фикеренчә, татар гәзитен зарури бер шарт белән генә чыгарырга мөмкин. Ул да булса—"мөхәррир һәм нашир татарларның аңына аларны гражданнарча урыслаштыру рухында йогынты ясауны үзләренең төп максатларының берсе итеп куярга тиеш"[1]. Билгеле инде, Максуди да, Терегулов та әлеге "югары" таләпләргә җавап биреп бетерә алмаган.

Патша хөкүмәте татар халкының мәдәни җәһәттән уянуына шулкадәр дошманнарча караган ки, хәтта алтын санагатенең танылган хуҗалары—миллиончы Рәмиевләрнең наширлек эшчәнлеген башларга омтылулары да гасыр башында властьлар тарафыннан тулысынча кире кагылган. Шушы ук чорда З.Таһиров үзенең "Хөррият" гәзитен, Г.Баязитов—"Нур"ны, Г.Апанаев—"Таң"ны, К.Мотыйгый-Төхфәтуллин "Әлгасрел-җәдид" журналын чыгара алмый. Хәтта рус телендәге уң монархистик гәзит булган "Казанский телеграф"ның нашиpәсе А.Ильяшенкога да татарча "Телеграф для мусульман" гәзитен чыгарырга рөхсәт бирелми. Югыйсә,

[1] ТРМА, 1—ф., 4—тасв., 1622—эш, 8 б.

анда фәкать "Казанский телеграф" гәзитендәге белешмәләрне татарча бирү генә күздә тотылган була.

Троицк шәһәрендәге типография хуҗасы Х.Сосновский да, үзенең татарча гәзит ачу омтылышына җавап итеп, шундый ук "вето" ала. 1904 елда ул матбугат эшләре буенча Баш идарәгә түбәндәге эчтәлекле хат юллый: "Троицк шәһәренең мөселман халкы, Ерак Көнчыгыштагы вакыйгалар белән чиксез кызыксынып та, рус грамотасын белмәү сәбәпле, башка халыклар белән беррәттән хәрби вакыйгаларны күзәтеп барудан мәхрүм. Шуңа күрә дә Россия агентлыгының минем тарафтан чыгарылучы телеграммаларын татарча да бастырырга рөхсәт юнәтүемне сорыйлар. Язылганнарга нигезләнеп, Сез галиҗәнаблардан мина Троицкидагы үз типографиямдә Россия агентлыгы телеграммаларын татар телендә бастырырга рөхсәт итүегезне сорыйм". Ләкин барысы да юкка. Оренбург губернаторы рус кешесенең "инородецлар" гәзитен чыгарырга алынуына берсүзсез каршы төшә, ә Эчке эшләр министры исә Х.Сосновскийга хөкүмәтнең нинди дә булса рәсми хәбәрләрен татарча чыгаруны гомумән катгый тыя.

Күрәсең, патша хөкүмәте, ата миссионер Н.Ильминский фикеренә нисбәтән, "русча белмәгән һәм укымышлы булмаган фанатикның русча цивилизацияле татардан чагыштырмача яхшырак" булуына инангандыр һәм шунлыктан милли матбугат басмаларын чыгаруга бөтен көчен куеп каршы килгәндер. Патша түрәләре әйләнә-кайта, "барыннан да куркынычы—гәзитнең хөкүмәткә каршы бернинди чыгыш ясамаса да, ирексездән милли үзаңны уятуы, хәтта ки сәяси хыяллар тудыруы ихтимал" дип санаган[1]. Шул рәвешчә, татар халкына сәяси хыялларга бирелү генә түгел, милли үзаңга ия булу да тыелган. Властьларның татарча гәзит-журналлар чыгаруга катгый каршы төшүе—самодержавие милли-колониаль сәясәтенең аерылгысыз бер өлеше булды. Әлеге сәясәт, үз чиратында, халыкны наданлыкта һәм хәерчелектә генә түгел, рухи бикләнгәнлек кысаларында тотуга да хезмәт итте.

Дөресен әйтергә кирәк: патша хөкүмәтенең татар матбугаты барлыкка килүгә каршы торуы—тиңдәше булмаган кыерсыту, җәберләү үрнәге ул. Югыйсә, 1905 елга кадәр үк әзәрбайҗан, әрмән, грузин, яһүд, латыш, молдаван, поляк, фин, эстон һ.б. телләрдә гәзит-журналлар чыгуы мәгълүм. Халык саны буенча татарлар әлеге милләтләр арасында поляк һәм яһүдиләрдән генә калышкан.

Бу золым-җәберләргә артык гаҗәпләнү дә урынсыз кебек, чөнки патша түрәләре татарларга шулкадәр кырын караган ки, хәтта аларның үз мәдәниятләре булуын да инкяр итеп маташкан. Хакимият болдырларында шактый калку фигура—Казан губернаторы бер рәсми документта, мәсәлән, болай дип белдергән: "Россиядә татар мәдәниятенең, һәм инде бигрәк тә, мөселман мәдәниятенең юклыгын һәм булырга да тиеш түгеллеген рус хөкүмәте ачыктан-ачык белдерергә тиеш"[2].

Түбәнрәк дәрәҗәдәге чиновниклар исә, татарларны бетереп ташлау өчен, аеруча "җете буяулар"дан файдаланган. Татар китабы цензоры Н.Ашмарин сүзләренә игътибар итик: "Дин күрсәтмәләре белән бәйле, гореф-гадәт һәм наданлыктан торган, фанатик мулла-мөәзин һәм халфәләргә колларча буйсынган татар җәмгыяте берничек тә яна эшләрне уңышлы оештырырга сәләтле, анлы, мәгърифәтле кешеләр тудыра алмады ... Гасырлардан килгән йомыклык, идеалларны үткәннәрдән, гарәп схоластикасы һәм әдәбиятыннан эзләү сыйфатлары татар кешесен күптән хәрәкәтсезгә, яналыкларны кабул итә белмәүчегә әверелдерде. Житмәсә, шәрыкъча фанатизмы да шуңа хезмәт итте. Татар кешесе, гомумән, иртәгәге көнен уйламый, "иртәгәге өчен ишәк кайгырган" дигән әйтеме дә шул хакта сөйләп тора"[3].

Әлеге "зыялы" зат татарларның хәтта мөстәкыйль фикер йөртә алу сәләтен инкяр итә: "Татарларда чынбарлык хакында шәхси фикер йөртү күнекмәләре юк, шуңа күрә татар гаммәсенең тормышы Аурупа халкы өчен генә түгел, әлегәчә, гомумән, terra incognita *(билгесез өлкә.—Р.Ә.)* булып кала[4].

Менә шушындый "мәдәниятле" мөнәсәбәтләр нигезендә татарча гәзит чыгару

[1] ТРМА, 1—ф., 4 тасв., 107—эш, 4 б.
[2] РГИА, 821—ф., 133—тасв., 424—эш, 125 б.
[3] ТРМА, 420—ф., 1—тасв., 104—эш, 88 б.
[4] Шунда ук, 90 б.

мәсьәләсе шул дәрәҗәдә өметсез була ки, милләтнең кайбер зыялылары (хосусан, Ш.Мөхәммәдов), нык ачынып, басма орган чыгару ихтималын, "дөнья асты-өстенә килмәенчә торса, йөз елдан соң" дигән шарт, ягъни ахырзаман могҗизасы белән бәйли.

Татар халкының иҗтимагый-сәяси фикер үсеше даими күзәтү астында тотыла. Бу бигрәк тә милләтнең тарихи башкаласы һәм мәдәни мәркәзе булган Казан шәһәре үрнәгендә ачык чагыла. Мәсәлән, Эчке эшләр министрлыгының полиция департаменты 1900 елның 31 декабрендәге циркулярына (махсус яңа гасыр бусагасында) татар мәдәниятен эзәрлекләүнең яңа үрнәгенә фатиха бирә, үзен халыкны агартуга багышлаган алдынгы карашлы эшлеклеләрнең һәркайсына "досье" булдыруны хуплый. Шул рәвешчә, "яктылык нуры" дистә еллар буена законсызлык, ялган, гаплади кешелек, гражданлык хокукларын һәм хөрриятен таптау дигән караңгылык дөньясын тишеп чыга алмый. Чыннан да, ахыр чиктә могҗизага, Галиҗәнаб очраклыкка гына өмет баглыйсы кала[1].

Могҗизаны 1905 ел инкыйлабы алып килә. Революция халыкның аңында тиңдәше булмаган дәрәҗәдә милли горурлык хисләре уята. 1905-1907 еллар татарларның чын мәгънәсендә уяну таны, актив иҗтимагый-сәяси тормышка баглану дәвере булып тарихка керә. Халык яшәешендә моңарчы күрелмәгән хәл—үз милли матбугатын барлыкка китерү, үстерү мөмкинлеге туа.

Әмма инкыйлабның башлангыч чорында да әле гәзит-журналлар чыгарырга рөхсәт алу гаҗәеп катлаулы эш булып кала бирә. Һ.Максудиның 1905 елдагы уңышсыз омтылышын искә алган идек инде. Тик, башкаладагы һәм урыннардагы түрәләрнең катгый каршылыгына да карамастан, матбугат органы ачарга омтылучылар саны да арта бара. Алар арасында үзенең активлыгы белән К.Мотыйгый-Төхфәтуллин аерылып тора. Хакимият, гәзит-журналлар ачуга каршы нинди генә сылтаулар тапса да, илдәге азатлык хәрәкәте киңәя бару нәтиҗәсендә, үз фикерләрен беркадәр үзгәртергә, үҗәтлеген тыя төшәргә мәҗбүр була.

Идарәчеләр, К.Мотыйгый үтенеченә җавап итеп, берьюлы ике четерекле мәсьәләне хәл итәргә карар кыла. Беренчедән, рус хөкүмәтендә татарларның рухи ихтыяҗлары үсүгә уңай караш булуын исбатлап, аларга рәхимлелек күрсәткән булырга. Икенчедән (һәм иң әһәмиятлесе шул), яңа татар матбугатын ("Әлгасрелҗәдид") Җаек (Урал) өлкәсе мөселманнарына самодержавие сәясәте турында "дөрес" мәгълүмат тарату өчен файдаланырга. Җаек өлкәсенең хәрби губернаторы матбугат эшләре буенча Баш идарәгә язган "яшерен" хатында әлеге журналның зарурлыгы хакында үзе үк әйтә. "Хәзерге тормыш вакыйгаларын дөрес итеп яктырту инородцлар өчен гаять файдалы булыр иде, чөнки алар арасына тенденциоз юнәлештәге һәм вакыйгаларны бозып күрсәтүче легаль булмаган басмалар үтеп керә"[2],—ди. Күрәсең, инкыйлаб шартларында өстәмә кыенлыклар килеп туа һәм патша түрәләре татарларны барыннан да элек сул-радикаль идеялардән саклау турында "хафалана".



Баш идарәгә К.Мотыйгый тәкъдим иткән программа, билгеле инде, бөтенләй башка максатларны күздә тота. Ләкин күнегелгән кырын караш журнал инициаторын идарәчеләрнең күрсәтмәләренә һәм кырыс цензура таләпләренә буйсынырга, программаны, өтегрәк итү бәрабәренә, берничә мәртәбә үзгәртергә мәҗбүр итә. Ниһаять, очсыз-кырыйсыз аңлашулардан, "ышанычлыкка", хөкүмәткә лояльлектә тикшерелүләрдән соң, күп мәшәкатьләр аша К.Мотыйгый журнал чыгару өчен таныклык алуга ирешә. Революциянең шактый кызган чоры—1905 елның июнь ае була бу.

[1] Нәкъ менә татар халкына матбугат ачарга ирек бирмәүнең асыл сәбәпләре бик тирән. Аның чын механизмын ачу өчен аерым мәкалә язарга кирәк.

[2] РГИА, 776—ф., 15—тасв., 26—эш, 2 б.

Әлеге могҗиза турындагы хәбәр бөтен татар дөньясында яңгыраш таба. Башта ышанып бетмиләр. Аннары инде, инангач, башка милли үзәкләрдә дә газит-журнал чыгару омтылышы бермә-бер көчәеп китә. Дәүләт идарәләре бусагасын яна тәвәккәллек белән таптый торгач, 1905 елның 7 июнендә С.-Петербург гарнизонының хәрби ахуны Гатаулла Баязитов та "Нур" газите ачарга рөхсәт ала. (Югыйсә, 1891-1895, 1905 ел башларында күпме йөреп тә, максатына ирешә алмаган кеше бит!). "Нур" газите, беренче татар басма органы булып, С.-Петербургта 1905 елның 2 (15) сентябреннән чыга башлый. Димәк, 2 (15) сентябрь татар вакытлы матбугатының туу датасы булып саналырга һәм татар матбугаты көне дип игълан ителергә тиешле. Газиткә мөхәррир һәм нашир сыйфатында Г.Баязитов үзе җитәкчелек итә. Күп телләр белүче, зыялы, әмма бигүк демократик карашта тормаган кеше була ул. Шуңа да газитнең нигездә консерватив юнәлештә алып барылуы гаҗәп түгел. Ләкин, шулай да, беренче матбугат органы дөньяга килү татар милли тормышында гаять зур вакыйга булып кала. Матбугат булдыру өчен йөз елга якын барган тартыш 1905-1907 елгы революция нәтиҗәсендә, ниһаять, җиңү белән тәмамлана. Милли мәдәният һәм җәмгыять эшлеклеләре "беренче карлыгач"ны сөенеп каршы ала. Г.Тукай, мәсәлән, бу вакыйгага менә нинди юллар багышлый:

*Шималь яктан чыгып бәркъ, орды бер нур,*
*Зыясыннан әһали улды пәрнур.*

*Мотабикъдер мөсәммасенә исме,*
*Мөнасыйбдыр дәхи исменә җисме.*

*Нә дәүләт милләтә, нә бәхт вә талигъ,*
*Бу көз төньяктан улды шәмес талигъ ...*[1].

Башкала үрнәге бик күп милләтпәрвәрләрнең күңелен кузгата. Төрле даирәләргә янадан-яңа гаризалар ява. Әмма самодержавие идарәчеләренең уенда татар матбугатын гөрләтеп җибәрү планы булмый. Алар бу эшкә ничек тә аяк чалырга гына омтыла. Шулай да халык гаммәсенең көчле басымы, мәмләкәтнең либеральләшә баруы аларны үзеннән-үзе яраклашырга, демократия уенын уйнарга мәҗбүр итә. Шуңа да властьлар вак-төяк ташламалар ясап котылырга, инерция буенча Россиянең "ышанычлы" кешеләренә таянырга тырыша.

Шундый "ышанычлы"ларның берсе—присяжный поверенный, Казан шәһәр думасы гласные Сәедгәрәй Алкин булып чыга. Алкин "Казан мөхбире" газите ачарга рөхсәт сорый. Баш идарәнең Алкин турындагы кызыксынуына җавап итеп, цензор М.Пинегин (ул "Отдельный цензор" атамасын йөртә) өметле генә җавап бирә: Алкин Казан полицмейстерының элекке ярдәмчесенең улы, Уфа аксөяк фамилияләре Тәфкилевлар, Солтановлар, Шәехалиләр һ.б. белән якын кардәшлек мөнәсәбәтләрендә тора, дип белдерә. Моннан тыш, ул "тулысынча русча яшәү рәвеше" алып бара һәм рус зыялылары даирәсе белән аралаша, ди.


فكر

1905 елның 7 октябрендә С.Алкин, татарча да, русча да чыгару шарты белән, "Казан мөхбире" газитен ачарга рөхсәт ала. Идарәчеләр кире уйлап, туып килүче басманың юлына киртә салмагайлары дип, Алкин һәм аның фикердәшләре "тимерне кызуында сугарга" ашыга. Нәтиҗәдә, эшне бик кызу тоту аркасында, 1905 елның 29 октябрендә, Россиядәге икенче татар газите—"Казан мөхбире" пәйда була. Башта ул, рөхсәткә нисбәтән, ике телдә, аннары татарча гына чыгарыла.

Ул арада Россиядә гаять зур тарихи вакыйгалар өлгереп килә. Колачы ягыннан

[1] Нур, 1905, 6 декабрь.

монархы күрелмәгән гомуми сәяси стачка 17 октябрьдә үзенең иң югары ноктасына житә. Эшче халык бөтен санагать, сәүдә һәм дәүләт тормышын чыгырдан чыгара. Инкыйлаб шаукымыннан куркып калган патша хөкүмәте берникадәр ташламалар ясый. 17 октябрь Манифестында "шәхеснең кагылгысызлыгы әсасында гражданлык хөрриятенең какшамас нигезләре, вөждан, сүз, жыелышлар һәм бердәмлекләр иреге ..." игълан ителә.

1905 елның 14 ноябрендә, 17 октябрь Манифесты нәтижәсе буларак, көндәлек матбугат турында Вакытлы кагыйдәләр барлыкка килә.



Алар тәфтиш алды цензурасын юкка чыгара һәм шул рәвешчә яңа матбугат органнары барлыкка килүне сизелерлек жиңеләйтә. Милләт зыялыларына татар телендә тагын да гәзит-журналлар ачарга мөмкинлекләр туа. 1905 елның 27 ноябрендә Жаек (Уральск) каласында "Фикер" гәзитенең беренче саны дөнья күрә. "Фикер" бу вакытта рөхсәтсез чыга дияргә мөмкин, чөнки аны гамәлгә кую өчен рәсми фатиха 1905 елның 4 гыйнварында гына алына. Гәзитнең мөхәррире һәм нашире—татарча гына түгел, урыс телендә дә чыккан күп гәзит-журналларның башында торучы талантлы журналист К.Мотыйгый-Төхфәтуллин була.

1905 елның 11 декабрендә С.-Петербургта Русиядәге дүртенче татар басмасы (башкалада—икенче)—"Өлфәт" гәзите барлыкка килә. Мөхәррирлек һәм наширлек вазифасын күренекле жәмәгать хадиме Габдерәшит Ибраһимов (Рәшит казый) үти.

Димәк, 1905 ел ахырында татар матбугатын С.-Петербургта, Казанда һәм Жаекта гамәлдә булган дүрт басма тәшкил итә. Моннан дүрт ай гына элек берниндиі гәзит тә булмавын искә алсаң, бу—бик зур казаныш, билгеле. Әлеге басмалар мәгърифәткә, белемгә, алдынгы мәдәниятkә омтылган милләтнең ижтимагый-сәяси тормышында яңа дәвер ачты, дисәк, бу һич тә арттыру булмас.

Әмма Россия империясендә туган телдә укый-яза белү жәһәтеннән иң алдынгы урыннарның берсен биләгән (80 процент тирәсе) халыкның үз милли матбугатына ихтыяжы да гаять зур була. Нәтижәдә, 1906 ел матбугат үсешендә яңа бер дулкын тудыра, татар журналистикасында мона кадәр күрелмәгән күтәрелеш күзәтелә, ягъни 16 яңа басма барлыкка килә. 15 гыйнварда Жаекта чыга башлаган беренче татар әдәби һәм ижтимагый-сәяси, алда телгә алынган "Әлгасрел-жәдид" журналына шул ук каланың "Уклар", Казанның—"Йолдыз", "Азат", "Бәянелхак", "Әддин вә әл-әдәб", "Таң йолдызы", "Азат халык", "Таң мәжмугасы", Оренбургның—"Вакыт", "Чикерткә", "Чүкеч", "Карчыга", "Дөнья вә мәгыйшәт", "Әстерханның—"Борһаны тәрәккый", Уфаның—"Әл-галәми-әл-ислами" гәзит-журналлары өстәлә. Шулай итеп, 1905-1906 елларда инде егерме исемдәге басма мәйдан тота (Казанда—8, Оренбургта—5, Жаекта—3, С.-Петербургта—2, Әстерханда һәм Уфада—берәр).



1907 елда матбугат үзенең үсешендә янә үрләр яулый, 13 яңа басма: Казанда—"Тавыш", "Әхбар", "Әл-ислах", Әстерханда—"Ислах", "Хәмият", "Туп", "Идел", Оренбургта—"Урал", "Яз", С.-Петербургта—"Дума", "Нәжат", "Мәскәүдә—"Тәрбияиәтфаль", Жаекта—"Яңа тормыш" гәзит-журналлары эшчәнлек жәелдерә. Дөрес, бу вакытта узган елларда барлыкка килгән кайбер басмалар төрле сәбәпләр аркасында ( полиция эзәрлекләве, цензура кысымы, матди яктан мохтажлык һ.б.) ябыла ("Таң йолдызы", "Азат", "Азат халык" һ.б.), ә кайберләре исемнәрен үзгәртә ("Тавыш", "Таң мәжмугасы"). Шулай да 1907 елда мәмләкәтнең жиде шәһәрендә 28 татар басмасы (18 гәзит һәм 10 журнал) чыгуын дәвам итә.

Мәгълүм инде, татар җәмәгатьчелеге үз матбугаты барлыкка килүне зур күтәренкелек белән каршы ала. Гәзит-журнал редакцияләренә, мөхәррирләренә төрле эчтәлектәге хатлар ява. Аларның географиясе шулкадәр киң була ки, төрле жанрлардагы язмаларын юлламаган бер генә татар төбәге дә калмый диярлек. Һәм бу табигый да. Гыйбрәтле-фаҗигале тарихында күпне кичергән халык, үз матбугатына язу мөмкинлеге алгач, күңелендә ургыган хисләре һәм омтылышлары белән уртаклашырга ашыга. Халыкның хатлары барысын да— милли мәсьәләләрне, тел, дин, мәдәният, мәгърифәт, тарих, икътисад, сәясәтне, кыскасы, рухи һәм матди хәятнең һәммә якларын да үз эченә ала. Гәзит-журналлар укучыларның активлыгын хуплый, аларны җанлы иҗтимагый тормышка өнди.




"Язының, бичара, мазлум милләт угыллары, язының,—ди, мәсәлән, "Фикер" гәзите.—Бу хакта сезнең морадларыңызга "Фикер" гәзитәсеннән бик зур ярдәмче табарсыз"[1].

Әлеге процесс рус җәмәгатьчелегенең дә алдынгы өлешен кызыксындыра. Ул татар җәмгыятендәге яңа күренешкә унай бәя бирә һәм патша хөкүмәтенең реакцион сәясәтен гаепләп чыга. 1906 елда "Волжский вестник" гәзите (Казан) болай дип яза: "Ике ел элек Россиядә бер мөселман гәзите бар иде *("Тәрҗеман" күздә тотыла.—Р.Ә.)*, ә хәзер алар 20. Мөселманнарның басма сүзгә ихтыяҗы нинди зур икәнлеген шушыннан да күрергә мөмкин! Ә бит рус хөкүмәте шушы ихтыяҗны канәгатьләндерергә ни гомер комачаулап килде"[2]. Милли матбугатның кызу һәм унышлы үсүенә шул ук елда Казан гәзите "Волжский курьер" да игътибар итә: "Ел башында биш гәзит чыгаручы татар үзәге Казан турында әйтеп тә тормастан, кечкенә генә өяз шәһәрчекләрендә дә ... яңгырдан соң баш калкыткан гөмбәләр төсле, күп санлы гәзитләр барлыкка килде"[3].



1908-1916 елларда татар матбугаты үзенең иң унышлы, өлгергәнлек чорын кичерә, дип бәяләргә мөмкин. Инкыйлаб шартларында барлыкка килгән матбугат өчен сабыйларча куану хисләре, үзенчәлекле күтәрелеш ("эйфория") дулкыннары инде сизелерлек төстә сүрелә. Бу хасиятләр матбугатның тормыштагы урынына төпле, басынкы мөнәсәбәт белән алышына. Җәмгыятьтә милли гәзит-журналларга шәхси мин-минлекне раслауга хезмәт иткән көрәш мәйданы, үзмаксат итеп кенә түгел, ә бәлки җитди интеллектуаль көч, социаль әһәмияткә ия булган һәм җәмгыятьнең төрле катламнарына зур йогынты ясаучы куәтле пропаганда коралы итеп карый башлыйлар. Бу чорларда милләтнең гомуми проблемаларын (тормыш дәрәҗәсе, прогресс, мәдәни янарыш, дингә мөнәсәбәт, милләтләр бердәмлегендә үз урыныңны ачыклау һ.б.) тәфтиш кылуга торган саен күбрәк урын бирелә. 1908-1916 елларда туган һәм гамәлдә булган иң әһәмиятле басмалардан беренче нәүбәттә "Шура", "Яшен", "Ялт-йолт", "Кояш", "Аң", "Тормыш", "Ак юл", "Сөембикә", "Ил", "Сүз" һ.б. гәзит-журналларны күрсәтергә кирәк. Реакция еллары, алдынгы басмаларга тискәре караш, империя көчләренең "панисламизм" эше карачкылар белән туктаусыз басым ясавы татар җәмәгатьчелеге өстендә "Дамокл кылычы" булып торса да, милли басма сүз үзенең бәрәкәтле йогынтысын дәвам итә, халыкны туплаучы, ә иҗат интеллигенциясе вәкилләрен тартып торучы "магнит"ка әверелә.

1917 ел татар матбугаты өчен сыйфат һәм сан ягыннан бөтенләй яңа чор тәшкил итә. Бу ел шактый "бәрәкәтле" 1906-1907 еллар колачын да узып китә, иҗади көчләрнең публицистлык активлыгында чын мәгънәсендә "шартлау" тудыра.

[1] Фикер, 1906, 12 март.

[2] Волжский вестник, 1906, 8 февраля.

[3] Волжский курьер, 1906, 6 октября.

Әлбәттә, әлеге күренеш яна демократик Россия тууын хәбәр иткән Февраль инкыйлабы казанышлары белән тыгыз бәйле. Берничә ай дәвамында Россия җиһанның иң демократик иле булып ала. Шушы чорда татарча ким дигәндә 35 басма үзенең дөньяга килүен хәбәр итә. Бу санны "тыныч" революция алды еллары белән чагыштырырлык та түгел. Яңа басмалардан иң тирән эз калдырганнары "Ил", "Ирек", "Аваз", "Кызыл байрак", "Корылтай", "Безнең юл", "Безнең тавыш" кебек гәзитләр була. Әүвәлдән чыгып килгәннәрен дә өстәсәк, 1917 ел дәвамында, тулы булмаган мәгълүматлар буенча, барлыгы 50ләп басма нәшер ителә, шуларның 14ен журналлар тәшкил итә.




Октябрь түнтәрешенә кадәрге елларда татар матбугатына, сан ягыннан караганда, өч текә биеклек (пик) хас: 1907 елда—28, 1914 елда—25, 1917 елда—50 исемдәге татарча гәзит-журнал эшчәнлек җәелдерә. Сәнгатьчәрәк итеп әйткәндә, 1907 елда татар матбугаты—Эльбрус биеклегенә, 1914 елда—Монбланга, 1917 елда—Эверестка күтәрелде, дияргә мөмкин.

Шунысына аерым басым ясарга кирәк: Россиянең иксез-чиксез киңлекләренә таралган татарларның (сан ягыннан рус, украин, поляк, белорус, яһүд һәм казакълардан кала, жиденче урында) матбугат органнары да географик җәһәттән шактый киң таралыш таба. Гәзит һәм журналлар ике башкала һәм эре губерна шәһәрләрендә генә түгел (С.-Петербург, Мәскәү, Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Самара, Томск, Семипалат, Сарытау, Сембер, ә кечерәк үзәкләрдә (Җаек, Петропавел, Ташкент, Хуканд), хәтта өяз шәһәрләрендә дә (Троицк, Минзәлә) чыгып килә. Тулы булмаган мәгълүматлар буенча, 1905-1917 елларда Казанда—29 матбугат органы (шуларның 11е—журнал), Оренбургта—15 (10), Уфада—14 (5), Әстерханда—13 (4), Җаекта—6 (2), С.-Петербургта—6 (1), Мәскәүдә—6 (1), Троицкида—2 (1), Петропавелда 2 (0), Ташкентта 2 (0), Самарада—1 журнал, Минзәләдә, Семипалатта, Хукандта, Сарытауда, Сембердә—берәр гәзит нәшер ителә. Һәм бу—1905 елның сентябренә чаклы сыңар вакытлы матбугаты да булмаган халыкта! Мәмләкәтнең 17 каласында төрле елларда һәм төрле вакытларда ким дигәндә 120 гәзит һәм журнал дөньяга чыга. Бу татар милләтенең һәр 18 мең кешесенә уртача бер басма туры килгән, дигән сүз. Үз чоры өчен шактый югары күрсәткеч!

Татар вакытлы матбугаты туган көненнән башлап профессиональ рух белән сугарыла, мәдәни-иҗтимагый интересларының күпкырлылыгы белән таныла. Басмаларның төп өлеше иҗтимагый-сәяси юнәлеш алса да, байтагы аерым бер "һөнәри" мәсләкне кыйбла итә. Мондыйлардан хронология җәһәтеннән дини басмалар алга чыга. Әйтик, 1906 елда гына да өч дини матбугат органы эшчәнлек җәелдерә ("Әддин вә әл-әдәп", "Әл-галәми-әл-ислами", "Дөнья вә мәгыйшәт"), бераз соңрак "Мәгълүматы мәхкәмәи шәргыяи Орынбургия" (1908) һәм "Мәгълүматы җәдидә" (1911) мәйдан тота.

Һәҗүи (сатирик) матбугатның колачы тагын да зур була. 1906 елда ук "Чикерткә", "Уклар", "Чүкеч", "Карчыга" журналлары дөньяга килә, аннары аларга "Туп", "Яз", "Яшен" кебек басмалар өстәлә, соңрак бу кыска гомерле ("Чүкеч"тән кала) органнарга "Ялт-йолт", "Акмулла", "Кармак" алмашка килә.

Татар җәмгыяте тормышында күренекле урынны шулай ук махсус шәкертләр гәзите, мәгарифи-педагогик басмалар били. Башта кульъязма, җилем басма рәвешендә тәрәккый тапкан бу органнар 1905-1907 еллардан соң рәсми төстә шәкелләшә ("Әл-Ислах", "Тәрбия", "Мәктәп", "Мөгаллим" һ.б.).

Сабыйлар гына түгел, бөтен татар халкының иҗтимагый хәятында да сизелерлек рольне балалар журналлары уйный ("Тәрбияи-этфаль", "Ак юл", "Балалар дөньясы").

Россия җәмгыятенең житештерү, сәүдә, кәсәбәчелек юнәлешендә үсеш алуы татар дөньясында да тәэсирсез калмый, аерым алганда, шушы закончалыкны чагылдырган һәм проблемаларны киң планда "кабыргасы белән" куйган рәсемле

журналлар нәшер ителәә ("Икътисад", "Игъланат", "Уфаның авыл көнкүреше журналы", "Уфа кооператоры", "Русия сәүдәсе"). Татар эшмәкәрләренең икътисади һәм хокукый мәнфәгатьләрен "Хокук вә хәят" журналы да тоемларга һәм якларга тиеш була.

Татар иҗтимагый фикеренең олуг казанышы буларак беренче хатын-кыз журналлары ("Сөембикә", "Азат ханым" һ.б.) вөҗүдкә килә. Махсус хатын-кыз басмалары нәшер итү—тәрәккыйпәрвәр зыялыларның хатын-кызларны азат итү, аларны актив җәмгыять тормышына алып керү юнәлешендә бәрәкәтле эшчәнлегенең ачык чагылышы ул.

Әлбәттә, 1905-1917 елларда гамәлдә булган татар матбугаты, Россиядәге башка барлык телләрдәге басма органнар төсле үк, бихисап сәяси вә иҗтимагый төркемнәргә бүленеп эш итә. Бу җәһәттән йөзләгән исемдәге гәзит-журналлары булган татар җәмгыятендә дә, әйтик, социал-демократларга, эсерларга, трудовикларга, кадетларга яисә октябристларга һ.б. фиркаләргә ияргән, мәсләкләргә мәел куйган органнарны санап үтәргә мөмкин. Бу гамәл артык киң урын алачак булганлыктан, без биредә әлеге мәсьәләгә тукталып тормыйбыз, фәкать ул чордагы татар матбугатында нинди гомуми агымнар хөкем сөргәнен генә искәртеп китәбез. Ул агымнар, безнең карашыбызча, түбәндәге: социал-демократик, революцион-демократик, радикаль-демократик, либераль-демократик, либераль-буржуаз, уртача (умеренно)-консерватив, консерватив (дини-монархистик), милли-патриотик, хәрбимилләтчел, милли-дини юнәлешләрдән гыйбарәт.

Шунысын аерым басым ясап әйтергә кирәк, татар милли вакытлы матбугаты, нинди генә юнәлештә булуына карамастан, үзенең бөтен яшәү дәверендә хакимият, цензура, полиция, жандармерия һәм башка кара көчләр тарафыннан туктаусыз эзәрлекләнә, шуның нәтиҗәсендә күп басмаларның исемнәре үзгәрә, "төсләре" уңа, егәре кими, ә бик күбесе гомумән сүнеп яки ябылып, мөхәррирләре хөкемгә тартыла. Әлеге тема шул кадәр зур ки, аның үзенә генә дә аерым хезмәт багышларга мөмкин[1].

Табигый ки, татар зыялыларының тиңдәшсез фидакярлеге һәм һиммәте аркасында вөҗүдкә килгән гәзит-журналлар иң беренче нәүбәттә татар милләте мәнфәгатьләрен алга сөрә. Октябрь түнтәрешенәчә булган 13 ел эчендә матбугат татар тормышының бөтен күзәнәкләренә үтеп керә, милләтнең ни белән сулаганын, нинди уй-фикерләр белән янып яшәвен энәсеннән җебенә кадәр тикшерә. Татар басмаларының инкыйлаб нәтиҗәсендә һәм шартларында гына мәйданга килүе аларның әүвәлдән үк нигездә алгарыш, гомуми һәм милли тәрәккыят идеясе белән сугарылуын билгели. "Хөр Русиянең хөр гражданнары булып калу" шигаре заман тарафыннан көн тәртибенә куелган таләпләрнең беренчеләреннән була һәм 1905-1907 елларда милли матбугат битләреннән төшми.

Әлбәттә, көтелмәгән борылышларга бай, катлаулы сәяси-иҗтимагый вазгыятьләргә тап булган гәзит-журналлар үз үсешләрендә байтак үзгәрешләр кичерә, гомуми һәм милли кыйблалары алмашынып тора, тора-бара, аеруча 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соң милләтнең үзбилгеләнү мәсьәләсендә төрле яна идеяләрне, мәсләкләрне байрак итә ("унитарчылык", "федеральчылык", "тупраклы" яисә "милли-мәдәни" мохтарият" һ.б.). Әмма шунысы бәхәссез: үзенең беренче адымнарыннан ук матбугат милләт проблемаларын төбеннән җигелеп тартучы "йөк аты"на әверелә. Аның битләрендә (беренче чиратта милли кисаларда) чорының иң өлгергән һәм кичектергесез хәл ителергә тиешле мәсьәләләре күтәрелә вә аларны чишүнең үтемле ысуллары күрсәтелә. Болар хисабына милләтне инкыйраздан коткару, татарның дәүләтен һәм дәүләтчелеген кайтару, дин-иманны, телне саклау, мәктәп-мәдрәсәләрне ислях кылу, мәдәниятнең барлык төрләрен, шул җөмләдән, әдәбиятны һәм сәнгатьне үстерү, мөфти сайлау, милләт аналары тәрбияләү, өметле киләчәккә ия яна буын әзерләү һ.б. керә. Аяусыз колониаль изү шартларында яшәгән халыкныкы булуына карамастан, матбугат әлеге темаларны гаҗәп эзлекле, әтрафлы күтәрүе белән тарихта тиңдәше булмаган рухи һәм

---

[1] Бу хакта тәфсиллерәк мәгълүматны безнең түбәндәге хезмәтләрдән алырга мөмкин: Хаклык даулап, ирек яулап. – Ялкын, 1975, № 7; Вакытлы матбугат һәм цензура. – Казан утлары, 1977, № 1; Татарская демократическая печать (1905–1907 гг.). – М., Наука, 1988.

мәдәни янарышка, хәтта ки, ыргылышка нигез сала. Гәзит-журналларнын бу хосусиятләрен тәфсиллерәк тасвир кылу өчен берничә томнан гыйбарәт фәнни хезмәт язарга кирәк булыр иде.

Беренче нәүбәттә мәмләкәттәге татар милләте мәнфәгатьләрен күз унында тотып оештырылса һәм гамәл кылса да, матбугат илдәге башка, бигрәк тә мөселман, төрки халыклар интересын да даимән яклый. Гомумән алганда, 1905-1917 елгы гәзит-журналларда аерым бер "татар" төшенчәсе генә өстенлек итми. Еш кына очракларда кавеми-этник һәм дини принциплар беркадәр "укмаштырылып", кирәк асыл татарлар, кирәк башка төрки халыклар (аерым очракларда ислам динендәге бүтән халыклар) өчен дә "төрки-татарлар", "төрекләр" ("төркиләр" түгел!), ә күбесенчә исә "мөселманнар" тәгъбире уртак бер атама булып йөри. Ул гына да түгел, Казаннын татар матбугаты үзе дә милләттәшләрен "мөселман" категориясенә кертеп язудан беркайчан да тайчынмый[1].

Бу чорларда милләтнең үзенчәлеклелеге (самобытность), үзатамасы мәсьәләсендә төрле карашлар хөкем сөрсә дә, "төркилек", "гомумтөркилек" идеясе дә үзәк урыннарның берсен били. "Шура" журналы бөтен татар дөньясында киң яңгыраш тапкан "Төрекме? Татармы?" дигән темага хәтта җитди бәхәс тә оештыра. Төрекчелек идеясен баштан ук кызу алга сөргән Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, С.Максуди, Й.Акчура һәм башка олпат әһелләргә соңрак Г.Исхакый кебек мәшһүр шәхесләр дә килеп кушыла. Мәскәүдә 1917 елда нәшер ителгән "Ил" гәзитендә, мәсәлән, Г.Исхакый "Төрексең!" исемле зур мәкалә белән чыгыш ясый, анда кавемдәшләренә хитабән мондый оран сала: "Син берсең, төрексең, утыз миллионлы шәүкәтсең, бәхтияр булырсың, берләш!"

Татар җәмгыятендә төрле дәверләрдә нинди генә караш-фикерләр яшәп килсә дә, төрки халыкларның кардәшлеге, берлеге, кыйблалар уртаклыгы матбугатта һәрвакыт диярлек алгы планга куелып килә. Татар гәзит-журналлары тугандаш төрки кавемнәр, аларның тормыш-мәгыйшәте, тәрәккыяте хакында ифрат күп яза. Шуның белән бергә әлеге басмаларда башкорт, комык, әзәрбәйҗан, кыргыз, ул вакыттагы атамалары әле башкачарак яңгыраган үзбәк, казакъ һ.б. халык зыялыларының катнашуы гадәти күренешләрдән санала. Әйтик, Җаекта 1905-1907 елларда чыгып килгән "Фикер", "Әлгасрел-җәдид" гәзит-журналларында казакъ эшлеклеләренең үз милләтләре мәнфәгатьләрен яклап язган казакъча материаллары басыла. С.-Петербургта 1907 елда нәшер ителгән "Дума" гәзитендә әзәрбәйҗан бүлеге алып барыла (З.Зәйналов), Әстерханда 1906-1911 елларда бер-берсенең дәвамы буларак эшләп килгән "Борһаны тәрәккый", "Хәмият", "Мизан", "Хак" гәзитләре (оештыручысы М.-Л.Исмәгыйлов-Ширванский), төрле төрки халык вәкилләренә урын биреп кенә калмый, бәлки гомумән татар һәм "госманлы" телләрендә эшли. Бу җәһәттән татар матбугаты милләтнең "эчке" этник төркемнәрен генә түгел, бәлки Россиядәге барлык төрки кавемнәрне мәгънәви яктан берләштерергә омтылышы белән дә танылa.

"Татар вакытлы матбугаты һәм Төркия"—үзенә бер зур һәм мөстәкыйль тема. 1905 елдан 1917 елга чаклы татарча гәзит-журналларда Төркия хакындагы гаҗәеп кинкырлы язмаларны тупласаң, мөгаен, бөтен бер "Төрек энциклопедиясе" килеп чыгар иде. XIX гасырда ук Шәрекъ (өлешчә) вә Гаребнең (тулаем диярлек) алдынгы мәдәнияте үрнәкләре белән барыннан да бигрәк төрек әдәбияты һәм китаплары аркылы таныш булган татар җәмәгатьчелеге, көндәлек матбугаты туу сәгатеннән үк традиция буенча Төркиягә ихлас куя башлый. Бу илтифатның сәбәпләре байтак: дин берлеге, төрки кардәшлек, тарихи уртак язмыш, мәдәни казанышлар һ.б. Ә инде Төркиянең барлык мөселманнарның хәлифлек үзәге, җиһанда бердәнбер мөстәкыйль, куәтле төрки дәүләт булуы—Истанбулга күңел куелуның төп сызыгын билгели. Татар матбугатында Төркиянең икътисади, хәрби хәле, гомуми сәясәте, дипломатик мөнәсәбәте, дөнья халыклары берлегендә биләгән урыны, яшь төрекләр хәрәкәте, солтан Габделхәмид язмышы, 1908 елгы инкыйлаб, шуннан соңгы ислахат һ.б. турында язылган материаллар татар җәмәгатьчелегенең еллар дәвамында Төркия әхвале белән гаять кызыксынып яшәвен шәрехли.

[1] Әлеге атаманың активлашуы үзе бер тема, шуңа күрә биредә аңа тукталып тормыйбыз.

Шунысы мөһим, 1911 елда кабынган итальян-төрек, 1912 елда куәт алган Балкан, 1914 елда Төркия катнашында да җәелгән бөтендөнья сугышы исә татарның бу мәмләкәт язмышын үз язмышы, төрек фаҗигасен үз фаҗигасе белән тәңгәлләштерүен күрсәтә. Татар дөньясының Төркия катнашкан сугыш хәрәкәтенә сүрелмәс игътибар бирүенең бер мисалы шул, милләтнең иң абруйлы вә киң таралган газитләре "Йолдыз" һәм "Вакыт" Аурупаның сугыш сәхнәсенә үзләренең иң күренекле каләм әһелләрен, Г.Камал белән Ф.Кәримине җибәрә. Бу ике мөхәррир Төркиянең хәрби, икътисади хәяты, киләчәк язмышы хакында үз газитләрендә берсеннән-берсе тәфсилле язмалар биреп бара. Алай гына да түгел, аларны бер системага салып, мөкәммәл публицистик әсәр дәрәҗәсенә күтәрә. Әйтик, Төркия әхваленнән бөтен бер профессиональ күзәтү, сәяси-иҗтимагый тезмә тәшкил иткән "Истанбул мәктүпләре"н Ф.Кәрими "Вакыт" газитендә генә бастырып калмый, бәлки зур күләмле аерым бер китап итеп тә нәшер итә.

Төркиягә игътибар ин тыныч һәм игелекле һөнәр—тиҗарәт-сәүдә мәсьәләсендә дә сүрелми. Мәсәлән, Казанда 1909 елда гамәлгә куелган "Игъланат", газит үзе белдергәнчә, "Русия вә Төркия мөселман сәүдәсенә васита улмак өчен" чыгарыла һәм бу шөгыльнең әһәмиятен арттыру максатында "һәфтәдә 1-3 мәртәбә буш" таратыла.

Гомумән алганда, татар вакытлы матбугаты, Россия хөкүмәтенең бу эшкә үтә кырын карашын һәр адымда тоеп килсә дә, Төркиягә карата үзенең самими тойгыларын яшерми, халыкта да шул рухның җирләшүенә вә ныгуына хезмәт итә.

XX гасыр башы шартларында татар матбугатында төркичелек мәсьәләсе табигый төстә исламчылык факторы белән дә үрелеп бара. Ул чорларда, борынгыдан килгән күчемчелек билгесе буларак, кавеми һәм дини бердәйлек бер тәнкәнең "күн" вә "иләк" ягы төслерәк кабул ителә. Шуна нисбәтән, милли газит-журналлар (махсус дини басмалар өстенә) дин, иман, вөҗдан иреге, исламның Россия шартларындагы халәте мәсьәләләрен киң күтәрә, Мөхәммәд өммәтенә, дине исламга төрле көчләр тарафыннан әледән-әле ясалып торган һөҗүмнәргә, кыерсытуларга нәфрәтен белдерә. Мондый яссылыктагы язмалар традицион ислам мәмләкәтләре тарихы, аларның бүгенге әхвален тасвирлау белән бәйләнеш таба. Матбугатта "ислам бишеге" булган Мәккәи-Мөкәррәмә, Мәдинәи-Мөнәүвәрә, шулай ук Мисыр, Марокко, Палестина, Эфиопия, Триполи, Сурия, Иран, Гыйрак һ.б. ислам мәркәзләре, дәүләтләр хакында бай мәгълүмат бирелә, ислам дөньясының һәм Шәрекънең бөек фикер ияләре вә асыл затларына (ибне Фазлан, ибне Сина, ибне Рөшед, ибне Баттута, ибне Гарәпшаһ, ибне Хәлдун, Нәваи, Хәйям, Хәмәви, Физули, Фараби, Низами, Ширази, Истахри, Бируни, Аристотель, Платон, Пифагор һ.б.) бөтен бер тезмәләр багышлана, кылган гамәлләре төрле каләм осталары һиммәте белән киң яңгыраш ала.

Төркичелек һәм исламчылык проблемаларына чыннан да иркен мәйдан биргән татар матбугаты бу яктан рус хөкүмәтенең, һәммә кара көчләрнең ачы каһәренә юлыга. Мәсьәләне күпертеп, аннан тиешле максатларда махсус карачкы ясап, самодержавие яна шәкелдәге күсәк сәясәтен эшкә җигә, дәүләт дәрәҗәсендә "панисламизм" вә "пантюркизм" күренеше белән көрәш оештыра. Фәкать йодрык селкү һәрвакыттагыча "зарур" юнәлештә ясалмый, барлык камчылау кампаниясе бер какшамас идеягә—бөекмәмләкәтчелек, панславизм, православие тантанасы идеясенә генә хезмәт итә.

Кыерсыту шаукымының урынсыз икәнлеге бигрәк тә түбәндәге мисаллардан ачык күренә: Русия җирлегендә тәрәккый тапкан татар газит-журналлары эчке ватанның да барлык проблемаларын колачлый. Бу фасылдагы язмалар үзләренең даимилеге, күплеге, саллылыгы, фактик яктан байлыгы белән тикшеренүчеләрне бүгенгечә хәйран калдыра. Татар матбугаты яшәешенең буеннан-буена Русия тарихы, географиясе, халкы, сәнагате, авыл хуҗалыгы, илнең яшәеш үзенчәлеге мәсьәләләрен күтәрә, рус мәдәниятен исә XVII гасыр уртасыннан алып XX гасыр башларынча профессиональ-публицистик, әдәби күзлектән карап күзәтә[1]. Татар газит-журналларыннан, аерым алганда, рус әдәбияты һәм дини-фәлсәфи фикер

[1] Татар матбугатында рус мәдәнияте мәсьәләләре безнең 2002 елда дөнья күргән "Татарская дореволюционная пресса (в контексте "Восток–Запад") дигән монографиябездә этрафлы тикшерелгән.

тарихы, чәчмә әдәбият һәм публицистика, шигърият, драматургия һәм театр, музыка һәм сынлы сәнгать, музей, күргәзмә, мигъмария һәйкәлләре, халык мәгарифе, урта һәм югары мәктәп, фән һәм гыйлем дөньясы, техника казанышлары, уйлап табулар, фәнни ачышлар һ.б. хакында гаҗәеп бай мәгълүмат алырга мөмкин. Татар матбугатында, теге яки бу унай белән, киң җәмәгатьчелеккә азмы-күпме мәгълүм булган бер генә рус фикер иясе, әдибе, шагыйре, галиме, җәмәгать эшлеклесенең исеме теркәлми калмагандыр, мөгаен. Гәзит-журналларда мәшһүр затларның биниһая озын исемлегендә түбәндәге шәхесләр алдынгы урыннарны били: Полоцкий, Яворский, Прокопович, Посошков, Кантемир, Ломоносов, Лобачевский, Аксаков, Пушкин, Гоголь, Белинский, Лермонтов, Тургенев, Толстой, Гончаров, Чернышевский, Добролюбов, Писарев, Куприн, Андреев, Горький, Менделеев, Петровский, Ковалевский, Мечников, Репин, Шаляпин һ.б. Хәтта шушы йолдызлыкны да, йөзек кашы сыман, гуманист, акыл иясе, җәмәгать хадиме, гаҗәеп сүз остасы, XIX гасырның икенче яртысы, XX гасыр башының гадәттән тыш күренеше—Лев Николаевич Толстой бизи.

Басым ясап әйтергә тиештер ки, татар басма сүзе, мәһабәт вә гали күренеш буларак, милли йомыклык, үз кабыгына бикләнгәнлек кебек сыйфатларны, гомумән, белми. Киресенчә, киң төрек, ислам дөньясы, гомумроссия кысаларыннан тыш, Аурупа, Америка, Азия, дөнья күләмендәге тормышчан, алгарыш мәсьәләләрен дә үзәккә куя. Татар матбугаты үзенең "тумышы" буенча төрки вә ислам дөньясы җимеше булган килеш, һәм географик һәм рухи җәһәттән ике бөек цивилизация "ялганыш"ында ат уйнаткан мөһим институт ул. Ул гына да түгел, милли басмалар бөтен кешелек тарафыннан тәкъдир ителгән Гареб вә Шәрекъ мәдәниятләрен үзенчәлекле төстә тоташтыручы затлы күпер вазифасын да үти. Гәзит-журнал битләрендә милләт, төркичелек, ислам дөньясы, Русия турындагы язмаларга берниндидә кысынкылык китермичә, иркен сулыш белән Германия, Швейцария, Франция, Италия, Швеция, Испания, АКШ, Кытай, Һиндстан, Япония вә башка бик күп дәүләтләр, шәһәрләр, хәтта ки кыйтгалар, алардагы матди һәм мәдәни тормыш хакында берсеннән-берсе гыйбрәтле, кызыктыргыч материаллар урын ала. Бу закончалык бигрәк тә гомумкешелек цивилизациясенә зур өлеш керткән шәхесләр үрнәгендә ачык гәүдәләнеш таба. Бер "Шура" журналында гына да "Мәшһүр адәмнәр вә бөек хадисләр" дигән бүлектә Аристотель, Платон, Һеракл, Лютер, Эдисон, Спенсер, Бэкон, Декарт, Нобеле, Руссо, Һете, Тагор һ.б. бик күпләр хакында бай эчтәлекле мәгълүматлар бирелгән, алар мисалында Көнбатыш вә дөнья цивилизациясенең югары казанышлары пропагандаланган.

* * *

Шулай итеп, 1905-1917 еллардагы милли матбугатны җентекләп өйрәнү—татар халкы XX гасыр башында да әле рухи һәм зиһни яктан фәкыйрь, кавеми җәһәттән чикләнгән, йомыклык тышауларында чәбәләнгән, фәкать дин вә миллият кысаларында гына гамәл йөрткән дигән сафсата-уйдырмаларны фаш итә, татар халкының, Шәрекъ вә ислам дөньясыннан читләшмәгән килеш, Аурупа, хәтта ки дөнья цивилизациясенә йөз тотуын, рус мәдәниятен дә тирән кызыксыну белән өйрәнүен, тәрәккыят юлында һәртөрле алдынгы мирастан иҗади файдалануын, халыкара сәхнәгә торган саен ныграк, кыюрак адымнар белән аяк басуын күрсәтә.

Әйе, татар көндәлек басмасы үзенең тәрәккыятендә сизелерлек казанышларга ирешкән милләтнең эчке үсеше һәм иҗтимагый-интеллектуаль яктан үз-үзен расларга омтылу ихтыяҗыннан туган. Халыкның этник үзәкләрендә барлыкка килгән матбугат асылда милләтне рухи яктан берләштереп, аңа хезмәт итүче инструментка әйләнә. Россия империясендә татарлар аеруча таралган-бүлгәләнгән кавемнәрнең берсе булганга, гәзит вә журналлар аерым этник төркемнәрне дә үзара бәйләндыручы көч хасил итә. Татар халкы мәмләкәтнең үзәк өлкәләрендә яшәсенме, ерак вилаятләрдә гомер кичерсенме—матбугат аларны күпмедер дәрәҗәдә тигезли, рухи ихтыяҗларын беректереп, аларга төрле төбәкләрдәге милли җәмгыятьләр турында өлгер-оператив хәбәрләрне ирештереп тора. Наширлек географиясенең кинлеге

һәм матбугатның Россиядәге күп шәһәр-авылларына таралуы тагын бер тапкыр шуны раслый: туган телдәге басма-публицистик сүз кебек рухландыргыч күренешкә милли мәдәниятнең озак еллар дәвамында аңлы рәвештә томаланып килүе генә монархы таралырга, ишетелергә ирек бирмәгән.

Житәкчеләренең күпчелеге (Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, Һ.Максуди, К.Мотыйгый-Төхфәтуллин, Г.Исхакый, М.Ф.Туктаров, Г.Камал, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, С.Рәмиев һ.б.) югары дәрәҗәле, зыялы гуманистлардан торган матбугат эшчәнлеге башлыча гомумкешелек кыйммәтләре һәм гражданлык нигезендә алып барыла. Матбугат үзгәртеп кору өчен көрәшә, җәмгыятьнең чорга лаеклы мәдәният тудырырга омтылучы көчләренә тугры юлдаш һәм шул ук вакытта киң иҗади мәйдан буларак хезмәт итә.

Дөнья цивилизациясенең матди вә мәдәни казанышларын даими үзләштереп, яктыртып һәм популярлаштырып барган матбугат йогынтысында, халыкның үз арасыннан аның хыялларын, уй-теләкләрен чагылдыручы яңа катлау зыялылар буыны үсеп чыга. 1905-1917 еллардагы татар матбугаты милли тарих кысаларында гына түгел, XX гасыр башы төрки, ислам, Россия, дөнья гарәби язмасы тарихында да үзенчәлекле күренеш буларак тикшерелергә хаклы.

Шунысы да игътибарга лаек: "гәзит-укучы-гәзит" дигән гыйбрәтле система матбугат эшчәнлегенең буеннан-буена тоткарлыксыз хезмәт итә, ныклыгын җуймый—алдынгы басмаларның рухи дәрәҗәсен, иҗтимагый мәртәбәсен үстерә бара. Үткәннәрдән башка киләчәк юк. Бу очракта ерак еллар куенында калган татар матбугаты тарихына күз ташлау—бүгенгене аңлау һәм киләчәккә сабак буларак, бигрәк тә әһәмиятле. Әгәр дә сүз Россия халыклары язмышында кискен борылыш елларына туры килгән мирасны өйрәнү һәм бәяләү турында бара икән—бигрәк тә.

---

*Мең санның бер чаткысы*



2006 ЕЛНЫҢ ФЕВРАЛЕНДӘ
ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 1000 нче САНЫ ДӨНЬЯ КҮРӘ

## МӘДӘНИ ФРОНТТА

**Татар тормышыннан кино-картиналар**

Таткино Татарстан Мәгариф халык комиссариатының Гыйльми үзәге житәкчелеге астында татар тормышыннан кино-картиналар чыгару эшенә керешге. Беренче татар кино-картинасы өчен маузуг 1905-1917 нче еллар вакыйгаларыннан алыну тиеш табылды. Хәзер бу эшне булдыру чарасына керешелде.

**Тюркология съезды**

Бу хакта гәзитләрдә хәбәр булган иде. Татарстанның соравы буенча, съезд 1925 нче елның 30 дикәберенә кичектерелде. Татар Җөмһүриятеннән барлыгы 7-8 вәкил барачак.

**Татар-башкорт мәгариф эшчеләренең III-нче съезды**

Җөмһүриятләргә кермәгән татар-башкорт халкының мәгариф эшләрен башкаручы Үзәк татар-башкорт бүлеге тарафыннан III-нче съезд чакырыла. Съезд дикәбер 17 сенә билгеләнгән. Съездга Татарстаннан 3 вәкил барачак.

*("Безнен юл".–1925.–N: 9-10).*

Гәп Фән

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***МӨҺАҖИР*** *г.* — Читкә күчеп китүче, эмигрант; качак. // *Әлмөһаҗир* — Мөхәммәд Пәйгамбәр белән бергә Йасрибкә (Мәдинә шәһәренә) күчеп китүче. *Мөһаҗир фи сәбилиллаһ* — Аллаһ юлы өчен күчеп китүче. Чыганакларда бу сүз хәзерге заман эмигрантларына карата да кулланыла: *"Азат Шәрык" — Берлинда 1923 елда татар мөһаҗирләре тарафыннан чыгарылган иҗтимагый-сәяси журнал".*

Күплек саны шәкеле: *мөһаҗирин.*

***МӨҺЕР*** *г.* — Штамп, пичәт. XIV-XVII гасырга караган рәсми кәгазьләрдә йөзек-мөһер һәм бадам-мөһер төрләре искә алына. Мөһернең язуында (легендасында) хуҗаның исеме, титулы һәм атасының исеме булган, ә хан мөһерендә нәсел гербы да күрсәтелгән. XIX гасырда шәхси мөһерләре булган кешеләрне *хәтем хуҗа*, ягъни пичәт, мөһер хуҗасы дип атаганнар. Мөһерле йөзек *хатим* дип аталган.

Баштарак Мөхәммәд Пәйгамбәр язган хатларына мөһер басмый торган булган. Аннары Һиҗрәнең алтынчы елында көмештән йөзек ясатып, кашына өч юл итеп "Мөхәммәдүр Рәсүллаһ" дип яздырган *(Аллаһ исеме иң өстә, "Рәсүл" сүзе уртада, Мөхәммәд исеме астында булган).* Мөхәммәд Пәйгамбәрнең вафатыннан соң бу мөһерне Әбүбәкер, Гомәр һәм Госман хәлифәләр дә файдаланган.

// *Мөһер муми*-сургыч. *Ал мөһер. Мөһер бирү. Мөһер сугу, мөһер басу.*

***МУЛДӘКӘ*** *тар.* — Кара: ***МЕЛЛА-ӘКӘ.*** Кыргыз (казакъ) арасында мөгаллим. Электә татар шәкертләре, матди яктан бераз ныгып калу өчен, җәйлеккә еш кына *мулдәкәлеккә* чыгып китә торган булганнар.

***МУЛЛА*** — Гарәпчә *мәүла*-әфәнде, боеручы мәгънәсендәге сүздән дип саныйлар. Фарсы телендә *мулла* — дин гыйлеме белгече, Ислам дине әһеле. Татарча язылышта *мелла, мөлля, менла* вариантлары күзәтелә. Мулла сүзе олылап эндәшү мәгънәсенә дә ия. Мәс., Минзәлә якларында әтисенең олы кыз туганына *мулла түтәй* дип эндәшү бар. Ә Себер татарларында иренең иң өлкән энесенә *мулла тусым* дип эндәшәләр икән. Шулай ук Себер татарларында "мулла" сүзе укыган, укымышлы мәгънәсендә дә йөри ( *"Пестә аннан мулла кеше юк"*).

Электә муллалар, мәчеттә имам вазифасын үтәү белән бергә, *мөдәррис (мәдрәсәдә дәрес бирүче)* һәм мөселманнар арасында чыккан төрле бәхәс-низагларны хәл итүче *казый* хезмәтен дә башкарганнар. Мулла исеме, мәзиннәрдән кала, барлык мөселман руханиларына да бирелә.

Мәхәлләләрнең баераклары да, ярлылары да булган. Шуңа карап, муллаларның килере XX гасыр башларында уртача 200 дән алып 700 сумга кадәр исәпләнгән, ләкин кайчагында 3000 сумга да җиткән. Авылларда аларның килере акчалата түгел, күбесенчә натуралата-икмәк һәм башка төрле азык продуктлары белән булган.

Электә муллалар, бигрәк тә авылларда, бәхәссез авторитетка ия булганнар, мәхәлләдәге мөселманнарның әхлак-тәртибен күзәтеп торганнар. Мәсәлән, Казан өязе Кара-Хуҗа авылында җыен бәйрәме, мөселманнарга хас булмаган төс алып, хәмер эчү, кыйнашу кебек нәрсәләр күзәтелә башлагач, мулла кушуы буенча бу бәйрәм тыела. Әтнә авылында барлык аракы һәм сыра лавкалары да муллалар таләбе буенча ябыла, югыйсә бу базарлы авылга базар көнне мөселманнар гына түгел, руслар да күп килә торган булган *(XX гасыр башы, Я.Д.Коблов буенча).*

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

Октябрь инкыйлабы елларында Татреспубликада 200 дән артык мулла үзләренең дини дәрәҗәләреннән ваз кичеп, муллалыкны ташлаганнар яки ташларга мәҗбүр ителгәннәр. Н.Маторин үзенең "Религия у народов волжско-камского края прежде и теперь" дигән китабында 20 нче елларда муллалар арасында еш кына элекке офицерлар һәм укытучылар очравы турында яза. Шунысы кызык, XX гасыр ахырларында да без аякка басып килгән мәчетләребездә мулла сыйфатында пенсиядәге укытучыларны, элекке коммунистларны һәм хәрбиләрне, хәтта милиция хезмәткәрләрен очратабыз.

Муллаларның галимлегенә карата Ризаэтдин Фәхретдин фикерен күрсәтеп китик. "Һәр галимгә мулла димәк дөрест улса да, һәр муллага галим димәк җаиз улмаз," — ди ул.

"Мулла" сүзе татардан мариларга да кергән. Мәсәлән, Арча кантоны Арбор волосте Улисьял авылы марилары үзләренең мәҗүси йолаларына җитәкчелек итүче кешене (каһинне) "мулла" дип атаганнар.

Татар телендә кайбер нәрсәләрнең мөһим өлешен "мулла" *("мулласы")* дип атау бар. Мәс., комган борыны очындагы бөҗраны комганның мулласы дигәннәр. Әгәр шундый мулласы булмаса, комган мәет юарга дөрес булмый дигән шарт та булган *(Мари Элдәге Бәрәңге ягы сөйләше)*. Тәсбихның йөзенче зуррак төймәсе (*шаһданә* яки *нишанә*) тәсбихнең мулласы дип тә атала.

***МУНЧА*** — Рус теленнән алынган сүз *("мовьница"* — юына торган урын). Ихтимал, ул күрше халыклар теле аша кергәндер (чуашта — *мулча, молча,* мари һәм удмурт телләрендә *момоца* сүзләре бар). Ләкин борынгы бабаларыбызда мунчада юыну культурасы руслардагыга караганда югарырак булган. Борынгы Болгарда һәм Казанда җәмәгать юына торган мунчаларны *хәммам* дип атаганнар. Алар үзәктән ягып җылытылган, су чүлмәк торбалар аша килгән. Болгар сабыны исә Новгород якларында да дан тоткан. Ләкин авыл җиренә *кара* һәм *ак мунчалар* руслардан кергән дип уйларга кирәк. *Мунчала* сүзе дә төптә русларныкы ("мочало" — юешләгеч). Шәрык мунчаларында моның өчен махсус бияләй хезмәт иткән. *Мунчалы, Бишмунча* исемле авыллар булуыннан чыгып, мунчаларның тормыш дәрәҗәсен күрсәткән үзенә бер төрле сыйфат билгесе булуын гөманларга мөмкин.

Тагын кара: ***ШӘРЫК МУНЧАЛАРЫ.***

***МУНЧА ИСЕМЕ*** *тар.* — Баланы беренче тапкыр юындырганда мунча иясләрен алдау өчен кушыла торган исем. Мунча ияләре, имештер, үз балаларын кеше баласына алмаштырып куярга яратканнар. Мондый исем тискәре мәгънәле яки оятсызрак сүзләрдән торган. Балаларны ике яки алты айлык булганчы шул исем белән атап йөрткәннәр, аннары чын исем кушканнар, ләкин кайчагында аның мунча исеме гомер буена калган.

***МЫЛТЫК*** — Яныңда йөртелмәле утлы корал *(фарсыча-тофәнг, тофәң)*. Рус телендә *фитильное ружье*, французча — *аркебуза*. Пермь татарлары сөйләшендә мылтыкны *корал* дигәннәр *(рус телендә дә "ружье" сүзенең беренчел мәгънәсе, гомумән, корал булган)*. "Мылтык" сүзе казакъ телендә дә бар, ә төрекләр һәм Кырым татарлары аны *туфәк* диләр. "Мылтык" термины төрки телдә *милтә (филтә)+ук* рәвешендә ясалган дигән фикер яши *(Р.Әхмәтьянов)*. Ләкин Алтай төркиләрендә аучылар куеп калдыра торган тозак җәясен дә *мылтык* дип атыйлар икән. Кайбер сүзлекләребезгә теркәлгән "мылтыкчы" — аучы, сунарчы сүзе әнә шул тозак җәясеннән үк килмиме икән? Уйгурларда да "мылтык" сүзе бар.

"Утлы" мылтыкларның *тәтесе (кулса), чакмасы, филтәсе, келәсе* һәм *нишаны (прицел белән мушкасы)* булган. Хәер, электә *мишеньне* дә нишан дип атаганнар *(хәзерге рус телендәге "мишень" сүзе фарси "нишан" сүзенә барып тоташа, ул руска төркиләрдән кергән)*. Мылтык көпшәсен *кубәк* дип тә атыйлар. Мылтыкның гадәттә агачтан ясалган сабының иңбашына терәтелә торган башы *мылтык түтәсе* яки *кондак* дип атала (приклад). Мылтыкка корыла торган *дары* сүзе татар теленә фарсыдан кергән *(мылтык даруы, баруд)*. "Корылма" сүзе русча "заряд"ка туры килә. *Дары* һәм *коршуннарны (кургаш; ядрә, пуля)* махсус мөгез савытка — *сенрәнгә* салып йөрткәннәр. Аткан вакытта

мылтык көпшәсен терәтеп кую өчен хезмәт итә торган чатлы таякны *чатага* дигәннәр. Төбәп атарга өйрәнгән вакытта кулланылган мишень, югарыда әйтелгән "нишан" сүзе белән янәшә, *тәмек* яки *мәрә* дип тә аталганга охшый. Мылтык *ядрә* белән корылган, ләкин хәзерге утлы кораллар *пуля* белән аталар ("пуля" – рус сүзе). Мылтык көпшәсен *шомпол* (төректә – *туфәк чыбыгы*) белән чистартканнар, мылтык механизмын һәм кыйтгаларын *мылтык мае* белән майлаганнар. Мылтыкка нисбәтле *патрон, капсюль (кәпсел), гильза, пистон* кебек көнбатыш сүзләре телебезгә соңрак кергән.

Пуляның төз очышын тәэмин итү өчен көпшә эченә спираль винт сыры ясалган *винтовкага* татар телендә махсус атама юк, төрек телендә дә ул *туфәк* сүзе белән бирелә ("винтовка"ны, ягъни русларда башта "нарезное ружье" дип аталган утлы коралны татарчада *"бормалы мылтык"* дип алырга булыр иде-булуын). Шунысы кызык, мондый мылтыкларга кадәр үк инде уклар туры очсын өчен дә аларның койрыгына уң яки сул канат каурыйлары куеп, укның буй күчәре тирәсендә уңга яки сулга таба бөтерелеп очуына ирешкәннәр.

Электә мылтык турында мондый бер табышмак та йөргән: "Агачтан аты, Тимердән хаты, Ходаның кодрәте, Кеше өстендә миннәте." Ихтимал, "ат" дигәндә мылтык куела торган *чатага* күздә тотылгандыр, "хат" – пуля, йадрә, коршун / коршын булыр. "Миннәт" дигәндә аның кешегә, бигрәк тә солдат кешегә ярдәме күз алдына килә. Әлбәттә, бу табышмак солдат арасында чыккандыр. Мылтык төбәү турында табышмак: "Астында беләк була, Кабыргасында ияк була, Өстендә күз була, Үзе төз була."

Казан арты, Минзәлә, Себер, Төмән якларында кыз утырган көймә егет өенә якынлашып килгәндә мылтык ату йоласы да булган.

*// Магазинлы мылтык. Ау мылтыгы. Сөннәтле мылтык* (русча – *обрез*). *Кыска мылтык* төшенчәсе дә булган ("Кыска мылтыкның шартлавы яман" дигән сүз шуны күрсәтә). *Сындырмалы мылтык* (русча – *централка, ружье центрального боя*). *Ике көпшәле мылтык* (русча – *двустволка*).

Тагын кара: ***ФИЛТӘ; ТУФӘК.***

***МЫЛТЫК АТЫМ ҖИР*** *тар.* – Мылтыктан аткан ядрә оча торган ара. *Ук атым* арадан (0,6 км дан) артыграк булса кирәк. *Таш атымы җир* дигән төшенчә дә булган.

***НАРДУГАН*** (кышкы нардуган) *тар.* – Бу сүзне *нард (шакмак атып уйнау һәм күрәзәлек итү)* һәм *фал* сүзләреннән оешкан дип карыйлар. Төрек сөйләшләрендә – *мартуфал, мартавал, мантувар.* Кыскасы, "нардуган" сүзе тәүге формасыннан шактый ераклашкан һәм нардуган көннәрендә җырлана торган "нардуганым нар булсын" сүзләренең мәгънәсен ачыклау кыен. Кышкы нардуган бәйрәме 25 декабрьдә башланып бер атна (кайбер төбәкләрдә унике көн) дәвам иткән. Мәгълүм булганча, иң суык кырык көнлек вакытны (25 декабрь – 5 февраль) халык *кышкы чиллә* дип йөртә. Кышкы нардуганның башы менә шушы кышкы чиллә башына туры килгән һәм нардуган уеннарында *Чиллә бабай* – хәзерге *Кыш бабай* катнаша торган булган. Чиллә бабай яки Нардуган бабай кышкы суыкларны җибәрә дип уйлаганнар. Нардуган руслардагы *святкига* туры килә. Нардуган бәйрәмендә кыз-кыркын уникешәрле төркемнәргә бүленеп, яңа ел кичәләре оештырган. Кичәләрдә тамашалы уеннар уйнаганнар һәм "Кулымдагы йөзегемнең исемнәре..." дип башланган җырлар ярдәмендә яңа елданиләр булачагын юрап караганнар. Күрәсең, мондый башлам хас булган җырларның күплеге нардуган кичәләрендә багу-юрау йоласының электә киң таралган булуы турында сөйли торгандыр. "Кышкы нардуган Казан дәүләтендә ярминкә вакытында бәйрәм ителгән һәм ярминкәгә килгән бүтән халык әһелләре аша күршеләргә таралган" *(Р.Әхмәтьянов).*

Р.Әхмәтьянов: "Нардуган тәүдә җәйге чиллә башында (25 июнь-5 июль) уздырылган һәм *аяу көннәре, аяу атнасы* дип тә аталган" дип яза. Бусы русларның *русалия, троицын* бәйрәменә туры килә. Тора-бара җәйге нардуган онытылган.

Ислам һәм җирле диннәр нардуган йоласын кире какканнар һәм ул халыкта еш кына *шайтан туйы* дип тә аталган (ә *җен* яки *пәри туе* бөтенләй башка нәрсә, кечкенә өермәне шулай дип атыйлар).

*Дәвамы киләсе саннарда*

Хәter
Хәтер

# ТӨРЕК ӘСИРЛӘРЕНЕҢ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Исәнмесез, хөрмәтле редакция хезмәткәрләре!

Мин 1995 елдан бирле Төркиядә яшим. Үзем төрек кешесенә кияүдә, кызыбыз Айсылу үсеп килә. Истанбул шәһәрендә торабыз. Иптәшем белән икебез дә Мәрмәрә университетында гыйльми хезмәткәр булып эшлибез, ул—төрки телләр белгече, мин—рус теленнән тәрҗемәче. Мин үзем Чирмешән ягыннан, Бәркәтә авылыннан. 1990—1995 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында укыдым. Төркиягә килгәч, белемемне бүтән юнәлешләрдә арттыруга форсат туды. Башта Мәрмәрә университетының аспирантурасында "Гомуми төрки тарих" бүлегендә укып, бу бүлекне мастер дәрәҗәсе белән тәмамладым. (Төркиядә аспирантура ике баскычлы, беренчесе мастер, аннан югарырак булган икенчесе—доктора дип атала.) Аннан соң кызым Айсылу туып, беравыкка укулардан бүленеп тордым. Менә хәзер Богазичи[1] университетының аспирантурасында Төркия тарихын өйрәнеп ятам.

Богазичи университетында "Беренче дөнья сугышы чорында Госманлы империясе" дигән темага багышланган лекцияләр барышында Россиядә әсир булып берничә ел гомер кичергән бер төрек офицерының истәлекләреннән өзек укыдык. Бу өзектә татарлар турында да мәгълүмат бар иде. Мин тиз арада китапның үзен табып, бөтен истәлекне укып чыктым. Моның белән генә канәгатьләнмичә, Россиядәге әсирлек хатирәләрен теркәгән башка истәлекләр дә юк микән дип, каталогны барладым. Тагын шундый алты әсәр бар икән. Бу истәлекләрнең авторлары Россиянең төрле почмакларында әсир булып яшәгәннәр. Төркиягә кайту юлында Россияне буйдан-буйга үткәннәр, чит тормыш рәвешенең төрледән-төрле манзараларына шаһит булганнар. Истәлекләрнең барысын да укып чыккач, 1915—1918 еллар арасындагы Россиянең искиткеч кызыклы дөньясы бар тулылыгы белән күз алдымда җанланып китте. Бу дөнья эчендә татарларның ничаклы әһәмиятле урын биләгәнлеге һәр авторның татарларны истәлекләрендә ничәмә-ничә тапкыр телгә алганыннан ук күренеп тора иде.

Әмирхан Еникинең хикәяләр җыентыгына язган кереш сүзендә Туфан Миңнуллин язучының бер хикәясе турында менә болай дип әйткән: "... хикәядә үземнең татарымны таныйм мин. Утта янмас, суда батмас татарымны күрәм. Бу әкәмәт дөньяда чарасызлыктан аптырап калганда, инде бетте дигәндә дә җаен тапкан татарымны очратып куанам". Бу сүзләр төрек офицерларының истәлекләренә тач туры килеп тора. Чөнки бу истәлекләрдә дә патша Россиясенең бөтен тишек-тошыкларына үтеп кергән, нинди генә кыен хәл булмасын, бер әмәлен тапкан, үз юлын ярган, якты дөньяда үзенә яшәр урын ачкан уңган, чыдам, зирәк, ярдәмчел, төрки җанлы татарны очратасың.

Төрек офицерларының истәлекләрен укып чыккач та бу хәзинәне татар укучылары белән уртаклашырга булдым. Егерменче гасыр башы татарының төрек күзгесендәге чагылышын хәзерге татар аудиториясенә җиткерүне үзем өчен бурыч итеп күрәм.

Беренче дөнья сугышы елларында Россиядә әсир булып гомер сөргән төрек сугышчылары һәм аларның 1917 елдагы вакыйгалардан соңгы язмышы турында Төркиядә зур дәрәҗәгә ирешкән танылган галим, милләттәшебез Әкъдәс Нигъмәт

[1] Богазичи – "бугаз эче" дигән сүз. Төрекләр Босфор бугазын шулай дип атап йөртәләр. (Л. Шаһин искәрмәләре.)

Курат[1] үзенең "Төркия һәм Русия" дигән китабында шактый киң мәгълүмат биргән[2]. Әкъдәс Нигъмәт Куратның китабыннан һәм төрек офицерларының истәлекләреннән файдаланып кыскача гына түбәндәге мәгълүматны биреп китик.

Беренче дөнья сугышы чорында 60–70 меңләп төрек сугышчысы Россия армиясенә әсир төшә. Боларның бер өлеше Баку каршысындагы Нарген утравында тотыла, күпчелеге Россиянең төрле почмакларына җибәрелә. Офицерлар күбесенчә Мәскәүгә якын Ветлуга шәһәренә һәм Себердәге Иркутск, Красноярск, Чита шәһәрләренә урнаштырыла. Рус хөкүмәте сугыш әсирләрен шәһәрләрнең тышына корылган хәрби казармаларда тота, офицерлар солдатлардан аерым, яхшырак шартларда яши. Әсирләргә дәрәҗәләренә күрә (офицерларга күбрәк, гади солдатларга азрак) акча да бирелә. Аны әсирләр лагерь кибетеннән азык-төлек, өс-баш юнәтер өчен тота.

1917 нче елда илдә хакимият дилбегәсе большевиклар кулына күчкәч, әсир лагерьларындагы тәэминат һәм дисциплинаның торышы начарлана. Россиядәге мөселман халкы, бигрәк тә татар һәм азәри җәмәгате, ярдәм комитетлары корып яисә газетага игълан бирү юлы белән акча җыеп, төрек әсирләренә ярдәм кулын суза.

Төрек әсирләре мәсьәләсе белән ул вакытта Йосыф Акчура бик кызыксына. Йосыф Акчура Кызыл Айның вәкиле сыйфатында төрек әсирләрен барлау һәм аларны ватаннарына кайтару эшен оештыру өчен 1918 елның 13 гыйнварыннан 1919 елның 1 февраленә кадәр Россиядә була[3]. Йосыф Акчурага бу эштә Мәскәүдә татарлар тарафыннан оештырылган ярдәм комитеты аеруча зур булышлык күрсәтә. Мәскәүдәге татар җәмәгате тирә-яктагы бөтен төрек әсирләрен җыеп, аларга акчалата ярдәм күрсәтә, революция чорындагы кыен хәлгә карамастан (ул вакытта Мәскәүдә икмәк карточка белән көнгә 200 гр. бирелә торган була), әсирләр өчен ашханә белән шифаханә ача. Россиянең бүтән почмакларындагы мөселман җәмәгатьләре дә әсирләргә кулдан килгәнчә булышлык күрсәтәләр. Мәсәлән, "Ил" газетасының хәбәре буенча, Тамбовтагы аз санлы татар мәхәлләсе 500гә якын төрек әсирен тәрбияләп тота. Татар газеталары *("Ил", "Йолдыз", "Вакыт" һ.б.)* әсирләр турында мәгълүмат биреп, ярдәм кампанияләре оештырып бу эшкә катнаша; газета битләрендә турыдан-туры әсирләргә мөрәҗәгать итүче белдерүләр дә басыла, шул рәвешле төрек әсирләре үзләренә нишләргә кирәклеген татар газеталарыннан укып белә. Мәсәлән, Йосыф Акчура, Россиягә килеп җиткәч тә татар газеталарында әсирләргә ачык хат бастырып, алардан үз хәлләрен газетада бирелгән адрес буенча белдерүләрен үтенә. Ягъни татар газеталары төрек әсирләре белән ярдәм оешмалары арасында үзенә бер төрле күпер вазифасын үти.

Йосыф Акчура төрек әсирләренең хәлен якыннан күреп белү өчен Мәскәүдән чыгып китеп Казан, Уфа, Оренбург якларын да урап кайта. Фәкать Россиядәге Гражданнар сугышы куркыныч төс ала башлагач кына кире Истанбулга әйләнеп кайтырга мәҗбүр була.

Төрек әсирләренең бер өлеше әсирлектән ялгыз башына яисә икешәр-өчәр кешелек төркемнәр булып качып китүгә ирешә. Күпчелеге исә 1918 елның март аенда Брест солыхы имзаланганнан соң гына иреккә чыга. Боларның күбесе әсирләрне үз илләренә кайтару белән шөгыльләнгән төрле җәмгыятьләрдән ярдәм күреп, уравыч юлдан Төркиягә кайта. Иреккә чыккан әсирләрнең бер өлеше туры ватанга кайтырга ашыкмый, Идел буенда, Азәрбайҗанда, Төркестандагы милли хәрәкәтләргә катнашып китә, мәгариф эшләре белән шөгыльләнә яисә берәр төрле

---

[1] Әкъдәс Нигъмәт Куратның (1903 – 1971) якташым икәнлеген дә әйтми узып китә алмыйм: ул минем туган авылым Бәркәтәдә Таһир мулла гаиләсендә дөньяга килгән. Әкъдәс җиде яшендә булганда, Таһир мулла гаиләсе Бөгелмәгә күченеп китә. Бәркәтәдә бу гаиләнең ничек киткәнен, арбаларында төен-төен китап булганын олыларның сөйләгәненнән хәтерләп белүчеләр бар әле. 1924 елда Төркиягә урнашкан Әкъдәс Нигъмәт монда Истанбул университетында укый, аннары төрле Европа илләрендә белемен күтәрә, гыйльми тикшеренүләр белән шөгыльләнә һәм күренекле тарихчы булып житешә. Төркиядә 1944 елда Анкара университетында профессор була, 1953-55 елларда Анкара университетының Тел һәм тарих-география факультетының деканы булып эшли. Төркиядә аның бигрәк тә Россия тарихына багышланган әсәрләре яхшы танылган.

[2] Kurat, Akdes Nimet. Turkiye ve Rusya (Ankara: Kultur Bakanligi Yay., 1990), s. 440-457.

[3] Йосыф Акчураның бу юнәлештәге эшчәнлеге турында тулы бер мәкалә бар: Mesut Capa, "Yusuf Akcura' nin Rusya Seyahati ve Turk Esirileri", Turk Kuluru, no. 366, Ekim 1993, s. 608-622. Бу мәкалә Йосыф Акчураның 1919 елның 20 ноябрендә тапшырган отчетына нигезләнеп язылган. Йосыф Акчураның әсирләр белән бәйле эшчәнлеге турында Әкъдәс Нигъмәт Курат та мәгълүмат бирә.

хәрби вазифа үти, совет власте ныклап урнашкач кына Төркиягә әйләнеп кайта. Ватанга кайтмыйча, Россиядә төпләнеп калучылар да булгалый.

Төрек әсирләренең каләменнән чыккан җиде истәлектән үземә кызыклы тоелган кайбер өзекләрне генә сайлап алдым. Истәлекләрне язучылар—барысы да офицерлар, ягъни ул вакыттагы Төркиянең иң укымышлы, зыялы катлавыннан. Һәркайсысы әсәрен әсирлек вакытында теркәгән көндәлек язмаларына нигезләнеп язган. Ләкин истәлекләрнең барысын да сыйфат ягыннан бер дәрәҗәдә дип әйтеп булмый. Язучыларның бер өлеше әсир төшкәндә егерме яшьләрендә генә була. Холык-фигыль, дөньяга карашның төрлелеге дә истәлекләрнең эчтәлегендә үзен шактый нык сиздерә. Язучыларның кайберсе үз-үзен үзәкрәк куйган, күбрәк эчке кичерешләрен теркәү белән шөгыльләнгән, шуңа күрә тышкы дөньядагы вакыйгаларга игътибары җитеп бетмәгән, аларга биргән бәясе дә бераз чикләнгәнрәк булып чыккан. Икенчеләре, киресенчә, тирә-ягын бик игътибарлап күзәткән, үзенә кызыклы тоелган бар нәрсәне дә теркәп барырга тырышкан, фикер йөрткән, шул рәвешле, тормыш материалын киңрәк колачлауга ирешкән. Тәрҗемә өчен өзекләр сайлаганда, мин бу хосусларны да истә тоттым. Табигый буларак, икенче төркемдәге истәлекләр миңа кызыклырак булып тоелды.

Татарларны кайда гына, нинди генә шартларда очратмый төрек әсирләре: Кавказ фронтында, Себер киңлекләрендә, Ерак Көнчыгышта, кырыс казакъ даласында, кояшлы Төркестанда, мәһабәт Петербургта, шаулы Мәскәүдә... Нинди генә рәвешкә керми татар: күз камаштыргыч затлы кибетнең хуҗасы, тыйнак кына мәчетнең имамы яки мәзине, поездда яки ат арбасында белән сәфәр чыккан вак сәүдәгәр, солдат, төрмәдә тоткын... Кем генә булмасын, нинди генә рәвешкә кермәсен, төрек әсире татарны актив, акыллы, киң күңелле кеше буларак, иң мөһиме, мөселманлык һәм төркилек тугандашлыгына зур әһәмият бирүче зат буларак хәтеренә салып куйган...

Тагын шунысын да әйтеп китим: истәлекләрне укыгач, "дөнья һаман шул эздән бара, әлләни үзгәрми икән", дип уйлап куйдым, чөнки төрек офицерлары тасвирлаган кайбер нәрсәләр Россиядә ул вакытта ничек булган булса, бүген дә шулай.

**Ләйсән ШАҺИН**

# Таһсин Ийбар

## "СЕБЕРДӘН СӘРӘНДИПКӘ" ӘСӘРЕННӘН ӨЗЕК

*Таһсин Ийбар (1888—1971) 1914 елның декабрендә Кавказ фронтында әсир төшә. Красноярск якынындагы әсирләр лагерена җибәрелә. 1918 елның җәендә берничә иптәше белән качып китеп, казакъ далалары, Урта Азия чүлләре аша Әфганстанга чыга, аннан Һиндстанны узып, ахырда диңгез юлы белән 1920 елның июнендә Истанбулга кайтып ирешә. Истәлекләре "Себердән Сәрәндипкә" исеме белән 1950 елда басылып чыга.*

"...Иң элек Ростов шәһәренә җибәреләсе идек. Анда Русия хәрби идарәсенең әсирләрне урнаштыру планына күрә безне кайсы лагерьга җибәреселәре тәгаенләнәчәк икән.

Новоселим[1] станциясендә 23 офицерны өченче сыйныф вагонга урнаштырдылар. Вагонның эчендә ятар урыннар өч катлы булганга күрә, урын житәрлек, иркен.

---

[1] Россиядәге шәһәр һәм авыл исемнәрен төрекләр күбесенчә үз телләренә яраштырып үзгәртеп язганнар. Кайбер исемнәрнең русча төгәл рәвешен билгеләп булмагач, болар төрекчә текстта ничек теркәлгән булса шулай бирелде.

Вагонны күмер ягыла торган мич жылыта. Сакчылар тукталышларда кирәкле әйберләр сатып алырга рөхсәт итәләр. Әмма Тбилиси, Баку кебек зур шәһәрләрдә вагонны станциядән ерактагы юлда аерып калдыралар, жирле халык белән аралашырга мөмкинлек бирмиләр иде.

Тбилисига якын бер тукталышта вагоныбызга азәрчә бик төзек сөйләшә торган бер әрмән офицеры килеп керде. Бик тел бистәсе булып чыкты бу, әз генә вакыт эчендә әллә ниләр сөйләп бетерде. Атасы Бакуның мәшһүр байларыннан икән. Үзе Берлинда укыган. Бакуда бик күп мөселман дусты бар икән. Бабасы поп икән. "Попның онигы йә үтә диндар, йә динсез булыр" дигән әйтем бар. Бу үзе хөр фикерле кеше икән, фәлән-фәсмәтән. Сөйләр сүзе бетмәгән булса да, поезд кузгалгач төшеп калырга мәжбүр булды. Вагоныбыз яныннан бераз барып безне озатып жибәрде.

Безнең белән төрекчә сөйләшкән Арслан бәйне, алманча сөйләшкән дивизия докторын, русчасы бик начар булганга күрә үз телендә сөйләшкән гөржү *(грузин)* офицерын һәм ниһаять бу әрмән офицерын да күргәч, патша Русиясенең тел һәм фикер ягыннан бер-берсеннән аерылып торучы төрле-төрле милләтләр коллекциясеннән гыйбарәт булганлыгын аңлап алдык. Русия турындагы беренче тәэсиребез шул булды.

Тбилиси белән Бакуны узганда жирле халык белән күрештермәделәр. Төньяк Кавказда кечкенә станцияләрдәге халыкка безгә төрле вак-төяк сатарга рөхсәт бирделәр. Мондагы халык бик көр, таза күренә. Черкис киеменнән, папахадан йөри.

Кавказ фронтына гаскәриләр һәм сугыш кирәк-ярагы ташучы поездларның үтеп киткәнен көтә-көтә барганга күрә, поездыбыз туктап-туктап бик акрын юл ала иде. Шундый тукталышларның берсендә вагоныбызга бер полковник килеп керде. Француз телен камил сөйләшсә дә рус икәнлеге күренеп тора иде. Үзен бик әдәп белән тотучы бу зыялы зат сугышның тизрәк бетүен һәм безнең тиз арада ватаныбызга әйләнеп кайтуыбызны теләде.

—Русиянең эченә юл тотасыз. Бу сезнең өчен бик шәп форсат, рус милләтен өйрәнергә тырышыгыз,—диде. Рус халкының тыйнаклык, житдилек, сабырлык кебек унай сыйфатларын мактап телгә алды, бу милләтнең патшага искиткеч тугрылыгын, бу тугрылыкка таянган Русиянең алманнарны һичшиксез жиңәчәген сөйләде. Безнең өчен бөтенләй диярлек билгесез булган бу яңа дөнья турында әйтер сүзебез юк иде, полковникны тавыш-тынсыз гына тыңладык.

Бу очрашудан соң өч ел узып киткәч, беркөнне Себердәге лагерьда газета сатучы Алексей исемле рус малаеның кәгазь акчадагы патша сурәтенә төкереп сүгенгәнен күрдем. Малай, алман шпионнарына ярдәм итә дип, патшабикәгә дә тел тидерде. Шунда рус полковнигының үз милләте турында әйткәннәре искә төште.

Сугышның башыннан ук Русиядәге революцион көчләрнең патшага теш кайраганы сизелә иде инде. Полковник, күрәсең, йә үтә оптимист бер кеше булгандыр, яисә хәл-әхвәлнең чын йөзен белеп торса да моны сиздерергә теләмичә, безне Русиядә көчле милли бердәмлек бар дип ышандырырга тырышкандыр.

1915 елның 1 гыйнварында иртән иртүк Ростовка килеп життек. Тимер юлларының күплегеннән, төрле яктан күккә омтылып торган фабрика моржаларыннан зур шәһәр икәнлеге беленеп тора иде.

Безнең 22 ноябрьдән бирле эчке күлмәкне алыштырган юк. Алмашка кием дә юк, керлелектән кашына башладык. Сакчылар безне Ростовта мунчага алып барасыларын әйттеләр. Бу хәбәр зур сөенеч булды. Ләкин шунда бер иптәшебез шикләнеп әйтеп куйды:

—Безне гомуми мунчага алып барырлар инде. Русларның бит пәштамал[1] урап юына торган гадәте юк, без дә алар кебек шәп-шәрә юынабызмы?

Арабызда хәрби мөфти дә бар иде, пәштамалсыз юынырга теләмәүче консерватор төркемне ул житәкләде. Бәхәс озакка сузылды. Шәрә килеш булса да юынырга карар бирүчеләр белән моннан кискен рәвештә баш тартучылар арасында фикер аерымлыгы килеп чыкты.

[1] Пәштамал—мунчада гаурәт урыннарын каплау өчен кулланыла торган тукыма кисәге. Моны ирләр биленә урый, хатын-кыз култык асларыннан ук урап куя.

Ахырда нинди рәвештә булса да юынырга дип карар биргән без алты кеше сак астында шәһәр мунчасына киттек. Билет алып мунчага кердек.

Тәрекләр килгәнне ишеткәч, яше-карты, шыр-ялангач бер көтү кеше чишенү бүлмәсенә чыгып, тирә-ягыбызны сырып алдылар. Бик сәер халәт иде бу. Чишенергә кыймыйча таптанып торабыз, сакчылар "Юынмыйсыз икән, нигә килдегез" дип мыгырданалар. Мунчага барырга теләмәгән иптәшләр хаклы булып чыкты болай булгач. Шулвакыт кинәт кенә төрекчә:

—Хуш килдегез, якташлар!—дигән сүзләр ишетелде.

Безне сәламләүчеләр хәмшинле[1] төрекләр булып чыкты. Болар бу тирәләрдә кечкенә кибетләр тота икән. Әйтүләренә караганда, Русия шәһәрләрендә икмәк, кләндир, прәнник ише камыр ашларын пешереп сату эше тоташтан диярлек хәмшинлеләрнең кулында икән. Берничә төрек офицерының сак астында мунчага китерелгәнен ишеткәч, эшләрен ташлап безне күрергә дип йөгерешеп килгәннәр.

Мөшкел хәлебезне боларга аңлатып бирдек.

—Хәзер жайлыйбыз аны. Сез билетларыгызны кире тапшырыгыз, сезгә аерым кабина өчен билет алырбыз, бер кабинада икешәр-өчәрләп юынырсыз, гомуми мунчадагы халыкның бәйләнчеклегеннән шул рәвешле котылырсыз,—диделәр.

Хәмшинле якташларның арадашлыгы белән мәсьәлә хәл ителде. Иркенләп юындык, эчке киемнәребезне дә юдык. Өске киемне ялангач тәнебез өстенә киеп, юеш керләребезне төенләп култык астына кыстырып, кайту юлын тоттык. Жылы су белән сабынның тәнгә биргән рәхәтен безнең кебек ләззәтләнеп татыган кеше булды микән дөньяда?

Ростов вокзалына кире әйләнеп кайтсак, вагоныбызны дезинфекция өчен алып киткәннәр икән, мунчадан чыккан килеш, эчке киемсез, салкында калтырап вагонның кире кайтканын көтә башладык.

Болай көтеп торуның озакка сузыласын чамалап алган сакчылар, бездән бушап шәһәрдә йөреп алыр өчен, безне Кызыл Хач хастаханәсенә илтеп куйдылар. Күптән түгел генә корылган булуы күренеп торган хастаханәдә безне шәфкать туташлары каршы алды. Болар—Ростовның абруйлы гаиләләренең кызлары, монда үзләре теләп хаста карарга килгәннәр икән. Барысы да гимназия бетергән, күбесе алман телен белә. Безгә чәй эчерделәр, эчке киемнәребезне киптерергә булыштылар.

Әңгәмәбез барышында сүз фронттагы хәл-әхвәлгә дә кагылды. Алманнарның Мазуриядагы уңышлы атакасы турында күбесенең хәбәре юк икән, бездән ишетеп белделәр. Рус хөкүмәте моны үз халкыннан яшереп калган. Алманча бик әйбәт сөйләшә торган бер үткен хатын сүзне шундук башка нәрсәгә борып жибәрде, үзе безгә шыпырт кына:

—Әйе, Мазуриядә безнекеләр жиңелгән, ләкин Русиядә моны бик аз кеше белә,—диде.

Төн уртасында вагон килгәч, сакчылар безне килеп алдылар. Иптәшләр безне кызыксыну белән зарыгып көткәннәр икән. Мунча мажарасын сөйләп биргәч, бармауларына үкенделәр.

2 гыйнварда Ростовтан кузгалып киттек. Гел төньякка таба барабыз. Каменский, Налинский, Поворнов, Ричево, Сызрань, Айдоллин, Уфа, Вязовая, Чиләбе, Екатеринбург шәһәрләрен уздык. 16 гыйнварда Пермьдә поездлан төшерделәр.

Ростовтан Пермьгә хәтле 14 көнлек сәяхәт кышның нәкъ уртасына туры килде. Русия буйдан-буйга кар белән капланган. Гел төньякка таба юл алганга күрә, барган саен суыграк була бара. Шәһәрләрнең тышында безнең өчен иң кызыклы манзара—бер-бер артлы тезелеп баручы ат жиккән чаналар. Толыпка төренгән, камчы тоткан рус агайлар чаналарына жиккән ике-өч айгырны камчы белән пешекләп өзлексез юырттыра, кайвакыт башка чананы узып китәр өчен бар көченә чаптыра. Кыңгырауларын шалтыратып чапкан айгырларның сыртларыннан пар күтәрелә... Елгаларның өстенә каткан боз шулхәтле калын, тонналап йөк тутырган йөзләп чана елга өстеннән шуып кына уза.

Русиянең урманнары да кышына ярашлы, әйтеп бетергесез мул, поезд ике көн,

[1] Хәмшин—Төркиянең төньяк-көнчыгышында, Грузия чиге янындагы бер урын.

ике төн тоташтан урман кырыеннан барган вакытлар булды. Урман бетеп үзәннәргә килеп чыкканда да агач бөтенләй бетми, һәр авылның янында һичшиксез агачлык була[1].

Юлда сакчыларның башлыгы булган рус офицеры көнлек 1,5 сум акча өләшә иде. Моның белән без йә вокзаллардагы ашханәләрдә ашыйбыз, йә кечкенә станцияләрдәге халыктан аны-моны сатып алып, вагонда капкалыйбыз. Почта ташучы поездлар туктала торган станцияләрдә кайнатып куйган су бирелә торган бина була. Без чиратлашып бу бинага барабыз, чәйнеккә су тутырып кайтып, поездда чәй ясап эчәбез.

Пермь станциясендә төшкән көнне тышта зәмһәрир суык иде. Гади солдатларны колоннага тезеп җәяү алып киттеләр. Чанага утыртабыз дип офицерларны бераз көттерделәр. Туңмас өчен кулларны-аякларны гел уып, бер-беренә суккалап тордык. Шактый вакыт узганнан соң көтелгән чаналар килде.

Офицерларны икешәрләп-өчәрләп чаналарга утырттылар. Юлда солдатлар колоннасын куып җиттек. Хәлсезрәкләре суыктан куырылган, аякларын көчкә сөйрәп баралар.

Шәһәрне чыкканда юлның кырыеннан баручы авыл хатыннары сакчыларга нидер кычкырды. Русча белүчеләр тәрҗемә итте: "Авыру һәм яралы әсирләрне нигә җәяү алып барасыз, ник халыктан чана сорап алмыйсыз?"—дип әрлиләр икән.

Хәлсезләнгән берничә солдатны кысылышып янибызга утырттык, юлыбызны дәвам иттек. Безне Мило дигән авылда шифаханә кебегрәк бер урынга китерделәр. Кер сабыны биреп берәмләп юынгычка керттеләр. Микроблардан арындырыр өчен киемнәребезне эссе һава бирә торган махсус җиһазга куеп эшкәрттеләр. Солдатлар өчен дә махсус хастаханә корганнар, яралы, авыру солдатларны шунда яткырганнар икән.

Бу хастаханәнең баш докторы олы яшьләрдәге бер ханым иде. Ул безнең солдатлар белән рус докторлары арасында тәрҗемәче булырлык, русча яисә алманча белүче берәр әсирне хастаханәгә җибәрүләрен сорагач, бу вазифага мин киттем. Гайрәтле доктор ханым иртә таңнан кичкә кадәр хастаханәнең тәртибен күзәтә, кирәк-яракны юнәтер өчен губернаторга чаклы барып житә. Берлинда белем алган. Кирәк нәрсәне миңа алманча сөйли, мин үзебезнең солдатларга тәрҗемә итәм.

Югары температура белән кызышып ятучы авырулар "су!" дип иңри. Шәфкать туташлары исә чәй эчертә, чөнки доктор ханым суны катгый рәвештә тыйган. Анадолуда һәм Кавказда халык таулар эченнән бәреп чыккан саф чишмә суларын эчә. Русиядә андый су булмагач, инеш суын эчәләр. Доктор ханымның әйтүенә караганда, бу суны кайнатмыйча эчәргә ярамый, Русиядә докторлар бу турыда авыл халкын гел кисәтеп тора икән. Шуңа күрә монда кешеләр билгеле сәгатьтә самавыр кайнатып, бөтен гаилә белән җыелышып чәй эчәләр, сусыннарын шул рәвешле басалар икән. Кайнамаган су эчсәң, йогышлы авыру эләктерүең ихтимал.

Мин моны безнең солдатларга аңлатып бирдем. Ләкин тауларда туып-үскән, боз кебек салкын, бәллүрдәй саф чишмә суына иялашкән безнең Мәхмәтчекләр[2] мин әйткәннәрне колагына да элми:

—Аллам, яндым, бер стакан гына су бирегез!—дип өзгәләнә.

Мин:

—Син башта бер-ике чынаяк чәй эчеп җибәр әле, сусавың басылмаса, су да бирермен,—дип хәйләләп, аларны чәй эчәргә күнектердем.

Мине офицерлар торган җирдән хастаханәгә һәр көн чана белән илтеп куялар, алып кайталар. Юл озын булмаса да тыштагы суыкка чак түзеп барам. Пермь Мәскәүдән төньяктарак, салкыннар 40 градуска житә, русларда ире-хатыны, баласы-чагасы—барысы да толыптан, калын бияләйдән, киез итектән йөри. Ыспай

---

[1] Төрек офицерлары күргән урыннарының географик шартларын, геологик үзенчәлекләрен, табигый байлыкларын һәрдаим искәреп баралар, боларның икътисадка тәэсире турында фикер йөртәләр, үз илләрендәге шартлар белән чагыштырып, Россия һәм Төркия җәмгыятьләренең үсеш юлларының төрлелеге турында уйланалар. Төркиянең таулы, урманнарга ярлы, корылыклы табигатенә иялашкән кешеләр буларак Россиядә аларның игътибарын бигрәк тә иксез-чиксез киңлекләр, калын урманнар, табигый хәзинәләрнең муллыгы җәлеп итә.

[2] Мәхмәтчек – төрекләрдә хәрбиләрне яратып атау рәвеше, бигрәк тә гади солдатларны күз алдында тотып кулланыла торган җыелма исем.

киенүчеләрнең аякларында шосон[1] була. Минем юка ботинкалар эчендә аякларым сызлый иде. Сарыкамышта[2] 12 көн буе кар өстендә ятып аяк бармакларымны туңдырган идем. Хәзер менә карга баскан саен энә кадаган кебек ачынып сызлыйлар.

Беренче форсатта калын толып һәм аягымны жылыда тотарлык аяк киеме алырга дип башыма салып куйдым. Кесәмдә йөрткән актык ике госманлы алтынын бу әйберләр өчен фида итәргә әзер идем.

26 гыйнварда тагын юлга чыктык. Бу юлы бары тик офицерларны гына алып баралар. Себердәге бер лагерьга озаталар икән. Екатеринбург, Камышлов, Төмән, Ишим, Омск, Богота, Красноярск шәһәрләрен уздык.

Кавказны үтеп киткәннән соң гел тип-тигез урыннардан барган идек, монда янадан тау күреп хозурландык. Поезд тар үзәннәрдән борыла-борыла бара. Бу, һичшиксез, Урал таулары булырга тиеш. Урал таулары агачлар, куаклар белән капланган, биеклеккә бик биек түгел икән.

Без инде хәзер Азиягә килеп кердек, Себернең эченнән барабыз. Монда агачлар калын, үзләре тыгыз утырган, урманнар куе. Русиянең үзәгендә кар белән капланган тоташ тигезлектән барган идек, монда табигать манзарасы төрләнеп тора, урманнар белән сазлыклар алмашынып бара. Сазлыклар өстенә меңләгән кыргый үрдәк кунган. География дәресендә укыган Иртеш һәм Обь елгаларын тимер күперләр өстеннән карап уздык. Өсләренә калын боз каткан, өстеннән ат чаналары шуып уза. Елгалар май ае ахырында гына боздан арчыла икән.

1915 елның 6 февралендә Енисей губернасының үзәге булган Красноярск шәһәренә килеп життек. Мана елгасы шәһәрнең кырыендагы мәхәлләләрен ялап узып Енисейга кушыла. Красноярск төньяк ярымшарның 56 нчы параллелендә урнашканга күрә, жәен көннәрнең, кышын төннәрнең озынлыгы безнең параллельдәгедән бөтенләй башка төрле. Жәйнең иң озын көнендә 20 сәгать көн, 4 сәгать төн була, кышын исә киресенчә 20 сәгать төн, 4 сәгать көн була. Жәйнең озын көннәрендә көнбатыштагы кызыллык таралып бетмәстән көнчыгышта таң сызыла башлый. Бу үзенчәлек сәбәпле Себернең бу якларында бодай житештерә алалар. Чөнки жәй кыска булса да игеннәр көндезләрен кояш яктысын мул ала.

Владивостокта очлана торган Себер тимер юлы Красноярск якынында бер тимер күпер өстеннән уза. Енисейның ике яры арасындагы элемтәне зур паром тәэмин итә. Бу паром 150 метр чамасы озынлыктагы калын бау белән елганың уртасындагы маякка тоташтырылган. Ике як ярда да ике такта пристань корылган. Ат арбалары, төрле йөкләр, юлаучылар белән тулган паромны чишеп жибәрәләр дә каршы якка таба агып барганда руль белән турылап тоталар. Паром шулай әле бирге, әле аргы ярга таба йөзеп тора, көндә берничә сәфәр ясый. Аргы якта зур шәһәр булмагач, аз санлы юлчыларны ташып торыр өчен күпер төзеп тормыйча әнә шундый кулай юл тапканнар.

Красноярскида пристань да бар. Июньнән октябрьгә хәтле елга буендагы шәһәрләр арасында пароходлар йөреп тора. Елгада боз ката башлагач, бу хәрәкәт туктала. Боз ныклап каткач, елгалар чана юлына әверелә. Атларының тоякларын дагалап алган чана хужалары туңган елгаларны каты жирдәге юлларга караганда да кулайрак күрә.

Красноярскиның көньяк-көнбатышында урманнар белән капланган Саян таулары күренеп тора. Бу таулар—Кытай белән Себерне аерып торучы Алтай тауларының төньяк тармаклары. Шәһәрдәге халыкның күпчелеге Себер руслары. Кечкенә генә мәчет тотучы татар жәмәгате азчылыкта.

Әсирләр лагеры—Красноярскидан кырык минутлык ераклыктагы тигез бер урынга корылган хәрби казармалар шәһәрчеге. Бу казармалар рус гаскәриләре өчен төзелгән булса да, сугыш башлангач бушап калган биналарга хәзер төрек, алман,

---

[1] Юка тиредән тегелгән тәбәнәк үкчәле ботинкалар (француз сүзе).

[2] 1914 нче елның декабрендә Әнвәр пашаның әмере белән Кавказ фронтындагы төрек сугышчылары кышкы шартларга хәзерлекле булмаган көе Кавказга якын Сарыкмыш дигән урында русларга каршы һөжүмгә күтәрелә. Әмма искитмәле кыен шартларда барган сугыш төрекләргә бик кыйммәткә төшә. Төрек армиясе бик нык кырыла, күп кенә сугышчылар туңып үлә. 15 меңләбе русларга әсир төшә.

австрияле һәм мажар офицерлары белән солдатларын урнаштырганнар. Биналар барысы да яна, кирпечтән төзелгән. Кайбер урыннарда төзелеш эшләре тәмамланып та җитмәгән. Офицер казармаларын койма белән уратып алганнар. Почмаклардагы такта манараларда күзләүчеләр тора. Солдат казармалары, шифаханә биналары койманың тышкы ягында. Без бишенче номерлы казармага урнаштык. Бүлмәдәшем музыкант офицер иде.

Лагерьдагы бөтен милләтләрнең офицерларына бер айда 50 сум, полковникларга 75 сум, генералларга 100 сум "эш хакы" бирәләр иде. Сугышка катнашучы бөтен дәүләтләр кара-каршылык принцибына нигезләнеп оештырылган бу түләү эшен төгәл үтиләр иде. Әлбәттә, халыкара Кызыл Хачның күзәтеп торуы да бу мәсьәләдә тәэсирен күрсәтә иде. Беренче елларда бу акчадан унбиш сумны Макаров исемле ашханә хуҗасына бирә идек. Калган акчаны өс-башка, кырыну әсбапларын алуга һәм башка шунын ише зарури ихтыяҗларга тота идек. Шәһәргә чыгар өчен лагерь сакчыларының җитәкчеләреннән рөхсәт алырга кирәк. Теш дәвалау, лагерьда булмаган әйберләрне юнәтү кебек эшләр өчен сакчы солдат сагында бару шарты белән бу рөхсәтне бирәләр иде. Рөхсәт алып шәһәрдән тун, бияләй, шосон кебек кышлык кием сатып алдым, бераз алмаш эчке кием дә юнәттем.

Аякларымдагы тунган урыннарны бер австрияле докторга күрсәттем. Итальян милләтеннән булган бу доктор бик зирәк, теле телгә йокмый торган шат күңелле кеше иде. Аякларымны карагач:

—Син моны халык ысулы белән дәвала. Бу лагерьда фәнни даруны каян табыйк. Юынганда аякларыңа кайнар су белән салкын суны алмаш-тилмәш кой. Туңган тирең кабарып чыгар. Кабарган урыннарны чиста пычак белән тишеп яхшылап кыр, астыннан яңа тире чыгар,—диде.

Доктор әйткәннәрне барысын да төгәл үтәдем, чыннан да файдасын күрдем.

Казармаларның тәрәзәләре һәм ишекләре ныгытып ясалган[1], тәрәзәләр ике кат пыялалы. Бүлмәләр "печь" дигән үзенә бер төрле мичләр белән җылытыла. Руслар көн дә бер тапкыр утын өләшәләр. Казармадан берәр офицер һәр көн утын өләшү урынына барып, җеп белән тарта торган кечкенә кул чанасына төяп утын алып кайта. Хезмәтче солдатлар утынны мичләргә ташый.

Мичне чистартканнан соң көн дә бер тапкыр утын тутырып ягып җибәрәләр. Ялкын морҗага китәр алдыннан мичнең кирпеч түшәп ясалган гөмбәз рәвешендәге түшәмен бер ялмап ала. Утыннар күмерләнеп төтен чыгармый башлагач, морҗаның капкачын ябып куялар. Мичнең түшәме биек булганга күрә эчтә күмерләрне озак вакыт сүнмичә тотар өчен җитәрлек һава була. Томаланган морҗа да җылыны суырмый. Мичнең утын сала торган авызын да томалап куйгач, бөтен җылылык мичнең эчендә бикләнеп кала. Бу җылы озакка бара. Утынны әрәм итмичә куллануның игътибарга лаек үрнәге булганга күрә, бу ваклыкларны теркәп китүне файдалы булыр дип уйладым.

Лагерьда һәр милләт төркеменең үз башлыгы бар. Төркем эчендә иң югары хәрби дәрәҗәгә ия булган бу затка рус идарәсе белән элемтәдә тору вазифасы йөкләнгән, группадагылар идарәгә аерым-аерым мөрәҗәгать итмиләр, теләкләрен башлыкларына белдерәләр. Рус идарәсе белән бергә сөйләшеп оештырылган тәртип буенча, авыруларны карау һәм шифаханәдә дежур тору эшен әсир докторлар башкара. Әгәр берәр әсир үлеп китеп, кыш вакыты булса, Себердә кыш көне туңган җирне казып булмаганга күрә, үлгән кешенең гәүдәсен исемен белгертеп келәт кебек бер урынга куеп торалар, язга чыккач, йомшара төшкән туфракны казып күмәләр иде.

Иртән торгач, яхшылап киенеп тышка чыгабыз, тыштагы һаваның нинди булуына карамастан лагерьны бер-ике тапкыр әйләнеп киләбез, шул рәвешле тәннәрне язып, хәрәкәтсезлектән котылабыз. Кирәкле әйберләрне дә иртәнге якта сатып алабыз. Монда сөтне кечкенә чиләкләргә салып төнгә тышта калдыралар, иртәнгә чаклы сөт чиләк калыбын алып туңган була, бу сөт башларын авыл кешеләре капчыкка тутырып алып килеп безгә саталар иде.

[1] Төркиядәге климат йомшак булганга күрә, тәрәзәләрне, ишекләрне җиңелчә ясыйлар, калын итеп ясау яисә тишек-тошыксыз итеп сылап ныгыту ягын әлләни кайгыртмыйлар.

Төшке ашка кадәрге вакытны әсирләрнең күбесе тел өйрәнүгә багышлый. Алманнар, австриялеләр һәм мажарлар төрекчәне, төрекләр алманча һәм мажарчаны өйрәнүгә күнел биргән иде.

Русиянең эчендә булсак та, лагерьда руслар белән аралашмыйбыз диярлек. Рус телен өйрәнергә теләүчеләр табыштыра алган китаплардан өйрәнергә тырыша, ләкин сөйләм телен үстерер өчен аралашу кирәк, анысына мөмкинлек юк.

Бу шөгыльләрдән башка тагын рәсем, карикатура ясаучылар бар иде. Австриялеләр һәм мажарлар арасында скрипкада уйнаучылар шактый, болар иртәләрен чарлакка менеп уйныйлар. Айда бер-ике тапкыр оперетта да куела. Руслардан рөхсәт алып әсирләр бер ат абзарын казып амфитеатр рәвешенә керттеләр, менә дигән сәхнә дә корып куйдылар. Австрияле һәм мажар офицерлар арасыннан сәхнә тәртибен һәм режиссер һөнәренең нечкәлекләрен белүче затлар да чыкты. Хатын-кыз роленда уйнаучы яшьләрне шундый оста буяп-бизәп куялар, әйтерсең, чып-чын туташлар уйный!

Төрек офицерлары да Хөсәен Рәхми Гүрпынарның "Мөрәббия" романын водевиль рәвешенә китереп уңышлы гына сәхнәләштерделәр.

Кайберәүләр шахмат уенына күнел куйды. Оста уйнаучылар арасында ярышлар да уздырыла иде. Спорт уеннарыннан да ваз кичмибез. Ике параллель колга өстендә гимнастика хәрәкәтләре ясау дисеңме, узышып йөгерүләр дисеңме, барысын да булдырабыз. Атна ахырында кичләрен футбол матчлары оештырыла. Без төрекләр бер команда тәшкил итәрлек санда түгел идек. Шулай да имән кебек таза ике егетебезне Австрия-Мажарстан командасы бик теләп үзләренә катнаштыра иде. Без исә иптәшләребез керткән голларга учларыбызны җәлләмичә кул чаба идек.

Русиядә матбугат цензура күзәтүе астында торганга күрә, әсирләр лагеренда рус газеталары һәм сугыш хәбәрләрен бирүче бюллетеньнар ирекле рәвештә сатыла, боларның сатышын тыюны кирәк тапмыйлар иде. Ләкин чит ил газета-журналлары сатышта юк. Алманнар һәм австриялеләр почта аша илләре белән безгә караганда ешрак һәм кулайрак хәбәрләшеп торалар иде, безнең ул яктан хәлебез канәгатьләндерерлек түгел. Әсирләрнең махсус ачык открыткаларына язып гаиләмнән Шәмседдин Саминең сүзлеген[1] сораган идем. Открытканы салганнан соң җиде ай ярым узгач кына җавап хаты белән сүзлекне алдым. Сүзлекне жентекләп тентегәннәре беленеп тора, битләре таушалган, тышлыгы ертылган иде.

Сугыш бетми дә бетми, тормыш итүләр исә торган саен кыенлаша. Бөтен нәрсәнең бәясе искиткеч артты. Элегрәк азык-төлеккә генә түгел, өс-башны юнәтүгә дә җитеп килгән 50 сум акча чак-чак тамак ялгарлык кына булып калды. Кайсыларыбыз билбауларының эченә тегеп яшереп калган госманлы алтыннарын берәм-берәм көн йөзенә чыгара, алтыннары булмаганнар булган әйберен сата, яисә илгә кайткач түләргә сүз биреп акчалы иптәшләрдән бурычка алып тора иде. Акчаны эшләп табуны булдыручылар да бар иде.

Ләкин акчаны табу гына тамак мәсьәләсен хәл итәргә җитми иде шул. Лагерьга азык-төлек бик чикләнгән микъдарда китерелә иде. Русча "каша" дип аталган көрән төстәге пылау[2] көндәлек ризыгыбызга әйләнде. Итне—анысы да ат ите—атнага ике тапкыр бирәләр.

Тормыш итүләре бик авырлашты. Әсирләр генә түгел, шәһәрдәге руслар да зарлана, канәгатьсезлекләрен бездән дә яшерми башлаганнар иде.

Рус гәзитләренең тәрҗемәсеннән Русия Думасындагы кайнар бәхәсләр турында мәгълүмат ала идек. Болардан рус дәүләтендәге хәлләрнең рәте киткәне беленеп тора иде.

Ниһаять, революция чыкты. Баштарак лагерьдагы тәртипләрдә әллә ни үзгәреш булмады. Керенский вакытында рус идарәсе белән мөнәсәбәтләр искечә барды. Бары тик берничә алман һәм австрияле офицерның качып китүе генә лагерь халкын

[1] Шәмседдин Сами (1850 – 1904) – төрекләрнең мәшһүр язучысы һәм тел белгече. Монда "Камусы төрки" (төрек теле сүзлеге) (1901) дигән хезмәте турында сүз бара, күрәсең.

[2] Карабодай боткасы булса кирәк.

дулкынландырган бер вакыйга булды. Руслар болар безнең кинлекләрдә бик еракка китә алмас, тиз арада тотылырлар дип сөйләнсәләр дә, качкыннарны лагерьга кире кайтара алмадылар.

1917 елның кышыннан чыгып барганда качу уе безнең башыбызга да кереп утырды. Ләкин бу уйны тормышка ашыру өчен өч нәрсә кирәк иде: акча, лагерь тышында безгә ярдәм итәрлек ышанычлы кешеләр һәм кышның узып китүе.

Без качарга хәзерләнеп яткан арада Рәсәйдә бер-бер артлы мөһим вакыйгалар булып узды. Керенскийның Галиция атакасы барып чыкмагач, халыктагы канәгатьсезлек соңгы чиккә житте, бу хәлдән оста файдаланып, кызыллар илгә баш булып алды. Бөтен жирдә кызыл комитетлар оештырыла иде, болар идарәне үз кулларына ала башлады.

Кешелекле мөгамәләсе белән әсирләр арасында уңай бәя казанган полковник Коновалов та вазифасын Красноярск кызыл комитетыннан килгән бер товарищка тапшырды. Коновалов китәр алдыннан як-ягына каранып алганнан соң безгә: "Сез киләчәктә ничек тә ватаныгызга әйләнеп кайтырсыз, бу бәладән котылырсыз. Чынында сез түгел, без әсир",—диде.

Кызылларның иң беренче эше офицерларга 50 сумлык "эш хакы" бирүне туктату булды. "Тамак туйдырырлык икмәк бирербез, яктырту-жылыту эшләрен карарбыз. Моннан арысы безне кызыксындырмый",—диделәр. Дөресен әйткәндә, бу вакытка хәтле хакимияттә алмашынган хөкүмәтләр барысы да үз исемнәрендә акча бастырганга күрә, рус акчасы искиткеч кыйммәтсезләнгән иде, ул 50 сумны бирделәр ни дә бирмәделәр ни, безнең өчен моның бер мәгънәсе дә калмаган иде.

Хәлләрнең болай мөшкелгә китә башлаганын күргәч акчамны бик исәпләп тота башлаган идем. Шулай булса да бурычка керүдән котыла алмадым. Ике иптәштән берәр алтын лира бурычка алдым.

Шәһәрдә кара базар эшли башлады, озын сакаллы яһүдиләр арадашчы булып шәһәр белән лагерь арасында килеп-китеп йөриләр. Бер госманлы алтыны төргәк-төргәк рус акчасына тәнгәл иде.

Качарга дип планнар корып ятканда идарәнең кызыллар кулына күчүе безне бераз уйландырды. Боларны белмәссең, әллә ниләр күрсәтерләр. Бер көнне бер алман унтер-офицеры лагерь коймасы яныннан узып киткән. Сакчының кисәтүенә катырак жавап биргәнме, аңлашылмаучанлык килеп чыкканмы, сакчы атып жибәргән. Яраланган офицер шифаханәдә үлде.

Күмү церемониясенә бөтен союзникларның армияләреннән вәкилләр катнашты. Алман офицерлары бу хәлне халыкара Кызыл Хачка белдереп хат яздылар.

Кызыллар террор ысулын әсирләр лагеренда да куллануданбер дә тайчанмыйча, шул рәвешле үзләренең хакимиятен ныгытып урнаштырырга һәвәслекләрен күрсәттеләр. Алман офицерын тик торганда үтереп ташлау моның беренче үрнәге булды. Шулай да без максатыбыздан кире кайтмаска дип күнелгә беркетеп куйдык.

Тешемне дәвалау сылтавы белән шәһәргә барырга рөхсәт алдым. Бер рус солдатының сагында шәһәргә киттем. Юлда сөйләшә алган хәтле русчам белән солдатны юмаларга тырыштым. Баксаң, кызыл товарищның да нечкә жире шул ук тәмәке белән акча икән.

Үзем тартмасам да, мондый очраклар өчен гел кесәмдә йөртә торган тәмәке янчыгыннан товарищны кат-кат сыйладым. "Теш докторыннан соң шәһәр мунчасына барырга уйлаган идем дә, товарищ мунча ишеге төбендә көтеп торып йончымас микән"—дигән булып сүз башладым.

Арабызда шундый сөйләшү узды:

—Өч елда икенче мәртәбә шәһәргә чыктым, ичмасам бөтен эшләремне бетереп кайтыйм.

—Мина барыбер, дөресен әйткәндә, минем дә кайбер эшләрем бар. Мин хәзер сина үзәк урамда бер урын күрсәтермен, сәгать өчтә шунда очрашырбыз, лагерьга бергә кайтырбыз.

Рәхмәт әйтеп, тәмәке һәм бераз акча бирдем.

Үзәк урамдагы кондитерский янында очрашырга сүз куешып, икебез дә үз юлыбызга киттек. Бераз йөреп алгач, татар мәхәлләсенә юнәлдем. Бер австрияле

кавалерист офицер А. әфәнденең[1] исемен биргән иде, аны эзләп таптым. Австрияле офицер бу зыялы татарның качкын австрияле офицерларга ялган паспорт табыштырып ярдәм иткәнен сөйләде, ләкин бу кеше зарар күрмәсен өчен әлеге мәгълүматны сер итеп сакларга кушты.

А. әфәнде минем төрек икәнемне белеп алгач, төрек туганнарга бигрәк тә теләп ярдәм итәчәген белдерде. Фәкать арадашчыларга бирелергә тиешле акча микъдарында аңлашырга кирәк иде. Паспорт башына 80 сум дип килештек. А. әфәнде хәрби форма кимәскә, гади рус халкы киенгән кебек киенергә кушты. Безне Красноярскида поездга утыртырга сүз бирде. Шундый киңәшен дә әйтте: "Аклар булсын, кызыллар булсын, Русиядә бөтен эшне акча хәл итә, җитәрлек акчагыз булмаса юлга чыкмагыз. Акчагыз булса, бөтен кыенлыкларны җиңеп чыгарсыз".

А. әфәнде белән саубуллашканнан соң урамнарда йөренүче, үз борчуларыннан башкаларына карар хәле калмаган халык арасыннан курыкмыйча узып, сүз куешкан урынга киттем. Сакчы солдат белән очрашып, лагерьга кайттык.

Иптәшләр мине сабырсызланып көтеп торган. А. әфәнде белән сөйләшкәннәремне аңлатып биргәч, хәзердән үк качып котылган кебек шау килеп сөенештек. Гамәлебез бик өметле башланып киткән иде.

Нәкъ шул вакытларда колагыбызга адмирал Колчак дигән исем чалына башлады. Тирә-яктагы авыллардан лагерьга төрле әйберләр сатарга килүче рус агайларының әйтүенә караганда, Колчак кызылларның чамасыз кыланышларына түзеп тормыйча тирә-ягына кеше җыйнап, кызылларның кирәген бирә башлаган, көч-куәте көннән-көн үсә бара икән. Авыл агайлары боларны аңлатканда Колчакны хуплаганнары, ана эчләреннән уңыш теләгәннәре сизелеп тора иде. Идарәне кулларында тотучы кызыл товарищлар исә бу хәлне ничек тә сиздермәскә тырышалар иде.

Көннәрдән бер көнне бер мажар солдаты белән кызыл сакчы ниндидер мәсьәлә буенча талашып киткәннәр. Яннарыннан узып баручы мажар офицеры милләттәш солдатын яклап чыккан. Бу яклаудан батыраеп киткән мажар солдаты җирдән кирпеч кисәге алып сакчыга атып бәргәнме, әллә кизәнгән генәме, анысы төгәл билгеле булмады, ни дә булса булган, кызыл сакчы муенында эленеп торган сыбызгысын сызгыртып бөтен сакчыларны аякка бастырды, кызыл солдатлар күз ачып йомганчы мылтыкларын эләктереп, лагерь мәйданына тәгәрәп таралып яттылар, коралсыз әсирләргә каршы тәртипсез рәвештә атарга керештеләр.

Әсирләр җан-фәрманга чабышып казармаларга качкан арада атыш тавышына килеп җиткән кызыл офицерлар дисциплинасыз солдатларын көч-хәл белән генә туктата алдылар. Бер мажар солдаты җинелчә яраланды, башка төрле зыян булмады. Бу вакыйганы сылтау итеп, кызыллар корал эзләп бөтен казармаларның астын өскә китерделәр, билгеле, берни дә тапмадылар. Алман офицерын үтергәннән соң килеп чыккан икенче террор вакыйгасы булды бу.

Кызылларның бу рәвешле тупас көч күрсәтүгә керешүләре юкка гына түгел икән. Себердәге хакимиятләре тотрыксызланган, шул зәгыйфьлекләрен яшерергә маташулары икән. Австриялеләрдән качып русларга бирелгән чехлардан мөстәкыйль чех легионы оештырылган иде. Шул чех легионы да Колчак көчләренә кушылып киткәч, Колчак кызылларны тар-мар итте. Рәсәйдә хәлләр искиткеч буталган иде, революцияләр алмашынып кына тора, хакимияткә әле бусы, әле тегесе менеп утыра. Менә безнең лагерь да инде хәзер Колчак идарәсенә күчте, сакчыларыбыз да хәзер кызыл солдатлар түгел, чех легионерлары иде.

Бу арада качу хәстәрләребез дә шактый алга китте. Бер иптәшебез шәһәргә төшеп, А. әфәндедән сиксәнешәр сумнан ялган паспортлар алып кайтты. Эчке паспортларга карточка ябыштырылмый икән, исем генә язылган. Яшь тә язылган, яшебезгә туры килерлек итеп паспортларны бүлештек. Минеке Егор Яноша Макаров исеменә язылган иде. Ялган исемнәребезне ятлап куйдык.

Узган вакыт эчендә әйберләребезне, китапларыбызны саткан идек. Тырышып-тырышып җыя торгач, кыйммәтсез рус акчасыннан мең сумга якын туплый алдым.

---

[1] Төрек офицерлары, үзләренә ярдәм иткән кешеләргә зарар килмәсен дип, истәлекләрендә аларның тулы исемнәрен язмаганнар.

Штатский киемем белән бүрегем шифаханәдә ятучы бер дустымның койкасы астына яшерелгән иде.

Лагерьның зур капкасында бер чех легионеры сакта тора иде. Австрия-Мажарстан империясенең ватандашлары булганга күрә, чехларның алман телен бик әйбәт сөйләшкәнен белә идек. Сакчының янына килеп, алман телендә:

—Шифаханәдә ятучы дустымның хәле авыр. Мине күрәсе килгән икән, ярты сәгатькә шифаханәгә барып килергә мөмкинме?—дип сорадым.

—Сезнең белән бергә барырга янәшәдә бер солдат та юк, бераз көтеп торырга туры килер.

—Хастаның хәлен бик авыр дигәннәр иде шул, миңа әйтәсе сүзе бар икән, ул-бу булмагае, тизрәк барып килим дип ашыгам.

—Ярар алайса, узыгыз.

Рәхмәт әйтеп, капкадан чыгып киттем. Артымнан карап торган сакчыны шикләндермәс өчен үз-үземне иркен, табигый тотарга тырышып, шифаханә урнашкан бинага таба юнәлдем. Шифаханәнең ишекләре лагерь капкасыннан күренми торган якта иде, сакчы минем анда ничек кереп чыкканымны күрә алмый иде.

Шифаханәдә штатский киемнәремне яшерелгән урыннан алдым, беркемгә дә күренмичә ашыгып киемнәремне алыштырдым. Офицер формамны алдан ук бер иптәшкә сату турында килешеп, акчасын да алган идем инде. Формамны ул иптәшкә тапшыруларын үтенеп, шифаханәдәге дуслар белән хушлаштым. Кечкенә төенчегемне, Себернең зәмһәрир кышларында мине моңарчы турылыклы җылытып килгән иске тунымны кыстырдым, бүрегемне йөземне яшерерлек итеп басып киеп куйдым. Ерактан күрүчеләр мине лагерьдан вак-төяк әйберләр сатып алырга килгән, хәзер менә култык астына төенчеген, берәүдән алган тунны кыстырып шәһәргә кайтып баручы искечегә охшатырга мөмкин иде.

Берничә иптәш "Ходай юлыңны ачык итсен" дип эчкерсез теләкләр тели-тели мине коридорга кадәр озата чыкты. Алар белән соңгы тапкыр саубуллашып, Аллага тапшырып, шифаханәнең ишегеннән чыгып киттем.

Юнәлешне шифаханә бинасы мине лагерь капкасындагы сакчының күзеннән ышыклап торырлык итеп сайлап алдым. Шәһәргә якынаеп барганда зират кырыеннан миңа таба килүче коралсыз рус солдатлары төркемен күреп алдым. Боларның янышнан узып китү минем өчен артык куркыныч булыр иде. Шундук юлымны үзгәртеп, зиратның сул ягыннан урауны сукмакка күчтем. Мана елгасы өстендәге такта күпер күренде. Аргы яктагы иңкүлектә татар мәхәлләсе урнашкан иде.

А. әфәнденең өен эзләп таптым. Үзе өйдә юк иде, хатыны: "Сез мәчеткә барып, анда көтеп торыгыз. Ул сезнең янга үзе килер,"—диде. Мәчетнең ишегалды ачык иде, кердем. Бераздан А. әфәнде дә килеп җитте.

—Үзегез генәме? Калган иптәшләрегез кайда?

—Алар да чыгып китәргә уңай форсат табып бер-ике көн эчендә килеп җитәргә тиеш.

—Сез шәһәргә чыгып йөрмәгез. Мин сезгә хәзер ашарга алып килермен. Монда кунарсыз, кичен безнең өйдән чәй дә китертермен.

Рәхмәт әйтеп, кушканча эшләдем. Август аеның ахыры иде. Һава безнең яклардагы көз һавасы кебек. Төнлә төенчегемне мендәр ясап, баш астыма салдым, тунымны ябынып яттым.

Иртәгесе көнне өч иптәшем килеп җитте. Лагерьда тагын ике иптәшебез калган иде, аларны көтеп бу көнне дә мәчеттә уздырдык. Барасы юлыбызны кечкенә картадан тикшереп, фикер алыштык. Исәбебез—Уралларның теге ягына чыккач, туп-туры Одессага юл тоту. Одессадан диңгез юлы белән кайтып булмаса, Добруҗадан урап кайтырга булыр дип фикер йөреттек. Адмирал Колчак көчләре белән Мәскәүдәге кызыл хөкүмәт көчләренең Урал тауларын чик итеп алып сугышып ятуын белсәк тә, без бу сугышны анда-санда кабынып-сүнеп торучы партизан сугышы рәвешендәрәк күз алдына китергән идек. Чынында исә бу сугыш 100-150 чакрымга сузылган тоташ фронт буенча бара икән.

Өч көннән Красноярск мәчетенең ишегалдында барлыгы алты төрек офицеры җыйналдык. Ике капитан, ике өлкән лейтенант, ике лейтенант.

Поезд Иркутск ягыннан кичке сәгать уннар тирәсендә килергә тиеш иде. А. әфәнде тоткан ике татар арбачысы безне сәгать тугызга таба станциягә китерде. Купе юлчылары кайсысы багажын урнаштыра, кайсысы диваннарда утырып тора, гади халык төенчекләрен кочаклап идәнгә урнашкан иде. Без дә аерым-аерым диваннарга утырдык. А. әфәнде билетларыбызны алырга кассага чиратка басты.

Иң башта Красноярскидан дүрт көн ераклыктагы Петропавловск шәһәренә китәсе идек. Анда татарлар мондагыдан күбрәк икән. А. әфәнде безгә андагы күренекле кешеләрдән Я. бай исеменә язылган бер хат бирде. "Бу хатны бары тик Я. байның кулына гына бирегез, башка беркемгә дә күрсәтмәгез!"—дип кисәтте.

Ниһаять, билетларыбыз алынды. Унбиш-егерме минутка соңарып поезд да килде. Перронның эче караңгы, кырык кешелек вагоннар бөтенесе дә шыгрым тулы. Кайсы вагонга гына үрелеп карамыйк, барысыннан да тупас русча тавышлар ишетелә: "Монда урын юк, кая тыгыласың?" Берничек тә урын табып урнаша алмадык. А. әфәндене дә күздән югалттык, өйрәнчек солдатлар кебек бер-беребезгә елышып аптырашып торабыз. Алты кешене бер генә вагон да кабул итми, поезд кузгалырга тора, нишләргә белми бөтенләй югалып калдык. Шулвакыт А. әфәнде күренде: "Бире килегез, бу вагонда безнең татарлардан ике сәүдәгәргә юлыктым, сезне аларга тапшырам, мин аларга барысын да аңлаттым",—диде.

Яна танышларыбыз бик тере, чая ике татар иде, Габдулла белән Шакирҗан. Болар шундук эчтәге русларның әйберләрен унга-сулга этәләп, безгә буш урын әзерләделәр. А. әфәнде белән хушлаштык. Поезд кузгалып китте.

Әлегәчә эшебез гел уң булды, юлыбызда бер киртә дә чыкмады. Шулай булса да, качышыбыз уңышлы барып чыгар микән дип борчылып берничә көнебез бик киеренке узган иде. Авыз исләре килеп торган ярым караңгы йөк вагонында тирән йокыга талдык.

Кырык кешелек вагонның эчен буйга тыгызлап, бүрәнә тезеп икегә бүлгәннәр. Өске һәм аскы кат хасил булган. Без аскы катта, уртада утырабыз, монда тирә-якны күзәтергә әлләни мөмкинлек юк. Хәер, без тирәбездә утырган русларга карамаска тырышабыз, алар да безгә игътибар итми кебек. Сүз куша калсалар, Габдулла белән Шакирҗан җавап бирәчәк дип сүз куештык. Без, имештер, базарга мал карарга баручы татарлар. Урысча әйбәт белмибез, безнең исемнән иптәшләр сөйләшә. Шакирҗан белән Габдулла поезд туктап торган арада ашарлык әйберләр сатып алдылар, бергәләп чәй эчтек. Беренче көнебез шулай хәтәрсез генә узып китте.

Икенче көннең кичендә кечкенә генә бер станциядә рус полицейскийлар юлчыларның документларын тикшерә башлады. Йөрәгебез убылып китте. Кинәшеп алгач, йоклаган булып кыланырга булдык. Паспортларны татар дусларга тапшырдык, полицейскийлар белән алар сөйләшәчәк иде.

Озын шинельле, кулбашлары повязкалы рус хәрбиләре эчкә керде. Башлыклары русчалап документларны күрсәтергә кушты.

Барча кеше документын әзерләде. Шакирҗан да безгә бармак белән төртеп күрсәтеп, "без сигез кеше, йоклап ятучыларның паспортлары да миндә" дип, документларны башлыкка сузды. Без керфек арасыннан тын да алмый күзәтеп ятабыз. Башлык паспортларны санап чыкты, иелә төшеп фонарен йөзебезгә якын китерде, менә хәзер торырга кушар дип куркып торганда кинәт кенә тураеп, паспортларны Шакирҗанга кире бирде.

Шакирҗан белән Габдулланың каз мамыгы тутырылган зур гына ике мендәре бар иде. Башлык бу мендәрләрнең берсен капшап карады да икесенә дә тышка чыгарырга кушты. Шакирҗан мендәрләрне күтәреп вагоннан төшеп китте. Полицейскийлар да тикшерүне тәмамлап вагоннан төштеләр. Без күзне уа-уа уянган булып Габдуллага шыпырт кына дәштек:

—Нәрсә, котылдыкмы?

—Сез котылдыгыз да менә без тотылдык.

—Ни булды?

—Сабыр итегез. Шакирҗан хәл итәргә маташа, ул килгәч аңлатырмын.

Шакирҗан озак кына килми торгач, Габдулла да вагоннан төште. Ни уйларга да

белмибез. Бераздан сулышы капкан Шакирҗан йөгереп килеп паспортларыбызны сорап алды да сигез паспорт тотып ашыга-ашыга янадан станция бинасына кереп китте. Бераз торгач, Габдулла белән Шакирҗан мендәрләрне күтәреп кире килделәр, поезд да кузгалып китте.

Эшнең асылын бераздан белдек. Баксаң, бу мендәрләрнең эчендә чәй каплары яшерелгән булган икән. Базарда бик кыйммәт бәягә сатылганга күрә, бу ике татар чәйне шулай яшереп мендәр эченә тыгып алып кайталар икән. Фонарь яктысы төшкәч, полицейскийлар башлыгы бу мендәрләрне күреп алган. Мендәрләр белән кызыксынып китмәгән булса, бәлкем, безнең паспортларны ныграк тикшереп, ялган икәнлекләрен тотып та алган булыр иде.

Шакирҗан белән Габдулла 15 сум биреп, полицейскийларны майлаганнар, кеше башына ике фунт чәй алырга рөхсәт булганга күрә, сигез кешенең өлешенә тигән 16 фунт чәйгә хаклары булганын раслар өчен безнең паспортларны да күрсәткәннәр, шул рәвешле мендәрләрне йолып калганнар.

Безнең котыбызны алган паспорт тикшерүеннән шулай мәзәк рәвештә котылырбыз дип башыбызга да килмәгән иде.

Сәгать уннар тирәсендә Петропавловскига барып ирештек. Безгә бу хәтле ярдәмнәре тигән татар дусларыбыз белән хушлашып, станциядә төшеп калдык. Бераз тирә-ягыбызны күзәтеп тордык. Юлчыларның берише ат арбасына утырып, калганы җәяүләп кенә шәһәргә таба юл тотты. Димәк, җәяү дә барып була икән дигән нәтиҗәгә килеп, без дә шәһәргә таба җәяүләп кенә киттек.

Кибетләр тезелеп киткән урамга барып җиткәч, кыяфәте татарга охшаган берәүдән Я. байның адресын белештек. Бу татар башта юлны сөйләп күрсәтте, ләкин безнең чит кешеләр икәнне аңлап алгач, бер яшүсмерне юл күрсәтергә дип безгә ияртеп җибәрде.

Я. байның йортына барып җиткәч, беребез өй хуҗасы белән күрешеп, А. әфәнденең хатын аңа тапшырды. Кем икәнлегебезне белгәч, Я. бай безгә кулыннан килгән бөтен ярдәмне күрсәтергә вәгъдә иткән. Мөселман диненнән булган мохтаҗ кешеләр татарлардагы гадәт буенча мәдрәсәләрдә яшәп тора икән, безгә дә Газизия мәдрәсәсенең бер бүлмәсенә урнашырга кушкан.

Иптәшебезнең бу хәбәренә барыбыз да бик шатландык. Юлыбыз бу юлы да унды болай булгач. Байның хезмәтчесе безне мәдрәсәгә илтеп куйды.

Я. бай Петропавловск шәһәренең—татарлар Кызыл Яр диләр—мәшһүр сәүдәгәрләреннән икән. Тире эше белән мәшгуль, мал фермасы да бар. Фәкыйрьләргә, мохтаҗларга гел ярдәм кулы суза икән. Халык үзен бик хөрмәт итә, руслар арасында да дуслары бар ди. Чыннан да бик мөхтәрәм, асыл зат иде.

Бер көнне безне өенә кичке ашка чакырды. Аштан соң залдагы китаплары арасыннан Истанбулда басыла торган "Шәһбал" җыентыгының—ул заманда Төркиядә чыга торган иң затлы журнал—төпләмәләрен чыгарып күрсәтте. Ватаныбыздан бик ерак җирләрдә Истанбул манзараларын карап утыру күңелләребезне нечкәртеп җибәрде.

Әңгәмә барышында Я. байга Одессага таба юл тотарга дип план коруыбызны да сөйләп бирдек. Ул бу уебызны хупламады.

—Колчак Себерне кулында тотып тора, мәгәр руслар Русиянең эчендә дә бик көчле. Моннан 300 чакрымнан соң сугыш аланы башлана, сез бу аланны, ай-һай, имин генә уза алырсыз микән. Мин үзем русчаны русларның үзләре кебек сөйләшә белсәм дә, ул тирәгә бару турында башыма да китерә алмыйм. Өстәвенә 150 чакрымнан соң хәрби идарәдән махсус рөхсәте булмаган кешеләрне поездга да утыртмыйлар.

—Алайса безгә нәрсә киңәш итәсез?

—Монда безнең татар җәмәгатенең яклавы астында яшисез. Тагын бераз торыгыз әле, аннары күз күрер,—диде бай. Аннары шулай дип тә өстәп куйды:

—Дала һавасына түзәрлек чыдамыгыз булса, бер котылу юлы бар барын. Моннан 250 чакрымдагы бер урыннан Төркестанга дөя кәрваны кузгалырга тора. Бу кәрванның хуҗасы минем дус, аңа хат язармын, ул сезне Төркестанга чыгарыр, анда хәтле барып җитә алсагыз, эшегез унайлашыр. Андагы халыкның күбесе русча

белми, сез дә аларнын арасында артык күзгә ташланмассыз. Халыктан ярдәм күреп Иранга чыгарсыз, аннан инде ватаныгызга да ерак калмый. Бу планнын барып чыгуы ихтимал, бөтен кыенлыгы бер айлык кәрван сәяхәтенә чыдауда.

—Бу мәсьәләне иптәшләр белән тикшереп карыйк, карарыбызны сезгә белдерербез,—дип, байнын самими һәм ягымлы мохитыннан аерылдык.

Бай үзе һәм анын бөтен гаиләсе шул хәтле ярдәмчел иде ки, безгә күрсәткән яхшылыкларынын әжерен ничек кайтарырга белмичә оялып бетә идек. Беребезнең башы авыртканын белеп алсалар да кирәкле им-том илтергә хезмәтчеләрен йөгерталәр. Байнын әнисе, мөхтәрәм байбичә, һәр иртәдә яна сауган сөт җибәрә иде.

Бу гаиләнең шул рәвешле безгә күрсәткән ярдәмнәрендә төрек милләтенә чиксез мәхәббәтләре чагылыш таба иде.

Бер көнне сүз арасында лагерьдагы итсезлекне, ат ите ашаганыбызны әйтеп киттек. Руслар пешереп биргән ат ите бик әче, озын җепселле була торган иде, ничарадан-бичара гына ашый идек дип, хатирәләребезне уртаклаштык.

Бай татарларнын ат ите ашаганын, теләсәк безгә аягына дага кагылмаган тай итеннән әзерләнгән теленне йотардай тәмле казылык җибәрәчәген әйтте. Бай җибәргән казылыкны бик ошаттык, чыннан да авызда эреп кенә китә иде.

Байнын кинәшен бераздан кабул иттек. Инде сентябрь ае узып бара, эшне тиз тотмасак, Себернен ул мәшһүр кышы безне язга кадәр бу шәһәргә бикләп куячак. Аллага шөкер, барыбыз да исән-сау, дала сәяхәте, чүлнең суык төннәре безне куркытмый. Әмма дә ләкин безнен өчен бөтенләй билгесез булган бу дөнья бераз өркетә. Бу кәрванчылар ышанычлы кешеләр микән соң? Берничә сум акчабызга кызыгып безне бер-бер хәл итмәсеннәр тагын.

Бу борчуларыбызны байга ачып биргәч, безне менә бу сүзләр белән тынычландырды ул.

Казакълар[1] күчмә халык булса да, диннән бихәбәр түгел, билгеле, авылларында дин укытучылары, ишаннары бар. Алар ишаннарга олы хөрмәт белән карый, сүзләреннән чыкмый. Мин моннан 500 чакрым ераклыктагы бер авылнын ишанына хат язармын. Сезнен исән-сау барып җитүегезне ул миңа хәбәр итәр. Бер-бер шигем була калса, сезне куркыныч астына куймас идем.

—Сезгә ихлас ышанабыз, бик зур рәхмәт. Алайса кайчан кузгалабыз?

—Кәрван хәзер моннан 250 чакрым ераклыкта тора. Даланын кырыенда дөяләрне утлаталар. Аларга өч арба бодай җибәрәсем бар, сезнең өчен тагын ике арба кушармын. Арбаларны безнен татарлар алып барыр. Алар юлны әйбәт белә. Бер-ике рус авылын узганнан соң ары юлда бер рус та очратмассыз. Инде казакъ даласына кереп киттегезме, Төркестанга хәтле русларнын исе дә юк.

22 сентябрьдә таннан торып юлга чыгып китәргә карар бирдек. Бу арада шәһәрдәге татар кибетләреннән юлда кирәгердәй төрле әйберләр алдык.

Я. бай белән хушлаштык. Бай казакъларнын кәрван башлыгына һәм ишанга язган хатларын бирде. Арбачыларны ныклап кисәтте, "Кадерле миһманнарны кәрван башына исән-сау тапшырганыгызны миңа белдерерсез",—диде.

Соныннан белдек, безгә сиздермичә генә арбачыга безнен дүрт-биш көнлек ихтыяҗыбызны күрерлек акча да биргән. Ходаем, ни кадәр асыл рухлы кешеләргә туры китерден безне!

22 сентябрьнен иртәсендә биш арба белән Петропавловскиның татар мәхәлләсеннән юлга чыктык. Олырак яшьтәге арбачылар йөк арбаларын алып бара, безнең өсте ябулы арбаны Хәкимҗан исемле яшь татарнын идарәсенә бирделәр. Хәкимҗан рус армиясендә ефрейтор булып хезмәт иткән икән, куәте ташып тора торган яшь ир. Юлда без мөмкин булган кадәре беркем белән дә аралашмаска сүз куештык. Кирәк-ярак сатып алу кебек эшләрне Хәкимҗан башкарачак иде.

Инде көз, агачлар яфрак коя. Урман эчендәге туфрак юлдан барабыз, әле ярый яңгыр яумый, юл сазлык була калса, арба кузгала да алмаган булыр иде.

Берничә рус авылын уздык. Хәкимҗан авылны чыгып җитәрәк бер урында

[1] Текстта "кыргыз" диелгән. Белгәнебезчә, бу вакытларда кыргыз дип казакъларны атаганнар, кыргызларны исә кыргыз-кайсак дип йөрткәннәр. Бүгенге атамаларга яраклы булсын өчен тексттагы кыргыз исеме тәрҗемәдә казакъка үзгәртелде.

арбаларны туктатып, үзе кире авылга китеп бара, авылдагы кешеләр белән сүз алыша, аларны тәмәке белән сыйлый, кыскасы, үзен бездән шикләнергә нигез калдырмаслык итеп тота иде. Тимер юллардан еракта калган, куе урманнарның кочагына сыенган бу авыллардагы халыкның тышкы дөнья белән кызыксынырга әлләни нияте дә юк иде шикелле.

Авыллар күбесенчә киң итеп ясалган озын юлның ике ягына тезелеп киткән агач өйләрдән гыйбарәт. Авылның уртасында агач чиркәү тора.

Өйләрне калын бүрәнәләрне бер-берсенең өстенә тыгызлап өеп куеп төзегәннәр. Һәр бүрәнәнең ике очында балта белән юнып ике тигез киртек ясыйлар, бүрәнәләрне бу киртекләрдән бер-берсенә эләгеп торырлык итеп өсте-өстенә өяләр, аннары бүрәнә араларын көймә палубасын эшкәрткән сыман мүкләп сумалалыйлар. Өйләрнең тышкы диварлары менә шушындый калын тоташ массадан хасил була, түбәне калын табаклы калай белән каплыйлар, калайны кызыл яки яшел төскә буйыйлар.

Гомумән алганда, Русия белән Себернең урманы мул булган төшләрендә авыл өйләре гел шушындый рәвештә була. Боларның ишекләре һәм тәрәзәләре бик ныгытып ясала. Мич өйнең эчендә була, бу мичтә икмәк тә пешерәләр, шул ук вакытта җылысыннан да файдаланалар.

Төркестан кебек урмансыз җирләрдә өйләрне кирпечтән салалар.

Хәкимҗан безне Карс дигән ерак губернадан ярминкәгә мал карарга килгән татарлар дип таныштыра. Ул “ерак губерна”ны надан авыл кешеләре генә түгел, бераз хәреф таныган руслар да белә алмый иде. Бер тапкырында Төркестанда бер кызыл офицер “Карс наш или ваш?” дип сорады. Шул рәвешле наданлыгын ярып салучы бер бу кызыл офицер гына булды. Күбесе исә исемен ишетмәгән губерна турында сорашып торуны да кирәк тапмый иде.

Тимер юлдан ераклаша барган саен авыллардагы халыкның йомыкыйлыгы да арта бара. Авылларыннан узып баручыларга карата бернинди дә кызыксыну галәмәте күрсәтмиләр. Авыллар барган саен тагы да артта калганрак, тагы да пычраграк була иде, чиркәү алдындагы мәйданда дуңгызлар борыннары белән пычрак сөреп йөри, шунда ук бала-чага уйный.

Моңа хәтле исән-имин генә бару безнең күңелләрне күтәреп җибәрде. Без инде авыл кешеләреннән качмыйбыз, Хәкимҗан белән бергә әңгәмәгә кушылып китәбез. Берәр узып киткән авылны атап, шул авыл кешесе икәнебезне, андагы кыен хәл-әхвәл, чиркәү янындагы кибетнең такырланып калуы һ. б. шуның ише гадәти әйберләр турында сөйләшкән булабыз. Сугыш чоры нужасыннан иза чигүче авыл кешеләре безне ихлас күңелдән ышанып, теләктәшлек белән җөпләп тыңлап тора.

Урманнар сирәгәя бара, көз вакытының аллы-гөлле урман манзарасыннан әкренләп ялангач далага күчәбез. Сазлыклы кечкенә күлләр өстендә меңләгән кыргый үрдәк пырылдап оча.

26 сентябрьнең кичендә Имәнтауга барып җиттек. Без күргән беренче казакъ авылы иде бу. Хәтта моңа авыл димичә, күчмә казакъларның бер тукталыш урыны дип әйтсәк дөресрәк булыр шикелле. Чөнки казакълар, тирә-якта хайваннарын туендырырлык үлән калмагач, тирмәләрен дөяләргә төяп күчеп-күчеп китәләр, авыл торган урынны күрсәткән билге булып чишмә яки кое гына торып кала. Шуңа күрә казакъ авылына “су башы” дип тә әйтеп була.

Имәнтау тигезлегенә дөяләр таралган, чәнечкегә охшап торган биек үләннәрне чәйниләр, бер тирмәнең тирәсенә дөяләргә төяр өчен пар-пар булып бәйләнгән, бодай тутырган капчыклар өелгән, тирмәгә кереп-чыгып үз эшен карап йөргән хатын-кызның башы-йөзе ачык, нәкъ бездәге йөрек яки төрекмән кабиләләрендәге кебек.

Хәкимҗан белән без утырып торучыларны “Әссаламегаләйкем!” дип ихлас күңелдән сәламләдек. Исәнләшкәч, Хәкимҗан кәрван башына Я. бай язган хатны бирде.

Иске тунын билбау белән кысып буган, аяк бөкләп утырган урта яшьләрдәге казакъ агайның кысык күзләре хатны укып чыкканнан соң тагын да ялтырабрак китте. Елмаеп безгә күз йөртеп чыкты, “Аман-әсәнме!” дип берәм-берәм хәлебезне белеште, кулларыбызны кысты.

—Тиваләр (дөяләр) туйды, ике көн эчендә кузгалып китәрбез. Ходайның ярдәме белән сезне ишан хәзрәткә кадәр илтеп куярбыз. Ләкин казакълар фәкыйрь кешеләр, хайван хакы итеп ни бирерсез?

Озак сатулашып тормыйча гына кеше башына 50 сумнан аңлаштык.

Кәрван башы Хәкимжанга:

—Без бу мохтажларны Ходай ризасы өчен генә дә илтеп куяр идек тә, үзен дә күреп торасың, болар йөкле дөяләргә атланып барасы, хайван хакын алдык, байның хәтере калмасын,—диде. Аннан соң безне исән-сау кабул итеп алганын белдереп байга кыска гына хат язды.

Арбачылар бодайны казакъларга саткач, кире кайтырга кузгалдылар. Я. байга шулхәтле ярдәмчеллеге өчен олы рәхмәтебезне тапшыруын үтенеп, Хәкимжан белән берәм-берәм хушлаштык. Я. байның ярдәме һәм планы булмаса, качышыбыз Петропавловскида ук терәлеп калган булыр иде. Себернең зәһәр кышы безне шәһәргә бикләп куйган булса, нишләр идек?

Казакълар белән дә, татарлар белән дә тел ягыннан авырсынмыйча аралашабыз. Илебездә Кырым мөһаҗирләренең сөйләшкәнен гел-гел ишетеп торганга күрә, татарларның телен бер дә авырсынмыйча аңлый идек. Казакъ теле безгә татар теленең гадирәк, сүз хәзинәсе бераз ярлырак рәвеше булып тоелды. Мәсәлән, казакълар "күчәмез" дип әйтәләр, моның мәгънәсен безнең "гөч" (күчү) сүзеннән аңлап була. "Нан ашамыз" дисәләр, фарсы телен белгәнгә күрә, "нан"ның "икмәк" икәне, "ашамыз" сүзен бездәге "ашчы" сүзеннән фикер йөртеп, "икмәк ашыйбыз" дигәннәрен аңлап ала идек.

"Кудук" сүзенең "кое" икәнен белеп алгач, "кудук башына төшәмез" җөмләсен аңлау бер дә авыр булмый иде.

Без казакъларны җинел аңласак та, алар безне аңлап житкерми иде. Шуңа күрә сөйләшкәндә телебезне үзгәртеп, казакъ теленә охшатырга тырышып сөйләшә идек. Мәсәлән: "Коега кайчан барып житәрбез?" дип сорарга теләсәк, "Кайда кудук башына барамыз?" дип әйтә идек.

Кайбер диалект аерымлыкларын исәпкә алмаганда, Әрзәрумнан Владивостокка кадәр нигездә уртак төрки телдә сөйләшеп аңлашып була.

Алтай тауларында туып, төньякка таба агып ятучы Иртеш елгасы белән көньяк Урал таулары һәм Урал елгасы арасындагы киңлекләр картада Казакъ далалары дип күрсәтелә. Даланың җәе дә, кышы да кырыс. Монда офыклар ачык диңгезләге кебек күз житмәс ераклыкларга сузыла. Бер тамчы су булмаган бу корылыклы тигезлек офыкка кадәр буп-буш булып сузылып китә, ник шунда бер калкулык, агач яисә кеше булсын. Бу бушлык өстендә кайвакыт күзебезгә кечкенә күл шикелле каралып торган таплар чалынса да, якыная төшкәч бу таплар ялгызы гына торган тирмә белән бер-ике дөягә әверелә, шулай итеп миражның безне алдатканын аңлап ала идек.

Далада көньякка таба саксаул исемле куактан зуррак, агачтан кечерәк үзенә бер төрле үсемлек үсә. Бу үсемлекнең ботаклары коп-коры, шыртлап тора, аны ягулык итеп кулланалар. Революция елларында руслар Төркестан тимер юлларын менә шул саксаулны ягып эшләттеләр. Янгырлар әйбәт яуса, далада тәбәнәк кенә үлән үсә. Казакъларга менә шул үлән кирәк тә инде. Корырак жирләрдә тимьян житешә, дымлы урыннарда камыш сабаклы үсемлекләр күренгәли.

800 километр буенча беркайда да сука яки сабан очратмадык. Казакълар игенчелекне бөтенләй ташлаган, хайван асрап көн күрә. Бу халык ат, дөя, сыер, сарык, кәҗә тота, тире, йон, май сатып, үзенә кирәкле бодай, тоз, чәй ише әйберләрне сатып ала.

Казакълардагы кебек киң күләмле хайванчылык өчен киң алан кирәк. Казакълар үлән беткәч тә ул урыннан янасына күчеп китә: җәйләрен төньякка, Себергә таба, кышларын исә кире юнәлештә күченеп, шулай әйләнеп йөри. Бу күчмәлек казакъның канына сеңгән, безнең өчен үзебезнең мәхәлләбез ни булса, казакъ өчен бу меӊ километрлык киңлекләр дә шул, ул аларны уч төбе кебек белә, аның өчен 800 километр арадагы кое безнең мәхәллә чишмәсе кебегрәк.

Казакъ күрше тирмәгә дә җәяү бармый, атка атланып бара; һәр тирмәнең янында иярләнгән ат тора. Балаларны кечкенә яшьтән үк иярсез атның сыртына куеп атта

йөрергә өйрәтәләр. Бер тапкырында унбиш яшьләрендәге бер казакъ кызының атын бар көченә чаптырып өч йөзләп елкыны куып барганын күрдек. Болар—Урта Азия далаларының ковбойлары. Менә дигән җайдак булсалар да, казакълар һич тә сугыш чукмары түгел, тынычлык сөюче халык, араларында бер генә кораллы кеше дә күрмәдек. Ауда да корал кулланмыйлар, лачын кошы белән аулыйлар. Кайчак үз араларында хайван урлау вакыйгалары булгалый икән.

Казакъ тирмәсен кәкре очлы 10-12 колганы түгәрәк буенча бастырып куеп, боларның өстенә калын киезләр ябып, киезләрне баулар белән бәйләп куеп ясыйлар. Тирмәнең очында төтен чыксын өчен тишек калдыралар. Тирмәнең эчендә яту урыннарын түр бүлмәдән бүлеп аерып куялар. Һәр тирмәдә ярым түгәрәк рәвешендәге казан, өчаяк, агачтан уеп ясалган подностар, самавыр була.

Хатын-кызларның йөзе ачык, башларына кигән биек башлыклары белән бездәге төрекмән кабиләләрендәге хатыннарга охшап торалар. Өч итәкле күлмәк кияләр.

Хатын-кыз кымыз ясый, киез баса, су ташый, кер уа; ягар өчен шайтан таягы яки чыбык-чабык җыю, сөт саву кебек эшләрдә дә катнаша.

Кымыз ясар өчен бияләрдән сауган сөтне зур турсыкка салып, бездә катык ясар өчен сөткә оеткы салган кебек, иске кымыз кушалар. Бу турсыкны учакның янына элеп куялар, килгән-киткән кеше турсыкның тар авызыннан эчкә тыгып куелган таяк белән сөтне бутап ала, ничәдер көннән кымыз өлгереп җитә. Кымыз—сыра шикелле көч бирә торган, хәл кертеп җибәрә торган эчемлек, касә тутырып эчеп куйсаң, тук та тота. Рус докторлары кымызны үпкә чире белән интегүчеләргә киңәш итәләр.

Бер авылда казакъ байларыннан берничәсе безне ашка чакырды. Мәҗлестә кунаклар озын палас өстенә кара-каршы аяк бөкләп утыралар, уртада агач подносларда түбәләмә өелгән пешкән ат ите, касәләрдә—кымыз. Бишенче, алтынчы кымыз касәсеннән соң кәефлә генә гөрләшү башлана.

Кунаклар подностан ит кисәге алып дусларының авызларына куеп сыйлыйлар. Мондый хөрмәтне кире кагарга ярамый, югыйсә сине сыйлаучыны үпкәләтәсең. Без бу гадәтне белгәнгә күрә, мәҗлеснең кәефен уртаклашып, казакълар авызыбызга куйган ит кисәкләрен рәхәтләнеп ашадык, үзебез дә аларны сыйладык. Кымыз касәләре бушап-тулып кына торды...

Бер авылда казакъ туена туры килдек. Яшь кызлар җыелышып дарбука[1] кагып казакъ көйләрен көйлиләр. Рәт-рәт алтын тәңкәләр тезелгән башлык кигәннәре, күрәсең, бай кызлары булгандыр. Яшь егетләр атта ярыштылар. Кияү кеше кайбер өй әйберләре белән бергә күп кенә мал да бүләк итәргә тиеш икән. Туйга халык шагыйрьләре—акыннар да килгән иде. Кәрванчылардан безнең кем икәнлегебезне белеп алгач, акыннар безнең хөрмәткә сазларында уйнап, Әнвәр пашаның[2] офицерлары үзләрендә кунак булганлыгы турында көйләп киттеләр.

Петропавловскиның көньягындагы Имәнтаудан Төркестан тимер юлы өстендәге Ак Мәчет станциясенә 25 көндә барып җиттек. Юл буенча бер генә рус авылын да, бер генә рус кешесен дә очратмадык. Казакъ юлдашларыбыз бик ышанычлы, безгә карата искиткеч җылы һәм самими булганга күрә, безнең өчен күнегелмәгән шартларда узган бу сәяхәтнең мәшәкатьләре безне һич йончытмады.

Тарих китапларында борынгы заманнарда Урта Азиядән кузгалып киткән кәрваннарның Урта дингезгә кадәр барып җитеп Финикия шәһәрләренә мал китергәннәрен укыган идек. Меннәрчә ел элек йөреп торган кәрваннар белән хәзерге замандагы кәрваннар арасында бернинди аерма юк. Уртача кәрван 200-500 дөядән барлыкка килә. Иң алда баручы дөягә юлны белүче, тәҗрибәле кеше атлана. Иң алдагы дөя бик озын атлап баручы эре хайван да, вак атлаучы кечкенә дөя дә булмаслык итеп, кәрвандагы бөтен дөяләр арымыйча үз җайлары белән иярерлек уртача тизлек белән баручы уртача дөя сайлап алына.

---

[1] Чүлмәк рәвешендәрәк барабан.

[2] Әнвәр паша (1881–1922)–төрек сәясәт эшлеклесе, "Иттихат вә тәрәккый" партиясенең лидерларыннан берсе. Беренче дөнья сугышы вакытында Госманлы империясенең хакимияте "Иттихат вә тәрәккый" партиясенең кулында була, бу вакытта Әнвәр паша сәясәттә әһәмиятле роль уйный. Госманлы империясе сугышта җиңелгәч, Әнвәр паша Урта Азиягә китә һәм анда Совет хакимиятенә каршы көрәш оештыра. 1922 елда кызыллар белән сугышта һәлак була.

Дөяләрне йөкләгәндә дә хайваннарның куәтен исәпкә алалар. 150ләп дөяне берсенең тезгенен икенчесенең өркәченә бәйләп, бер тезмә ясыйлар. Дөяләр 150дән артык булса, артып калганнарын аерым тезмәгә тезәләр. Һәр тезмәнең башына, уртасына, ахырына дөячеләр куела. Дөя балаларына йөк йөкләмиләр, алар тезмәдәге аналары янәшәсендә иректә бара. Юлда берәр дөя авырып китсә, йөгенең күп өлешен башка дөяләргә күчереп, йөген жиңеләйтәләр.

Казакъ дөясе—бездәге һәм Гарәбстандагы дөяләргә караганда күпкә эрерәк, суыкка чыдамлы Урта Азия дөясе. Бу дөяләрнең муеннарындагы йоннарның озынлыгы 60 сантиметрга кадәр житә, чүл эссесенә дә, кыш чиләсенә дә түземле булалар. Юлга чыгар алдыннан дөяләрне салам һәм көрпә катнаштырылган камыр йомарламнары белән тукландыралар, иртәдән кичкә кадәр утлаталар. Шуннан соң ашказаннарына тутырылган запасны күшәү һәм кичләрен өч сәгать чамасы гына утлап алу дөяләргә юл ахырына кадәр житә.

Дөяләрнең бөтен кирәк-ярагын—бауларны, йөк ияләрен, кылдан үреп ясалган капчыкларны казакълар үз куллары белән ясый. Моның хәтле эре гәүдәле хайваннарны даланың уртасында максатка ярашлы рәвештә куллану, билгеле сәгатьтә утлауга чыгарып билгеле сәгатьтә жыеп алу, тезләндерү, йөкләү, билгеле вакытта кәрванны юлга чыгару—шактый катлаулы эш. Ләкин казакълар бу эшләрне жиңеләйтерлек чараны тапканнар. Бу чара белән биш яшьлек бала да дәү дөяне тыңлата ала.

Дөянең бала чакта ук борыннарындагы пәрдәләрен тишеп, каты агачтан юнып ясалган таякчык тыгып куялар, аның бер очы кадак эшләпәсе сыман юанрак була, икенче очына калын тире кисәген беркетеп, таякчыкны дөянең борынынан чыкмаслык итәләр. Дөя үсеп житеп хезмәткә кергәч, борынындагы бу таякчыкка жеп бәйләп куялар. Жепне тарту дөянең борынын уңайсызлый, авыртуга түзмичә, дөя әмерләргә буйсынырга мәжбүр була. Шул рәвешле, ияр яки башлык тагуның кирәге дә калмый. Хайваннарны яклау оешмалары бу ысулны хупламас иде, билгеле, ләкин казакълар сүзенә караганда шактый холыксыз хайван булган дөяләрне тыңлатуның бирдәнбер чарасы бу икән.

Кәрван кояш баюга өч сәгать кала су башына туктала. Башта дөяләрне чүктереп, йөкләрне бәйләгән бауларны бушаталар. Дөяләрне янадан торгызып иреккә жибәрәләр, йөкләре шунда чүгәләгән төшләрендә торып кала. Дөяләр өч сәгать чамасы якын-тирәдә йөри, су эчә. Караңгы төшкәч, аларны жыеп алалар. Һәр дөяне үз йөгенең уртасына чүктерәләр. Тамагы туйган хайван шуннан соң торып йөрми.

Таң атарга өч сәгать кала кәрванчылар торып, дөяләрнең йөген бәйләп беркетәләр. Бу эш тәмам булгач, бөтен дөяләрне аякка бастыралар. Кәрван кузгалып китә. 12 сәгатьтә кәрван 30-35 чакрым юл үтә. Су башы ерак булганга күрә ике тапкыр 40 чакрым барырга туры килде.

Бөтен сәяхәт буенча өч мәртәбә генә авылга тукталып тирмәдә кундык. Калган төннәрне ачык һавада яттык. Казакълар таң тумас борын торырга күнеккән халык, һәрвакыт бездән иртәрәк торып, "Әйдәгез, торыгыз, дөяләрегезнең йөген бәйләгез!" дип безне уяталар иде. Без йөкләрне бәйләргә булыша идек, ләкин тәжрибәсез булганга күрә озаклап маташабыз, ике-өч дөяне йөкләгәнче казакълар егермеләп дөяне йөкләгән була. Дөресен әйткәндә, йокыдан ачылып бетмәгән күзләрне уа-уа, төнге суыктан куырылып дөя йөкләү бер дә күнелле эш түгел икән. Ләкин кәрван юл графигыннан тайпылмасын өчен моны эшләргә кирәк иде.

Кайвакыт казакълардан тагын күпме юл калганын сорыйбыз. Сәгать яки чакрым белән әйтеп, шактый төгәл җавап бирәләр иде.

Дөя чүгәләгәндә һәм чүгәләгән хәлдән торганда өркәчләре бик каты селкенә, яхшылап тотынмаган булсаң, мәтәлчек атып очып төшәсең. Шуна күрә менгәндә дә, төшкәндә дә дөяне чүктермәү яхшы. Казакъ ысулы буенча иң кулае—басып торган дөягә менү. Ул болай була: дөянең борынындагы жепне тартып башын идерәсең, йөзеңне өркәчләргә юнәлтеп дөянең муенына атланасың, жепне бушаткач, дөя башын күтәрә, шул вакытта сине катапультадан атып жибәргән шикеллерәк итеп өркәчләренә таба ыргыта. Сиңа өркәчләрдәге йоннарга тотынып капчыклар уртасына жайлап утырасы гына кала.

Төшкәндә исә дөянең муеныннан аска гына шуасы. Бер-ике тапкыр менеп-төшеп карагач, җайлашып китәсең, бер авырлыгы да юк.

Корабльләрдә һәрвакыт дежур күзәтүче булган шикелле кәрванның иң башындагы дөядә һәрвакыт уяу булырга тиешле бер казакъ бара. Ул төнлә йолдызлардан, көндез тояк эзләреннән, тизәкләрдән юнәлешнең дөреслеген күзәтеп бара. Бер мәртәбәсендә кәрванныбызның капитаны юлны югалтты. Дөянең өстендә аягүрә басып офыкларны карап чыкты, ахырда даланың соры үләннәре арасында күренер-күренмәс беленеп торган ерактагы ноктачыкны шәйләп алып, юнәлешне турылады. Кәрван башлыкларының эз табу һәм кое якынлыгын сиземләү сәләтләренә барыбыз да хәйран калдык.

Дөяләрне бер-беренә тоташтырганда борыннарындагы таякчыкка калын бау бәйләмиләр. Таякчыкка нечкә генә йон җеп бәйлиләр, бу җепкә тоташтырылган калынрак бау бер дөяне икенчесенә куша. Нечкә йон җепнең хикмәте шул: әгәр дөя арып китсә, җилкә калкымы яраланса, хәлсезлектән алдагы дөянең тизлегенә җитешә алмый башласа, бау киерелә башлый. Күпмедер вакыттан соң йон җеп өзелеп китә, җепнең калынлыгы дөянең борын пәрдәсен ертмыйча өзелерлек итеп исәпләнгән була. Җеп өзелеп алдагы дөя әз генә ераклашуга арттагы дөя белән кәрванның калган өлеше туктап кала. Дөяче шундук алгы очка: "дөя купты!" дип сөрән сала. Алгы як та туктап, хәлсез дөянең йөген бушаталар. Йөкне башка дөяләргә тигезләп бүләләр, дөянең үзен кәрванның койрыгына күчерәләр яисә кәрван тышына чыгаралар.

Кәрванда без дә казакълар шикелле тукландык. Ит мул, икмәк юк. Юлда очраган көтүләрдән сарык сатып алабыз. Казакълар сарыкны пәке белән генә суеп тазарта. Итләрне ике өлешкә бүлеп, ике дөягә куябыз.

Кичен су башына туктагач, беренче эш итеп учак хәстәрлибез. Кайсыбыз чыбык-чабык, кайсыбыз бездән алда узган кәрваннардан калган тизәкләрне җыя. Тизәкләр арасында иң яхшы янучысы дөя тизәге булыр. Кып-кызыл төскә кереп куәтле эссе бирүче дөя тизәген тизәкләрнең антрациты дип атап була.

Ярым гөмбәз формасындагы казакъ казанына ит турап салып, шуны пешерәбез. Кайнап торган шулпага берничә камыр кисәге дә кушып җибәрәбез. Бу камырларны кечкенә уклаулар белән үзебез җәябез. Ашарга утыргач, кеше башына берәр кило ит белән бишәр кисәк пешкән камыр төшә иде. Дөресен әйткәндә, икмәксез ит ашый идек. Казакъларда он әз, шуңа күрә далада икмәк пешерү гадәтләре юк.

Аштан соң чәй эчәбез. Учакта су кайнатып Я. бай бүләк иткән кирпеч чәйдән[1] сындырып алган кисәкләрне кружкаларыбызга салып пешерәбез. Хәер, җыелып торган мүкләнгән суларны башка төрле эчеп тә булмый иде. Кайбер урыннарда су бик тозлы да була торган иде.

Кирпеч чәй дигәннәре менә шундыйрак әйбер: фабрикада чәй катнашмасы ясаганнан соң төптә җыелып калган чәй тузаннарын пресслап калын шоколадка охшаш тәгәрмәч формасына кертәләр. Моны пәке белән кайнар суга кырып салсаң, менә дигән чәй була. Төрле-төрле чәй катнашмаларыннан барлыкка килгәнгә күрә бу кирпеч чәйнең тәме искиткеч шәп иде.

Ашап алу шулай кичләрен генә, тәүлеккә бер мәртәбә була иде. Шулай да без көндез дөя өстендә кимергәләргә дип янчыбызга бераз сөякле ит кисәкләрен ала торган идек.

Бер тапкырында сарык итебез бетте, сатып алырга юлда сарык көтүе дә очрамады. Бер казакъ безгә дөя ите әзерләде, ләкин аның пешүен сәгатьләр буе көтәргә туры килде, җитмәсә каеш кебек бер нәрсә булып чыкты.

Шул рәвешле, сәяхәтебез буенча бердәнбер ризыгыбыз ит белән чәй булды.

Өченче октябрьда Бикташҗан авылына таба юл алып ятканда бик каты җил исә башлады, күп тә үтми бу җил күз ачырмаслык буранга әверелде, башта кар катыш яңгыр, аннары бурап-бурап тоташтан кар яварга тотынды. Дөяләрнең өстендә аякларыбызны алмаш-тилмәш астыбызга кыстырып утырып җылытырга тырышабыз. Бер аяк оегач, икенчесен кыстырасың. Буран булгач, кәрван өчен юлдан язу

[1] Таһсин Ийбар такта чәйне "кирпеч чәй" дип язган.

куркынычы да артып китте. Казакълардан тәҗрибәлерәге иң баштагы дөягә кучеп утырды, өсләреннән кар себереп торган иске эзләрне ничек тә куздән югалтмаска тырышып бара-бара, билгеләнгән вакыттан шактый кичегеп авылга барып ирештек.

Бу авыл ярыйсы гына зур икән, 50-60 тирмә тора. Авыл борчу эчендә иде. Көчле бураннан көтуләр бер-берсенә буталып беткән, кәҗә ише вак баш хайваннардан бер өлеше югалган, шуларны эзләргә дип төрле якка җайдаклар китеп тора. Безне тирмәләрендә кунак иттеләр, шулай итеп мондый кар-буранда тышта кунудан котылдык.

Иртәгесе көнне буран тынган иде. Җир өстендә кар булганга күрә, кәрван ул көнне көн яктыргач кына юлга кузгалды. Кичкә таба кәрванчылар безне тапшырып калдырасы ишанның авылына барып ирештек.

Ишан үзенә күрә белемле, акыллы зат иде. Безнең кәрван башлыгы ишанга Я. бай язган хатны бирде. Ишан: "Сез юл килеп арыгансыздыр, берничә көн бездә кунак булып торыгыз, шул арада сезне Төркестанга җиткерерлек чараны Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән табырбыз. Мондый һавада сезне теләсә кем белән җибәрә алмыйм. Үзе дә, дөяләре дә ышанычлы булган кешене табарга кирәк",—диде.

Күнелебездәге бердәнбер теләк ватаныбызга мөмкин булган иң тиз вакытта барып ирешү теләге булса да, бу яхшы күнелле кешеләрнең саклык йөзеннән безне тоткарлавына карышмыйча күнүдән башка чарабыз юк иде.

Ишан безне үз тирмәсендә кунак итте. Биш көннән соң безгә ышанычлы юл күрсәтүче һәм дөяләр табылды, ул арада көньяктан искән җылы җилләр һаваларны да йомшартып җибәргән иде.

Түрәкол исемле дөяченең житәкчелегендә җиде дөя белән юлга чыктык. Түрәколга сәяхәтебезнең акчасын алдан ук түләп куйдык. Ишан хәзрәт Түрәколга безне Төркестанның Ак Мәчет каласындагы Җиһанбәй исемле бер танышына тапшырырга кушты, безне исән-имин илтеп җиткерергә дип ныгытып кисәтте. Түрәкол яхшы күнелле, диндар кеше иде. Юлда барганда аның чыннан да ишанның ышанычына лаеклы тәҗрибәле юл күрсәтүче булганлыгын күрдек.

Бер-ике тәүлек бик тә буш, кеше яшәми торган урыннардан бардык. Барган саен саксавыл күбәя бара. Бу безгә бик тә ярап тора, чөнки төннәрен җылыныр өчен тизәк урынына саксавыл ягабыз. Һаман көньякка таба барсак та кыш артыбыздан калмый куып килә, җилсез генә кар явып тора. Кичләрен Түрәкол дөяләрнең өстендә йөрткән киезләрдән кечерәк кенә чатыр корып куя, чатырның керешенә саксавыл өеп ягып җибәрәбез. Күмеренең җылысы танга кадәр җитә. Бер тапкырында төнлә ерактан бүре улаган тавыш килде. Беребездә дә корал юк, бары тик Түрәколның киңәше белән учактагы утны сүндермичә саклап тоттык. Бүреләр уттан курка икән.

Инде Төркестанга якынлашып киләбез, анда-санда агачлар күренгәли, димәк, чүлдән чыгып барабыз. Түрәкол еракта күренгән яшеллекнең Сыр-Дәрья үзәне икәнен әйткәч, барыбыз да әйтеп бетергесез сөендек. Болай булгач, сәяхәтебезнең икенче этабы да уңышлы рәвештә тәмам булды.

Киртләч-киртләч булып торган бер калкулыктан аска төшкәч, алдыбызга камышлы сазлык килеп чыкты. Сулары яртылаш туңган, кырыйларына боз каткан. Түрәкол билдән суга кереп, дөяләрне берәм-берәм үзе генә белгән сукмаклардан теге якка чыгарды.

Чүлдә узган бер ай вакыттан соң янәдән урман, бакчалар һәм кирпеч өйләр күрдек. Себердән котылу шатлыгы күңелләребезне күтәрде. Төркестанда бик аз кеше генә русча белә, безнең ярым-йорты русчабыз монда беркемдә дә шик уяндырмас. Я. бай чыннан да бик урынлы киңәш биргән иде.

Егерменче октябрьдә җиде дөя өстендә чып-чын төркестанлылар кебек Ак Мәчет каласына барып кердек. Ишан хәзрәтнең танышы Җиһанбәйгә барып төштек. Түрәкол дөяләрне бер кәрвансарайга илтеп куйды, кичкә таба безнең белән хушлашырга килде. Балаларына күчтәнәчкә бераз Төркестан җимешләре алсын дип берничә сум акча бирдек. Бу ихлас күңелле казакъның безгә карата күрсәткән фидакарьлеге акча белән генә түләп бетермәслек иде.

Кирпеч өйләре, койма урынына тирәкләр белән уратып алынган бакчалары

белән безнең Анадолу калаларына охшап тора торган Ак Мәчеттә ике төн кундык. Ак Мәчет—"Оренбург-Ташкент" тимер юлы өстендәге бер станция. Җиһанбәй Ташкентка баручы поезд турында белешергә тиеш иде.

Иртәгесе көнне каланың базарын йөреп кайттык. Ничә айдан соң беренче тапкыр кипкән җимешләр күрдек. Бер җимеш төре игътибарыбызны җәлеп итте. Бау кебек ишеп куйган бу кипкән җимешнең ни икәнен сорадык, "кипкән кавын" диделәр. Зур кавынны бер сантиметр киңлегендә телем-телем кисеп күләгәдә киптерәләр икән. Сүле кибеп, катылыгы киптерелгән инжирнеке кебек булгач, өч-дүрт телемне бау ишкән кебек үреп куялар. Бер кадак кипкән кавын алып татып карадык, мондагы кавыннар бик шикәрле булганга күрә, бозылыр, әчер дип шикләнмичә шул рәвешле киптереп була икән. Соңыннан әфганлы бер хаҗидан ишеттек, Төркестанда елга ярларындагы комлыкларда кырыктан артык сорт кавын үстерелә икән.

Җиһанбәй белеште, берсекөнгә Ташкентка поезд бар икән. Поездларга гаскәриләр хуҗа, станция чиновниклары да хәрби форма кигәннәр. Бер гаскәри поездга станция шефы күпме кушса шуның хәтле генә гадәти юлчы алынасы икән. Без дә көтеп торучы юлчылар төркеменә кушылдык. Акчабызны барлап торганда станция чиновнигы безнең кулдагы Керенский акчалары арасында патша сумнарын да күреп алды.

—Патша сумы белән түләсәгез, сезгә шундук билет табып бирәм,—диде.

Без дә шундук хәлне аңлап алдык, патша сумнары белән түләп, кичекмәстән билетларыбызны алдык. Керенский акчасына һәм кызыллар баскан сумнарга караганда халык иске акчаны—патша сумнарын артыграк күрә иде.

Төркестан бу вакытта кызылларның кул астында иде. Бөтен җирдә кызыл исполкомнар.

Поезд килде, ябык вагоннар хәрбиләр һәм сугыш кирәк-яраклары өчен икән, гадәти юлчылар ачык вагоннарга урнашты. Юлда күбесенчә агачлыклар, бакчалар янынннан уздык, иген кырларын, ындыр табакларын күрмәдек диярлек. Ул елны Төркестанда кытлык булган икән, революцияләр аркасында тимер юл бәйләнеше дә еш-еш кына өзелеп торганга күрә, күп җирләрдә ризык житмәүчәнлек үзен шактый сиздерә иде. Кайбер станцияләрдә тирә-яктан җыелган бала-чаганың вагоннардан ыргытылган икмәк катыларын, балык башларын чүпләгәнен күрдек.

Иртәгесе көнне иртән Ташкент станциясендә төштек.

Иске Ташкент белән руслар төзегән яңа Ташкент янәшә торалар... Хөкүмәт биналары, банк, станция, клуб ише зур корылмалар—яңа шәһәрдә. Яңа шәһәр соңрак һәм планлы рәвештә төзелгәнгә күрә, биналар төзек, урамнар туры һәм киң. Генерал Кауфман һәйкәле алты юл аерылып киткән мәйданда тора. Сугыш, революция һәм кытлык аркасында шәһәр боегып калган. Кызыллар сәүдәханәләрне тартып алганга күрә, халык бөтен вакытын дәүләт кибетләре алдына тезелеп чират көтеп уздыра иде.

Иске шәһәр үзенең арыклары, тирәкләре, бакчалары, бигрәк тә алма бакчалары (монда алар "әлмазар" дип атала) белән нәкъ менә безнең Анадолу шәһәрчеге. Иске шәһәрнең бер-ике урамы бераз киңәйтелгән булса да мәхәллә эчендәге урамнар тар, өйләр теләсә ничек урнашкан.

Руслар җирле Ташкент халкын "сарт", "үзбәк" дип төрле исемнәр белән атап йөртә. Мондагы халык казакълар кебек кысык күзле түгел. Сөйләшүләре үзгәрәк булса да, казакълар белән дә аңлашалар. Гәливатымән, гидиватимән дип сөйләшәләр. Телләрендә шактый күп фарсыча алынма сүз бар. Башларына бездә "Төркестан таккәсе" дип атала торган тәкыя, өсләренә "чапан" дигән озын халат киеп йөриләр.

Патша заманында голәма тәэсире астында яшәгәнгә күрә, үтә тәкъва халык. Казакълардан аермалы буларак, мондагы шәһәр халкы тәсәттергә[1] бик тугрылык күрсәтә. Урамда хатын-кыз бөтенләй күренми диярлек, мәхәлләдә күршегә генә чыгып керүчеләр дә күзләре дә күренмәслек итеп ябынган була.

Ташкентны барыннан да элек җиләк-җимеш мәмләкәте дип атап була. Кайбер җимешләр руслар тарафыннан культуралаштырылган, мәсәлән, бик тәмле алма

[1] Тесәттер—(гарәпчә пәрдәләнү, бөркәнү, ябыну, каплану дигән сүз) ислам динендә хатын-кызга чит ир-атлардан качарга, өс-башын кием белән ябарга кушучы тәртип.

һәм груша төрләре бар. Ләкин җимеш төрләре Төркиядәгегә караганда әзрәк, бездәге кебек хуш исле дә түгел. Ташкент чүлләр белән уратып алынганга күрә, монда җәйләр кызурак була, шуна күрә җимешләре баллырак.

Бер ташкентлы безне өендә кунак иткәндә дүрт төрле варенье белән сыйлады. Боларның барысын да шикәр кушмыйча гына ясыйлар икән. Башта җимешнең суын кайнаталар, ул куерып "ширин" булгач, шуна җимешнең үзен салып кайнаталар икән. Менә дигән варенье була.

Төркестандагы халыкның баш ризыгы—пылау. Бу пылауга озынча итеп туралган кишер дә салалар. Нечкә итеп туралган ит һәм камырдан ясала торган "нарин" дигән ризыкны да яратып ашыйлар. Бәрәнгегә әле ияләшеп кенә киләләр, бәрәнгегә "рус ризыгы" дип каршы чыгучы фанатикларны да күрергә туры килде.

Мәҗлесләрдә аяк бөкләп утырган кунаклар алдына тәбәнәк озын өстәлләр тезәләр, бу өстәлләргә күп төрле тазә һәм киптерелгән җиләк-җимеш куялар. Шул җиләк-җимешне капкалап, самавырда пешкән чәйне касәләргә салып күпләп эчәләр. Касәнең авызы өскә карап торса, табынга хезмәт итеп торучы кеше сездән рөхсәт сорап тормыйча аны бушаган саен тутыра бирә. Әгәр инде чәй эчәсегез килми икән, касәгезне әйләндереп каплап куярга кирәк.

Тормышы хәлле булган һәр ташкентлының өендә һичшиксез 15-20 данә юрган булыр. Бу юрганнар безнекеләрдән озынрак, үзләре ефәк тышлы. Боларны кат-кат ябынып яталар. Кыш көне әңгәмә өчен җыелганда урта урынга тандыр рәвешендәге мангал куеп, шуның тирәли утырышып, тезләрен юрганнар белән каплыйлар.

Әсирләр лагерыннан чыгып киткәнгә инде өч ай тулып ашты, без әле һаман юлда. Кыш та килеп җитте. Җирле халыкның сүзенә карасаң, Төркестанда кызыл идарәгә каршы теләсә кайсы вакытта баш күтәрү кузгалып китәргә мөмкин икән. Мондый борчулы, идарә ныклап урнашмаган заманда кышка каршы тәвәккәлләп кая да булса чыгып китү дөрес булмас.

Беренче көннәребезне Ташкентның могтәбәр кешеләрендә кунак булып уздырдык. Аннары бер мәктәпнең укытучылар бүлмәсендә тора башладык. Кыш беткәнче дүрт ай буе буш ятсак, кулдагы бөтен акчабызны тотып бетерербез дип, берәр төрле эштә эшләп алырга кирәк дигән фикергә килдек. Киңәш сорап мөрәҗәгать иткән ташкентлылар безгә башлангыч мәктәптә укытучы булып эшләргә тәкъдим иттеләр.

—Безнең монда һәр мәхәлләдә башлангыч мәктәп ачылып тора, укытучы җитешми. Укытучы булсагыз, эш хакы да алырсыз, балаларыбызны да тәрбияләрсез,—диделәр.

—Рус җирле идарәсе моңа каршы килмәсме соң?

—Бер дә борчылмагыз, хәзергесе вакытта бөтен мәсьәләне комиссарлар хәл итә. Сезне мәгариф комиссары мадам Сорокинага мактап тәкъдим итәрбез. Ул шундук сезне эшкә кабул итү турындагы боерыкка имза куяр.

Чыннан да шулай булды, безнең эшкә алыну мәсьәләсе җиңел генә хәл ителде, барыбыз да башлангыч мәктәпләрдә мөгаллим булып киттек. Мин үзем 41 нче мәктәптә укыта башладым.

Нәни ташкентлылар белем алырга атлыгып тора, мин сөйләгәннәрне йотылып тыңлыйлар. Гимнастика дәресләрен һәм мәктәп йортында марш атлап йөрүне бигрәк тә ошаттылар.

Революцияне котлау бәйрәмендә безнең мәктәп балалары да парадка катнашты. Кауфман һәйкәле янында тезелеп торган комиссарлар алдыннан төз рәтләр оештырып, матур атлап уздылар. Рус башлангыч мәктәбе балалары алай матур узмады, рәтләре буталды. Соңыннан җирле милләт комиссарларыннан ишетеп белдек, бер рус комиссар шунда, рус укытучыларның булдыксызлыгына ачуы килеп, мәшһүр рус сүгенү сүзен әйтеп җиргә төкергән икән.

Укытучы булып киткәч, һәрберебез үзенең мәктәбендәге укытучылар бүлмәсендә тора башладык. Мәктәпнең хезмәткәре безне карап тора. Атна ахырында дуслар белән очрашып сөйләшәбез, моннан соңгы юл турында планнар корабыз.

Бер көнне укучылар мәктәп бакчасында уйнап йөргән вакытта һәр яктан мылтык аткан тавышлар килә башлады. Боларга туп аткан һәм граната шартлаган тавышлар да кушылып китте. Балаларны шундук өйләренә озатып, мәктәп хезмәткәрләрен

ни булганын белешергә җибәрдем. Осипов исемле бер командир кызылларга каршы баш күтәргән икән. Көне буе Ташкент урамнарында сугыш барды.

Баш күтәрүнең беренче көнендә Осипов кызыл комиссарларның күп өлешен тезеп куеп аттырган. Кызылларга ярдәм килеп җиткәч, Осипов чүлләргә таба качты. Кызыллар өч көнлек Осипов идарәсе буенча аңа ярдәм иткән кешеләрне атып үтерделәр. Карап торышка, аклар да, кызыллар да нәфрәт һәм үч алу теләге белән хәрәкәт итә. Тойгыларына буйсынып эш итүчеләрнең хөкеме кыска, алар сорау алып, мәхкәмә[1] ясап азапланмыйлар.

Яз якынлашып килгәнгә күрә, без инде юлга кузгалу турында сөйләшә башладык. Укытучылык өчен алган эш хакын да кушкач, акчабыз җитәрлек булды, ул яктан борчыласы түгел. Поезд юлы белән Одессага яки Кавказга барырга булдык. Җирле халыктан дусларыбыз бу планыбызга каршы килсәләр дә, уебыздан кире чигенмәдек. 23 мартта поезд белән Оренбургка таба кузгалып киттек. Өченче класс билетлары алган идек. 30 мартта Эмба станциясенә килеп җиткәч, станция начальнигы бөтен пассажирларны поездан төшерде. Оренбург казаклары кызыллар белән сугышып ята икән, безнең поездны яраланган кызыл солдатларны ташыр өчен алганнар. Моны ишеткәч, аптырашта калдык.

—Безнең билетыбыз бар иде бит, инде нишләргә кушасыз?—дидек.

—Авылда кунып торыгыз, һәр көн килеп белешерсез, Ташкент юнәлешендә баручы поезд булса, сезне түләүсез кире утыртып җибәрербез,—диделәр.

Ничарадан бичара Эмба авылына таба юл тоттык. Пассажирлар арасында татарлар да бар иде, алардан берәү бу авылда бер-ике татар кешесе яшәгәнен әйтеп, безгә Сөләйман исемле бер татарны эзләп табарга киңәш итте. Сөләйманны эзләп таптык, ул безгә урын җәеп бирде, самавыр кайнаткан арада:

—Икмәгебез генә юк, безнең монда икмәк кытлыгы, гаскәриләр икмәгебезне үзләренә алалар,—диде.

Беренче көнне поездда алган пирожкилар белән туклandык. Икенче көнне авыл буенча икмәк эзләп киттем. Бер рус картыннан икмәк сатуын үтендем, поездан төшерелгән юлчылар икәнебезне әйтәм. Карт рус башта төксе генә:

—Без үзебез монда ачлыктан интегәбез, икмәкне каян табып бирим?—дип сөйләнде.

—Сез бит монда яшәүчеләр, икмәкне ничек тә юнәтерсез, менә безгә нишләргә?—дидем.

Рус үзалдына мыгырданып, хатынына дәште, акчалата хакын алып миңа ярты икмәк тоттырды. Рәхмәт әйтеп алдым, монда икмәкне акча белән дә табулары авыр.

2 апрельдә Ташкентка баручы поездга утырып, кирегә таба киттек. Юлда Арал күле янындагы тукталышта ысланган балык сатып торалар иде, башка пассажирлардан күрмәкче, без дә сатып алдык. Балыклар бик майлы һәм тәмле иде. Кышын өстенә боз ката торган бу күлдә балыкчылык бик алга киткән, шактый зур күләмдә балык экспорты ясала икән.

Ташкентка кайтып җиткәч, безнең бу юлга чыгуыбызга бер дә риза булмаган дусларыбыз:

—Әйткән идек бит сезгә юллар имин түгел дип, йә, күрдегезме инде?—дип шелтәләп каршы алдылар.

Ләкин безнең инде күңелләр урыныннан купкан, Ташкентта моннан ары торасыбыз килми. Бу юлы көньяк юнәлешкә чыгып китеп Иранга таба юл алырга дип план кордык, Бохара-Мәрв-Ашхабад-Мәшхәт аркылы барырга булдык. Бу план өчен барыбызга да ат кирәк иде.

Базардан ат сатып алып, атларны җирле дусларның абзарларына урнаштырдык. Сәяхәт өчен кирәкле төрле нәрсәләрне табыштырдык. Ул арада русларның Төркестанда качып йөргән төрек офицерларны эзләгәне турында имеш-мимешләр колакка чалына башлады. Шуна күрә, юлга билгеләнгән көннән дә иртәрәк кузгалып китеп, гадәттәге юлдан бармыйча, турыдан чүл аша китәргә булдык.

[1] Мәхкәмә—суд.

Кызылком һәм Караком чүлләрен узарга тиеш идек. Ташкентлы дуслар бу чүлләрнең казакъ далаларыннан да куркынычрак булганын әйтеп, аларны исән-имин узу өчен җирле халык ни әйтсә шуны төгәл үтәргә кирәклеген белгерттеләр. Безгә юл күрсәтүче итеп бер фәкыйрь казакъны таптылар. Казакъның ишәге бар икән, шул рәвешле казакъ ишәк өстендә, без атка атланып, алты кеше булып (төрекләр—дүрт офицер һәм бер трабзонлы солдат) Ташкенттан чыгып киттек.

Бер дуснын кышлагында төн уздырдык, безне озата килгән ташкентлы дуслар моннан кире кайтып киттеләр. Көньяк-көнбатышка таба юл ала башладык. Ике көн буе арыклардан су агып ята торган, тирәкләр үсеп утырган матур урыннардан бардык. Өч көннән соң Сыр-Дәрьяның ярына килеп җиттек. Юл күрсәтүчебез сөрән салгач, аргы яктан кечкенә генә казакъ көймәсе килде. Елганың киңлеге бу урында чама белән 500-600 метр иде.

Кешеләр өчәрләп көймәгә утырып, хайваннарны йөздереп елганы ике тапкырда кичәргә булдык. Хайваннар иркенләп йөзсен дип тезгеннәрне озын тотып суга кереп киттек. Ләкин атлар төрлесе төрле юнәлештә йөзеп киткәч, нәкъ агымсу кызу булган төштә көймәбез чайкалып әйләнә башлады, чүт кенә әйләнеп капланмадык. Шундук тезгеннәрне ычкындырып җибәрдек, иректә калган атлар ярда калган иптәшләренә таба йөзеп киттеләр. Безгә дә ирексездән кире әйләнеп кайтырга туры килде.

Бу юлы тезгеннәрне бик кыска тотып, хайваннарны башлары көймәнең кырыенда ук калыгып торырлык итеп бәйләдек. Шул рәвешле аргы якка чыгып ирешә алдык. Хайваннар йөзеп арган булганга күрә, ул көнне яр буенда ял итеп уздырдык.

Шул тирәдәге казакълар:

—Тагын бер төн кунгач, чүл комына кереп китәчәксез. Берәр фляга гына су җитмәс, сезгә турсык та кирәк булыр,—диделәр. Якын-тирәдәге тирмәләрдә эзләнеп безгә бер турсык табып китерделәр. Ләкин артык кибүдән ярылгалаган, әзрәк су саркытып тора иде. Моны озак кына вакыт суда җебетеп тотып, ямап куярга кирәк икән. Безнең моңа түзем бармыни? "Чүлдә нибары ике көн үтәчәк, ике көн өчен генә бу тишек капчыктагы су да җитәр әле"—дип юлга кузгалдык.

Кызылкомның комы кирпеч оны сыманрак. Язгы яңгырлар явып үткән булганга күрә, ара-тирә үлән дә шытып чыккан. Хәтта кыргый арпа да бар. Юл күрсәтүче казакъ ишәгенә атланып алган да аяк астындагы эзләрне күзәтеп уңга-сулга карамый юырта гына. Көн узып кичкә авышканчы эсседән ярыйсы ук әлсерәдек.

Кич җиткәч, "Шор кудук" дигән тозлы сулы кое башына тукталдык. Коедан алган суда мең төрле бөҗәк кайнаша иде. Шул судан чәй кайнатып эчтек, малларны сугардык. Икенче көнне иртән иртүк юлга кузгалдык. Иртәнге сәгать тугыз тирәсендә үк кояштан миебезне кайнатырлык эссе бәрә башлады. Төштән соңгы кызуны исә әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел. Казакъларның киңәше буенча, өстебездәге киемнәргә тыгызрак төрендек. Мондый эсседә тәнне кояшка ачарга ярамый, киресенчә, төреп тирләтергә кирәк. Тән һәрвакыт тирдән дымланып торырга тиеш. Шуның өчен әйбәтләп төренеп, мөмкин булса күп итеп чәй эчеп торырга кирәк. Тән кояшка ачылып кибеп китсә, көт тә тор, шундук кояш сугудан аңны югалтып егыласың.

Шул көнне бик зур куркынычка тарыдык, юл күрсәтүчебез эзне югалтып, кичкә таба барып ирешәсе коены таба алмады, турсык та гел су саркытып торганга күрә, суыбыз да бетүгә якынлашкан иде.

Иртәгесе көнне икендегә таба хайваннар да, кешеләр дә хәлсезләнеп калды. Кырыйларына катлам-катлам булып тоз утырган инешкә юлыктык, суы шул кадәрле тозлы, атларыбыз бер йотым да эчә алмады. Хайваннарның соңгы куәтен бетермәс өчен бик әкрен адым белән барабыз. Биш кешегә бер флягадан чак кына артыграк су калды. Бу кич тә су тапмасак, хәлебез харап...

Кояш баюга таба борылгач, бер калкулыктан сузылган күләгәгә ышыкланып туктап калдык. Бер иптәшебез сусызлыктан һәм эсседән тәмам гаҗиз булып саташып сөйләнә башлады. Әллә инде күзенә күренә, су тутырылган зур шешә турында сөйли һаман. Кояш исә рәхимсез куыра, шул калкулык төбендә уздырган ике сәгать җәһәннәм газабы булды. Ниһаять, кояш батты. Бер сәгатьтән соң чүл өсте әзрәк

суынды, без дә бераз исебезгә килеп, кыен хәлдән чыгу юлларын эзләп кинәшләшә башладык.

Хайваннарны төн буе чиратлашып утлатырга булдык, шул рәвешле аларның суга булган ихтыяжы күпмедер дәрәҗәдә канәгатьләнергә тиеш иде. Иртән таң атуга өч сәгать кала торып юлга кузгалырга, көндез көньяк юнәлешендә күргән тауларга турылап барырга булдык. Безнең фараз буенча, бу таулар һичшиксез Бохарага чиктәш таулар булырга тиеш иде.

Ятар алдыннан фляганың төбендә калган суны бүлештек. Бер тамчы сусыз, хәлдән тайган, чүл уртасында адашкан килеш төнне уздырырга җыендык. Гарәпләрнең "йә, ләйли!" дип төнгә, төннең җиләслегенә мөкиббән китүләренең хикмәтен чүлдә кунганда аңладык. Чыннан да куыргыч эссенең рәхимсез кочагыннан инде бетәбез дигәндә генә төн коткарып алды бит безне.

Йокламыйча вакытны күзәтеп торган иптәшебез сәгать төнге өч тирәсендә барыбызны да уятты, төнге җиләстән җанланып киткән атларга атланып, Тимер Казыкны артыбызга алып, көньякка таба юл тоттык. Сызылып таң атты, ком дулкыннары өстеннән тавыш-тынсыз өзлексез барабыз да барабыз. Төшкә хәтле берәр кое очратмасак, нишләрбез?

Кинәт кенә Сабыр (юл күрсәтүчебез):

—Туктагыз!—дип кычкырып җибәрде.

Туктап калдык. Сабыр тынлыкка тирә-якка колак салды да:

—Эт өргән тавыш ишетелә. Якын-тирәдә авыл булырга тиеш,—диде.

Калкулыкка мендек. Калкулыкның теге ягында тирмәләрне күрдек. Йөгерәатлый дигәндәй казакъ авылына барып кердек. Авылның зур кешеләреннән берәү безне кунак итте. Сабыр башыбыздан үткәннәрне аңлатты. Безне тыңлаучылар коены таба алмавыбызга гаҗәпләнделәр (бик якыннан узып киткәнбез икән), елның бу вакытында дөясез генә чүлне кичәргә маташуның башсызлык икәнен әйттеләр. Без кунак булган тирмәнең хуҗасы хайваннарга ашарга һәм эчәргә бирде. Безне милли ашлары—әйрән ашы белән сыйладылар. Йотлыгып эчеп сусыныбызны һәм ачлыгыбызны бастырдык.

Далаларның, чүлләрнең бөтен михнәтен татып яшәгән бу ихлас күңелле кешеләрдән күргән яхшылыкны, аларның безнең өчен күрсәткән фидакарьлекләрен әле дә олы рәхмәт хисләре белән искә алам. Әгәр аларның кунакчыллыгыннан көч тапмаган булсак, үзебезнең гайрәт белән генә качу планнарыбызны тормышка ашыра алмаган булыр идек.

Казакъ авылыннан соң корылыклы туфрак өстеннән бара башладык. Чүлнең мич авызыннан бәреп торган кебек эссе сулышы монда юк иде инде. Бохарага чиктәш тауларны ашып, ямь-яшел үзәнгә барып кердек. Табигать шартлары нинди кискен үзгәреп китте бит әй! Әле кичә генә җәһәннәм кебек ком дәрьясыннан барган идек, монда исә челтерәп сулар ага, бакчаларда төрледән-төрле җимешләр пешә, яшеллек җәйрап ята! Шундый капма-каршы шартларны нибары бер көнлек юл аерып тора.

Кичкә таба Бохараның "Нур Ата" дигән каласына килеп җиттек. Бохараны әмир идарә итә. Мондагы халык искитмәле тәкъва, җиледән җитмешенә башына чалма ураган, үз күзләре белән мәчеттә намаз укыганыбызны күрми торып беркем дә безнең мөселман һәм төрек булганга ышанырга уйламый да. Ул яктан караганда даладагы казакълар бик тә либераль кешеләр иде.

Атларга ял бирер һәм яңа юл күрсәтүче эзләр өчен Нур Атада өч-дүрт көн тордык. Монда торган арада өяз башлыгына хөрмәтебезне белдерергә дип хөкүмәт бинасына барып килдек, ләкин башлык урынында туры килмәде. Җирле казыйга кереп чыктык, бик могтәбәр зат. Безгә өеннән тазә ләвәшләр җибәрде. Мәчет янындагы зур бассейн эчендә балыклар йөзеп йөри, ләкин әүлия Нур Атага багышланган изге балыклар булганга күрә боларга беркем дә кул тидерергә кыймый икән.

Яңа юл күрсәтүче тапкач, бакчалар арасыннан юлыбызга дәвам иттек. Чакрым саен юлыбызны арык кисә, бер юлы солдат Хәсәннең аты арыкка егылып төште, төшенә хәтле суга күмелгән хайванны көчкә тартып чыгардык.

[1] Мәхкәмә—суд.

Шулай арыклар белән бакчаларга таралып беткәнгә күрә, Зәрәфшанның сулары бу үзәннән ары китми. Бохара шәһәренең янәшәсеннән уздык, кереп тормадык. Манаралар, мәчет гөмбәзләренең күплегеннән мөселман шәһәре икәнлеге күренеп тора.

Сарык тиреләре белән мәшһүр Каракүлдән узып киттек. Тирә-якта клевер басулары, абрикос бакчалары җәйрәп ята, сарык көтүләре очрый, көнчыгышта офык буйлап бик биек таулар тезелеп киткән.

Бохара җирләрендә эшкәртелмәгән бер генә буш урын да юк. Төркестандагы кытлык белән чагыштырганда монда бар нәрсә дә бар.

Аму-Дәрьяның кырыендагы Жаржуй дигән урынга килеп җиттек. Моннан Аму-Дәрья өстенә төзелгән зур тимер юл күпере күренеп тора. Төрекмән көймәләре белән аргы якка чыгарга тиеш идек. Төрекмән көймәсе бездәге баржалар кебек яссы төпле зур көймә. Атларны, дөяләрне, кешеләрне, арбаларны, төрле йөкне—барысын да сыйдыра. Хакын түләп аргы якка чыктык, инде төрекмән җиренә килеп җиткән идек. Моннан соң Караком чүлен кичеп Иранга кереп китәчәкбез.

Поезд белән барып булмый. Төрекмәннәр кызылларга каршы баш күтәргәннәр. Җүнәйт Сәрдан һәм башка башлыклары җитәкчелегендә кызыллар белән сугышып яталар икән. Шуңа күрә Мәрв юнәлешендә поездлар йөрми, барса да гаскәри поезд гына бара икән. Поездлар йөри торган булса да аларга утырып бармас идек, чөнки русларның күз алдында артык тулганып йөрисебез килми. Инде монда хәтле килеп җиткәч, тотылып харап булмыйк тагын.

Шулай итеп, чүлдән бару ышанычлырак күренә, ләкин юл күрсәтүчебез июнь аенда чүлне атлар белән кичеп булмас дип әйтә. Чыннан да, Аму-Дәрьяның ярына кадәр килеп җиткән ком бураннарыннан өелеп калган комнарны күрдек, рых[1] кебегрәк, кызыл комда үсемлек үсә иде, монда берни дә үсмәс. Бу бит—чәнечке дә үсми торган, урыннан урынга күчеп йөри торган агучан ком диңгезе дигән сүз. Ләкин бу Флорья пляжындагы[2] кебек табаннарны җинелчә пешергәли торган ком түгел инде. Бу—саксыз рәвештә килеп керүчене куырып көйдерә торган мич. Әлеге куркыныч чүлне бик оста төрекмән юл күрсәтүчеләр генә июнь аенда дөя белән узса узар, имеш. Анда да һәр дөянең корсагы астына бәйләп зур турсык белән су алмасаң, чүлгә керү турында уйлама да икән.

Алай куркыныч булгач, без Караком чүле эченә кермичә, Аму-Дәрья буйлап Әфганстан чигенә хәтле төшәргә, аннан инде йә Әфганстанның эченнән, йә чик буенча Караком чүленең кырыеннан барып Иранга чыгарга дип карар бирдек. Бу планга юл күрсәтүчебез дә ризалашты.

Башына сарык тиресенең яртысыннан теккән озын башлык утырткан, өч итәкле буй-буй киеме өстеннән чапан яки тун киеп җибәреп билен билбау белән буган, муенына кәкре кылыч асып, гарәп атларына охшаш кайнар холыклы аты өстенә атланып алган төрекмән—моңа хәтле очраган халыклар арасында иң сугышчаны, тел буенча безгә иң якыны иде. Төрекмәннәр белән телебезне үзгәртми аңлаштык, алар да үз телендә сөйли, без үз телебездә, барысы да аңлашыла.

Төрекмәннәр казакъгылар кебек үк хөр түгел, шулай да Бохара кешеләре төсле фанатик та түгел. Ләкин ул вакытта кызыллар белән сугышып ятканга күрә, чит кешеләргә шикләнеп карыйлар иде. Безгә дә аларның бу шикләнүчән уяулыгыннан үз өлешебезне алырга туры килде.

Юл күрсәтүчебез алда, солдат Хәсән иң арттa булып тезелеп, Аму-Дәрья буйлап Кәрки дигән урынга таба барып ята идек. Сумкаларыбызда өч револьвер бар, берсенең ядрәсе бөтенләй юк, калганнарында икешәр сигнал ракетасы бар, аларын да бер дә атып карамадык, әллә аталар, әллә юк. Боларны безгә Ташкентта бер кызыл комиссар биргән иде. Көндезләрен кызыл комитетта буталып йөрсә дә, моның кызыллыгы ташка үлчим, безнең белән гел күрешеп, хәл белешеп торган, качу өчен кирәкле төрле ярдәмнәрне кулдан килгәнчә башкарырга тырышкан иде.

---

[1] Рых—элеккеге вакытларда кара белән язылган язуны киптерер өчен кәгазь өстенә сибелә торган үзенә бер төрле бик вак ком.

[2] Истанбулдагы пляж урыны.

Юлда безгә таба килүче атлы төрекмән күренде, ләкин безне күрүгә борылып бер өйнен артына кереп югалды. Бу хәрәкәтеннән шикләнеп киттек. Житмәсә, юл күрсәтүчебез дә төрекмән бандитларының кайвакыт уйлап та бирмичә кеше үтергәнен сөйләп, шикләребезне куертып жибәрде. Нишләргә дә белмичә әкрен генә юлыбызны дәвам иттек. Теге төрекмән кереп югалган өй турысына килеп житкәч, шунда ышыкланып торган ике төрекмән безгә "Туктагыз!" дип боерды. Берсе шул без күргән төрекмән иде. Икенчесе кулына иске генә мылтык тоткан.

Без үзара пышылдашып кинәшеп алгач, буйсынырга булдык. Коралланган булуы ихтимал алты жайдакны әмер биреп туктатырга кыюлыгы житкән ике кешенең һичшиксез каядыр якында үз кешеләре булырга тиеш иде.

Мылтыклы төрекмән кем булуыбызны, монда ни эш куып йөрүебезне сорады.

—Әлхәмделилла, без мөселман кешеләре, төрекләр булабыз,—дип, рус әсирлегеннән качып монда хәтле килеп житкәнебезне, ләкин дөяләребез булмаганга күрә чүлне кичеп Ашхабадка бара алмаганыбызны, шул сәбәпле яр буенча барып әфган чигенә житү, аннан Иранга күчеп Төркиягә кайту ниятендә булганыбызны, юл күрсәтүчене Бохарада яллаганыбызны сөйләп бирдек.

Төрекмәннәр шактый ук гажәпләнделәр. Безгә ишеттермичә генә үзара кинәшеп алгач, "Коралыгыз бармы!" дип сорадылар. Револьверларны чыгарып бирдек. "Хәтерегез калмасын, сумкаларыгызны да карыйк әле"—дип, сумкаларыбызны селеккәләп жентекләп эзләнделәр. Минем сумкамның төбендә теш щеткасы буталып калган икән, моны тапкан төрекмән "Бу ни бу? Мөселман кешегә щетка куллану килешми, мөселман тешен мисвәк[1] белән чистартырга тиеш"—дип әйтеп салмасынмы. "Әсирләр лагерындагы рус кибетләрендә мисвәк сатылмый иде шул, тешебезне щетка белән чистартырга мәжбүр булдык. Хәзер инде моның кирәге юк, сындырып ташласак та була"—дип күз алларында сындыргалап читкә ыргыттым.

Тикшерү тәмамлангач, төрекмәннәр "Сезнен төрекме, түгелме икәнен без анлый алмабыз. Монда якында гына ишан бар, ул хажи кеше, бик белемле, ул сезнен кем икәнегезне белер. Ишан хәзрәт ни әйтсә шул булыр, без үзебез боерык кешесе генә. Без сезне ана алып барабыз",—диделәр. "Ярый соң, алып барыгыз",—дип ризалаштык. Төрекмән тагын шуны да өстәде: "Сезнен кебек үк төрекчә камил сөйләшә торган бер кеше килгән иде. Үзе Бакулы әрмән булып чыкты. Рус шпионы икән. Без хәзер руслар белән сугышып ятабыз, зур кешеләребезнең әмере булмаса, төрекмән жирләреннән бер генә чит кешене дә уздырмыйбыз",—диде.

Шулай итеп, мәсьәлә бөтенләй ачыкланып житте. Төрекмән бездән шикләнә, ләкин шул ук вакытта безнең куркынычсыз кеше булып чыгу ихтималын күздә тотып, безгә карата мөлаемрак булырга тырыша иде. Атларыбызны тартып алып, безне жәяүләтеп алдыннан да куып бара алыр иде, югыйсә.

Төрекмәннәрнең берсе алдыбызга, берсе артыбызга узып, безне уртага алдылар. Шул рәвешле тезелеп ишан хәзрәтнең хозурына киттек.

Әзрәк баргач, поскынга яткан 25 ләп коралы төрекмән күрдем. Безне озата баручы төрекмәннәр боларның башлыгына хәлне анлатып бирде. Башлык ягымлы йөз белән безгә якынлашты, сәлам биреп, "Гаепләмәгез, без хәзер сугыш хәлендә, ишан хәзрәт моннан якында гына, ярты сәгатьтән барып житәрсез",—диде. Башлыкның бу ягымлы сүзләре борчуларыбызны таратып жибәрде.

Төрекмәннәр монда нәкъ гаскәри тәртип белән сугышчан позицияләр корып куйганнар икән. Безне тоткарлаган ике төрекмән—күзәтүчеләр, поскынга ятучылар—алгы төркем, аннан соң тагын да ишлерәк икенче бер төркем тора. Ахырда төрле-төрле кораллар белән коралланган 500-600 төрекмән жыйналган штабка барып життек. Ишанның чатыры да монда икән. Атларыбызны кырыйгарак алып киттеләр, үзебезне берничә коралы сакчы уратып алды. Чатыр янында утырттылар, чәй бирделәр. Без чәй эчкән арада ишан хәзрәт безне китергән төрекмәннәр белән

---

[1] Мисвәк – теш чистарту өчен үзенә бер төрле агачтан ясалган таякчык. Мөхәммәт пәйгамбәр заманнарында мөселманнар тешләрен мисвәк белән чистартканга күрә, үтә тәкъва мөселманнар хәзергесе көндә дә тешләрен мисвәк белән генә чистартуны үзенә күрә диннең сафлыгын саклау чараларыннан берсе итеп күрәләр. Төркиядә бүген дә кайбер мәчетләрнең ишегалдында мисвәк агачының ботаклары сатыла.

күрештe. Аннары безне чатырга чакырып алдылар. Ишан хәзрәтнең кулын үбәргә дип иелдек, кулын үптермәде, кулыбызны гына кысып күреште. Утырдык. Әле ишан хәзрәт берни дә сорамады, шуңа күрә без дә дәшмичә генә торабыз. Чатырда бездән башка тагын күп кенә төрекмән бар, ләкин чатыр эче тып-тын, бөтен кеше ишан хәзрәт ни әйтер икән дип колагын торгызган.

Ишан хәзрәт иң өлкәнебез булган "З. бәйгә мөрәҗәгать итеп: "Төрек офицеры икәнсез, Төркиянең кай ягыннан?"—дип сорады.

—Истанбулдан.

—Истанбулның кай төшеннән?

Бу сораудан ишанның Истанбулны белгәнлеге аңлашылды. Иптәшебез дә моны аңлап алып, хаҗга барышлый Истанбулдан үтүчеләрнең күрүе мөмкин булган мәхәлләләрдән берсенең исемен атап, аны тасвирлап китте.

—Фатих мәхәлләсеннән. Фатих мәчете ике манаралы. Фатих хәзрәтнең төрбәсе мәчетнең кыйблага юнәлгән ягында урнашкан. Төрбә ишек алдында тора. Мәчетнең ике ягында да мәйдан бар. Мәйданнарны мәдрәсәләр уратып алган.

Ишан хәзрәт миңа да мөрәҗәгать итте: "Сез кай төштән?"

—Мин Әюп мәхәлләсеннән. Алтын Мөгез култыгындагы пристаньнең чыгышында Әюп Әнсариның мәчете һәм төрбәсе урнашкан. Бу мәчетнең ишек алдында күгәрченнәр, ләкләкләр йөри, мәчеткә килүчеләр аларга тары ярмасы бирә.

—Без Солтан Әхмәт мәхәлләсенә якын җирдә торабыз. Солтан Әхмәт мәчете алты манаралы. Алдында бик зур мәйдан бар, анда борынгы вакытлардан калган баганалар тора. Арырак Ая-Суфия мәчете тора. Серкәчедән килә торган олы юл бу төштә борылып Чәмбәрле ташка таба китеп бара.

Истанбулдагы корылмаларны бик җентекләп тасвир иткәнебезне тын гына тыңлап торган ишан хәзрәт "Раст! Болар һичшиксез төрек кешеләре",—дигән карарга килде. Аннары үзе сөйләп китте.

Чама белән 70-80 яшендәге ишан хәзрәт ике тапкыр хаҗга барган, икесендә дә юл өстендә Истанбулга кереп чыккан икән. Ике генә тапкыр күргән булса да, без сөйләгән нәрсәләр бөтен ваклыкларына хәтле хәтерендә икән. Беренче сүзләребездән үк безнең төрек икәнлегебезгә ишанып житте булса кирәк. Ләкин безне уратып алган төрекмәннәрне дә ышандырыр өчен менә шундый үзенә бер төрле имтихан ясап алды.

Истанбул хатирәләрен аңлатканда ничек Бешикташтан Йолдыз сараеның сәламлыгына[1] баруларын, сәламлыкта күргән музыкалы һәм сөңгеле кавалеристларны Петроградтагы патша сараенда да күрмәгәнлеген сөйләде. Аннары безгә "Бер дә борчылмагыз, сез хәзер безнең хас миһманыбыз[2]. Берничә көн монда ял итегез. Аксакаллар белән күрешеп һичшиксез сезнең өчен бер-бер чара табарбыз" диде.

Руслар белән төрекмәннәр арасындагы сугыш сәер генә иде. Руслар Кәрки каласының ныгытмалары артына посып ята, төрекмәннәр исә калага илтүче юлларны япканнар. Атка атланып каланың ныгытмаларына һөҗүм итеп булмаганга күрә, төрекмәннәр туп атышына эләкмәслек ераклыкта Кәрки каласын әйләндереп саклап торалар. Руслар да, күрәсең, тыштан ярдәм килер дигән өмет белән ныгытмалардан чыкмыйча көтеп яталар.

Без Кәрки каласын саклап ятучы төрекмән көчләренең алгы төркеменә килеп эләккәнбез икән. Хәзер инде бөтен өметебез ишанга һәм аның белән күрешергә тиешле төрекмән олыларының карарына бәйләнде.

Ике көн штабта кунак булып тордык. Ниһаять, өченче көн булды дигәндә ишан хәзрәт безне чатырына чакырып алды: "Аксакаллар белән күрештек, сез Әфганстан эченнән юлыгызга дәвам итәргә ирекле. Ашхабадка юнәлсәгез, бу безнең өчен дә, сезнең өчен дә хәтәр булыр. Безнең өчен хәтәре шул—сез бездә тордыгыз, көчләребезнең ничек урнашканын күрдегез. Рус казакларның кулына эләксәгез, сезне көчләп бу мәгълүматны әйттерерләр. Үзегез өчен зарары—мона хәтле исән-

[1] Сәламлык—мөселман өендә ирләр өчен аерылган бүлем. Хатын-кызлар өчен аерылган бүлем "хәрамлык" (тыелган урын) дип атала.

[2] Михман—кунак.

имин килгән көе юкка гына руслар кулына эләгеп харап булырсыз. Карт кешенең сүзен тыңлагыз, сезне әфган чигендәге сакчыларга тапшырыйк, сезне озатып баручыларны үзем сайлап алырмын".

Инде рус туфракларыннан чыгып китәргә бер көн ярымлык кына юл калганда бу тәкъдимне кире кагу акылсызлык булыр иде. Әфганстан—тарафсыз һәм дус дәүләт, әфганнар безнең узып китүебезгә каршы килмәсләр, шәт. Шуларны уйлап, беравыздан "Кабул, кабул, хәзрәт"—диештек. Ишан үзе дә кыен хәлдән котылган кебек сөенде. Иртәгә иртән үк юлга чыгарга булып, ишаннан чыгып киттек.

Иртәгесе көнне бер төрекмән башлыгы белән ике төрекмән җайдагы безне килеп алды. Юлга чыгар алдыннан ишан хәзрәт белән күрешеп чыктык. Ишан сакчыларга тиешле әмерләрне бирде.

Аму-Дәрья буйлап барабыз. Юл өстендә тагын бер төрекмән гаскәри төркеме очрады. Ике күзәтүче юлыбызны кисеп туктарга кушты. "Бүгеннең исеме ничек?"— дип сорадылар. Бу—пароль икән. Кирәкле җавапны ишеткәч, тоткарламыйча уздырып җибәрделәр. Төрекмән кабиләләре тарафыннан чүлдә корылган бу гаскәри тәртип соклангыч иде. Ике күзәтүче без күздән югалганчы күзләрен аермый артыбыздан карап калды.

Төн житкәнче үк бер урынга тукталдык. Сакчылар шундук учак ягып чәй кайнаттылар. Төнлә ут күренмәсен дип учакны шундук сүндереп тә куйдылар.

Иртәгесе көнне төшкә таба әфган чигенә килеп җиттек. Бос Ага дигән төрекмән авылы янынннан аккан арык чик булып тора. Арык өстенә агачлар салып ясалган күпернең аргы ягында—әфган җире.

Төрекмән сакчысы белән чикне саклаучы әфган офицеры үзара сөйләшеп алдылар. Әфган "Паспортлары бармы соң?"—дип сорады. Шул вакыт без дә сүзгә катнашып киттек. Сөйләшә алган хәтле фарсыча сөйләп: "Туганкай, Русиядә һәрбер мөселман кешесеннән ярдәм күреп әфган чигенә хәтле килеп җиттек. Качкын кешедә паспорт каян килсен инде. Сез безне үз ягыгызга уздырып җибәрегез, сездән өстәрәк торучыларга хәбәр бирегез, алар ни эшләргә икәнен үзләре карар кылыр",—дидек.

Әфган: "Ярар соң алайса, мин болай да сезне Иранга үткәреп җибәрә алмаган булыр идем, моңа хакым юк. Сезне Мазари Шәриф дип аталган өяз үзәгенә озатып куярмын",—диде.

—Бик хуп, безнең теләгебез дә нәкъ шул иде,—дидек.

Озата килүче төрекмәннәр белән хушлашып, ишан хәзрәткә исәнлек-саулыклар теләдек, безгә хәер-дога кылып торуын үтендек. Төрекмәннәр арыкның теге ягында калды. Без агач күпердән узып, 1919 елның 15 июнендә әфган җиренә аяк бастык. 1914 елның 22 декабрендә башланып киткән Русия мажарасы шулай итеп бүген тәмам булды.

Ватаныбызга кайтып житкәнче әле тагын күп юллар узарга тиешлегебезне белә идек. Фәкать юлыбызның иң мөһим өлеше исән-имин тәмамланган иде. Лагерьдагы руслар "Русия киңлекләреннән чыгып китә алмассыз!" дисәләр дә, менә шул минутта Русия чигендә басып тора идек, чөнки бу туфраклардан чыгып китүне үзебезгә максат итеп куеп, моның өчен тырышлык күрсәттек. Ләкин шуны әйтмичә ярамый: сәяхәтебезнең уңышлы рәвештә очлануы, һичшиксез, юл буенча очраткан дусларның изгелекләре аркасында булды. Русиядәге төркичә сөйләшә торган барча халык, яше-карты, бае, ярлысы, сәяси карашлары нинди булуга карамастан безгә ярдәм кулын сузды. Байлары җәмгыятьтә тоткан урыннарына зарар килү ихтималын уйлап тормастан безгә юл күрсәтте, ярлылары соңгы икмәк телемен, фәкыйрь ятагын безнең белән уртаклашты. Булган малын җәлләгән яки курыкканлыгын белдереп ярдәм күрсәтүдән баш тарткан бер генә кешегә дә юлыкмадык.

Хатирәләремнең бу өлешен тәмамлаганда бөтен бу исемсез дусларыбызга чын күңелдән олы рәхмәт әйтүне бурычым итеп күрәм".

*Ахыры киләсе санда.*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Ә

**ӘМИРХАН** Фатих Мөхәммәтзариф улы (1.1.1886, Казан – 9.3.1926, шунда ук), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе. М.Әмирхановның улы. 1895–1905 елларда "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә укый; үзлегеннән рус теле һәм әдәбиятын өйрәнә. 1905–07 еллардагы рев-ция йогынтысында "әл-Ислах" исемле шәкертләр оешмасы эшчәнлегендә катнаша. Ә.ның тормышы һәм иҗаты гаять дәрәҗәдә катлаулы. 1907 елның башында Мәскәүдә нәшер ителә торган беренче балалар ж-лы "Тәрбиятел этфаль"нең редакторы булып эшли. Шул ук елда Ә.ны паралич суга, калган гомерен әдип инвалид коляскасында үткәрергә мәҗбүр була. 1907–09 да "әл-Ислах" г-тасының редакторы. 1912 елдан актив рәвештә "Кояш" г-тасы һәм "Аң" ж-лы белән хезмәттәшлек итә. 20 йөз башындагы вакыйгалар һәм катаклизмнар язучының дөньяга карашларының синкретизмын, Шәрекъ һәм Гареб фәлсәфи системалары тәэсирендә формалашкан мәгърифәтчел, рев.- демократик, социаль фикерләрен билгелиләр. Ә. – татар әдәбиятында тәнкыйди реализмга нигез салучыларның берсе. Әдипнең иҗади эзләнүләре реализм кысалары белән генә чикләнми. Ул романтик рухтагы әсәрләр дә яза. Импрессионизм, экспрессионизм, акмеизм кебек модернистик агымнар өлкәсендә дә үзен кыю һәм сәләтле экспериментатор булып таныта. Әдәбиятка Ә. үзенең "Гарәфә көн төшемдә" (1907) исемле романтик рухта язылган хикәясе белән килеп керә. Мәгърифәтче әдип буларак, ул татар җәмгыятенең феодаль торгынлыгын тәнкыйтьли, милли яңарыш идеалларын яклап чыга. 20 йөз башы татар сатирик әдәбиятының классик әсәренә әйләнгән, "Фәтхулла хәзрәт" (1909) повестенда Ә. искелек тарафдарларын фаш итә. Шул ук елда язылган "Яшьләр" пьесасының асылында татар яшьләренең кадимчелек белән бәйле искелектән арыну теләге, шәхес ирекен, европача белем алу хокукын яклап чыгуы, европача яшәү теләге чагылдырыла, татар яшьләренең идеаллары һәм омтылышлары тасвирлана. "Татар кызы" (1909) хикәясендә экзистенциализм һәм экспрессионизм алымнарын оста куллану нәтиҗәсендә, татар хатын-кызын ире кулында уенчыкка, ә соңыннан "тере мәеткә" әверелүдән, феодаль-патриархаль изелүдән коткару проблемасы күтәрелә. Фабуланың өзеклеге, композициянең схема рәвешендә бирелүе, героинянең Яшәү һәм Үлемнең шартлы чигендә торуын күрсәтү модернистик әдәбиятның төрле алымнарын куллану нигезендә гомумиләштерелә. "Хәят" (1911) романтик повестенда автор бала чактан ук рус мәдәнияте йогынтысында тәрбияләнгән татар кызының рухи драмасын тасвирлый. Әдипнең төп игътибары иске кануннарга буйсынып яшәргә мәҗбүр булган героиняның эчке рухи дөньясын күрсәтүгә юнәлдерелгән. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы әдәбиятында киң таралган аталар һәм балалар арасындагы конфликт автор тарафыннан шулай ук романтизм рухында күзаллана. Повестьта матурлык эстетикасы, тирән лиризм, табигать һәм мәхәббәт культы өстенлек итә; психологик анализның портретлар, эчке монологлар, пейзаж кебек төрле формалары уңышлы кулланылган. Риваятьләр нигезендә язылган "Ай өстендә Зөһрә кыз" (1913), "Сөембикә" (1913), "Картада оттырылган Зөлхәбирә" (1913), "Бер хәрабәдә" (1913) романтик хикәяләрендә милли рухның үзенчәлекләре чагылыш тапкан. Тәмамланмый калган, тоташ сюжеты һәм динамик рәвештә үсеш алган конфликты булмаган "Урталыкта" (1911–12) романында укучы яшьләрнең, зыялыларның яшәү рәвешен яңа сәнгати алымнар ярдәмендә тасвирлау омтылышы күзәтелә. Романның төп герое Хәсән Арсланов татар яшьләренең бер өлешенә хас булган катгыйлыкны (радикализмны) уртаклашмаган кебек, кадимчеләр идеологиясен дә кабул итми. Геройның бай рухи дөньясын милли мәдәният язмышы турында уйланулар били. "Тигезсезләр", 1914) психологик драмасында Ә. А.П.Чехов драматургиясенә хас булган импрессионистик стильне уңай кулланып, бай образлар аша дөнья-

дагы кешеләрнең тигезсезлеге, мәхәббәтнең яклауга мохтаҗлыгы, кеше бәхетенең нечкәлеге хакында уйлана. Пьеса тормышны ышандырырлык итеп сурәтли, геройларның рухи тормышын күпкырлы итеп күрсәтә, үзенчәлекләре б-н эпик әсәргә охшаш. Хикәяләү стиле авторның ремаркалары татар җәмгыятенең икътисади нигезләрен үзгәртү, Европадагыча алымнар белән укыту, хатын-кыз эмансипациясе турында уйланулар, мәхәббәт, әдәбият, тел, музыка, сынлы сәнгать, рус мәдәнияте турында диологлар б-н тыгыз үрелеп бара. "Габделбасыйр гыйшкы" (1914), "Сәмигулла абзый" (1916) һәм башка хикәяләрендә акмеизм алымнарын куллану очраклары күзәтелә. Ә.—татар реалистик тәнкыйтенә нигез салучыларыннан берсе. Мәкаләләренең күбесе Г.Тукай ("Габдулла Тукаев шигырьләре", 1908, "Азмы какканны вә сукканны...", 1913), һәм Г.Исхакый ("Гаяз", 1907, "Алдым-бирдем", 1907, "Зиндан". 1908, "Зөләйха", 1917) иҗатларының сәнгать үзенчәлекләрен, З.Һади, Ф.Кәрими, Я.Вәли, М.Гафури, С.Рәмиев, Г.Коләхмәтевнең аерым әсәрләрен анализлауга багышланган. 1917 елгы Февраль инкыйлабын Ә. "Богаулар өзелде" дигән публицистик мәкаләсе б-н хуплап каршы ала. Октябрь инкыйлабыннан соң язучы "Кызыл Армия", "Эш", "Татарстан", "Татарстан хәбәрләре", "Шәрекъ кызы", "Безнең юл" г-та һәм ж-лларында язышa. "Марксист" тәхәллүсе б-н публицистик мәкаләләрен бастыра, республиканың иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышында актив катнаша. Ләкин 1924 тә язган "Шәфигулла агай" (1991 дә басылып чыга) исемле сатирик хикәясендә Ә. эшчеләр сыйныфының большевиклар идеологиясе тәэсирендә гамьсез роботларга әверелүен, гасырлар буе яшәп килгән милли традицияләрдән һәм гомумкешелек кыйммәтләреннән ваз кичүен күрсәтә. Романтик рухта язылган "Тәгъзия" (1922) хикәясендә дин-фәлсәфә яссылыгында яшәү һәм үлем мәсьәләләрен яктырта. Халык тарафыннан "татарның язмышын хәл итүче" дип аталган Ә. истәлегенә күпсанлы әдәби һәм публицистик әсәрләр багышланган.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1957–58; Избранное: Рассказы и повести. М., 1975; Әсәрләр: 4 томда. К., 1984–86.

Әд.: Хисматуллин Х. Фатих Әмирхан: Тормышы һәм иҗаты турында кыскача популяр очерк. К., 1961; Краткая литературная энциклопедия. М., 1962; Сайганов А.Д. Фатих Әмирхан әсәрләренең библиографиясе һәм язучы турында фәнни әдәбият. (1906–1972). К., 1972; Гайнуллин М. Татар әдипләре. К., 1978; Сайганов А. У истоков эстетики реализма: Эстетика Фатиха Амирхана и её место в развитии татарской реалистической литературы. К., 1982; Магдеев М. Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. К., 1986; Нуруллин И.З. Фатих Әмирхан. К., 1988; Идейноэстетическое наследие Фатиха Амирхана: Межвуз. сб. науч. тр. К., 1989; Нуруллин И.З. Прометей из Ново-Татарской слободы. К., 1991.

*Р.К.Ганиева.*

**ӘМИРХАНОВ** Марат Әмирхан улы (22.4.1933, Актаныш р-ны Кәзкәй а.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). 1955 елда Казан педагогия интын тәмамлый. 1970-87 елларда "Социалистик Татарстан" г-тасы хәбәрчесе, бүлек мөдире, 1987 елдан "Сөембикә" ж-лы баш мөхәррире урынбасары. Төзүчеләр, нефтьчеләр турындагы очерклары, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә караган публицистик мәкаләләре матбугатта даими басылып килә. 1980 еллар урталарыннан китаплары басыла башлый: балалар өчен "Таш һәйкәл" (1987) исемле повесть һәм хикәяләр, "Чулманның ак йолдызы" (1988), "Сөн моңы" (1995) дигән очерклар җыентыклары укучыларга таныш. "Каргыш" (1993) повестенда сүз сугыш шаукымы аркасында усалланып, вәхшиләнеп беткән, үзләре дә каргышка дучар булган буын турында бара. "Тәкъдир" (1999) романы фәлсәфи-теологик планда язылган әсәр: анда яшәү һәм үлем, язмышның котылгысызлыгы, фани дөньяның чикләнгәнлеге, һәр кешенең үз тормышы өчен җаваплылыгы сәнгатьчә алымнар белән, замандашларыбызның тулы образлары аша тасвирлана. "Дөя муены" (1996) повесте татар әдәбиятында сирәк очрый торган сатира жанрында язылган. Автор төп героеның мажаралары аша тормышның тискәре якларын чагылдыра. Юмористик хикәяләрендә 1990 елларда илдә барган үзгәрешләр чорында күзәтелгән җитешсезлекләрне көлкеле ситуацияләрдә сурәтли.

**ӘМИРХАНОВ** Рәхматулла (1805, Түбән Кишет а., Казан губ., Казан өязе – 1876, Казан), мәгърифәтче, язучы–тәрҗемәче,

нашир. Казанда мәдрәсә тәмамлый, үзлегеннән рус телен үзләштерә. Казан шәһәр татар бистәләре ратушасында тәрҗемәче булып эшли. Бер үк вакытта сәүдә һәм наширлек эше б-н шөгыльләнә. Татарда китап басу эшенең аякка басуы нигездә Ә. исеме б-н бәйле. Үз акчасына «Зөбдәтен-нәсаих» («Иң яхшы киңәшләр», 1849), «Гакаиде мәнзумә» («Дини ышану-шигырьләре», 1856) кебек укыту-тәрбия китаплары һәм үз әсәрләрен бастырып, авыл мәктәпләренә бушлай тарата. Кол Галинең атаклы «Кыйссаи Йосыф» поэмасының Утыз-Имәни әзерләгән беренче басмасын дөньяга чыгара (1839), 1841 елга беренче татарча календарь төзеп бастыра («Горрәнамә»), Төрек шагыйре Ибраһим Хаккыйның «Мәгърифәтнамә» китабын (1845), «Тутыйнамә» исемле хикәятләр җыентыгын (1851) татар теленә тәрҗемә итеп бастыра, пәйгамбәрләр турындагы «Кыссас әл-әнбия» җыентыгын басмага әзерли. Кайбер басма китапларга укучыларга мөрәҗәгать рәвешендә язылган үз шигырьләрен дә урнаштыра. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аның берничә сатирик парчасы үрнәк итеп китерелә. Ә.гомеренең соңгы елларында бөлеп, хәерчелектә вафат була.

Әд: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинов.*

**ӘПСӘЛӘМЕВ** Габдрахман Сафа улы (28.12.1911, хәзерге Мордва Респ-касы, Ковылкино р-ны Иске Аллагол а. – 7.2.1979, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1940 елда Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-тын тәмамлый. 1937 елда "Совет әдәбияты" ж-лында аның "Маһинур" исемле беренче хикәясе, ә 1940 елда балалар өчен "Киләчәк безнеке" пьесасы, 1941 елда "Бәхет кояшы" исемле хикәяләр җыентыгы басылып чыга. 1941 елның августыннан Ә. фронтка китә: миномет расчеты командиры, разведчик, аннан соң хәрби хәбәрче булып хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы геройлары турында хикәя һәм очерклар сериясен бастыра: "Мәңгелек дан" (1942), "Кыска дулкында" (1943), "Үлемнән көчлерәк" (1943), "Зәңгәр иртә" (1943) һ.б. Ә.нең таланты сугыштан соңгы иҗатында аеруча киң ачылды. Күп санлы хикәя һәм истәлек язмаларыннан тыш мавыктыргыч сюжетлы, совет минерларының дошман тылындагы көрәшен сурәтләгән "Ак төннәр" (1947; русчага тәрҗемәсе "Белые ночи", 1949) повесте, героик романтика, югары патриотик рух белән сугарылган "Алтын Йолдыз", 1949; русчага тәрҗемәсе "Орлята", 1952), "Газинур" (1961) романнарын иҗат итте. Сугыш темасын "Мәңгелек кеше" (1960; русчага тәрҗемәсе "Вечный человек", 1964), "Агыла болыт" (1980) романнарында да дәвам итте. Язучының тыныч тормыш, хезмәт, мәхәббәт темасы белән бәйләнешле әхлак проблемаларын күтәргән әсәрләре дә байтак. Бер эшче гаиләнең буыннар тарихын сурәтләгән "Сүнмәс утлар" (1958; русчага тәрҗемәсе "Огонь неугасимый", 1959; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе, 1959), медицина хезмәткәрләре, галимнәре тормышыннан "Ак чәчәкләр" (1965; русчага тәрҗемәсе "Белые цветы", 1968), укытучыларга багышланган "Яшел яр" (1968; русчага тәрҗемәсе "Зеленый берег", 1975), В.И.Ленинның Казан чоры революцион эшчәнлегенә багышланган "Күк күкрәр" (1975), студентлар арасындагы дуслык элемтәләрен яктырткан "Миңа унтугыз яшь иде" (1972), иҗат кешеләренең уй-кичерешләрен бәян иткән "Идел хикәяте" (1968) кебек романнары һәм повестьлары әдип иҗатының күпкырлы һәм үзенчәлекле булуын күрсәтә. Ә.нең әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә хезмәтләре бар: ул В.В.Короленко, А.П.Гайдар, Э.К.Казакевич, Н.С.Лесков, А.А.Фадеев, Д.Н.Мамин-Сибиряк, М.М.Пришвин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте. Ә. әсәрләренең күпчелеге рус теленә һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. 1962-66 елларда СССР ЮС депутаты. Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы , Кызыл Йолдыз орденнары һәм медальләр белән бүләкләнде.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 6 томда. К., 1968-72.

Әд.: Мухамедова Г.С. Абдурахман Абсалямов. К., 1971; Мустафин Р. Литературные портреты. К., 1986.

**ӘСГАТЬ МОХТАР** (чын фамилиясе Мохтаров) (23.12.1920, Төркстан АССР, Фиргана ш. – 14.4.1997, Ташкент), язучы, тәрҗемәче, Үзбәкстан ССРның халык язучысы (1980). Үзбәк телендә язган. Урта Азия дәүләт ун-тын тәмамлый (1942, Ташкент). Андижан пед. ин-тында укыта

(1942–45), "Ёш ленинчы" (1945–48), "Кизил Узбекистон" (1945–60) г-таларында хезмәттәшлек итә. Узбәкстан Язучылары берлегенең җаваплы сәркәтибе була (1957–69). "Шарк юлдузи" (1960–65) һәм "Гулистон" (1969–80) ж-налларының, "Узбекистон адабиети ва санъати" г-тасының (1981–82) баш мөхәррире. Әсәрләре 1938 елдан басыла башлый. Ә.М. – "Пулат куювчи" ("Булат коючы", 1947), "Катта йулда" ("Зур юлда", 1949) поэмалары, "Хамшахарларим" ("Хөрмәтле кардәшләрем", 1949), "Рахмат, мехрибоним" ("Рәхмәт, сөеклем", 1954), "99 миниатюра" (1962) шигъри жыентыклары, "Дарёлар тугашган жойда" ("Елгалар кушылган җирдә", 1950), "Кора-калпок киссаси" ("Каракалпак кыйссасы", 1958) повестьлары, "Опа-сингиллар" ("Апа-сеңелләр", 1955), "Тугилиш" ("Туу", 1961), "Давр менинг такдиримда" ("Минем язмышым һәм вакыт", 1964), "Чинор" (Үзбәкстан ССРның Хәмзә исем. дәүләт бүләге, 1968), "Тундаликлар..." ("Күзгә йокы кермәгәндә...", 1997) романнары, берничә пьеса, А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, А.А.Блок, К.Симонов, У.Шекспир, Ф.Шиллер, Софокл әсәрләре тәрҗемәләре авторы. Үзбәкстанда татар әдәбиятының Үзбәкстанда актив пропагандалаучы буларак, вакытлы матбугатта Г.Тукай, М.Җәлил, Г.Әпсәләмов, Х.Такташ иҗаты турында мәкаләләр бастырган, Т.Тукай (1946, 1961, 1986) һәм М.Җәлил (1958, 1982) шигырьләре җыентыкларын басмага әзерләгән (төзүче, кереш сүз һәм кайбер шигырьләренең тәрҗемәләре авторы). Ә.М. әсәрләре рус, инглиз, белорус, украин, кытай, румын, хинд, урду һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән.

Әсәр.: Танланган асарлар. Таш., 1958; Танланган асарлар: 4т. Таш., 1971–73.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ӘХМӘД БИДҖАН** (Ahmed Bidcan) Язычы оглы (15 йөз), төрек шагыйре. Язучы Сәләхетдин Кятибнең улы. Ә.Б. һәм аның абыйсы, шагыйрь Мөхәммәд Чәләби, суфилар шәехе Хуҗа Бәйрәмнең мөридләре булалар. Суфилар ритуалындагы күзаллау күнегүләрен ясый-ясый, Ә.Б. үзен тәмам хәлсезләнү-җансызлану дәрәҗәсенә китереп җиткерә. "Биҗан" (гарәпчә— җансыз) кушаматы алуы да аның шул халәте б-н бәйле. Ә.Б. үзенең абыйсы Мөхәммәд Чәләби тарафыннан гарәп телендә язылган "Мәгариб әз-заман" ("Заман кояшының батышы") исемле әсәрен 1460 елда төрки телгә ирекле тәрҗемә итә һәм аны "Әнварел-гашыйкыйн" ("Гашыйклар нуры") дип атый. Шул исем б-н әсәр 19 йөзнең 2 нче яртысында татарлар арасында киң таралыш ала һәм Казанда күп тапкырлар басылып чыга. Ә.Б. фарсы галиме Зәкәрия әл-Казвининың "Гаҗаиб әлмәхлүкат" ("Гаҗәеп җан ияләре") китабы нигезендә иҗат ителгән шул исемдәге әсәр (1453) һәм оригинал иҗат җимеше "Дөрре мәкнүн" ("Энҗеләр тезмәсе") әсәре авторы буларак та билгеле. Әсәрләрнең өчесе дә дини эчтәлеккә ия, аларда хикәяләр рәвешендә пәйгамбәр һәм хәлифләрнең эшгамәлләре, ислам шәригатенең нигез кагыйдәләре бәян ителә.

Әсәре: Әнварул-гашыйкыйн. К., 1898.

*Әд.*: Абилов Ш.Ш. Татарская литература XV—XVI вв. (Эпоха Казанского ханства) // Средневековая татарская литература (VIII—XVIII). К., 1999; Islam Ansiklopedisi. Ist., 1978. 2 cilt.

Автор: *М.В.Гайнетдинов.*

**ӘХМӘД ХУҖА әс-САРАИ** (14 йөзнең 2 нче яртысы), Алтын Урда чоры төркитатар шагыйре. Тумышы б-н Идел буе төбәгеннән. Гарәп һәм фарсы телләре мөгаллиме, әдәби иҗат б-н шөгыльләнгән. Алтын Урда дәүләтенә Аксак Тимер һөҗүме вакытында (14 йөзнең 90 нчы еллары) әсир төшеп, Сәмәрканд шәһәренә озатылган дип фараз ителә. Иҗат мирасыннан Сәйф Сараиның "Китабе Гөлестан бит-төрки" кулъязма җыентыгында урнаштырылган газәл жанрындагы бер шигыре ("Дилбәремнең ул сәдәфтик агъзында дөр бар ирер... ") б-н мәгълүм. Иҗаты һәм тормышы аз өйрәнелгән.

*Әд.:* Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен материал. К., 1967; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 китап; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

**ӘХМӘД әш-ШӘФИГЫЙ** (тулы исеме Әхмәд ибне Гали ибне Хәҗәр әл-Гаскыйлани әл-Мисрый әш-Шәфигый) (28.02.1372, Каһирә—1449, шунда ук), гарәп галиме, әдип. Фәләстыйнда укып белем ала, соңыннан үзе дә хәдистән дәресләр бирә. 1408 елдан Мисырдагы Әл-Әзһар һәм Омар мәчетләре имамы. Алтын Урда б-н мәмлүкләр Мисыры арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләрне яктырткан "Китабе

анба әл-гомр би абна әл-әмр" ("Чорның балалары турында акылсызлар хәбәре") исемле тарихи китап авторы. Кулъязма нөсхәләре Британия музее (Лондон), Париж милли китапханәсе һәм Европаның башка архивханәләрендә саклана. Әдипнең дини-дидактик эчтәлекле "Мөнәббиһат" ("Фикерләр уятучы") исемле әсәре Касыйм шәһәренең зыялы бер кешесе тарафыннан 1630 елда татар теленә тәрҗемә ителә һәм 1905, 1915 елларда Казанда аерым китап булып басыла.

*Әд.*: Тизенгаузен В. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; Марджани Ш. Вафият ал-аслаф ва тахият ал-ахлаф (Пер. с араб. А.Н. Юзеева. К., 1999); Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 *т.*

Автор: *Р.Ф.Исламов.*

**ӘХМӘДБИК** (18 йөзнең 2 нче яртысы—19 йөз башы), шагыйрь. 1970 елларда Ленинградның Дәүләт тарих архивында табылган кулъязма шигырьләр җыентыгының авторы дип уйланыла. Шигырьләр 1786–1804 елларга карый. Эчтәлеге б-н алар хаҗга бару һәм Мәккә шәһәренә сәяхәт кылу вакыйгаларына багышланган. Шигырьләрнең икесе—"Әл-видагъ" ("Аерылышу") һәм "Вәйс әл-Карани" ("Һәр сәхәр вакътында калкып гизәрди..."), тәмам халыкчалашып, Рамазан ае көннәрендә кичке намаздан соң мәчетләрдә көйләп әйтелә торган булган. Ә.нең иҗатында дини һәм дөньяви мотивлар аралашып бара, автор социаль һәм рухи бөлгенлекне тәнкыйть итә, җәмгыятьне сафландыру идеяләрен алга сөрә. Шул үзенчәлекләре б-н Ә. иҗаты татар шигърияте үсешендәге мөһим бер яңалык буларак тәкъдир ителә. Ә.нең аерым шигырьләре, авторы күрсәтелмичә, 1905 елда Казанда "Мәҗмугаи илаһи" ("Илаһи җыентык") иseме белән басылып чыга. Ә.нең биографиясенә кагылышлы мәгълүматлар сакланмаган.

*Әд.*: Гайнетдинов М.В. XIX йөз татар әдәбияты тарихына яңа материаллар // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 *т.*; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 *т.*; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 китап.

Автор: *М.В.Гайнетдинов.*

**ӘХМӘДИ** (Ahmedi) Таҗеддин ибне Ибраһим ибне Хызыр Гирмияни (1334, Гирмияни ш., Төркия—1413, Амасья ш., шунда ук), төрек шагыйре. Яшьлегендә мәмлүкләр Мисырына барып, тарих, фәлсәфә, теология, философия, медицина һ.б. фәннәрне тирәнтен өйрәнә, шагыйрьләр, галимнәр, ш.и. Алтын Урдадан чыккан кешеләр б-н аралаша. Төркиягә әйләнеп кайткач, солтан Баязид Йылдырым һәм аның уллары б-н элемтә урнаштыра. Бик күп әдәби әсәрләр авторы: шигырьләр тупланмасы "Диван" (8 мең бәйт), "Җәмшид вә Хөршид" дигән романтик мәхәббәт поэмасы (күләме—5 мең бәйт), медицинадан трактат "Тәрвихел-әрвах" ("Әрвахларны сафландыру", 4 мең бәйт), шигъри лөгать "Миркател-адаб" ("Әдәплелек дәрәҗәләре") һ.б. Ибне Синаның "Канун әт-тыйбб" ("Табиблек гыйльме кануннары" хезмәтен, Фәридеддин Гаттарның "Әсрарнамә" ("Серләр китабы") әсәрен төрек теленә тәрҗемә итә. Аеруча күләмле әсәрләреннән—12 йөз шагыйре һәм фикер иясе Низаминың "Искәндәрнамә" поэмасына нәзыйрә жанрында иҗат иткән шул ук исемдәге шигъри әсәрен (күләме—8250 бәйт) 1389 елда тәмамлый. Үз заманының төрле проблемаларын, кеше тормышы, яшәү мәгънәсе, тәгълим-тәрбия мәсьәләләре турында авторның әхлакый-фәлсәфи уйлануларын эченә алган бу поэма кулъязма нөсхәләр рәвешендә татарлар арасында киң таралып, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы итеп файдаланыла. Поэмадан зур бер өзекне С.Кукляшев укыту материалы буларак үзенең "Диване хикайәте татар" (Казан, 1859) исемле хрестоматиясенә урнаштыра. Поэманың аерым кулъязма күчермәләре Казан, С.-Петербург һәм башка шәһәрләрнең архив һәм китапханә фондларында саклана.

*Әд.*: Миннегулов Х.Ю., Садретдинов Ш.А. XIX йөз татар хрестоматияләре. К., 1982; Асланов В.И. Ахмеди и его "Искандер-наме" // Народы Азии и африки. 1966. № 4; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и восточная классика: Вопросы взаимосвязей и поэтики. К., 1993.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**ӘХМӘДИЕВ** Нур Гариф улы (14.12.1946, Азнакай р-ны Әсәй а.), язучы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). 1970 елда Казан ун-тын, 1987 елда Мәскәүдә М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курслар тәмамлый. 1971-73 елларда ВЛКСМның Азнакай райкомы секретаре, 1979-83 – "Азнакайнефть" НГДУсының курслап укыту комб-ты директоры, 1987-93 елларда ТР Язучылар берлеге Әлмәт бүлегенең җаваплы сәркәтибе. 1994 елдан "Тат-

нефть" АЖнең "Хәзинә" г-тасы мөхәррире. Беренче шигырьләре һәм балалар өчен хикәяләре 1970 еллар башында "Ялкын" ж-лында, "Яшь ленинчы", "Татарстан яшьләре" г-таларында басыла. Ул – "Аһәң" (1980), "Ак бишегем" (1987), "Яралы күк" (1994), "Күзгә-күз" (1996), "Чакматаш" (2002) кебек шигъри җыентыклар, "Бал яңгыры" (1984), "Күктә ничә йолдыз бар?" (1991), "Аксак төлке" (1994), "Атларым – колыннарым" (1997) исемле балалар өчен шигырьләр, хикәяләр, мажаралы повестьлар авторы. Ә. әсәрләрендә җирдә барган вакыйгаларга, гаилә тормышына, яшьлек һәм мәхәббәткә, хезмәткә үзенең мөнәсәбәтен белдерә. Аның геройлары тормыш сөючән, оптимист кешеләр.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 4 томда. К., 2001-2002.

Әд.: Афзал Г. Шагыйрьнең уңышы // Ватаным Татарстан. 1995. 24 янв.; Гамбәр Н. Каеннар яктысында // Казан утлары. 1996. №12.

**ӘХМӘДУЛЛИН** Азат Гыйльмулла улы (13.10.1932, Саба р-ның Байлар Сабасы а.), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1994), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). Казан ун-тын тәмамлый (1956). Тубыл пед. ин-тында укыта (1956–58), Татарстан радиокомитетында эшли (1958–61). 1963–80 елларда СССР ФАнең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1972 дән директор урынбасары булып эшли. 1981 елдан Казан ун-ты профессоры, 1999 га кадәр татар әдәбияты каф. мөдире. 1999–2004 елларда Казан пед. ун-тында татар әдәбияты каф. мөдире. Хезмәтләре татар драматургиясе һәм театры тарихына, Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, М.Фәйзи, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Х.Вахит, Т.Миңнуллин һ. б. татар язучылары, драматурглары иҗатларына карый. Урта мәктәп өчен әдәбият буенча дәреслекләр авторы (1970 елдан бирле 15 басма чыга). Әдәби терминнар тупланган "Әдәбият белеме сүзлеге" (1990) төзүчесе.

Хезм.: Ничек сурәтләргә сине, замандаш (Бүгенге татар драматургиясенең актуаль проблемалары турында). К., 1976; Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980; Горизонты татарской драмы. К., 1983; Татарская драматургия. М., 1983; Офыклар киңәйгәндә. К., 2002.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986; Ханзафаров Н. Зыялы галим! // Мирас. 1997. N 12.

**ӘХМӘТ** Абдулла Сафиулла улы (25.3.1905, хәзерге Курган өлкәсе Притобольный р-ны Звериный (Звериноголовск) а. – 28.10.1976, Казан), прозаик, драматург. 1936 елда Казан пед. ин-тын тәмамлый. 1925 елда Свердловск шәһәрендә чыга торган "Сабан һәм чүкеч" г-тасында беренче язмалары басыла башлый. 1932 елда Казанга күчеп килә. 1936-41 елларда "Совет әдәбияты" ж-лы хезмәткәре, соңрак Казан химия-технол. техникумы һәм музыка мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. "Алга, дошман өстенә!" фронт г-тасында хезмәттәшлек итә. 1946-51 елларда Татарстан дәүләт нәшр-тында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире, 1952-55 елларда "Пионер" ж-лы җаваплы мөхәррире. Беренче очерклары һәм хикәяләре 1931 елда Мәскәүдә "Кара баганалар" исеме белән басылып чыга. Балалар өчен "Йолдыз" (1935), "Солдат балалары" (1948), "Яңа дуслар" (1954) хикәя җыентыклары, Татарстанда нефть промышленносте барлыкка килү турында "Кара алтын" (1947), "Яшәү көче" (1951) дигән очерклар китаплары авторы. "Серләр" (1948), "Егет сүзе" (1954) пьесалары Казан, Уфа, Бөгелмә, Екатеринбург театр сәхнәләрендә куелды, рус һәм башкорт телләренә тәрҗемә ителде. Ә. татар халык иҗаты әсәрләрен туплап, аларны әдәби эшкәртеп матбугатка әзерләде. Аның тарафыннан төзелгән "Халык иҗаты" (1938, 1940; Х.Ярми белән бергә), "Хуҗа Насретдин мәзәкләре" (1942, 3-басма 1966), "Мәкальләр" (1948), "Табышмак әйтәм – табыгыз" (1949) җыентыклары дөнья күрде. Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнде.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1964; Пьесалар. К., 1981; Рассказы. К., 1974.

Әд.: Советские детские писатели: Биографический словарь. М., 1961; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Дәвамы киләсе саннарда*

*Юмор-сатира*

## Тәлгат Нәҗмиев

# МӘЗӘК ХӘЛЛӘР

### Борчылуын белдергән

Якташыбыз—күренекле рәссам, Татарстан Дәүләт флагы авторы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Тавил ага Хажиәхмәтов белән дә очрашкалап торабыз. Аның Николай Ершов урамындагы киң, зур иҗат остаханәсендә дә булганым бар. Тавил аганың улы Нияз да "Казан Кремле" музейтыюлыгының баш рәссамы дәрәҗәсенә күтәрелде. Төрле конкурсларда катнаша. 2004 елның җәендә Президентыбыз каршындагы Геральдика советы ул иҗат иткән Сабантуй символын—кызыл башлы ак сөлге рәсемен раслады. Әлеге милли эмблемабыз Татарстанның авыл, шәһәр районнарына һәм Россиянең милләттәшләребез күпләп яшәгән илле дүрт төбәгенә җибәрелде.

Тавил абый озак еллар "Ялкын" журналы белән хезмәттәшлек итә. Һәр сан саен журнал тышлыгының өченче битендә аның иллюстрацияләре белән бер әкият урнаштырылып килә. Ничектер, бер сайлау ыгы-зыгысы белән журнал монсыз гына чыккан. Тавил Гыйниятулла улы шунда:

—Әкиятне төшереп калдыргансыз да, ә гонорарын ничек итеп түләрсез икән соң...—дип тирән борчылуын белдереп куйган.

### Ай янында якты йолдыз

Яңа ел турында сүз чыгуга, ялтыравыклы уенчыклар белән бизәлгән яшел чыршы, янында Кыш бабай һәм Кар кызы күз алдына килеп баса.

Яшел чыршыны бизәү гадәте иң әүвәл урта гасырларда Германиядә керә. 25 декабрь католик дине буенча Раштуа бәйрәме генә түгел, Адәм белән Хаваны искә алу көне булып та санала. Шуңа күрә беренче чыршыларны алмалар белән бизәгәннәр. Ул оҗмах агачын хәтерләткән. Соңрак, XVII гасырда, немецлар чыршыны уенчыклар һәм янып торган шәмнәр белән матурлыйлар.

Күп тә үтми, бизәлгән яшел чыршы Франциягә һәм Англиягә үтеп керә.

Ә Россиядә Петр I йортларны чыршы һәм нарат ботаклары белән бизәүне кертсә дә, чыршы "киендерү" гадәте булмый әле, аны Петербургта яшәүче немецлар Германиядән XIX гасыр урталарында алып килә.

1916 елда Изге Синод, дошман-немец тәэсире, дип, Раштуа чыршыларын бизәүне тыя. Совет власте да баштарак бу гадәттә совет халкына чит булган буржуазия тәэсирен күрә. Әмма 1935 елда Сталин, эшче халык байлар тормышын күз алдына китерә алсын өчен, илнең бөтен җирендә дә Яңа ел чыршылары бизәүне рөхсәт иткән карар чыгара. Бары тик чыршы очындагы "Вифлеем йолдызы"н гына биш почмаклы кызыл йолдызга алыштыралар.

...Сабадагы үзәк чыршыны бизиләр икән туксанынчы еллар уртасында. Ул вакыттагы хакимият башлыгы Фәрит Гыйльметдин улы үзенең беренче урынбасарына болай дигән:

—Нурислам Фәтхуллович, чыршы бизәгәндәниндидер үзгәреш кертәсе иде бит?!

—Берниндн проблема юк, Фәрит Гыйльмиевич, йолдыз урынына ай куябыз,—дигән аксакал.

## Читкә чыгару

Мәскәүгә журналистларнын VI корылтаена баргач, без кунакханәнең бер блогына өчәү—университетнын журналистика һәм социология факультеты деканы, профессор, газетабызның элекке хәбәрчесе Васил Гарифуллин, юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясенен (ЮХИДИ) "Досье—02" тапшыруларын русча алып баручы мөхәррир, Казан егете Арслан Ганиев һәм мин урнаштык. Иң яшебез Арслан иде. Без аңа башта әллә ни игътибар да итмәгән идек, әмма вакыты житкәч шаккатырды ул безне...

Съездның икенче көнендә төшке ашка тәнәфес игълан иттеләр. Тиз генә тукланып чыктым да, бераз ял итәргә дип бүлмәбезгә юнәлдем. Килеп керсәм... Арслан өйлә намазы укып утыра...

—Тәлгат абый, интернет аша бер Мәскәү кызы белән танышкан идек,—дип сөйләп китте кичен Арслан.—Бүген беренче мәртәбә очраштык. Бик тә ошады. Әти-әниләре дә диндар кешеләр икән, чыгышлары белән Түбән Новгород мишәрләре.

Менә шулай итеп, тормыш, яшәеш турында әңгәмәләр кора башладык без. Арсланнын әнисе Әлфия дә журналист, "Молодежь Татарстана" газетасында эшли икән.

Дуслыгыбыз Казанга кайтканда тагын да ныгыды. Хрустальный гусь станциясен Мәскәү юлын үтүчеләрнең күбесе беләдер. Пыяла һәм бәллүр фужерлар, рюмкалар, тагын әллә нәрсәләр саталар анда. Миңа үземнең гәүдәдән әз генә кечкенә булган, матурлап рәсем ясалган фарфор ваза ошады. Башта биш мең сум сорадылар, поезд китә башлагач, ике меңгә бирергә мәжбүр булдылар эшмәкәрләр. "Бүтән акчам юк",—дип бик нык сатулаштым инде, әлбәттә. Каләмдәшләрем "аh" итте затлы сәнгать әсәрен күргәч...

Мин аны, купега кергәч, төшеп китмәслек итеп йомшак одеялга бәби кебек итеп төреп, вагоннын өченче киштәсенә урнаштырдым.

Ярар, төн үтте. Казанга да якынлашабыз. Ничек алып чыгарга соң теге "бәби"не,—дип баш ватып утырдым да:

—Арслан,—дидем.—Син минем сумкаларны да алырсың инде вокзал алды мәйданына кадәр. Шуның өчен мин сине машина белән өеңә үк илтеп куярмын, яме.

Берсүзсез ризалашты, әлбәттә, юлдашым. Әйбәт егет бит...

Шактый вакыттан соң Сабага, дөресрәге Лесхозга—Татарстан ЮХИДИе оештырган картингчыларның республика ярышларына килгән иде ул.

—Мәскәү белән элемтәләр ничек?—дип сорадым.

—Мөнәсәбәтләр житдиләнә бара, озакламый туганлашырбыз, Ходай Тәгалә боерса...—дигән иде ул вакытта.

...Менә "Татарстан яшьләре" газетасындагы "Казан белән Мәскәүне мәхәббәт бәйләде" дигән мәкаләгә күзем төште. Танышым Арслан елмаеп тора фотосурәттә. Янәшәсендә—акъяулык япкан Зөлфиясе. Бәхетле булсыннар, берүк. Ә үзем текстны укуны дәвам итәм. "...Бәйрәм бер атнаны Мәскәүдә, икенче атнаны Казанда булды. Тамада әйтмешли, мәжлескә ике авыл халкы—мәскәүлеләр һәм казанлылар жыелган иде.

—Мәскәү бездән гел яхшыны тартып ала,—дип шаярды туйдагы бер кыз..."

Шушы урынга житкәч, нәкъ әлеге дә баягы "тартып алу", "читкә чыгару" белән бәйле, совет чорында район хәрби комиссариатында булган хәл исемә кылт итеп килеп төште. Хезмәткә чакыру комиссиясе бара икән. Хирургка да күренәсе булгач, бирегә анадан тума керәсең инде.

—Энем, бик чибәр дә, спортчы да икәнсең, белемең дә житәрлек, шулай булгач, Германиядә хезмәт итәрсең инде,—диде подполковник комиссар.

Бик унайсызланып, оялып кына басып торучы әлеге егетнең "гөрнәдирдай" гәүдәсенә, чия кебек алсу иреннәренә, йонлы күкрәгенә, тагын әллә кай төшләренә ябь-яшь сәркатип кыз күз төшереп алды да:

—Бездә гел шулай инде, әдәм рәтле корал булса, чит илгә чыгаралар,—диде.

## Галиәкбәр кайтсын

Хәләл көчләре, үз тырышлыклары белән гомер итүче Сөнгатовлар нәселе бар Олыяз авылында. Шуларның берсенә—Мәрзия белән Галиәкбәр гаиләсенә тукталыйк әле. Тыйнак һәм гади тормышта биш малай, бер кыз тәрбияләп үстерәләр алар. Ир-егетләрнең барысы да—Мөнәвир, Рәдиф, Әбүзәр, Шәмсүн, Илнур армиядә булып, Ватан алдындагы бурычларын үтәп кайттылар, шәфкать туташы буларак, кызлары Тәгъзимә дә хәрби учетта тора.

Гаилә башлыгы кайда кушсалар, шунда эшли. Көтүен дә көтә. Туры сүзлелеге белән дә аерылып тора, шуна күрә колхоз житәкчеләре белән "женнәре килешмәгән" вакытлары да була. Терлекчеләр жыелышында кожан белән резин итек сорый ул берсендә. Бернечә "йомры" сүз дә өсти, әлбәттә.

Колхоз рәисе урынбасары Мөхәммәтзакир аганың күнеленә бер дә хуш килми Галиәкбәрнең бу гамәле. Участковый инспекторга әйтеп, аны өч көнгә таш йорттагы "кунак йортына" жибәртә. Акчасы киселмәсен диптер инде, көтүгә улы Шәмсүн чыга. Сыерларның күбенүеннән куркып, тиешенчә ашатып бетерми яна көтүче. Нәтижәдә сөт кими. Бу мәсьәлә иртәнге нәрәттә күтәрелә.

—Олыязда нишләп сөт кимегән?—дип сорыйлар урынбасардан.

—Ни, Фәрит Фәрхетдинеч, Галиәкбәрне өч суткыга жибәрттергән идем. Шунадыр...

—Закир,—ди рәис,—бүген дә сөт төшсә, райком безне асып куя. Анын урынына үзен барып утырып бетер, Галиәкбәр кайтсын!

## Гонорар исәбенә

Саба төбәген үз итүче Туфан ага Миннуллин кендек каны тамган Олы Мәрәтхужасына кайтса, шау-гөр килеп, ягъни дуфан куптарып кибеткә кереп чыгарга ярата. Чөнки кибет ул—кечкенә авылның Мәдәният йорты да, Спорт сарае да, Матбугат үзәге дә. Шунда кызык хәлләр сөйләнелә, яналыклар ачыклана, хәтта моннан житмеш-сиксән ел элек булган хатирәләр дә искә алына.

Матур итеп исәнләшә драматург якташлары белән, хәл-әхвәлләрен сораша.

Шуннан сон читтәрәк басып торган Касыйм бабай юка иреннәрен ерып куя да, аракыга бик исе китмәсә дә, Казаннан кайткан авылдашына вәкарь белән генә күз кыса:

—Туфан, энем, куй син хәзер үк безгә бер яртыны!

—Касыйм абый, ничек әле аласы бурычын бар шикелле итеп, приказ биргән кебегрәк әйтәсең бу сүзенне?—дип сорый Олы Мәрәтхужанын Габдулла малае.

Шуннан Касыйм абзый башлаган фикерен иплап кенә йомгаклап та куя:

—Аласын, Туфан энем, башка хутын юк! Чөнки без монда сөйләгәннәрне син анда язгалап, хәйран гына акча эшләп ятасын икән бит...

## Кыскалыкта—осталык

Кайбер язмаларым озынгарак та китә, ахры. Нишлисен бит, сөйләр сүз күп, тема зур. Тагын шунысы бар: кызык хәлләр бармактан суырып чыгарылган түгел. Барысы да булган хәлләр. Бик кыска язып, әз сөйләшә торган кешеләр дә бар, билгеле. Мәсәлән, жәмгыятьтә үз-үзен тотышы, галим-голәмәнен тормышын һәм хезмәтен дөрес анлап, фәнгә керткән шәхси өлеше белән республикада хөрмәт казанган шәхес—Татар энциклопедиясе институты директорынын фәнни эшләр буенча урынбасары Гомәр ага Сабиржанов сөйләгән иде Самара өлкәсендәге Яна Жүрәй (Гомәр Салих улынын туган жире) авылындагы бер кыска вакыйганы.

Ике авылдаш жигүле арбада унбиш километр араны сөйләшеп кайталар икән.

—Бу атна базарында он кыйммәт,—диган юлга кузгалганда Гайнулла абзый.

Кайтып житәбез дигәндә юлдашы жавап биргән:

—Әйтмә дә инде...

## Урыны шушы икән

Авыл кешеләренең кайберләрендә бик начар гадәт бар: табак-савыт, идән юган суларны капка төбенә, яисә асфальтка ук чыгарып түгәләр. Аны бит абзар артындагы тирескә түксә дә була югыйсә.

Чалт аяз көнне шул юынтык су түгелгән җирдә таеп егыла Хисам ага һәм:

—Радио, урыны белән кыска вакытлы яңгыр, дигән иде аны, урыны шушында икән,—дип китеп бара.

## Хушлашу

Сабада Заман Таһирын белмәгән кеше юктыр. Шактый еллар Казан авиация заводында эшләп, Мәскәү аэропортларына хезмәт күрсәтүдә катнашты ул.

Үзләренең махсус самолетлары белән башкалага еш баргалаган. Берсендә ахирәт дусты, Саба автотранспорт предприятиесендә автобус шоферы һәм механик булып эшләгән Рөстәм ага Нәҗметдиновны да кодалаган үзләре белән.

Ярар, очкыч тиешле биеклеккә менеп, Мәскәүгә курс алган. Башта тыйнак кына табын әзерләгәннәр болар. Аннары самолетны "автопилот"ка көйләп куйганнар да, кызык өчен, әлбәттә, очучы кәнәфиенә Рөстәм Каюм улын утыртып куйганнар.

Кереп чумган ул очучы урынына һәм гомер иткән җәмәгатен күз алдында тотып, ике генә сүз әйткән:

—Прощай, Рәфыйга!

## Сарык булсалар да...

Балтачтагы каләмдәшем Нурулла Галиев егерме елдан артык җирле радиотапшырулар алып барды. Эфирдагы тавышын әле дә булса сагынып телгә алалар. Аны "Балтач Левитаны" дияләр иде. Нурулланың Сабантуйларны алып баруы да тарих сәхифәләренә мәңгегә язылып калыр әле.

Радиодан сөйләгәндә телдән-телгә күчеп йөрерлек кызыклы җөмләләре дә китә, әлбәттә. Терлек азыгы әзерләү чорындагы бер тапшыруда ул болай дигән:

—"Труд", Тимирязев исемендәге, "Кама" хуҗалары рәисләре Чернов, Исрафилов, Мәхмүтов үзләре сарык (шушы урында "колхозлары" дигән сүзне төшереп калдыра) булуга карамастан, яфрак азыгы җыйнауны тиешенчә оештырмыйлар...

## Сүзнең асылы

Катнаш никахлар турында сүз чыкса, нервы тетрәве кичергәндәй булам. Чөнки бердәнбер улым Ниязга гел әйтә килдем: "Улым, зинһар, марҗага өйләнә күрмә, без бит саф татар районында яшибез. Гәҗитебез дә русча чыкмый җитмәсә".

Казанга укырга китте малаебыз. Һәм озак та үтмәде, котчыкмалы хәл булды. Тал чыбыгы кебек нәфис гәүдәле, нииндидер сөйкемле чибәр генә кыз җитәкләп кайтты Саба урта мәктәбенең рус классын тәмамлаган улыбыз. Һәм әйтте:—Эти, киленегез булыр бу. Исеме Люба. Өйләнмичә булмый. Любаны люблю,—диде дә маңгай чәчен "көрәп" куйды.

Башта күз яше чыгарып елардай булдык, аннары бик каты каршы килеп карадык әнисе белән. Ата-анасына бердәнбер кыз булуын белгәч, киеренкелекне тагын да арттырсак, малайның безгә үпкәләп Любага ияреп китеп барачагын чамалагач, "немедленно" ризалаштык.

Любабыз Казан педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамларга җыена икән.

—Татарча бик тиз өйрәнәчәкмен,—диде ул, кечкенә сумкасыннан "Русча-татарча сүзлек" тә алып күрсәтте.

Баштан көфер уйларны чыгарып ташлап, матур гына яши башладык һәм җиде ел бер түбә астында тордык. Кода-кодагыйлар да итагатьле, тәртипле, кыскасы, югары культуралы кешеләр булып чыкты. Любабызны үзебез дә, мәктәп коллективында да, укучылары да яратты. Татарчаны тиз арада су кебек "эчә"

башлады. Танылган тележурналист Гөлнара Зиннәтуллина безнең редакциягә һәм гаиләгә багышлап әзерләгән "Иртә түгел, соң түгел" тапшыруында да катнашты әле киленебез. Шуннан соң Әнвәр Сәмигуллин (кайсы районнан икәне истә түгел, Мөслим яклары кебек хәтердә калган) "Шәһри Казан" газетасының "Кайтаваз" рубрикасына *(16 февраль, 2001 ел)* мәкалә дә язып җибәргән.

"...Күптән түгел Татарстан каналыннан бер тапшыру карарга туры килде. Анда Саба район газетасында баш мөхәррир булып эшләүче кешенең дә килене безнең милләт түгел, ягъни катнаш никахта яшиләр, дип сөйләделәр. Казанда туып-үскән кыз татарча өйрәнгән. Менә дигән итеп интервью бирде. Кычкырып татарча шигырьләр укый. Чын татар кызыннан бер дә аермасы юк. Бу гаиләдә балалар да татарча сөйләшергә өйрәнәчәк. Бер авыз татарча белмәүче кызның тел өйрәнүе—бик күңелле күренеш"...

Дөрестән дә, Любабыз саф татарча, хәтта "һәм", "шәһәр"ләрне "һ" хәрефен дөрес кулланып сөйләвенә үзе сөенеп бетә алмый. Мисалга китерелгән бу язманы газетадан кисеп алып, альбомына ябыштырып куйган ул. Кайбер вакытта акценты чыгып куя-куюын. Әле менә 2004 елны каршылау табынына аларда җыелгач, килен "урдяк" дип ычкындырды. Бу сүзне беренче класста укучы Гаделебез эләктереп алды да: "Әни-әни, үрдәкне тагын бер әйт әле",—дип кабатлады. Үзе ята-ята көлгән була.

Гаделгә килсәк, ике телне дә искитмәле белә. Кирәк вакытта "тылмач" ролен үти. "Дедуля"сы белән "бабуля"сы бар вакытта сөйләшкәндә алар аңларга тиеш булмаган җөмләләрне күзен кыса-кыса татарча сибә, үзләре белән фәкать русча сөйләшә.

Люба һәр сүзнең асылын аңларга омтыла. Беркөнне эш бүлмәмдә колак салып утырам. Тегеләр телевизордан "Татарстан-Яңа гасыр" программасын карыйлар. Ниндидер аңлашылмаган сүз килеп чыкты. Аны ачыклагач, килен малайдан сорап куйды:

—Нияз, менә ун ел бергә торабыз инде, минем тагын бер аңламаган сүзем калды бит әле. Әни, ачуы килгәндә әйтә аны.

—Нәрсә ди?

—Күт саруын кайнатып йөрмә әле.

## Исәнләшергә ярыймы?

Редакциянең әдәби хезмәткәрләре генә түгел, техничкалары да үзенчәлекле була. Пенсиягә киткәнче идәнне Әминә апа юган. Аны кызы Флера алыштыра. Ул типографиядә 1950 елда эшли башлый. Газета басу машинасын җиделе лампа яктысында кул белән әйләндерәләр.

1956 елда гына электр ярдәме белән эшли башлыйлар. Теге лампаны яңа гасырга—2000 елга кадәр саклаган Флера Закировна. Матбугат музеебызга бүләк итте ул аны.

Флера апабыз 2001 елда дөнья күргән "Кыз-әбиләр" дигән китапка да керде. Алтмыш җиде яшьтә булса да күзлексез укый, хәтере бик яхшы, әллә кайчангы вакыйгаларны шул чор кешеләренең нәсел-шәҗәрәләре белән бәйләп-сөйләп җибәрсә, туктатырмын димә. "Эшеңне калдырдым",—дип, ашыккан рәвеш ясый аннары.

—Исәнләшергә ярыймы?—ди ул берсендә, ике катлы ишекнең уртасында туктап калып.

—Кер, Флера апа, нишләп алай рөхсәт сорыйсын?—дим.

—Әхмәтшин дигән редактор бар иде,—дип сөйләп китте ул,—бик важный йомышыгыз булмаса, исәнләшмәгез, фикеремне чуалтасыз,—дия торган иде.

## Тигез кирәк булмаган

Шәмәрдән бистәсендә яшәп, җырлар, көйләр, шигырьләр, эссе-хикәяләр, пародияләр, юмористик парчалар, милләтебез язмышына багышланган публицистик мәкаләләр, лирик трагикомедияләр иҗат итүче, 2004 елда "Тамчы гөл" дигән китабын

да чыгарган Рөстәм Зарипов кызы белән малаена шоколад булә икән. Кызы рәхмәт әйтеп китә. Ә менә малае Раушан тузына, дулый, елый башлый.

—Тип-тигез булендә ләбаса, ник психланасың алай?—дип сорап куя әтисе.

—Мина тигез кирәк түгел иде шул,—дип лышкылдавын дәвам итә малай.

## Йомыркалы чәй

Чәйнең бик кадерле заманнары бар иде. Бигрәк тә тартмасына фил рәсеме төшкән һинд чәенең. Аны Казаннан килгән һәр кунак сорап интектерә иде. Райпо рәисе әмере белән ун кап чәйне тугыз сум да илле тиенгә алып бирә алсаң, син—әйбәт житәкче, коеп куйган редактор! Халкыбызның яраткан жырчысы Фән Вәлиәхмәтов та тикмәгә генә:

*"Туган йортта безне көтәләрдер,*
*Көткән кеше барда кайткалыйк.*
*Әти картка—күлмәк, әнкәйгә—шәл,*
*Кучтәнәчкә тәмле чәй алыйк,*—дип жырламыйдыр.

Без бала вакытта чәй генә түгел, тавык күкәе дә бик кадерле иде. Шуны кибеткә тапшырып чәй-шикәр алдылар әбиләр, аннары әниләр... Ә минем яраткан Хәдичә әбиемнең бикләнә торган агач сандыгында һәрвакыт запасы була иде. Чөнки аңа Чиләбедәге кызлары Дилбәр, Сәрвәр, Зәйтүнә апалар гел посылка салып тордылар. Шуңа күрә чәй-шикәр, конфет, прәннек, манный, дөге кебек әйберләрдән өзелеп тормады.

Әтигә, гаилә башлыгына, өчьяак өстенә куеп манный пешерә дә, безгә—алты балага өлеш чыгарып, берәр кисәк ипи кисеп, шулар өстенә берәр кашык манный боткасы ягып бирер иде.

Берсендә, әби чирләп киткәч, авылдагы кызы Бәдәр апа чәй токмачы (кош теле) пешереп китерде. Мин, яраткан оныгы буларак, әбием белән йоклый идем. "Хәдичә түти", урлап ашамасын дип, кучтәнәчен ястыгы астына тыкты. Мин, төн буе, кулны астан әкрен генә тыгып алып, ашап бетерә язганмын "тәмнүшкә"не.

Ә хәзер балаларны ничек үстерәбез, ә?!.

Ашасаң—үсәсең, зур буласың, Айратны жиңәсең!—дип ялынабыз.

Авыз тутырып йомырка ашап утырганны да хәтерләмим. Әй, ялгышам бит, булгалаган икән...

Элек "керәчинкә" дигән ут белән ризык әзерләү бар иде. "Примус", "керогаз" да дип йөрттеләр бугай аларны. Сөекле әбиемнең берәр ахирәт дусты килсә, өйнең алгы өлешендәге әлеге дә баягы теге керосинканы сакларга куялар иде үземне. Мин кечкенәдән үк югалып кала торган булмаганмын. Яшен тизлеге белән "выжт" печәнлеккә. Яңа гына тавык эченнән "борын төрткән" ике йомырканы оядан чәлдерәм дә, кашык белән тиз-тиз генә чәйнеккә чумдырам (юып торырга ара юк). Чәй дә кайный, бер үк вакытта йомырка да пешә. Сунын күбекләре күренә башлагач, теге газиз күкәйләремне карлыган төбенә чыгарып куям да, йөгереп керәп: "Әби, чәең кайнап чыкты",—дип сөенче алам.

—Рәхмәт, бар бераз уйнап кер, балам,—дип әби ахирәте янына ашыга. Мин тоз белән ипи дә эләктерәм. Карлыган төбендә тегеләрне сипләп, кабыгын жиргә күмгәннән соң: "Хәзер менә әйбәт булып китте",—диясе килә. Әмма ул вакытта мин Һади Такташның "Тәуфыйклы песи"ен укымаган шул әле.

Бераздан әби кунагын озата чыга:

—Чәең бик тәмле булды, ахирәт. Сезнең суыгыз бигрәк тә тәмле шул,—дигән сүзләр ишетәм...

## Очына—очына сөйләшү

"Хатын-кыз тәүлегенә уртача—7000, ир-ат 2000 сүз сөйли",—дип язган иде "Татарстан яшьләре" газетасы. Бу мәгълүматның чамага килү-килмәве турында уйланып ятканда Кави Байкиев исемендәге Икшермә урта мәктәбендә кырык ел укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләгән, югары

категорияле тарих укытучысы Фәһим ага Җәләев сөйләгән вакыйга искә төште.

...Ике хатын биш ел төрмәнең бер камерасында утырганнар. Эч серләрен бүлешкәннәр, гөрләшкәннәр, елашканнар болар. Көнелләре булганчы сөйләшкәннәр. Вакыт күп бит анда. Айлар, еллар үткән. Берсенең срогы тулып, икенчесе ярлыкауга эләгеп, иреккә дә бергә чыкканнар һәм төрмә капкасы төбендә фикерләрен йомгаклап бетерә алмыйча, тагын биш сәгать очына-очына сөйләшкәннәр...

Бүрттермә, дип уйлыйсыңдыр инде, укучым. Булырга да бик мөмкин. Мәсәлән, Сатышта бик күп сөйләшергә ярата торган ике хатын чишмә юлында кара-каршы очрашканнар да, бөтен дөньяларын онытып, туйганчы рәхәтләнеп сөйләшкәннәр. Шуннан теге суга дип баручы ханым, чишмәдән менә торганына ияреп, буш чиләкләре белән кайтып та киткән.

## "Саба мәзәкләре"—ләүкәдә

"Жирле геройлар үпкәләмиме?—дип сорыйлар миннән.

Дөнья бит, бер дә юк, дип булмый... Рәхмәт әйтүчеләр дә бар. Китапка керткән өчен дәгъва белдерүче юк әле. Гәҗиткә бирсән, бераз кымырҗып алалар. Чөнки гәҗит чыккач, минем "героема" шалтыратып (яки күреп) мыскылларга теләүчеләр, төрттерүчеләр очраштыргалый. Янәсе.. сине...

Бик үпкәләүчеләр булса, теге ике әбинең сүзләрен китереп күрсәтәм, ачу сакламаска тәкъдим итәм.

—Мин синең җеназага килмим,—ди икән аларның берсе.

Икенчесе аптырап калмыйча:

—И, малай, бигрәк тә үпкәчел инде син. Мин алай ачу сакламыйм. Синең җеназаңа әбизәтельни киләм, Алла Боерса,—дип җавап биргән.

Ә инде Саба мәзәкләренең укылышына килсәк, иманым камил, танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиев әйтмешли, бөтен татар дөньясына таралып өлгерделәр алар. Танылган сәясәтче, җәмәгать эшлеклесенең бу фикерен сатирик язучы Әхәт Сафиуллин "Ватаным Татарстан" газетасында *(14 апрель, 2004 ел)* болайрак дип ныгытты:

"Ә Тәлгат Нәҗмиев дигән язучы Язучылар берлегенә "Мин—публицист!" дип алдалап керде. Гомумән, аны белмәгән кеше юктыр. Тормышка гел зәңгәрле-яшелле, каралы-аклы көлке күзлегеннән карап яши, шуңа күрә анын Саба мәзәкләре һәр районда үзләренеке итеп кабул ителә..."

Алтын чыккан җирендә кадерле, дип дөрес әйтәләр. Саба җирендә бигрәк тә түмен, кадерен белеп укыйлар мәзәкләрне. Шуны бер мисал белән раслап куйыйм әле.

...Ильяс Фәтхетдинов кич буе укыган "Тагын... Саба мәзәкләре"н.

—Мунча суынып бетә бит инде... Керәсенме, юкмы?—дип катырак итеп әйткәч, мыштым гына юкка чыга бу.

Бер ике-сәгать үткәч, ис тидеме әллә дип артыннан барсалар...

Ильяс Шәрипович, ничек керсә—шул килеш ләүкәдә китап укып утыра икән, имеш...

* * *

## Рафаэль Хәким, ТАТАР РУХЫ

ТӨРКИ-ТАТАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ МӘСЬӘЛӘСЕНӘ КАРАТА
ДӘВАМЛЫ ТАРИХИ-ФӘЛСӘФИ-СӘЯСИ ӘСӘР

*"...Сүнгән рух халыкның дөнья аренасыннан юкка чыгуына бәрабәр. Аның исеме елъязмада һәм топонимикада кала, рухы исә башка халык, башка мәдәният эчендә эреп, башка рәвешкә керә, көчлерәк ихтыяр тарафыннан йотыла... Әмма мең еллар сакланган рух эзсез югала алмый. Ул яңаруны көтә, ул яңа биеклекләргә омтыла, ул яңа әверелешләргә әзерләнә, ул кискен үзгәрешләр көтеп үзенә тартып тора. Яңа меңьеллык яңа геройлар таләп итә. Татарлар заман чакыруына ничек җавап бирерләр?.."*

Татар рухы нигә сүрелгән? Аны тергезү мөмкинме? Руслар һәм татарларны ни аера һәм ни берләштерә? Татар яугирләре нигә ефәк эчке кием кигән? Петр I Россияне ни рәвешле "алга этәрә?" Столыпин татар җәдитчеләреннән нигә курыккан? Татарга нинди университет кирәк? Без хәзер нишләргә тиеш? — Укучы әсәрдә бу һәм тагын бик күп сорауларга җавап табар.

* * *

## Рәйсә Юсупова, АК САГЫШ ИЯСЕ

ШӘРИФ ХӨСӘЕНОВ ТУРЫНДА ОЧЕРК-ХАТИРӘ

*"...1999 елның 28 июнендә тамашачы Камал театрына "Әни килде" нең премьерасына җыелды. Күпләрне бирегә Шәриф әфәнде Хөсәеновның соңгы тапкыр күреп калу кебек аяныч теләк китерде. Кычкырып сөйләшү дә, көлү дә юк — бәйрәм рухы сагыш пәрдәсенә төренгән иде..."*

Әйе, истә әле бу... Ә менә монысы беренче тапкыр әйтелә: Ш. Хөсәеновның атаклы "Мәхәббәт сагышы" повестен авторның үз сагышы сугарган. "Казан утлары" укучысы аны бу сагышка салган серле затның исемен дә белер, хатларын да укыр, кадерле ядкярне — күп еллардан соң бу ике гашыйкны бергә итеп теркәп калдырган фотосурәтне дә күрер.

* * *

## Айрат Ибраһим, УЗИДАРӘ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНЫП

МӘКАЛӘ

*"...Ульянов өлкәсенең Кече Кандал районында биш татар авылы укмашып яшиләр иде. Соры кардинал Суелов тәкъдиме белән бу районны бетерәләр, татар авылларын төрле районнарга "тараталар". Шундый ук хәл Пенза арьягындагы элек Алтавыл исемендә бөтен татар дөньясында шөһрәтле волость җирендә дә башкарыла. Ә Мордовиянең Ләмберә районын таркатмыйлар, бары тик аннан кайбер татар авылларын "суырып алып", башка районнарга бирәләр. Мондый мисаллар — кая карама. Барлык өлкәләрдә дә бер сценарий буенча бара әлеге эш. Бу исә районнар кимәлендә үзидарә диген нәрсәнең тамырына балта чаба..."*

* * *

## Нурихан Фәттах, ИСТӘЛЕКЛӘР

Татарның бөекләрен тормыш-иҗат юлын өйрәнүчеләр, биограф-фәләннәр бик борчымый. Нурихан аганың башыннан кичкән хәлләр дә тулаем диярлек бөтенләйгә җуелды кебек тоелган иде. Вафатыннан соң бер ел үткәч, бу саллы кульязманың редакциягә килеп керүе сүнгән йолдызның соңгы нурлары килеп ирешү кебек булды. Шөкер, классигыбыз тагын бер "тарихи әсәр" язып калдырган икән. Бусында аның үз тормыш тарихы бәян ителә.

*"... Рельслар тоташкан турыда тимерләр шакы-шокы килә, тимер вагоннар котырып, җенләнеп каядыр алга ыргыла. Кайчагында җир өсте бик якын, якты булып күренә, вагон да әлләни кызу бармый сыман тоела. "Сикеримме? Сикеримме, малайлар?!" дип кычкырам мин җан ачысы белән. Иң дөрес киңәшне алар гына бирә ала иде. Күрәсең, алар минем кычкырганны ишетмәгәннәрдер дә — ул дөбердектә нинди тавыш ишетелсен? Зур гәүдәле адәм күнитеге белән минем башка тибә, тимер тоткадагы чандыр кулларга тибә.*

*Мин әле дә төнлә төшләремдә шул каядыр караңгыда чапкан буш вагоннарны күрәм, тимер тоткага чытырдатып ябышкан хәлсез малайны күрәм. Әле дә ул шашып, коты алынып "Сикеримме?! Сикеримме?" дип кычкыра сыман..."*

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2006 елның беренче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу дәвам итә. «Казан утлары»ның индексы—**73210**, ярты елга язылу бәясе **144 сум**.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар журналга «Горпечать» киоскларында языла алалар. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Фатирыгызда почта әрҗәсе бик үк ышанычлы булмаса, сезгә моннан да кулай ысул юк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи "Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*Казан утлары* (наименование издания) | Количество комплектов:

на **2006** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | литер |
|---|---|---|
| | | |

на ~~газету~~ журнал **73210** (индекс издания)

*Казан утлары* (наименование издания)

| Стоимость | подписки | ______ руб. ______ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | переадресовки | ______ руб. ______ коп. | |

на **2006** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

*Котлыйбыз!*

# ТАТАР ҖАНЛЫ МӘСКӘҮЛЕ

ВАХИТ ЮНЫСКА 75 ЯШЬ

Без бер елга суын эчеп үстек... Исергәп авылының Закир агай улы Вахит, абыйсы Миргазиян кебек хәрби самолетларда да очмады, дөнья илләре буйлап корабларда да гизмәде һәм том-том китаплар да язмады. Аның Миргазиян абыйсы хәзер инде татар халкының күренекле әдибе. Вахит энесе исә, бер гаиләдә тәрбияләнсә дә, Исергәп уньеллык мәктәбен тәмамлагач, артык та түгел, ким дә түгел, Мәскәүдәге халыкара мөнәсәбәтләр институтына укырга баруны максат итеп куя. Һәм бу хакта әти-әнисенә дә әйтә. Вахит үзе аны болайрак аңлаткан иде.



Улының хыялын белүгә, әтисе Закир ага бу хәлгә бик үк ышанып җитмәсә дә, шиген улына сиздерми. Әйе, ничек инде рус телендә укымаган улы Вахит Мәскәү кадәр Мәскәүгә укырга барырга җыена, акча туздырып кайтуы гына булмасмы? Алай да сер бирми, башта өс-башына күз ташлый. Буй-сынга ару гына булса да, малайның өстендә күрше хатыны теккән кием—ни костюм, ни җилән түгел. Аягында да "мин чабата түгел" дип кычкырырга торган нәрсә генә. Авыл малаена яраса да киемнәре бер дә кала кешесе киярдәй түгел шул.

Кичке якта табынга утыралар. Әтисе Вахитның әнисенә карап-карап ала. Янәсе: йә, анасы, син нигә дәшми утырасың, әллә мәйтәм, тәвәккәлләп малайны җибәрикме шул Мәскәү дигән калага, анда да адәм балалары яшидер бит әле... Ләкин Закир ага бу хакта хатынына әйтергә ашыкмый, ашап утыра, авыл кешесенә хас булганча уйлана, уйлый. Һәм тәгаен фикергә килеп, табын янында сүзне болайрак башлый: "Әнисе дим, әллә, мәйтәм, малайга рәтлерәк костюм алыйкмы?.. Мәскәү кадәр Мәскәүгә бара бит. Әллә мәйтәм, теге быел кысыр калган сарыкны..."

Кысыр калган, ит-май җыйган сарыкны чалып, Закир агай күршедәге Октябрьск каласына илтеп сата һәм Мәскәүгә китәсе улына менә дигән костюм-күлмәк, ялтырап торган туфли алып кайта. "Кеше арасына бара ич улыбыз, әнисе, үз хакыбызга алган әйберләр, кеше хакына кермәдек",—дип, Закир ага костюм белән туфлины улының кулына бирә. Бүләкне кулына алуга бер башка үсеп киткәндәй була Вахит. Ата-анасын шаккаттырып: "Әти-әнием, мин сезгә, чит илләрдә эшли башлагач, мондый гына бүләкләр җибәрмәмен әле. Әйтте диярсез",—ди. Әти-әнисе бер-берсенең күзләренә карап елмаешып ала. Әнисе: "Бирсен Ходай, улым",—дип тәгаенли.

Институтка керүе турында Вахит сөйләргә яратмый. Әйе, тәвәккәлләп башкалага барган, кергән, укыган, диплом алган, хәзер мөселман илләрендә хезмәт итеп ята. Бәтте-китте! Ләкин ул Казанны, туган якларын беркайчан да онытмады, ялга кайткан саен, якташы булгангамы, мин эшләгән Язучылар берлегенә керер, һәм: "Менә чит илләрдә йөргәндә башыма килгән хикәяләрне яздым әле"—дип кинәнер иде. Татар халкының язмышы, бигрәк тә яшьләр тормышы аны һәрчак борчыды һәм ул шул хакта шактый хикәятләр язды, ул язганны республика газета-журналлары бик теләп бастылар.

Вахит һәрдаим ыспай киенгән булыр, өс-башы ялтырап торыр. Моның өстенә ул, соңарыбрак булса да, Башкортстанга кунакка баргач, Хода язган алиһәсен тапкан, өйләнгән.

Ә туксанынчы елларда агалы-энеле Юнысовлар, инде аксөякләргә әверелеп, җәмәгатьләре белән Казанга кайттылар. Мин аларны "Болгар" кунакханәсенә урнаштырдым. Кич белән без—якташлар—шунда җыелдык. Бик озак сөйләшеп утырдык. Бу кичтә безгә дөньяны корабларда гизгән Миргазиян һәм чит илләрдә илчелекләрдә эшләгән Вахит бик күп могҗизаи хәлләр турында сөйләделәр. Ахырда Вахит әйтте: "Татар халкынын тарихы безнең гун бабаларыбызга барып тоташа. Дөнья каһарманы Атилланың оныгының-оныгы Кубрат хан исә көнчыгыш Ауропада беренчеләрдән булып дәүләт төзи. Безнең тарих шул чордан башланырга тиеш, Кубрат хан чорыннан..."

Шул көннәрдә генә танылган язучы Җәмит Рәхимовның "Мәдәни җомга" газетасында "Тарихыбыз кай чордан башланырга тиеш" дигән мәкаләсе басылган иде. Әле булса хәтеремдә: Вахит мәкалә турында кайнарланып сөйләде. Гәрчә бу сүзләрне шактый еллар элек олуг галим Лев Николаевич Гумилевтан ишеткән булсам да, мин якташым Вахитны дикъкать белән тыңладым. Һәм ерак бабабыз Кубрат хан хакында әсәр язганда ниндидер күләмдә ул биргән мәгълүматлардан да файдаландым.

Якташлар илә очрашу минем өчен бик мәгънәле булды. Урамга йөрергә чыккач Вахит мина әйтте: "Мин Казанга кайта алмам, койрык каткан, ә менә Миргазиян шул хакта хыялланып йөри. Чөнки актив яза, каләме бар". Аерылышканда әйткән сүзләре дә истә: "Мин булган мөселман илләрендә татарларны хөрмәт итәләр, безнең бабаларыбыз турында анда бик күп мәгълүматлар саклана. Кулыма төшерә алсам, мин аларны сиңа җибәрә торырмын",—диде ул.

Якташым Вахит Юныс авырып киткән икән... Ләкин мин ышанам: Мәскәүне дә үз иткән Баулы районы Исергәп авылының ватанпәрвәр егете Вахит Юныс үзенең алиһәсе белән мәркәзебез Казанга тагын кайтыр! Якташым-замандашым Вахит үз алиһәсе белән янарып киткән Казан урамнарыннан тагын үтәр! Һәм мәркәзебезнең яшәреп китүен күреп, "мәңге яшәсен Татарстаным, яшәсен татар халкы!" дип янә-янә кинәнер. Аңа бит әле бары тик 75 кенә яшь. Яшибез әле, Ходай кушып, якташым-замандашым, яшибез!

**Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН**

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез.
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Рөстәм Зарипов

Зарипов Рөстәм Зәет улы 1952 елда Татарстанның Саба районы Түлешкә авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1974 елны Саба урта мәктәбен тәмамлагач, Казан төзүче инженерлар институтына укырга керә һәм аны 1974 нче елны тәмамлап, хезмәт юлын юл төзүче мастер булып башлый. Ул төзелеш белән бәйле оешмаларда өлкән инженер, баш инженер, житәкче вазифаларын башкара. 1984 елдан 1990 нчы елга кадәр милициядә эшли. 1990 елдан Шәмәрдән магистраль газүткәргечләр идарәсенә житәкче урынбасары булып килә. Хәзерге көндә "Таттрансгаз" жәмгыятенең техник күзәтү инженеры булып эшли.



Р. Зарипов мәктәп елларында ук шигырьләр яза, баянда уйнап, музыка серләрен үзләштерергә омтыла. 1976 елда "Идел" альманахында "Аууу" исемле хикәясе дөнья күрә. Шуннан бирле аның хикәяләре һәм шигырьләре республика матбугатында еш күренә. 1978 елны Рөстәм Зарипов "Тамчы гөл" исемле жыр яза (көен һәм сүзләрен) һәм әлеге жыр тиз арада популярлык казана. Аның шулай ук башка көйләре дә бар ("Алфавит", "Мөһажир жыры", "Бүре" һ. б.)

Р. Зарипов Мөслим милиция бүлегендә сәяси эшләр буенча урынбасар булып эшләгән чагында районда оешкан Татар Ижтимагый Үзәк бүлекчәсенең беренче рәисе булып сайлана һәм Марат Мөлековка әлеге районда СССР халык депутатлыгына кандидат булып теркәлергә булыша. Милли хәрәкәттә, ТИҮ корылтайларында катнаша. 1999 елда нигездә милли яңарышка кагылышлы мәкаләләр, юморескалар һәм шигырьләрдән торган беренче китабы "Тамчы гөл" исеме белән "Школа" нәшриятында басылып чыга. 2004 елда шушы ук исем белән авторның икенче китабы Татарстан китап нәшриятында дөнья күрде. Бусында проза, шигъри әсәрләр рәтендә бер трагикомедия дә урын алган.

Рөстәм Зариповның үткен мәкаләләрен "Шәһри Казан", "Ватаным Татарстан", "Татарстан яшьләре" һәм "Звезда Поволжья" газеталары теләп баса. Соңгы елларда ул яңа жанрда — әдәби тәнкыйтьтә дә уңышлы гына эшли башлады. Әдәбиятның актуаль темаларын яктырткан мәкаләләре "Казан утлары" журналында әледән-әле басылып тора.

29 сентябрьдә Кабул итү Коллегиясе карары нигезендә (рекомендация бирүчеләр—Рафис Корбан, Жәүдәт Дәрзаман, Флүс Латыйфи) Язучылар берлеге идарәсе Зарипов Рөстәм Зәет улын Татарстан Язучылар оешмасына әгъза итеп кабул итте.

## 2006 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр (мөселман ай календаре буенча 1426-1427 һиҗри еллар)

9 гыйнвар (дүшәмбе)—Гарәфә көне. Хаҗ кылучылар тарафыннан Мәккә янындагы Гарәфә тавына бару һәм тау итәгендә намаз уку көне.

10 гыйнвар (сишәмбе)—Гәйдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме. Иң зур мөселман бәйрәме. Бу ураза тәмамлангач, нәкъ 70 көннән соң башлана торган Корбан чалу бәйрәме һәм ул 3 көн дәвам итә. Бу көн Татарстан җөмһүриятендәге барлык календарьларда кызыл төс белән билгеләнгән.

11, 12, 13 (чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)—Тәшрикъ көннәре. Бу көннәрдә мөселманнар фарыз намазларын укыганнан соң, Аллаһ Тәгаләне мактап махсус сүзләр әйтәләр.

31 гыйнвар (сишәмбе)—Мөхәррәм ае башланган көн. 1427 ел, яңа мөселман елы башланган көн. Бу көнне күп итеп хәер (зәкят) бирелә, изге гамәлләр кылына.

9 февраль (пәнҗешәмбе)—Гашура көне. Сөнниләр тарафыннан Аллаһ Тәгалә үзенең ун пәйгамбәренә күндергән изгелекләре хөрмәтенә, ә шиитләр тарафыннан Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныгы Гали хәлифәнең улы имам Хөсәенне (626-680) җәзалап үтерү көне хөрмәтенә билгеләп үтелә.

15 февраль (чәршәмбе)—Идел Болгарстанында Ислам диненең рәсми рәвештә кабул иткән көн. (310 нчы һиҗри, 922 нче милади ел).

1 март (чәршәмбе)—Сәфәр ае башланган көн.

26 март (якшәмбе)—Һиҗрәт кичәсе көне. Мөхәммәд пәйгамбәрнең һәм аның сәхабәләренең туган шәһәрләре Мәккәдән (Ясриб) Мәдинә шәһәренә мәҗбүри күчеп киткән, һиҗрәт иткән көн. Шушы көннән, ягъни 622 елның 16 июль көненнән башлап, мөселман ел исәбе, ягъни һиҗри ел исәбе башлана.

10 апрель (дүшәмбе)—Мәүлид бәйрәме. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе—Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көне. Бу изге бәйрәм нәкъ бер ай дәвам итә. Бу вакытта мәчетләрдә вәгазьләр укыла, хәер, сәдака (зәкят) өләшенә. Күп кенә мөселман илләрендә факеллар һәм фонарьлар кабызып, тантаналы мәрасимнәр уздырыла.

26 июль (чәршәмбе)—Мөселман календарендә изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим пәйгамбәрнең, Гайсә пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

27 июль (пәнҗешәмбе)—Рәгаиб кичәсе. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдаллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе.

21 август (дүшәмбе)—Мигъраҗ бәйрәме. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә—Аллаһ тәгаләнең тәхете янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 төн ураза тотуга тиңләнә.

25 август (җомга)—дүрт изге айның берсе, мөселман ай календаре буенча, сигезенче ай—Шәгъбән ае башлану көне.

7 сентябрь (пәнҗешәмбе)—Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт".

Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһ Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышы турында карар кабул итә.

24 сентябрь (якшәмбе)—изге Рамазан ае һәм ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә—Кадер кичәсе.

15 октябрь (якшәмбе)—Хәтер көне. Казанны саклап каһарманнарча һәлак булган бабаларыбызны искә алу көне.

23 октябрь (дүшәмбе)—Гайдел-фитыр. Ураза бәйрәме. Ураза тәмамлангач, авыз ачу бәйрәме башлана.

30 декабрь (шимбә)—Гарәфә көне.

31 декабрь (якшәмбе)—Гәйдел-Әдъхә, Корбан бәйрәме.

Төзүче мөхәррир **Хаҗи Абдулла ДУБИН**

## *Укучы сүзе*

Хөрмәтле Маннур ага Саттаров!

Бүгенге ял көнем сезнең "Казан утлары"нда чыккан (№ 3) повестьны укуга багышланды. Нинди кичерешләр, дулкынлану белән укуымны туктаусыз аккан күз яшьләрем раслый.

Сезнең язган әйберләрне кулыма эләккән газета-журналлардан эзләп алып укып барам. Сез үткен каләм иясе—чынбарлыкны уйдырмасыз, чын ирләрчә ихластан әйтеп бирәсез. Заманында шушындый кешеләргә—ветераннарга кайгыртучанлык күрсәтсәләр, хәзерге көнгә үлеп беткән сугышчыларга (инде дошманны җиңеп кайткач) яки үлеп калганнарның аналарына дәүләт тарафыннан бераз гына булса да ярдәм булган булыр иде. Әбием 16 сум пособие алып, 98 яшькә җитеп үлеп китте. Өч үз улы, өч үги улы сугышта ятып калды. Әти ике тапкыр яраланып, бер контузия алып—берниндн дә ярдәм алмый дөнья куйды. Бер кулының бармаклары эшләмәс хәлгә килеп, таякка таянып кайтып керде ул сугыштан.

Сезнең кебек батыр ветераннарга дәүләт зур бүләкләр биреп, үткән хезмәтегезне данласын иде. Мондый тынгысыз йөрәкле, кеше хәленә кереп, үзен аямыйча ярдәм кулын сузарга омтылучылар бик аз хәзер.

Язмый түзә алмадым.

Сезгә нык сәламәтлек, тормышыгызда, язу эшләрегездә уңышлар теләп—

**Наилә ӘХМӘТОВА,**
*Казан*

***

Күптән түгел "Казан утларында" (2005, № 1) язучы Әсгать Сәлахның "Көт син мине" повесте дөнья күрде. Әсәрнең төп герое—Палта Миңнуры. Язучы үз героеның тормышы аша Ватан сугышының бөтен фаҗигасен сурәтләп бирә. Чөнки автор үзе дә шул елларның олы хәсрәтен башыннан кичергән. Әсәр сугышка кадәр татар (мишәр) авылын сурәтләү белән башланып китә. Авыл яшьләренең аулак өйгә җыелып күңел ачулары, егет-кызларның үзара аралашулары, мәхәббәт йөртүләрен автор чын рәссамнарча тасвирлый. Менә шул яшьләр арасында Миңнур белән Минәхмәт тә үзара яратышып йөриләр. Яңа гына армия хезмәтеннән кайткан Мифтах та аулак өйгә килеп кызга гашыйк була. Ул тәҗрибәлерәк егет була шул, икенче көнне үк кызга баш кода җибәрә. Миңнурның язмышы уйламаганда Мифтахка барып тоташа. Миңнур татар хатын-кызларына хас булганча, ата-анасына карата сабыр була, алар сүзенә каршы бара алмый. Ике яшь йөрәккә бергә кушылып озак яшәргә насыйп булмаган икән. Мифтахны сугышка озатуны яшь хатын авыр кичерә. Автор 17 яшьлек Миңнур образы аша татар хатын-кызларының сугыш елларында күрсәткән эшләренә бәя биреп бетергесезлеген күрсәтә. Ирләр һәм атлар—сугышта. Авыл—хатын-кыз җилкәсендә. Алар җирен дә эшкәртә, чәчүдә дә алар, көн-төн урагын да уралар. Ашарга ризык, киярргә киеме юк. Әмма берсенең дә авызыннан зарлану сүзе ишетмәссең, барысының да төп уй-гаме дошманны җиңү турында.

Сугыш ул елларда һәркемнең ишеген шакыды. Әмма Миңнурга ул берничә мәртәбә әйләнеп килә. Башта яшьлек мәхәббәте Минәхмәт үлгән диген хәбәрен ишетә, күпмедер вакыттан соң йөрәгенә якын ире Мифтахның хәбәрсез югалуы билгеле була... Хәсрәт өстенә хәсрәт, кайгы артлы кайгы... Әмма ул тормышта югалып калмый, киләчәк хакына, теше-тырнагы белән тормышка ябышып яшәргә омтыла.

Бу әсәрнең геройлары—реаль кешеләр.

Язучы Ә. Сәлах сугыш чорын сурәтләүдә Г. Бәширов, М. Мәһдиев традицияләрен дәвам итеп, шул ук вакытта үзенчәлекле алымнар кулланып үз укучыларына сугыш чорының тагын бер рәхимсез сәхифәсен ача. “Көт син мине…” повестеның яшь буынга патриотик, әхлакый тәрбия бирүдә дә әһәмияте зур дип саныйм.

**Фәнис ШӘФЫЙКОВ,**
*Чирмешән.*

***

Сез инде ничә еллар буе латин графикасында кайбер үрнәкләр биреп киләсез. Бу бик кирәк гамәл. Без аларны зур кызыксыну белән укыйбыз. Ул чорлар тарихыбызның бер кисәге бит. Теләгебез шул: латин шрифтында әсәрләр күбрәк һәм ешрак басылсын. “Татар хикәяләре хәзинәсеннән” рубрикасындагы хикәяләрне тулысы белән латин язуында бирсәгез дә яхшы булыр иде.

**Вәнсит АБДУЛЛИН,**
**Тәнзилә ФӘЙЗУЛЛИНА,**
*Башкортстан, Мәләвез районы,*
*Җиргән авылы.*

***

Журналның җиденче санында минем игътибарны аерым җәлеп иткән ике әйбер булды.

Беренчесе—Роберт Миңнуллинга Татарстанның халык язучысы дигән мактаулы исем бирү турындагы Президент Указы һәм шунда ук Миңнуллинның яңа шигырьләре.

Югары исем бирелү белән Робертны чын күңелдән котлыйм, аңа сәламәтлек һәм яңа иҗат уңышлары телим! Миңа, гади укучыга аның иҗаты бигрәк тә якын. Чөнки ул минем якташым. Аның авылы Сөннең аръягында, минем авыл бу ягында—Актаныш районы Ахун авылы; ягъни без Минзәлә төбәге татарлары. Шуңа күрә аның әсәрләрендә безнең як тел үзенчәлекләре сизелеп тора.

Шигырьләре бик җиңел укыла, һәр куплеты йөрәккә май булып ята.

Икенчесе—Тәлгат Галиуллинның “Мәкер” повесте. Күптән укыганым юк иде андый әсәрне. Бер утыруда тын да алмыйча укып чыктым, андый ләззәтне күптән татыганым юк иде. Молодец! Бу әсәрне Фатих Урманче “Йөзек кошы” белән тиңдәш саныйм.

**Санияф ГАРДАНОВ,**
*Беларусь иле,*
*Гродно шәһәре.*

## «Казан утлары» архивыннан



*Халык язучысы Әмирхан Еникинең соңгы рәсемнәренең берсе. 1999 ел.*



*Дуслар-каләмдәшләр. Халык шагыйре, халык язучысы буласы көннәр алда әле. Илдар Юзеев, Хисам Камал. 1964 ел.*



*Язучы Шәйхи Маннур һәм КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Мөҗәһит Вәлиев. 1979 ел.*



*"Казан утлары" журналында төрле елларда элек эшләгән һәм хәзер хезмәт итүче язучылардан бер төркем. Беренче рәттә утырганнар, сулдан уңга — Вакыйф Нуруллин, Кояш Тимбикова, Равил Фәйзуллин, Яхъя Халитов, Әхсән Баян, Ләбибә Ихсанова, Әхәт Гаффар; икенче рәттә — Флүс Латыйфи, Марат Закир, Наис Гамбәр, Шамил Маннапов, Рәдиф Гаташ, Шаһинур Мостафин, Марсель Галиев, Мөдәррис Вәлиев, Солтан Шәмси, Мансур Вәлиев, Алмаз Гыймадиев. 2002 ел.*



*Күренекле тарихчы галим, публицист Мурат Аджиның (Морат Хаҗи) "Казан утлары" журналында очрашу вакытында алынган рәсеме. 2005 ел.*



*Язучылар, журналистлар, баш мөхәррирләр. Сулдан уңга: Ренат Харис ("Татарстан хәбәрләре" газетасы), Роберт Миңнуллин ("Сабантуй" газетасы), Рифат Фәттахов ("Мәгърифәт" газетасы), Фәиз Зөлкарнәй ("Идел" журналы). Германия, Эрфурт шәһәре. 1995 ел.*

# Хушлашу сүзе



2005 елның 20 сентябрендә Башкортстанның халык шагыйре, күренекле җәмәгать эшлеклесе **Мостафа Сафа улы Кәримов** (Мостай Кәрим) вафат булды.

Мостай Кәрим 1919 елның 20 октябрендә Башкортстан АССРның Чишмә районы Келәш авылында туган. Үз авылында урта мәктәпне тәмамлагач, ике ел Уфа педагогия рабфагында укый, 1937-1941 елларда Башкорт дәүләт педагогия институтының тел һәм әдәбият факультетында белем ала.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, Мостай Кәрим армия сафына алына, хәрби курсларны узганнан соң элемтә бүлеге һәм артиллерия дивизионы штабы начальнигы булып хезмәт итә. 1942 елның августында каты яралана, госпитальдән чыккач, фронт газеталарында хәрби журналист булып эшли. Сугыштагы батырлыклары өчен орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан соң Мостай Кәрим тулысынча иҗат һәм җәмәгать эшендә булды. 1951-1962 елларда ул—Башкортстан Язучылар Союзы идарәсе рәисе, 1962 елның маенда РСФСР Язучылар Союзы секретаре итеп сайланды, озак еллар дәвамында тынычлык саклау комитетының Башкортстан бүлеген җитәкләде.

Халыкның үз эченнән чыккан сирәк очрый торган зур талант иясе иде ул. Әдәбияттагы казанышлары, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен төрле дәрәҗәдәге орденнар белән бүләкләнде, 1979 елда Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Башкортстанның халык шагыйре Мостай Кәримгә Ленин премиясе, СССР дәүләт премиясе, Башкортстанның Салават Юлаев исемендәге республика премиясе лауреаты дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Мостай Кәрим заманның җитез агышын, кешеләрнең бәхетен, сагышын, чорның катлаулы борылышын җырга салу тылсымына ия булган шагыйрь. Ул дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе дә, ил күләмендә барган хәл-үзгәрешләргә карата вакытында үз сүзен әйтерлек ил агасы да иде. Аның дистәләгән китаплары татар телендә дә дөнья күрде, чит илләрдә тәрҗемә ителеп, күпсанлы поэзия сөючеләрнең күңелләрен яулап алды.

Шул ук вакытта Мостай Кәрим күренекле драматург һәм прозаик та иде. "Ай тотылган төндә", "Айгөл иле", "Салават", "Ташлама утны, Прометей", "Кыз урлау" исемле пьесалары, "Безнең өйнең яме", "Өч таган", "Озын-озак балачак", "Ярлыкау", "Авыл адвокатлары" һ. б. проза әсәрләре башкорт, татар, башка милләт укучыларының яратып укыла торган әсәрләренә әверелде. Алар үткәннең, бүгенгенең һәм киләчәкнең уртаклыгын, аерылмаслыгын искәртәләр, тирән фәлсәфә белән сугарылганнар.

Мостай Кәрим башкорт һәм татар халыкларының туганлыгын ныгытуга булышкан абруйлы ил агасы иде. Ул Казанга еш килде. Татарстан җәмәгатьчелеге белән дустанә мөнәсәбәттә булды. Зур тантаналар, Тукай, Җәлил һәм башка олуг шәхесләргә багышланган юбилейларда катнашты, онытылмас чыгышлар ясады, мәкалә-хезмәтләр язды, бәйрәмнәребезне уртаклашты, табын күрке булды. Үзенең дә байтак китаплары Казанда басылып чыкты. Татар әдәбиятының бөек әдәбият икәнен яшьли үк танып, аның корифейлары белән горурланып яшәде.

Аның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

*Татарстан Язучылар берлеге*
*"Казан утлары" журналы редакциясе*

# Ictimaġi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### ЮНЕСКО ҖЫЕНЫ КАЗАНДА УЗАЧАК

ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы шәһәрләре оешмасы җыены 2007 елда Казанда үткәреләчәк. Кускода (Перу) узган утырышта күпчелек тавышны Казан җыйган. Барлыгы сигез шәһәр әлеге зур җыенны үзендә үткәрергә теләгән иде. Соңыннан йә Казан, йә Люксембург диделәр. Утырышта катнашкан чит ил вәкилләре башкалабыздагы милли һәм динара татулыкка сокланууларын белдергәннәр. Шулай итеп, җыелышларын бездә үткәрергә хәл иткәннәр.

### КОЛ ГАЛИЛЕ ЮБИЛЕЙ БАКЧАСЫ

Шәһәребез юбилее көннәрендә мәшһүр Кабан күле янәшәсендә "Казанның меңьеллыгы" паркы ачылды. Ул 5,6 гектар мәйдан били, киләчәктә ул тагын да киңәйтеләчәк. Паркның нәкъ үзәгендә "Кыйссаи Йосыф" әсәрен иҗат иткән олуг шагыйрь Кол Галигә һәйкәл урнаштырылган (авторлары—сынчылар А. Балашов, А. Миннуллина, архитектор Р. Нургалиева). Аның янында Казанның исеме килеп чыгуга ишарә булып Казан фонтаны эшләнгән. Паркны ачу тантанасында Казанның меңьеллыгына килгән кунаклар—Россия өлкәләре губернаторлары һәм шәһәр мэрлары катнашты.

### ПЕТЕРБУРГ УРАМЫНДА ТАНТАНА

Санкт-Петербургның 300 еллыгы уңаеннан казанлылар анда бер урамны төзекләндергән иде. Ул Казан исемен йөртә. Быел исә җавап йөзеннән Нева буендагы кала хезмәтчәннәре башкалабыздагы элеккеге Свердлов урамын Казанның 1000 еллыгы хөрмәтенә янартты.

Хәзер 514 метрга сузылган иске урам нәкъ Кече Петербург урамына охшатып үзгәртеп корылды. Андагы символик күперләр, фонтаннар, мәчет гөмбәзе, яктырткычлар, урамга Нева елгасы дулкыннары төсмерендә түшәлгән ташлар, хәтта утыргычлар да Кече Петербургны хәтерләтә. Бу Кремль сөзәклегеннән башланган җәяүлеләр урамының дәвамы булачак.

Аны ачу тантанасына Санкт-Петербург губернаторы Валентина Матвиенко җитәкчелегендәге делегация килде. Әлеге вакыйга Казанда Санкт-Петербург көне булараk үткәрелде.

Татарстан Президенты М. Шәймиев, Санкт-Петербург губернаторы В. Матвиенко, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева, Санкт-Петербургның вице-губернаторы А. Вахмистров, академик М. Госманов, Эрмитаж директоры М. Пиотровский һ.б. мөхтәрәм кешеләр катнашкан бу тантананы Казан шәһәре хакимияте башлыгы К. Исхаков ачып җибәрде. "Төньяк башкала бүләк иткән бу урам—ике шәһәрнең дуслык символы булып тора",—диде ул.

Губернатор В. Матвиенко чыгышында казанлыларга зур ихтирам сизелеп торды. "Без бу вакыйгага ике ел әзерләндек. Татарстан халкы Санкт-Петербургның 300 еллыгына Казан урамы бүләк иткән иде. Монысы—сезгә җавап бүләгебез",—диде ул.

М. Шәймиев үз чыгышында халыклар, шәһәрләр дуслыгына тукталды. "Безнең шәһәрләребезне тагын бер әйбер берләштерә: Санкт-Петербургның 300 еллык, Казанның 1000 еллык юбилейларын бәйрәм итү буенча дәүләт комиссиясе рәисе Россия Президенты В. Путин иде. Юбилейлар күп, ә менә комиссия рәисе Илбашы булган очрак бер генә",—диде ул. Президент шулай ук урамның галим-этнограф Лев Гумилев бюсты белән ачылып китүенә игътибар итте һәм аның һәйкәленә уелган сүзләрне атап үтте: "Я русский человек, всю жизнь защищаю татар от клеветы".

Петербург урамын ачу бәйрәме ике шәһәр халкының дуслык тантанасына әверелде. Анда Санкт-Петербург һәм Казанның сәнгать осталары да катнашты. Кичке сәгать 7дә бәйрәм Г. Камал исемендәге

Татар дәүләт академия театрына күчте. Ә кичен Санкт-Петербург көне хөрмәтенә яна урамда бәйрәм фейерверкы балкыды.

### ҮЗ ЭРМИТАЖЫБЫЗ

Казанның меңьеллык бәйрәме көннәрендә "Казан Кремле" биләмәсендә Эрмитаж үзәге ачылды. Элеккеге Юнкерлар училищесы бинасына төпләнгән әлеге Эрмитаж Татарстан халкын Дәүләт Эрмитажында (Санкт-Петербургта) саклауда булган кыйммәтле тарихи ядкарьләр белән таныштыру йөзеннән оештырылды. Әлеге үзәктә күргәзмәләр генә үткәрелеп калмыйча, төрле фәнни программалар, симпозиумнар, "түгәрәк өстәл"ләр дә уздырылыр дип планлаштырыла. Ә беренче ачылган көннәрендә әлеге музей киң җәмәгатьчелеккә "Алтын Урда" күргәзмәсеннән 700ләп экспонатны тәкъдим итте.

### "КАЗАН ПЛАНЕТАСЫ"

Күптән түгел башкалабыз кинотеатрларында "Казан планетасы" исемле фильмнар атналыгы узды. Башкалабызның 1000 еллыгына багышланган кинофильмнар сериясен шәһәрнең Мәдәният идарәсе оештырган иде. Казанның "Кинохроника" студиясе хезмәткәрләре төшергән әлеге фильмнарда гасырлар буе тупланган тарихи материаллар (Турнерелли литографиясе, А Дубин фотоархивы һ. б.), танылган шәхесләребез турында мәгълүматлар чагылдырылган. Әйтик, мәшһүр композитор Софья Гобәйдуллинага багышланган "Туган ягым җылысы", йә "Бурнашевалар турында бәет", "Якуповлар", "Габдулла Тукай", "Салих Сәйдәшев" кебек фильмнар үзеннән-үзе ерак чорларга, тарихка алып кереп китә. Башкаланың 15 кинотеатрында ("Чулпан", "Мираж", "Сувар", "Дуслык"...) тамашачыларга 28 кинофильм күрсәтелде. Татарстанның танылган кинорежиссерлары төшергән әлеге сериядә "Күктау" нәфис фильмы, махсус балалар өчен әзерләнгән "Таң-Батыр" мультипликацион фильмы да бар иде. Казанлылар һәм башкалабыз кунаклары күнеленә "Мәйдан", "Казаным" исемле премьералар да хуш килде.

### ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Казанның 1000 еллыгы уңаеннан үткәрелгән бәйрәм чараларында Язучылар берлегенең дә актив катнашуы билгеләп үтелде. Хакасия, Чуашстан, Удмуртия, Чечен, Мари республикалары, Түбән Новгород өлкәсе һәм Россия Язучылар берлекләре житәкчеләре белән фикер алышу, тәҗрибә уртаклашу һәр ике як өчен дә файдалы булды. Идарә иҗат оешмасы житәкчелегенен үзара багланышларны ныгытуга юнәлдерелгән омтылышын хуплады. Алдагы айларга план кабул итү дә эшлекле шартларда узды.

Балалар язучысы, каһарман әдип Абдулла Алишның туган көне уңаеннан ел саен балалар әдәбиятын үстерүдәге һәм пропагандалаудагы зур хезмәтләре өчен Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләген бирү мәсьәләсе карала. Быел әлеге премияне булдыруга 10 ел тулды. Язучылар берлеге идарәсе дүрт лауреатны билгеләп, быел Абдулла Алиш исемендәге бүләкне танылган әдипләр Энже Мөэминовага, Әнәс Хәсәновка, Татарстан китап нәшриятына һәм "Салават күпере" журналына бирергә дигән карар кабул итте.

Бүгенге көндә Татарстан Язучылар берлегенә кабул итүләрен сорап йөздән артык гариза кергән. Кабул итү коллегиясе (житәкчесе Равил Фәйзуллин) гаризаларны жентекләп караганнан соң, иҗатларын хуплап, идарә каравына ике авторны— Ижау шәһәреннән шагыйрь Ибраһим Биектаулыны (Ибраһим Шәйдулла улы Нәфыйков), Саба районы Шәмәрдән бистәсендә яшәп иҗат итүче шагыйрь һәм прозаик Рөстәм Зәид улы Зариповны тәкъдим иткән иде. Идарә әлеге ике авторны да Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

### ШИГЪРИЯТ—ДУСЛЫК ИЛЧЕСЕ

Бөтенроссия мәдәни-мәгълүмати акция кысаларында Татарстан Милли китапханәсендә "Чечен халык шигърияте (XIX—XX гасырлар)" исемле антологияне тәкъдир итү булды. Делегация вәкилләрен китапханә директоры Н. Камбеев, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов һ. б. сәламләде. Бу очрашуда әлеге затлы китапның (Мәскәү, "Новый ключ" нәшрияты, 2005) төзүчесе һәм әдәби редакторы, СССР Дәүләт бүләге иясе, шагыйрь һәм галим А. Преловский, басманың оештыручысы һәм җаваплы нашире, шагыйрь В. Рахманов та катнашты. Тәкъдир итү залында Чечня Республикасына кагылышлы күргәзмә дә тәкъдим ителгән иде. Шушында ук кунаклар башкаруында чечен халык җыры да башкарылды.

Антологияне чыгаруда зур көч куйган А. Преловский һәм В. Рахманов белән очрашу Язучылар йортында да үткәрелде. Чәй өстәле янында узган әлеге ихлас сөйләшүдә Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, "Казан утлары", "Идел" журналлары баш мөхәррирләре Р. Фәйзуллин, Р. Низами, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррире З. Мансуров, язучылар һәм шагыйрьләр Ш. Мостафин, Р. Зәйдулла, Л. Газизова, С. Малышев, Р. Сәгъди катнашты.

## ТАКТАШКА—МУЗЕЙ

Мордовиянең Гордеев районы, Сыркыды авылында Һади Такташның музей-йорты ачылды. Татарстанның һәм Мордовиянең сәламәтлек саклау министрлары К. Зыятдинов белән Р. Аширов, шагыйрьнең туган төбәгенә барып кайтканнан соң, инде күп еллардан бирле кирәклеге турында сөйләнелгән музейны төзетергә булдылар.

Министрлар үз акчаларын да биреп, иганәчеләр да табып, йортка бура һәм проект-смета документлары эшләтеп алдылар. Бу ниятне Мордовия губернаторы Н. Меркушкин да, Гордеев районы хакимияте башлыгы И. Шумкин да хуплап, төзү эшләрендә зур ярдәм күрсәттеләр. Быел җәй музей-йорт төзелеп бетте.

Сыркыды мәктәбендә озак еллар буе бөртекләп җыелып барган экспонатлар яңа музейның нигезен тәшкил итә. Бу вакыйга уңаеннан Мордовия типографиясе шагыйрь турында "Такташ—безнең якташыбыз" дип аталган буклет та чыгарды.

## ЛИТВАГА ТӘРӘЗӘ

"Татарстанда Литва Республикасы көннәре" уңаеннан, Казанда күп кенә кызыклы чаралар узды.

7 сентябрьдә М. Горький музеенда латыш композиторы һәм рәссамы М. Чюрленис әсәрләреннән концерт булды. Анда шулай ук композиторның фоторәсемнәреннән стенд та оештырылды. Шул ук көнне С. Сайдашев исемендәге Зур дәүләт концерт залында М. Чюрленис исемендәге квартет концерт куйды.

8 сентябрьдә Татарстанның Сынлы сәнгать музеенда "Литвага тәрәзә" дигән күргәзмә ачылды. Анда сынлы сәнгать, нәкыш әсәрләре, фоторәсемнәр күрсәтелде. Кич белән Яшь тамашачы театрында Литваның джаз төркеме чыгыш ясады.

Әлеге көннәрдә "Беркем дә үләргә теләмәде" дигән бик мәгълүм фильм, Литваның яшь режиссерлары әсәрләре дә күрсәтелде.

## ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫНА БАГЫШЛАП

Казан университетының филология факультетында Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин иҗаты буенча диссертация якланды. "Равил Фәйзуллинның поэтик дөньясы" дип аталган бу гыйльми хезмәтнең авторы—Удмуртиядә яшәп иҗат итүче, Ижевск университеты галимәсе Мәүлидә Хуҗина. Диссертантның фәнни җитәкчесе—язучы һәм галим, профессор Т. Галиуллин, рәсми оппонентлары—профессор Р. Ганиева һәм филология фәннәре кандидаты Р. Хайбрахманов иделәр. Яклау утырышында шулай ук күренекле галимнәр һәм әдипләрдән А. Әхмәдуллин, Х. Миңнегулов, Л. Савельева, Р. Гаташ һ. б. чыгыш ясады.

## САВАПЛЫ БҮЛӘК

Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь Гакыйль Сәгыйровка Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев фәрманы белән "Ока" автомобиле тапшырылды.

Язучылар йортына бүләкне иясенә тапшыру өчен Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева килде. Гомеренең 50 елын урын өстендә үткәргән, әмма мәгънәле итеп яшәргә омтылган шагыйрь һәм рәссам Гакыйль Сәгыйров адресына ул үзенең җылы сүзләрен ирештерде.

"Гакыйль әфәнде—Казанның меңьеллыгы алдыннан башкалага юлларның кунаклар өчен ачык икәнлеген исбатлап килгән илче ул. Шигъриятькә тугрылыклы калып, каһарманнарча гомер кичереп яшәгән кешенең иҗаты күпләргә үрнәк. Һәм без ана авыр иҗатында зур уңышлар телибез",—диде Зилә Вәлиева.

Татарстанның Норлат районы Әхмәт авылында туган Гакыйль Сәгыйров озак еллар әнисе тәрбиясендә яшәде. Әнисенең, туганнарының олы ярдәме белән шагыйрь иҗатта зур уңышларга иреште. Шәйхи Маннур, Гаяз Исхакый исемендәге премияләр лауреаты дигән мәртәбәле исеме бар аның. Рәссамнар да аның иҗатын "Филантроп" дигән премия белән зурлады. Г. Сәгыйровның алты китабы бар. Кайберләренә иллюстрацияләрне үзе ясаган. Исәннәр көнләшеп укырлык шигырьләрне, күзләләр сокланып карарлык картиналарны ул тешләренә каләм һәм кылкаләм кыстырып яза. Әнә шулай тормышка аяклары, куллары тыңламаганда тешләре белән ябышып яшәргә омтылучылар безне—әле җирдә йөгереп йөри алучыларны тормышның, яшәүнең кадерен белергә өйрәтә.

## ПЕН-ҮЗӘК ХӘРӘКӘТТӘ

Словениянең Альп таулары кочагында урнашкан Блед шәһәрендә язучыларның (Халыкара ПЕН-клуб) 71 нче Бөтендөнья конгрессы җыелды. Анда дөньяның 73 иленнән килгән 268 кеше арасында Татар ПЕН-үзәге вәкилләре Миркасыйм Госманов, Марсель Галиев, Нур Әхмәдиев, Әхәт Мушинский, Борис Пантелеев та бар иде.

Конгрессның шигаре "Бабил манарасы—явызлыкмы, аллә яхшылыкмы?" дип абстракт яңгыраса да, төп сөйләшүләр, асылда, тел глобальләшүе мәсьәләләренә һәм аз санлы халыкларның телләрен саклауга багышланды.

Конгресста катнашучылар белән Словения Республикасы Президенты Янис Дрновшек, Любляна мэры Данис Симшич, Словения Республикасы тышкы эшләр министры Дмитрий Рапел һәм Германия Республикасының Словениядәге илчесе Ганс Петерс очрашты.

Конгресс вакытында шигъри кичәләр үткәрелде. Татар делегациясе вәкилләре Словения әдәбияты классигы, язучы Станислав Шкрабецның Рибница шәһәрендәге музей-утарында чыгыш ясады.

Бөтендөнья конгрессына килгән язучылар республика башкаласы Любляна шәһәрендә Словения ПЕН-үзәгенең беренче хатын-кыз президенты Мира Михеличка (1912-1985) һәйкәл ачуда катнаштылар. Словения ПЕН-үзәге 1929 елдан бирле эшли икән.

Конгресста төрле әдәбият вәкилләре арасында тыгыз иҗади элемтәләр урнаштырылды. Инглиз телендә басылган һәм матур итеп бизәлгән татар китаплары халыкара форумда катнашучыларда зур кызыксыну тудырды.

## "РУХИЯТ" БҮЛӘГЕ

Моннан сигез ел элек "Татнефть" ААЖнең "Рухият" рухи янарыш фонды оештырылган иде. Ул үзенең кыска гына эшчәнлек дәверендә республиканың мәдәни тормышында лаеклы урын алды. Язын УНИКСта "Сандугач керде күңелгә" дигән яшь талантлар фестивалендә җиңүчеләрнең гала-концерты зур уңыш белән үткән иде. Соңрак ТР Милли китапханәсендә алты авторның: шагыйрь-фронтовик Ә. Маликовның "Җуелмас хәтер", Э. Шәрифуллинаның "Сөюемнән мин бер чибәр идем...", М. Юнысның сайланма әсәрләренең III томы, Р. Кәраминең "Мәхәббәт бураннары", Р. Габделхакованың "Көзге яшен", Ю. Әминовның "Кичеккән тәүбә" китапларын тәкъдир итү булды.

Шунысын да искәртеп үтү кирәк: моңа кадәр дә "Рухият" нәшрияты татар әдәбиятының күренекле вәкилләренең Сайланма әсәрләрен бастырып чыгарган иде: Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Ф. Яруллин, А. Хәлим, К. Сибгатуллин, Рәшит һәм Роберт Әхмәтҗановлар, Зөлфәт, М. Әгъләмов, Р. Гаташ, М. Галиев, Ф. Гыйззәтуллина...

"Рухият" фонды советы рәисе урынбасары Р. Рафиков әлеге һәм кайбер башка китапларны "Татнефть" исеменнән ТР Милли китапханәсенә бүләк итте. Татарстан Милли китапханәсенең Попечительләр Советы рәисе, Дәүләт Советы даими комиссиясе рәисе Р. Вәлиев, "Рухият" фондының моңа кадәр дә изге эшләре күп булды, дип искәрткәннән соң, "Татнефть" ААЖ җитәкчелегенә, "Рухият" фондына эчкерсез рәхмәт белдерде.

Фонд эшчәнлеген тантанада чыгыш ясаучылар—язучы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты М. Юныс, Казан дәүләт университеты профессоры Т. Галиуллин һ. б. югары бәяләде. Милли китапханә генераль директоры Н. Камбеев "Татнефть" җитәкчелегенә рәхмәт белдергәннән соң, сез бүләк иткән китаплар китапханә фондларында "эшсез ятмаячак", алар, китап алмашу программалары буенча, Россия һәм чит илләр китапханәләренә дә җибәреләчәк, дип билгеләп үтте.

Быел "Рухият" фонды китапханәгә 20 исемдәге 2 меннән артык китап тапшырды. Бу китаплар Казанның меңьеллыгы уңаеннан "Татнефть"нең истәлекле бүләге булды.

## БЕР КҮРЕШҮ—ҮЗЕ БЕР ГОМЕР

Татарстанның бер төркем язучылары Башкортстанда иҗади сәфәрдә булып кайтты. Аларның максаты Уфа һәм республиканың көньяк-көнчыгыш районнары белән танышу, шулай ук каләм әһелләре һәм җирле халык белән очрашулар үткәрү иде.

Татарстанда гына түгел, Башкортстанда да киң мәгълүм "Сәхнә" һәм "Салават күпере" журналларының баш мөхәррире, язучы Зиннур Хәснияр, шушы журналның бүлек мөхәррире, шагыйрь һәм прозаик Ләбиб Лерон, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррир урынбасары, шагыйрь Газинур Морат, "Идел" журналының бүлек мөхәррире, шагыйрь һәм прозаик Ркаил Зәйдулла, Татарстан Язучылар берлегенең Әдәбият фонды директоры, драматург Данил Салихов Уфага килүнең тәүге көнендә республикадагы татар әдипләре һәм журналистлары белән очрашты. Икенче көнне кунаклар Башкортстанның Кырмыскалы, Архангель, Белорет һәм Бөрҗән районнары белән таныштı. Бу сәфәрдә Татарстан әдипләрен башкорт телендә чыгучы "Шоңкар" журналының баш мөхәррире, прозаик Иршат Теләүембәтов һәм татар телендә нәшер ителүче "Тулпар" яшьләр журналының бүлек мөхәррире, шагыйрь Мөнир Вафин, шулай ук татар-башкорт дөньясында киң билгеле журналист Фәнис Фәтхи озатып йөрде.

Сәфәрнең өченче көнендә Татарстан кунаклары зур күпчелек халкын башкортлар тәшкил иткән Бөрҗән районы белән таныштı. Бу районда бар дөньяга киң билгеле Шүлгәнташ табигый тыюлыгы һәм Шүлгәнташ мәгарәсе урнашкан. Биредә булу Татарстан язучыларында онытылмаслык тәэсирләр калдырды. Шүлгәнташ мәгарәсе диварларында борынгы бабаларыбыз 14 мең еллар элек үк төшергән сурәтләр әле дә саклана.

Бөрҗән районы—үзләренең милли йөзен бик яхшы саклаучы чын башкорт төбәкләренең берсе. Туган телне, гореф-гадәтләрне күз карасыдай саклау милли мәдәниятне үстерүдә нык булышлык итә. Бөрҗән районы шулай ук кыргый бал кортларыннан алынган бик кыйммәтле һәм шифалы балы белән дә дан тота. Үзе дә шушы районда туып-үскән И. Теләүембәтов кунакларга бу төбәкнең тарихы һәм бүгенге яшәеше хакында күп мәгълүмат

бирде. Жирле халык белән очрашуларда Казан кунаклары үзләренең иҗатлары белән таныштырдылар һәм яна китапларын бүләк иттеләр.

### ИГЕННӘР ИЛЕНДӘ

Җәй-көз айларында республикабыз язучыларының авыл хезмәтчәннәре белән эшлекле очрашулары еш булды. Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, язучы Марсель Галиев, шагыйрь, "Мәдәни җомга" газетасының баш мөхәррире Зиннур Мансуров Балык Бистәсе районында булып кайтты. Бирелә алар төркеменә шушы төбәктә яшәп иҗат итүче шагыйрь, "Авыл офыклары" газетасы мөхәррире Вазыйх Фатыйхов та кушылды. Ике көнлек сәфәрләре вакытында каләм әһелләре, кыр эшләренең барышы белән якыннан танышу максатыннан, район ашлык кабул итү пунктында, Трой-Урай, Уракчы, Балтач (Юлсубино), Котлы Бөкәш һ. б. авылларда булды, шулай ук мәктәпләргә кагылып чыкты, төбәкнең тарихи урыннарын карады.

Балык Бистәсе районы хакимияте башлыгы Равил Хәйруллин белән очрашып сөйләшү вакытында язучылар авыл мәдәниятен үстерүгә, аерым алганда, рухи мирасны саклау, татар китапларын тарату, милли матбугатка язылу һ. б. шундый мәсьәләләргә игътибар юнәлтте. Сөйләшүдә әдипләрнең авыл халкы белән даими аралашып яшәве һәр ике як өчен дә файдалы булуы искәртеп үтелде.

### КИЛӘЧӘККӘ КАЛЫР БҮЛӘК

Казанның Җиңү паркында сугыш кырларында ятып калган сугышчылар өчен олы хәсрәт кичерүче Ана һәйкәле куелды. Әлеге һәйкәлне шәһәребезгә Президент Минтимер Шәймиев гаиләсе бүләк итте.

Скульптураның гипстан эшләнгән варианты быелның 9 маенда—Президентның Мәңгелек утка чәчәкләр куйган көнендә ачылган иде. Республика җитәкчесе шул чагында аны бронзадан эшләтергә вәгъдә бирде.

Дүрт метрлы фигура, тормышның дәвам итүен аңлатып, агачлар арасыннан күккә ашкан. Ул Җиңү көнен күрергә насыйп булмаганнарның хәсрәте һәм истәлеге билгесе итеп кулларына лалә чәчәге тоткан.

Шунысын да әйтеп китәргә кирәк, М. Шәймиев үтенече белән, әлеге вакыйга шау-шусыз узды. Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм паркка ял итәргә килгән кешеләр генә әлеге вакыйга шаһиты булдылар.

### ЧИЛӘБЕДӘ ҮЗ КЕШЕБЕЗ

Чиләбе өлкәсе Еманжелинск шәһәрендә шагыйрь Ирек Сабировның иҗат кичәсе булып узды. Бирегә Бөтендөнья Татар конгрессыннан вәкилләр, Татарстан һәм Башкортстаннан бер төркем язучылар килгән иде.

Ирек Сабиров дистә елдан артык Еманжелинск шәһәрендәге татар һәм башкорт Мәдәният үзәгенә җитәкчелек итә. Быел аны II дәрәҗә "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" медале белән бүләкләгәннәр. Ул—Россия Федерациясе һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы, Башкортстанда үткәрелгән "Илһам чишмәләре" фестивале лауреаты.

Чиләбене үз иткән безнең халык. Шунда төпләнгән, тамыр җәйгән. Хезмәт юлын заводта гап-гади мастер булып башлаган Ирек Сабиров исә бүгенге көндә Еманжелинск шәһәренең хакимият башлыгы урынбасары постын били. Читтә милли мәдәниятне күтәрү җиңел түгел, шулай да бирелә татарлыкны сакларга, югалтмаска тырышалар. Өлкә "Халыклар дуслыгы" йортында яшьләр өчен милли ял кичәләре оештырыла, татар балалары өчен аерым Яңа ел бәйрәмнәре, Сабантуйлар үткәрелә. "Без быел татар мәктәпләре укучыларының өлкә олимпиадасын үткәрдек,—ди Ирек Нәгыйм улы,—узган еллар белән чагыштырганда үсеш бар. Ә чын үсешне һәр гаиләгә, һәркемнең аңына даими кереп торган татар сүзе генә тәэмин итә ала. Шуна да, Чиләбе төбәгендә милли мохитны җанландыру өчен бөтен көчебезне куярга тырышабыз".

* * *

Фәнни эшчәнлегендәге казанышлары өчен филология фәннәре докторы, профессор, "В. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты югары һөнәри белем дәүләт мәгариф учреждениесе кафедра мөдире **Хатыйп Йосыф улы Миңнегуловка** "Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе" дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Иске Казандагы Кекин йорты. ***А. Тимергалина*** *эше.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы һәм җәмәгать эшлеклесе **Рәшит Ягъфәров**.

*Хушлашу сүзе*

## РОЗА ХАФИЗОВА

2005 елның 20 августында күренекле балалар язучысы Роза Хафизова вафат булды.

Роза Сәет кызы Хафизова 1929 елның 6 февралендә Татарстанның Бөгелмә шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туган. Ул 1947—1951 елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлегендә югары белем ала. 1951-52 елларда Түмән өлкәсенең Тубыл шәһәрендәге урта мәктәптә татар теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта.

Р. Хафизованың шуннан соңгы хезмәт юлы журналистика белән бәйле. 1952-60 елларда ул "Яшь сталинчы" *(хәзерге "Татарстан яшьләре")*, "Сталин байрагы" *(Чистай өлкә газетасы)*, аннары Казандагы күп тиражлы завод газетасы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1962 — 1986 елларда, ягъни лаеклы ялга киткәнче, Роза Хафизова "Ялкын" республика татар балалар журналының баш мөхәррире була.

Роза Хафизова үзенең иҗатын тулысынча балаларга багышлаган мөхтәрәм әдибәләребезнең берсе иде. Язучының нәниләр өчен әкиятләр һәм тәрбияви эчтәлектәге хикәяләре тупланган "Кыңгыраулар җыры" исемле беренче китабы 1967 елда басылып чыга. Шуннан соң аның ике дистәдән артык китабы дөнья күрде. Р. Хафизованың "Курайлалай мажаралары" (1969), "Кирләмән" (1970), "Кашкарыйлар озын гомерле" (1975), "Әкиятләр" (1976), "Без әле кайтырбыз" (1977), "Сак-Сок тавышы" (1987), "Киек каз юлы" (1988), "Актәпи ник моная?" (1991), "Карурманда нинләр булмас" (1999) кебек китаплары яшь укучылар арасында популярлык казанды. Аның аерым әсәрләре урыс, үзбәк, казакъ, украин һ. б. телләргә дә тәрҗемә ителде.

Матбугат һәм балалар әдәбияты өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен Роза Сәет кызына 1974 елда Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре, 1983 елда исә РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде. 2002 елда ул балалар әдәбияты өлкәсендәге казанышлары өчен Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләгенә лаек булды.

## КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВ

Сентябрь башында тагын бер каләмдәшебез — күренекле тәрҗемәче, прозаик һәм мөхәррир Кыям Миңлебаев дөнья куйды.

Булачак каләм әһеле Кыяметдин Сәләхетдин улы Миңлебаев 1929 елның 25 июнендә Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туган. 1938 елда гаиләләре белән Казанга күчеп килгәч, укуын Дәрвишләр бистәсендә җидееллык һәм Кабан күле буендагы 12 нче татар мәктәбендә укый. 1953 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлагач, ике ел Сарман урта мәктәбендә укучыларга рус теле һәм әдәбияты фәннәрен укыта.

1955 елның көзендә ул янәдән Казанга кайта һәм Татарстан китап нәшриятында эшли башлый: әүвәл яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә мөхәррир (1955 — 1958), редакция мөдире (1959 — 1966), аннары 1967 елдан башлап, лаеклы ялга киткәнче, матур әдәбият редакциясенең өлкән мөхәррире була.


Кыям Миңлебаев үзенең иҗади сәләтен тәрҗемә жанрына багышлаган каләмдәшләребезнең берсе иде. Ярты гасыр дәвамында аның тәрҗемәсендә рус әдәбияты, чит ил әдәбияты һәм совет авторларының дистәләрчә китаплары дөнья күрде. Алар арасында Л. Толстойның "Балачак", "Үсмерчак", "Егетчак", "Казаклар", В. Шишковның "Хәсрәт дәрьясы", В. Катаевның "Ялгыз җилкән", А. Толстойның "Михнәтле заман", "Аэлита", "Инженер Гаринның гиперболоиды", Н. Носовның "Белмәмеш мажаралары", Э. Войничның "Кигәвен", Г. Гарсиа-Маркесның "Ялгызлык", Ж. Амадуның "Габриэланың гыйшкы" һ. б. бар.

Югары дәрәҗәле профессиональ тәрҗемәче К. Миңлебаев тәрҗемә теориясенә һәм практикасына кагылышлы саллы-саллы мәкаләләр, үткен рецензияләр авторы буларак та яхшы билгеле. Аның яшьләрне тәрҗемә эшенә тарту һәм тәрбияләү юнәлешендә алып барган практик хезмәте дә зур игътибарга һәм ихтирамга лаек булды.

К. Миңлебаев үзен сынлы сәнгатьне нечкә белүче буларак та танытты. Заманында ул мәшһүр сынчы һәм рәссам Бакый Урманченың иҗади эшчәнлеген яктырткан төсле альбом төзеп чыгарды һәм аңа кереш сүз язды. Аннары мөхтәрәм Бакый ага турында роман да иҗат итте. Гомеренең соңгы елларында ул "Акыллы атын мактар..." дигән автобиографик романын иҗат итеп, китап сөючеләр кулына тапшырырга өлгерде...

# ЯҢА КИТАПЛАР


**Казаным—шигъри азаным**: Риваятьләр, бәетләр, шигырьләр, поэмалар. —Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. —175 б.




Казанны шагыйрьләр шәһәре диләр. Урта гасырлар шагыйре Мөхәммәдъяр тикмәгә генә язмагандыр: "Бер гъәжиб бу кем шәһрнең эче тулуг: шагъир улмыш барча кечек һәм олуг". Димәк, Казан үзе дә шагыйрьләр өчен илһам чыганагы булган. Бу басма тулысы белән Казанга багышланган. Жыентык халык ижаты үрнәкләре—бәетләр, риваятьләр белән ачылса да, төп өлешне аерым шагыйрьләрнең (алар йөзгә якын) Казанга багышланган шигырьләре тәшкил итә. Китапның ахырында төрле чор шагыйрьләренең берничә поэмасы да урын алган.

Китапның төзүчесе—Илназ Салахиев, мөхәррире—Рафис Корбанов.

Рәдиф Гаташ. **Мәңгелек сусау** (хиссият аятьләре): шигырьләр, газәлләр, робагыйлар. —Казан: Рухият, 2005. —512 б.




Күренекле шагыйрь Рәдиф Гаташның сайланмалар рәвешендә басылып чыккан бу китабын, аннотация-аңлатмада язылганча, "шигъри-хисси роман дип тә атап була: аның лирик-романтик герое гомере буе "мәңгелек белән сөйләшә", янып-сусап, Бәхет, Матурлык эзли, Мәхәббәт һәм туган халкы, Әнкә теле турында уйларын бүленмәс дога—бербөтен жыр санап яши".

Рәдиф Гаташның кырык елдан артык вакыт эчендә язылган иң яхшы әсәрләре тупланган бу китапка. Алар, хис-фикер ягыннан да, шәкли-форма ягыннан да, шагыйрь ижатының үсеш эволюциясен шактый ук тулы чагылдыралар.

Китапка кереш сүзне Ркаил Зәйдулла язган. Төзүче мөхәррир—Наис Гамбәр.

Индекс 73210



Рәшит Ягъфәров

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)